# Казан утлары

июнь № 6 1966

# КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

## Бу санда:

Г. Тукай премиясе лауреатлары . . . . . . . . 3
М. Әмир. Алга карап. . . . . . . . . . . . . 4

ПОВЕСТЬ, СКЕТЧ, ШИГЫРЬЛӘР

М. Садри. Сайлау таңында. . . . . . . . . . . 9
А. Гыйләҗев. Бераү. Повесть. Ахыры. . . . . . 10
Г. Латыйп. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . 59
Галимов. План. Скетч. . . . . . . . . . . . 62
Яшьләр иҗаты. . . . . . . . . . . . . . . 65
Г. Гобәй. Коръән серләре. Ахыры. . . . . . . . 71

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Р. Халид. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . 91

БӨЕК ОКТЯБРЬНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

А. Юсупов. Полкташымның якты язмышы. . . . 98
Ш. Абилов. Татар әдәбиятында Нәвай . . . . . . 107
Ф. Урманчеев. Совет чоры бәетләре. . . . . 110

Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Г. Хикмәтуллин. Тукай турында исемдә калганнар. 120

БӨЕК ОКТЯБРЬНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Л. Антов. Артистның тормыш юлы. . . . . . . 125

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Д. Зөбәерова. Гаҗәп һәйкәл сала. . . . . . 131

6

ИЮНЬ
1966

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

А. Шакир. Борынгы әдәбиятыбызны өйрәнүнең өлгергән проблемалары . . . . . . . . . . . 135

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ш. Садретдинов. Үткәннәр белән очрашу . . . . 139
Ү. Билалов, А. Тарасов. Иҗтимагый-политик карашлар үсеше буенча җитди хезмәт . . . . . . 143
Т. Нурмөхәммәтов. Җыр белән очрашу өчен . . 146
Х. Миннегулов. Гади кешене олы итеп . . . . . . 148
Төрлесеннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . 156

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

# *Габдулла Тукай премиясе лауреатлары*

*25 апрельдә Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре комитетының утырышы булды. Комитет 1966 елгы Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен «Сайланма әсәрләр» дигән шигырьләр җыентыгы өчен шагыйрь Хәсән Туфанга һәм яңа җырлар циклы өчен композитор Җәүдәт Фәйзигә бирү турында карар чыгарды.*





## *Котлыйбыз*

Күренекле шагыйребез Хәсән Туфанга, композитор Җәүдәт Фәйзигә Габдулла Тукай премиясе лауреатлары дигән мактаулы исем бирү турындагы карарны меңнәрчә укучыларыбыз, җыр-музыка сөючеләребез шатланып каршылады. Һәр ике лауреатыбыз — әсәрләре белән халкыбызның хөрмәтен һәм мәхәббәтен казанган, культурабыз үсешенә лаеклы өлеш керткән зур сәнгать әһелләре.

Кояшлы, чәчәкле җир йөзендәге һәрнәрсә өчен шатланып, кайгырып, борчылып, дулкынланып яшәүче өлкән шагыйребез Хәсән Туфан, күп санлы шигырь һәм поэмалары белән, поэзиябезне яңа биеклеккә күтәрде.

Җәүдәт Фәйзи — татар совет музыкасын бөтенсоюз аренасына алып чыккан күренекле, талантлы композиторларыбызның берсе. Ул иҗат иткән җырларны, романсларны, музыкаль комедияләрне киң илебезнең бөтен почмакларында беләләр, яратып башкаралар.

ХӘСӘН АГА ТУФАН, ҖӘҮДӘТ АГА ФӘЙЗИ!

Күп меңнәрчә укучыларыбыз исеменнән Сезне мактаулы исем белән котлыйбыз! Яңа иҗат уңышларына ирешүегезне теләп калабыз!

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ,**
**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ.**

*Мирсәй Әмир*

# АЛГА КАРАП

Мәскәү!..

Бу исемнең үзендә генә дә нинди тирән мәгънә ята. Халыклар азатлыгы өчен, социализм өчен, коммунизм өчен дөнья күләмендә барган бөек көрәшнең рухи үзәге булып, шаулап, кайнап торучы башкала! Шуңадыр күрәсең, Мәскәүдә йөргән чакларда гомумән синдә гражданлык хисе көчәебрәк киткән кебек була, совет кешесе булуың белән горурлану хисен ныграк тоясың.

Кремль!..

Аның капкасын үтеп керүгә һәркемнең йөреше үк, аяк атлаулары, гәүдәсен, башын тотышлары ук сизелерлек үзгәреп китә дисәм дә, язучы кеше өчен арттырып әйтү булмас. Әйе, биредә һәркем үзенең Кеше икәнлеген үткенрәк хис итә. Исеме баш хәрефтән язылырга лаек булган, Горький әйткәнчә, горур яңгырый торган Кеше!

Изге йортның тарихи капкалары кулында мандаты яки махсус чакыру билеты булган кешеләр өчен генә ачылган көннәрдә исә бу хәл тагын да ачыграк сизелә...

Үтә калын итеп салынган булулары белән бүгенге кеше күзе өчен сәер тоелган тарихи стеналар буйлап тезелгән борынгы туплар яныннан узуга, каршыңа төзү сәнгатенең соңгы сүзе белән салынган мәшһүр съездлар Сарае килеп баса. Бу бинаны күрүдән күңелдә кабынган беренче тәэсир: очып торган җиңеллек, балкып көлеп торган яктылык!

Кремльне, съездлар Сараен минем беренче күрүем түгел. Ләкин күргән саен ул минем күңелемдә шулай яңа куаныч хисләре кузгата, өметле фикерләр уята. Һәм аны әлегә күрмәгән иптәшләргә тизрәк күрсәтәсе килә. Бик әйбәт китап укысаң шулай була бит: аны якын иптәшләреңә дә, хәтта таныш булмаган кешеләргә дә укырга тәкъдим итәсең.

Съездлар Сараеның иң гүзәл чагы, архитектура сәнгате үрнәге буларак форма һәм эчтәлеге ягыннан тулы мәгънәсендә ачылган чагы, әлбәттә, съезд көннәрендә була торгандыр. Тоташ пыяла стена аша аның кулуарларында кайнашкан меңнәрчә кешеләр, тыштан ук күренеп, сине тизрәк эчкә тарталар. Мәһабәт пыяла ишекләрне ачып керүгә, син бу «очып торган» бинаның бер үк вакытта какшамас нык нигезгә корылганлыгын, һәр өлешенең ышанычлы, чыдамлы материалдан торганлыгын тоясың. Аска таба да, өскә таба да өзлексез йөреп торган баскыч-эскалаторлар сине йөзләрчә, меңнәрчә кешеләр белән бергә үз стихияләренә тартып алып кереп китәләр...

Хәзер инде синең бөтен ихтыяр көчең кешеләргә юнәлә.

Съезд башланырга әле сәгатьтән артык вакыт бар. Кулуарлар инде кеше белән тулган. Зур бәйрәмгә килгән кебек чистарынып, матурланып, иң кадерле киемнәрен киеп килгән кешеләр бер-берсе белән очрашалар. Еракларда килгән якын дуслар, бер-берсенә әллә кайдан ук якты йөз күрсәтеп, килеп күрешәләр, кочаклашалар, хәл-әхвәл сорашалар.

Мин дә таныш язучыларны ерактан күреп алдым. Әнә, танылган язучы булу өстенә, буйга да озынлыгы белән булса кирәк, беренче булып Сергей Михалков күзгә бәрелде. Әле узган ел гына Казанда булган иде бит ул. Татар язучыларын сораша. Мин аңа аларның сәламен тапшырам. Михалковны ерактан күреп алучылар бер мин генә булмаганмын, күрәсең, якын-тирәдә башка язучылар да кубәеп китте. Кожевников, Грибачев, Софронов... Ленинградтагы дустыбыз Михаил Дудин. Әле күптән түгел булып узган Муса көннәре истәлекләреннән арынып житмәгән Константин Симонов... Һәр төркемнең уртасында булырга житешә торган Расүл Гамзатов... Татар язучыларының һәрвакыттагы якын дусты Мостай Кәрим, татар язучыларына гына түгел, укучыларыбызга да үзенең соңгы еллардагы гүзәл әсәрләре белән якын булып, үз булып әверелгән кыргыз язучысы, Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматов... Мин аңа татар язучыларының сәламен тапшырам. Ул үзенең татар язучылары һәм аларның иҗаты белән кызыксынуын әйтә. Казанны күрәсе килүен белдерә.

— Мене Тукай юбилее көннәренә рәхим итегез!

— Бик рәхәтләнеп барырга әзер торам,— ди Чыңгыз.

Тукай, аның алда торган 80 еллыгы тугандаш әдәбият язучылары өчен уртак тема булып китте. Татар культурасының, әдәбиятының борынгы дусты, казакъ халкының өлкән язучысы Сабит ага Муканов та Тукай көннәрендә Казанга килергә вәгъдә итә.

— Тукай турында әйтәсе бик әйбәт сүзләрем бар,— ди ул.— Тукай — ул минем дә остазларымнан,— ди.

— Рәхим итегез, кунагыбыз булырсыз.

Делегатлар арасында үзбәк Язучылары союзының председателе, күренекле драматург Камил Яшен дә бар. Алар быел көзен РСФСРга әдәби кунакка килергә җыеналар.

— Беренче чиратта безнең Татарстанга рәхим итегез, Камил юлдаш...

Алар үзләре дә моны күздә тоталар икән. Камил шулай ди...

Язучыларга үз түгәрәкләрендә бикләнеп озак торырга ирек бирмиләр. Күренекле иҗат җимешләре белән дөньяга танылган каләм ияләрен күрергә, алар белән сөйләшергә теләүчеләр үзләре язучы булмаган делегатлар арасында тагын да күбрәк. Фотографлар, кино-телевизор кешеләре, журналистлар язучылар тирәсеннән бер дә өзелми. Ул әрсез һәм җитез халыкның бер әйбәт ягы бар: бер-берсе белән күреп таныш булмаган ике яки өч атаклы кешене тотып алалар да, бергә китереп таныштыралар, тегеләр бер-берсе белән кул кысышкан, исемнәрен әйтешкән арада чырылдатып лентага төшереп алалар. Геройлар әйтеп өлгермәгән сүзләрне күп вакытта үзләреннән өстәп, бастырып та чыгаралар. Шулай да ялганлауда гаепли алмыйм мин аларны. Матур әдәбиятның, сәнгатьнең үз дәреслеге булган кебек, журналистның, фотографның да үз дәреслеге бар. Бер-берсе белән гомерләрендә беренче тапкыр очрашкан ике кеше, икесе дә хезмәтләре, кешелек сыйфатлары белән хөрмәткә лаеклы кеше, газета яки журнал битендә күптәнге танышлар сыйфатында басылып чыкканнар икән, монда ялган дип әйтерлек берни дә юк. Чөнки ул кешеләр бер-берсен хезмәтләре буенча чынлап та күптән белгән кешеләр, тик моңарчы аларга күзгә-күз очрашырга гына туры килмәгән, ә менә хәзер очрашырга җае чыккан һәм аларны очраштыруда фотограф-журналист бик әйбәт арадашлык күрсәткән. Рәхмәт аңарга. Таныш түгел дуслар хәзер чынлап та таныштылар. Шәхси танышлык алар арасындагы иҗатташлыкны, гражданлык дуслыгын тагын да ныгытты, гомерлек итте. Һәм бу съездда үзенә яхшы дуслар табып кайтучылар аз булмагандыр...

• • •

Сүзне үзәк мәсьәләләрдән башламыйча, съезд ачылганга кадәр булган гади күренешләргә болай озак тукталуыма укучы иптәшләр сәерсенмәсен.

XXIII съездны мин, анда катнашучы буларак, гадәттәгегә караганда күп тапкыр зуррак, тулырак күләмдә күрә алдым, аны күп тапкыр ныграк, ачыграк тоя алдым. (Бөтен тулылыгында күрдем яки тоя алдым дип әйтергә кыюлыгым җитми, чөнки аның зурлыгы, дөньякүләм әһәмияте чиксез икәнлеген аңлыйм мин. Аны бөтен тулылыгында күреп бетерү мөмкин түгелдер шикелле.)

Съезд минем өчен делегат булып сайланган көннән башланды, дисәм дә ялган булмас. Әйе, шул көннән башлап аны тоя, аны күңелдән кичерә башлыйсың. Ә инде өлкәбездән сайланган бөтен делегатлар белән бергә җыелып «Татарстан» поездында барганда съезд атмосферасын тагын да якынрак хис итәсең. Әйе, үзебезнең поездда ук язучы буларак моны бик ачык тойдым мин.

Безнең арада республикабызны нефть буенча Союз күләмендә иң алдынгы урынга алып чыккан кара алтын осталары бар. Аларның да алдынгылары. Әнә Гәрәй Багманов, вышкалар төзү остасы. Бу эштә Союз күләмендә дан казанган кеше. Ул үзенең бригадасындагы дуслык, бердәмлек турында сөйли. Эштә уңышның нигезен ул шунда күрә. Коллективның үзара бердәмлегендә. Тот та үзе турында китап яз. Ә безнең арада алар, нефтьчеләр, күбәү.

Үткән җидееллыкта Татарстанда химия промышленностеның бик нык үскәнлеге, яңа бишьеллыкта аның тагын да зуррак күләмдә үсәргә тиешлеге турында беләбез. Бу өлкәдәге алдынгылар да бар безнең арада. Атаклы иген үстерүчеләр, терлекчелек батырлары... Әнә Кукмара районының «Коммунизмга» колхозы председателе Камил Шакиров. Әле күптән түгел бик нык артта калып килгән колхоз аның оста җитәкчелеге нәтиҗәсендә республика күләмендә иң алдынгылар сафына чыкты. Ниндирәк соң ул хәзерге көндәге алдынгы колхоз председателе? Мин үзем, авылда туып үскән кеше буларак, авыл кешеләрен элек-электән якын күрәм, аларны аеруча үз итәм, алар белән бик тиз уртак тел табам. Әле кайчан гына мондый хәл иде: колхоз җитәкчеләрен мин бик яхшы аңлыйм, һәм алар да мине шулай ук яхшы аңласыннар өчен, әдәбият турында, сәнгать турында сөйләгәндә, телемне юри гадиләштеребрәк сөйләргә тырыша идем. Шакиров белән сөйләшкәндә моның кирәге юк. Әдәбият турында да, сәнгать турында да, политика турында да язучы телен, гомумән теләсә кайсы өлкәдәге интеллигент телен ул бик яхшы аңлый. Ә менә миңа аның — колхоз председателенең телен аңлау хәзер бераз читенләшә төшкән икән. Авыл кешесенең эше турында, бүгенге колхоз производствосы турында ул фән теле, экономист теле, агроном теле белән сөйли... Һәм мин аңардан кайбер сүзләрен шәрехләп бирүен сорарга мәҗбүр булам...

Съезд барышында мин күбрәк әдәбиятка кагылышлы мәсьәләләргә игътибар итәргә тырыштым. Ләкин, Үзәк Комитетның хисап докладында да, яңа бишьеллык план турындагы Директиваларда да, шулай ук алар буенча сөйләнгән бик күп чыгышларда булсын — матур әдәбиятка, язучы хезмәтенә кагылмаган бер генә мәсьәлә дә булмады. Матур әдәбиятның хәзер инде бездә тулы мәгънәсендә халык эше, Ленин әйткәнчә, гомумпартия эшенең бер өлеше булып әверелгәнлеге бу съездда аеруча ачык күренде.

Минем өчен, делегат өчен, XXIII съезд 29 нчы март көнне иртән сәгать унда гына башланмаган көбек, ул бер съездлар Сарае эчендә бару белән генә дә чикләнмәде.

Башкаланың кай төшендә булсам, шунда хис иттем мин аны. Гостиницада иртән торуга радионы тоташтырабыз. Турыдан-туры безнең арадагы делегатларның исемнәрен әйтеп, Татарстан хезмәт ияләре үзләренең съездга багышланган уңышлары турында рапорт бирәләр. Бөтен ил буенча шулай... Съезд уңае белән махсус хатлар килә һәркемгә, телеграммалар... Съезд материаллары белән тулы газеталар кулга килеп керә, аларның артларыннан ук диярлек яңа номерлар өчен материал туплаучы хәбәрчеләр... Көне-төне эшлиләр алар бу көннәрдә һәм аларның җитмәгән җире юк. Бөтен ил күләмендә барды съезд. Алай гына түгел, бөтен дөнья күләмендә!..

Үзәк Комитетның иптәш Брежнев тарафыннан ясалган хисап докладында һәм яңа бишьеллык турында XXIII съезд Директивалары буенча иптәш Косыгин докладында, шулай ук алар буенча чыгышларда күтәрелгән политик һәм экономик мәсьәләләрнең барына да тукталу бер мәкаләдә генә, әлбәттә, мөмкин түгел. Һәм анда инде укучыга матбугат буенча бик нык таныш булган мәсьәләләрне кабатлаудан да котылып булмас иде.

Хәзергә шуны гына әйтәсе килә: хисап докладында политик оештыру мәсьәләләре буенча партия тарафыннан башкарылган чиксез зур эшләргә, совет халкының героик хезмәтенә йомгак ясалды, халыкара хәлнең хәзерге торышына, дөнья күләмендә социализм системасының үсүенә, аның көче һәм абруе артуына марксизм-ленинизм принципларыннан чыгып анализ бирелде. Капитализмның каршылыклары арта, тирәнәя баруының сәбәпләре фәнни нигездә ачып бирелде, дөнья пролетариатының сыйнфый көрәш барышы һәм милли азатлык өчен көрәшнең үсә баруы сурәтләнде. Хисап докладында һәм делегатларның чыгышларында Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең һәм совет халкының коммунистик төзелеш эшендәге зур тәҗрибәләре гомумиләштерелде.

Тарихи әһәмияткә ия булган икенче момент: бу съездда халык хуҗалыгының яңа бишьеллык планы буенча Директивалар кабул ителде. Бер үк вакытта Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXIII съезды халыкара коммунистик хәрәкәтнең дөнья күләм форумына да әверелде. Анда коммунистик партияләрдән, эшче, милли демократик һәм сул социалистик партияләрдән 86 илдән килгән вәкилләр катнашты. КПССның абруе чиксез зур икәнлеген күрсәтүче интернациональ бердәмлек съезды булды бу. Һәм бу хәл, әлбәттә, табигый буларак, коммунизмга каршы лагерь кешеләренең күңелләрен бик нык төшерде. Бу съездан үз файдаларына нинди дә булса скандал һәм провал көтүчеләр, коммунизм дошманнары бик нык алдандылар...

Съезд материаллары башыннан ахырына кадәр әдәбиятка кагыла дибез икән, моннан беренче нәтиҗә шул: димәк, аны безгә, язучыларга, аеруча нечкәләп, иҗатыбыз белән бәйләп өйрәнергә кирәк.

Хәзергә, турыдан-туры әдәбият дөньясына кагылган мәсьәләләргә тукталып, берничә сүз әйтәсе килә.

* * *

Турыдан-туры әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә дә съездда күп урын бирелде. Шунысы куанычлы: әдәбиятка багышланган һәр чыгышта язучы хезмәтенә бик зур бәя бирелде. Партиянең Үзәк Комитетның әдәбият һәм сәнгатькә карата, аларны оештыру эшенә карата һәрвакыт җитди кайгыртучанлык күрсәтүе һәм алда да шулай булачагы турында әйтелде.

> «Иҗат оешмаларының һәм учреждениеләренең эшләренә партия һәрвакыт юнәлеш биреп килде,— диде иптәш Л. Брежнев.— һәм алда да юнәлеш биреп барыр, бер үк вакытта аларга һәртөрле ярдәм һәм булышлык та күрсәтер».

Әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә карата башбаштаклык күрсәтү, түрәлек итү кебек хәлләргә карата партиянең һәрвакыт каршы булуы турында әйтелде. Шуның белән бергә партиянең сәнгатьтә партиялелек принципларыннан чыгып эш итүе, культура өлкәсендә эшләнгән һәр эшкә сыйнфый күзлектән карап бәя бирелүе турында да бик ачык әйтелде.

Язучылардан Михаил Шолохов, Георгий Марков чыгышларында да, шулай ук әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә кагылышлы башка чыгышларда да (ә алар аз булмады) әдәбиятта-сәнгатьтә партиялелек принцибына басым ясалды.

Үзәк Комитетның хисап докладында Леонид Ильич Брежнев, совет әдәбиятының интернациональ характерда булуына тукталып, болай диде:

> «Бездә сәнгать һәм әдәбиятның теге яки бу өлкәсендә бик шәп казанышлары, күренекле талантлары белән горурланмый торган бер генә республика да юк. Совет Социалистик Республикалар Союзының тугандаш семьясына берләшкән халыкларның милли һәм шуңа күрә дә формасы ягыннан искиткеч күп төрле культуралары, бер үк вакытта коммунистик төзелеш пафосы белән, күп милләтле Бөек Ватаныбызның бәхете һәм аны чәчәк аттыру турында уртак кайгыртучанлык белән сугарылган һәм әчтәлеге белән социалистик булган бердәм культураны тәшкил итәләр».

Тугандаш халыклар семьясында безнең татар халкы да культура өлкәсендә җитди уңышларга иреште. Шул җирлектә татар совет әдәбияты да XXIII съездга шактый күләмдә күзгә бәрелерлек уңышлар белән килде.

Партиянең XX—XXII съездлары рухында урнашкан ленинчыл демократия шартларында безнең язучыларыбыз илһамланып, дәртләнеп иҗат иттеләр.

Моңа кадәр әдәбиятыбыз тарихында булмаган күләмдә күп һәм әчтәлекләре, художество сыйфатлары белән дә игътибарга лаеклы югарылыкта торган романнар, повестьләр барлыкка килде. Укучыда поэзиягә мәхәббәт уяткан бик күп поэмалар, шигырьләр язылды. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть буенча да күзгә күренерлек хезмәтләр иҗат ителде. Башка жанрлар белән чагыштырганда азрак булса да, сәхнә әсәрләре иҗат итү буенча да драматургларыбыз күп кенә житди яңа әсәрләр белән театрларыбызның репертуарларын баеттылар. Нәтиҗәдә әдәбиятыбызның халык каршында, укучы каршында дәрәҗәсе күтәрелде. Китапларыбызның, әдәби журналларыбызның укучы тарафыннан көтеп каршы алынулары, аларның моңарчы безнең матбугат тарихында булмаган дәрәҗәдә күп таралулары моңа бик ачык дәлил булып торалар.

Илдә коммунистик төзелешнең, халык тормышын яхшыртуның яңа баскычка күтәрелүен билгеләгән XXIII съезд карарлары, яңа бишьеллык сызган үсеш планы яктылыгына тотып караганда, безнең бу ирешкән уңышларыбыз инде үтелгән юл булып калалар. Хәзер безнең алдыбызда әдәбиятыбызның бүгене һәм иртәгәсе турында күбрәк уйлау, шулардан чыгып иҗат планнарыбызны ачыклау бурычы тора.

Әдәбиятыбыз идея позицияләре ягыннан дөрес юлда, социалистик реализм принципларында үсә, алга бара. Ләкин әдәби иҗат бервакытта да үткәнне кабатлау, инде ачылганны ачу юлы белән үсә алмый. Һәр яңа сәнгать әсәре яңа ачыш китерсә генә әдәби хәзинәгә яңа байлык өсти ала. Шуңа күрә, бик табигый буларак, әдәби иҗат өчен һаман эзләнү хас. Шунлыктан катлаулы иҗат практикасында кайбер язучыларның әйләнечле юлга кереп китүләре дә, хәтта кайвакыт ялгыш юлга төшеп китүләр дә булмый торган хәл түгел. Кайвакыт исә бик кирәкле байлыклар белән тулы юлларның игътибар үзәгеннән төшеп читтә калулары яки читенлекләреннән куркып, аларны читләтеп үтү күренешләре дә була.

Бүгенге көндә безнең татар әдәбиятының җитди кимчелекләреннән берсе, минемчә, әнә шулай, тормышның гаять әһәмиятле, бай тармакларын күп кенә каләм иясләребезнең читләтеп үтүендә. Һәркайсыбызга мәгълүм, Татарстан күптән инде Советлар Союзының зур промышленность үзәкләреннән берсе булып әверелде. Яңа бишьеллыкта аның бу ягы тагы да ачыграк күренә. Шулай булуга карамастан, безнең әдәби әсәрләребез арасында эшчеләр сыйныфы кешеләрен, аларның тормышын күрсәтүгә багышланган яки аларның чиксез бай эчке һәм тышкы дөньялары белән рухланып, алардан илһамланып язылган китаплар һаман да бик аз. Без инде сүз җае чыккан саен бу турыда әйтә киләбез.

Күрәсең, әйтү генә җитми, бу теләкне тормышка ашыруның конкрет чараларын табарга кирәктер.

Яшь буынны тәрбияләү эшендә матур әдәбиятның роле аеруча зур булуы турында съездда күп сүзләр әйтелде. Бу мәсьәлә дә безгә бик туры кагыла. Балалар әдәбияты буенча бездә күп кенә әһәмиятле әсәрләр язылса да, алар бу өлкәдәге таләпләрне канәгатьләндерерлек күләмдә түгел әле. Яшьләр, балалар әдәбиятын җитди, яңа әсәрләр исәбенә баетасы бар.

XXIII съездан соң әдәбият турында беренче җитди сөйләшү РСФСР язучылары союзы идарәсенең апрель Пленумында булды. Эшче сыйныф турында әдәби әсәрләр иҗат итү мәсьәләсенә анда да басым ясалды.

Ул пленумда тагын съезд карарлары рухында, әдәбиятта идея сафлыгы өчен, партиялелек принципларын нык саклау өчен көрәш мәсьәләләре дә күтәрелде. Кайбер язучыларның иҗат практикасында чын художество дөреслеге, ягъни реалистик дөреслек урынына факт дөреслегенә таянып эш итү тенденцияләре барлыгы турында әйтелде. Тормышта булган һәр фактны реалистик дөреслек дип булмый. Алар арасында чынбарлыкны дөрес чагылдырмый торганнары, очраклы характердагылары да күп була. Шуңа күрә әдәбиятта партиялелек, халыкчанлык принципларын искә алмыйча, факт дөреслегенә генә таянып эш итү иҗатта натурализмга алып баруы мөмкин. Мондый характердагы кимчелекләрнең кайбер элементлары безнең әдәбиятта да күренгәли. Мәсәлән, тормышны берьяклы гына итеп чагылдыру тенденциясен без Н. Фәттахның «Артта калган юллар» повестенда күрәбез. Тормышта булган кимчелекләрне, җәмгыятебезгә яңа тормыш төзүгә комачаулык итә торган күренешләрне фаш итү, әлбәттә, социалистик реализм әдәбиятына ят нәрсә түгел. Тик бу мәсьәләдә язучының үз позициясе ачык булырга тиеш. Әгәр дә берәү, автор буларак, «мин бары үзем белгән фактларны гына күрсәтәм, алардан нәтиҗә ясау укучының үз эше» дигән карашта тора икән, аның белән, әлбәттә, килешеп булмый. Чөнки автор үзе язган әсәргә карата үзе битараф була алмый. Авторның дөньяга карашы үзе язган фактларга бәя бирүдә генә түгел, аларны сайлауда да күренә.

Идеология фронтында коммунизм белән аның дошманнары арасында дөньякүләм кискен көрәш барган хәзерге заманда язучының идея позициясе ачык булуы аерата әһәмиятле. Бу мәсьәләдә гамьсезлек яки җавапсызлык ирексездән дошман тегерменена су коюга китерергә мөмкин.

Әдәбиятта партиялелекне, халыкчанлыкны, әлбәттә, авторның үз позициясен декларатив төстә әйтеп бирергә тырышуы белән бәйләргә ярамый. Идеялелек әдәби әсәр-

нең художество кыйммәтенә зыян китерү исәбенә бирелергә тырышыла икән — андый әсәрнең әдәбият өчен дә, халык өчен дә, партия өчен дә кирәге шул кадәр. Кызганычка каршы, андый характердагы кимчелекләр дә бездә күренгәли әле. Матур әдәбиятның укучы каршында кадерен кимәтә торган мондый күренешләрдән котылу өчен безгә, язучыларга, әдәби осталыкны күтәрү мәсьәләсенә бик нык игътибар итәргә кирәк. Бу инде әдәби әсәрләрнең сыйфатын күтәрү өчен көрәшү дигән сүз.

XXIII съездга мөһим бер үзенчәлек биргән тагын бер момент — аның зур тарихи бәйрәмнәр алдына туры килүе һәм шулар рухында узуы булды. Алда совет властеның 50 еллыгы, бөек Ленинның тууына 100 ел тулу тантаналары тора. Бу тарихи көннәр ил күләмендә барган барлык эшләргә зур йогынты ясаган кебек, матур әдәбият, сәнгать дөньясына да бик якыннан кагылалар. РСФСР язучылары идарәсенең апрель пленумы да шушы тарихи бәйрәмнәргә әзерлек, аларны ничек каршылау мәсьәләләренә багышланган иде.

Бездә исә, болар өстенә, тагын Татарстанның 50 еллыгы да килеп өстәлә. Бу бәйрәмнәр уңае белән безгә, әлбәттә, 50 ел буена эшләнгән иҗат эшләребезгә мөмкин кадәр тулы йомгак ясарга кирәк булыр. Тагын да әһәмиятлерәге: аларны зурлыкларына лаеклы яңа җитди әдәби әсәрләр белән каршылау булырга тиеш. Күп кенә күренекле язучыларыбыз арасында, әлбәттә, бу көннәргә җитди әзерлек бара. Ләкин әле җитәрлек дип әйтеп булмый.

Алда торган бу тарихи һәм җаваплы көннәргә әзерлек уңае белән, әдәбиятыбызда күзгә бәрелеп торган тагын бер җитди кимчелекне искә төшерәсе килә: бездә тарихи темаларга язылган әдәби әсәрләр бик аз. Хәтта юк дәрәҗәсендә диярлек. Ә бит татар халкының зур тарихы бар. Җитмәсә тагын бик катлаулы. Шул темага чын партия дәреслегеннән чыгып язылган әдәби-тарихи әсәрләр булса, халыкны интернациональ рухта тәрбияләүдә аның әһәмияте чиксез зур булыр иде. Дөресен әйтергә кирәк, без, татар язучылары, сүз җае чыккан саен, әдәбиятыбызның зурлыгы, аның сигез гасырга якын тарихы булуы белән горурланырга яратабыз. Ләкин халкыбызның художестволы тарихын җанландырган, аның тарихында якты эз калдырган галимнәрнең, язучыларның, революционерларның тормышларын гәүдәләндергән әдәби әсәрләр язу ягыннан караганда, башка бик күп тугандаш әдәбиятлардан артта калып барабыз.

Бу турыда да безгә, барыбызга да, тирән уйланырга, кимчелекләребезне бетерү буенча җитди чаралар эзләргә, табарга кирәк.

Тарихи съезд, халкыбызның, илебезнең бүгенге культура дәрәҗәсе безне барысы турында да шулай җитди уйланырга, уйланырга һәм уйланып кына калмаска, җитди чараларга керешергә чакыралар.

*Мөхәммәт Садри*

## Сайлау таңында

Җәйнең таңы. Гранит ярлар буйлап,
Ак калага — нурлы Казанга
Карап йөрим, төрле уйлар уйлап,
Азык эзләп шигырь язарга.

Килеп чыгам Ленин күперенә,
Җем-җем итеп сулар серләшә...
Бер алсу кыз белән егет мена
Битне-биткә куеп сөйләшә.

Кояш бәхет кошы булып чыккан,
Аңар иркен дөнья табылган.
Мин сөенәм яшьләр язмышына:
Күперләре инде салынган!

Рәхәт шулай иркен сулу алып
Хыялларга чумып йөрүе;
Аннан илең белән горурланып,
Сайлау залларына керүе.

Без сайладык юлны Октябрьда,
Безнең тавыш туды шул чакта,
Ленин белән күтәрелеп бергә,
Балкыттык без җирне һәрьякта.

Безнең тавыш туды көрәшләрдә,
Бүгенгегә килде ут аша;
Сайлаулардан сайлауларга үтеп
Ул йөрәккә килеп тоташа.

Тавыш бирә халык партиягә,
Ватанына, якты елларга,
Айдан гына түгел, йолдызлардан
Интернационал гимнын тыңларга.

*Аяз Гыйләҗев*

# БЕРӘҮ

*Повесть*[1]

## 8

Саниләр киттеләр дә югалдылар.

Алар белән киткәннәрнең һәммәсенең дә я юлдан, я сугышка барып кергәч тә язган исәнлек хатлары килде.

Исхакка хат та, хәбәр дә юк иде.

Үзе атна саен диярлек хат язып торды, әмма аның хатлары суга аккан кебек эзсез югалдылар.

Авылның иртән «сугыш!» дип авызы ачылды, көндез сулаганнары да, төннәрен сөйләшкәннәре дә «сугыш» булды. Сугыш — авылның бисмилласы да, аллаһе әкбәре дә иде. Я тегеләй, я болай сугышка бәйләнмәгән бер генә гаилә дә калмады.

Маһибәдәрнең ике кызы да мари урманнарына агач кисүгә киттеләр. Үзен исә сарык фермасына куйдылар. Ул көне-төне шунда кайнашты.

Исхак атлы эштә иде.

Сугыш хәлләрен ул бик авыр кичерде. Исхак иске география китабыннан Европа картасын ертып алып үзе йоклый торган почмакка стенага ябыштырып куйган иде. Немецлар алган шәһәрләрне ул кара карандаш белән билгеләп бара башлады.

Менә фронт ыргылып-ыргылып Россия җире буйлап үтә башлады. Малай башта немецларның Саниләр яшәгән урынга якынаюын коты чыгып күзәтеп торды. Кызыл каләм белән әйләндереп алынган нокта, әллә кайда, немецлар астында калгач, картаны стенадан ертып алды, сандык төбенә тыгып куйды.

Немецлар керделәр дә керделәр, ә көтелгән хат һаман килмәде.

Нигә безнекеләр һаман җиңеләләр?

Ул караган киноларда безнең танклар агачларны ерып баралар, выжлап тирән елгаларны кичәләр иде. Гүелдәп самолетлар оча, кызылармеецлар гел



---

[1] Ахыры. Башы 5 санда.

ур-ра кычкырып һөҗүмгә чабалар иде. Яшьтән үк «без дошманны үз җирендә тукмарбыз», дип күнегеп килгәнгә, хәзер шулай ашыгып-ашыгып Иделгә тәгәрәү Күктау авылы малае өчен дә бик сәер иде.

— Нигә алай?

Газеталар укыла-укыла телгәләнеп бетәләр. Тик алардан да бөтен сорауларга җавап табып булмый.

Берзаман бөтен авыл гөж килде:

— Кәрам кайткан! Солдат кайткан!

Өтәләнеп беткән шинель кигән кодасын Исхак урамда очратты. Хәл-әхвәл алышып, тегене-моны сорашкач, Исхак түзмәде:

— Безнең танклар ничек? Күрдеңме? — дип сорады.

Кәрам төньякта, акфиннәргә һәм немецларга каршы сугышкан икән. Аның җилдә каралган ябык чырае тагын да каралып китте:

— Бер сугыштан чыгып барганда, биш-алты нәмәстәкәйнең сазлыкка батып ятуын күргән идем, — диде ул.

Ничек барып керделәр икән алар сазлыкка? Нигә Кәрам кодасы шушы кадәр аз сүзләнгән? Ни яшерә ул? «Батырлык өчен» медале алып кайткан бит. Ни өчен биргәннәр соң анысын?

— Фин снайперын бәреп төшердем, — дип аңлатты Кәрам.

Малайның йөзе яктырып китте.

Әһә: димәк, гитлерчылар да ансат кына килмиләрдер әле!

Аларны да кыралардыр. Әнә бит, аның кодасы бер снайперны чүкеп төшергән...

Еллар үтә торды, тик егет күңелендәге сораулар җавап тапмадылар. Хат та килмәде аңа.

Аңа ундүрт тулды, унбиш, уналты...

Кайчандыр кайчы белән эләктерергә азапланган бала йоннары әрсезләнеп иякне, чигәне капладылар. Исхак озын буйлы, зур куллы, уйчан, басынкы егет булып үсеп житте.

Үсмер йөрәгенә уй иртә кагылды. Ниләр генә уйлап бетермәде ул!.. Авылны ташлап сугышка барырга кыҗрап та йөрде.

Фронт сызыгы аша үтеп Санияне эзләп табыйммы әллә дип тә уйлады. Өй түбәсенә капчык меңгереп сохариләр да җыя башлады. Акылы дуамаллыгын җиңде: гомер-гомергә авылны узып чыкмаган, русчаны да такы-токы гына белгән кеше дөнья буталышында кемне эзләп тапсын?!

Сугыш һаман кешеләрне үзенә чүпләп торды. Аналар балаларының буй үстерүләренә куанмый башладылар. Чөнки кавырсыны яңа гына ката башлаган үсмерләрне һәр көн саен елатып-елатып сугышка озата тордылар.

Океаннан-океанга сузылган фронтны тотар өчен арыслан йөрәкле бик күп ирләр кирәген белсәләр дә, аналар елап калалар.

Исхак үз елгыларына чират җитә башлагач, эчтән генә куанып йөрде. Нөркәй базарында хәрби комиссариат үткәргән искәрмәс облава вакытында, буйлырак үсмерләр, чабата сатып торучы аксак-туксак агайлар белән үзен дә сөреп зур ишек алдына алып кайтып тутыргач, ул тагын да шәбәеп китте.

Тик аларны шундук, документлар тикшереп, сорашып бетерүгә үк чыгарып җибәрделәр...

Бөтен яшь-җилкенчәк фронтта булгач, авылдагы яшь этәчләргә әллә никадәр кыз-кыркын өелеп калды. Алар буасы киткән, таллары киселгән шып-шыр инеш буена җыелалар да төннәр буе айга карап җырлыйлар. Аннары чабата үкчәләре белән тып-тып басып, ай-һайлап егетләрчә сызгырып биешеп алалар. Тагын тупланып, бер-берсенә кысылышып җырларга тотыналар. Аннары тып-тын гына, өрәкләр кебек, тар тыкрыклардан өйләренә таралышалар...

Вәкил-мазар күреп калмасын, заемга яздырып җелегенә төшәр.

Яшь булса да буе-сыны шәбәйгән Исхакка күз төшерә дә башладылар. Мутрак кызлар турыдан-туры да, читләтеп тә аның кылын тарткалыйлар иде. Нөркәй очындагы Җамал исемле ялгыз солдатка тавык тотырып аны кичке аулакка дәште.

— Теге заманнан калган бер бәләкәчем дә утыра. Тавыгым да әтәч булып кычкыра башлады. Килсәң бер тавык та, бер савыт синеке. Тагын кайбер нәрсәләр булыр әле...

Ихахайлап көлде Җамал. Исхак аңа исе китеп карап торды. Аның ирен, Вәдүтне бик яхшы белә иде ул... Орел астында үлеп калган дип хәбәре килде...

Тик егетнең күңел кыллары ятлар теләгән көйне уйнамады.

Икенче көнне карда янында Җамал очрап Исхакны эттән алып эткә салды...

— Юк икән, энем, — диде. — Ирлек юк икән синдә! Булмас синнән, ул да тумас, кыз да тумас. Туса да тормас! Менә шул! Гомереңдә хатын чырае күрмә...

Теге бәләкәчне бүген иртән тәмамлап чыккан хатынның ачы теленә чыдарлык түгел иде. Соңыннан ул Исхакны кочаклап елады:

— Сиңа ачулануларым түгел лә, апаем! Сугыш каһәре безне шушы көннәргә калдырды. Гитлер мәлгуны!..

Элек тә ялгызлыкны ярата торган Исхак тора-бара кешеләрдән тагын да бизенде. Көне буе бергә эшләгән иптәшләре алдында авыз ачып бер сүз дә дәшми торган иде. Ялгыз калган чакларында һаман-һаман бер җырны сузды:

Чәчәкләр күп,
Ләкин чәчәк өзмим,
Табу өчен шундый ислесен.
Мин тапканчы шундый бик ислесен,
Җил исмәсен,
Гөл дә үсмәсен!

Гөлләр кимеделәр, ә җилләр исте. Җилләр әллә кайдан офык тирәнлегеннән әле язны, әле көзне ияртеп килделәр. Кешеләр яңгыр көткәндә корылык, жылы теләгәндә карлы-бозлы яңгырлар алып килделәр алар.

Нигә алай?

Күрше Вильдан билен мунчала зәр белән буып аларга кергәли.

— Тешләк булып чыктың әле син, күрше, — ди ул, Исхак озак кына сүзсез утыргач.

— Ни сөйлисең инде? — дип көлемсери тишек итек ямап утыручы Исхак.

Сөйләшер сүзләре күп, тик сөйләшер кешесе генә юк егетнең...

Җырларда гөл дә үстертмәс кодрәтле егет алабута күмәче һәм черек бәрәңге кәлҗемәсе ашап кырларда бодай үстерде. Дәүләткә көз буе ашлык ташыды. Сөтен, маен, күкәен, йонын, итен, балын илтте. Үзе бервакытта да тук булмады.

Фашистлар Иделгә кадәр үтеп кергәч, Исхак: «Үз күзең белән күрмичә аңлап буламени бу сугыш хәлләрен!» дип йөргән иде.

Хәзер барысы да аңлашыла: фашистларны пыр туздырып куалар!

Ниһаять, танклар гүелдәп бара, самолетлар гитлерчыларны җиргә сеңдереп выжылдап очалар...

Тик үсмер егет күңелендә сорау бетәме соң? Менә ничә ел рәттән хезмәт көненә бер бөртек ашлык, сыңар бәрәңге бирмиләр. Кырдан ялгыш уралып кайткан биш башак өчен биш елга утырталар.

Нигә алай? Дәүләткә, үз дәүләтенә икмәк кирәген колхозчы белмиме әллә? Тик ул үзе нәрсә ашап көн күрергә, эшләргә тиеш? Урлашыргамы?

Сүз иярә сүз чыгып, әнисеннән сорашса, Мәһибәдәр:

— Күпне белмә, балам. Күп шауласаң телеңне кисәрләр. Сугыш елы — хәтәр ел. Тамагың ачмы-тукмы, аны тикшереп торучы булмас. Бар булганы сугышка китә. Дәшмә,— дип, улын куркыта иде. Соңыннан йомшап өстәп тә куя: — Түз, улым, түз инде. Менә җир корткыч мимеч мәлгуньне генә бетерсеннәр.

Түзә анысы Исхак, түзә!

Май ашамыйча да түзә, ямаулы иске чалбарга да түзә, авыр эштән бөтен тәне котырып сызласа да түзә. Түземнең дә бер чиге була икән ич!

Колхоз председателе Гыйльми Салихы (чулак булганга аны армиягә алмадылар) Кырынды өстендә тырмачы малайларны камчы белән яра иде. Председатель бит, сүз әйтмәде, үтеп китте Исхак. Гыйльми Салихы көннән-көн азынды, авыру хатыннарны урыннарыннан типкәләп төшереп эшкә куа иде. Аз гына карышып сүз кактың исә, заемны арттырып җәфалый, налогын икеләтә салдыра, нәсел-нәсәбеңне ФЗУга, марига урман кисәргә озатып тинтерәтә.

Беркөнне Исхак шундый күренешкә тап булды. Яшелчә утаучы хатыннар төшлеккә кайтканда утау чүпләрен култык асларына кыстырганнар. Тыкрыкта аларга каршы очраган Гыйльми Салихы хатыннарны уңлы-суллы яңакларга кереште. Йөгән тотып менеп килгән Исхак түзмәде, атылып килеп Салихның якасыннан эләктерде.

— Икенче кулың да корыр бит, Салих абый!

Кич белән Исхакны кәнсәләргә чакырдылар.

— Кем чакыра, — диде Исхак кашыгын куеп. Сөт белән бәрәңге боламыгы ашап утыра иде.

— Анда күрерсең... Барысы да шунда, — диде йомышчы.

Председатель бүлмәсенә алып кереп вәкил белән милиционер шундый китереп кыстылар егетне:

— Син анда ни лыгырдап йөрисең? Теге вакытта безнең танклар турында да нидер сөйләнгәнсең. Төрмәдә черисең киләме? Колхоз председателен нигә тыңламыйсың?!.

Мәһибәдәр улы яткан сәкегә иелә-иелә ялынды:

— Чыда, балам. Сабыр төбе сары алтын. Дәшмә шул каруңнарга! Менә сугыш кына бетсен. Илнең асыл ирләре кайтсыннар... Дәшмә, балакаем...

Иң гаҗәбе, икенче көнне аны үзе яклаган хатыннар тотып сүктеләр:

— Олыны олы итә белмисең... Нигә катышып, тылкышып йөрергә?.. Сүксә ни, укабыз коелмаган ич!.. Сукса, сөягебез сынмаган, үзе беләдер әле... Фәлән-фәсхет...

— Сезнең горурлыгыгыз юкмени? — дип, каршы төште егет.

— Безнең ипи ашыйсыбыз килә... Горурлык менә шул!

Ни кыен булса да, Исхак мәктәпне ташламады. Авылда дүртенчене бетергәч тә Мәлләгә йөри башлады, һаман шунда укыды.

— Укы, балам, — диер иде әнисе. — Әгәренки Гыйльми Салихы ишеләргә баш бирергә бик теләмәсәң, укы!

Укыды Исхак.

Тугызынчыны бетерде. Унынчыга керде.

Еллар үтте, тик Саниялардән хәбәр-хәтәр һаман килмәде.

Мең тугыз йөз кырык бишенче елның язында Исхак урта мәктәпне тәмамлады. Урта мәктәпне тәмамлаучылар шул елны беренче мәртәбә закон белән кертелгән өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшырырга тиеш иделәр. Имтиханнарны да югары белемле укытучылардан торган дәүләт комиссиясе алырга тиеш иде. Мәллә мәктәбендә комиссия төзерлек югары белемле укытучылар юк иде. Сугыш еллары! Исхакларны класслары белән район үзәгенә имтихан тапшырырга җибәрделәр.

Ай буе куна-ята, шунда торып, яна мәктәптә, яңа иптәшләр белән яңа укытучыларга имтихан тапшырып яттылар алар.

Исхак соңгы имтиханын биреп чыгып мәктәп янындагы каен бакчасында утыра иде. Бакча зур, кайчандыр сөеп, яратылып утыртылганы күренеп тора. Ничек кисеп бетермәделәр икән аларны?..

Әле дә ярый сак кешеләр булган! Ял итү, уйлану өчен нинди рәхәт урын калган... Онытылып, рәхәт итеп, бөтен авырлыгын ташлап, тәне дә, җаны да ял итә егетнең.

Урта мәктәп тәмамланган...

Сугыш беткән!..

Дөмектерде совет халкы гитлерчыларны!..

Кинәт хәвефләнеп селкенеп куйды егет, күзләрен ачты.

Хәзер нишләргә?

Хәрәкәттә бәрәкәт, дигәннәр борынгылар...

Инде хәзер нишләргә? Кая барырга? Укыргамы? Авылда калыргамы? Әллә җәйге чорда Санияләр ягыннан бер әйләнеп кайтыргамы?

Исхак кулларын җәеп җибәргән дә артлы эскәмиягә ярым чалкан ятып кояшта изри. Карыны ач, ашказаны сулыгып-сулыгып куя... Тик бүгенге норма ашалып беткән!.. Менә ул күзен ачып җибәрде һәм бакча кырыеннан үтеп баручы таныш алашаны күрде. Сулагай ич бу! Хат ташучы Ниса апаның аты.

— Ниса апа-у!

— Әү? Тр-р, ләгыйнь, туктаса, кузгала алмый, кузгалса, туктатырмын димә... Нәрсә бар, апаем?..

— Минем әйберләрне салып кайт әле, Ниса апа. Үзем җәяү дә тәпиләрмен... Укулар бетте, Ниса апа!

Ниса, юантык кына кашсыз хатын, чыбыркы сабы белән колак янын кашып алды.

— Тр-р, диләр сиңа, Сулагай!

— Әйбер дигәч тә, исеме генә инде аның. Бер колак мендәре дә китаплар...

— Атка авыррак булыр шул, апаем, — диде Ниса, коры сөяккә генә калган алашага карап. — Иртәгә алып кайтырмын инде. Ашыгыч түгелдер бит. Качмас, иртәгә дә бик әйбәт кайтыр. Минем фатирга төшереп куй. Теге кыяр сатучы урысларны беләсеңдер бит?.. Бүген булмас, апаем, теге Нурулла абзыйлар кайтып төште бит.

Исхак киндер кебек агарынды:

— Кайсы Нурулла?

— Теге инде, Хәерлебәнат Нурулласы.

— Алар кайда әле? — дип сорады егет, көчкә-көчкә телен әйләндереп.

— Авыл очында көтеп калдылар. Әйдә-ә, Сулагай, атла!

Исхак авыл очына йөгерде. Анда икмәк амбарлары янындагы чирәмлектә, гадәттә, юлчылар олау көтә торган урын бар. Мөгаен, шунда утыралардыр!

Чыннан да үзәнлектә укмашып берничә кеше утыра иде.

«Өчәүме, икәүме алар? Ниса ападан сорасы калган... Тукта, бу ак күлмәк дигәне чемодан өстенә куйган төенчек кенә түгелме соң? Әйе, төен генә, ахры... Димәк, икәү... Хәерлебәнат апага берәр хәл булмагандыр бит? Нурулла абый да бик чирле иде инде... Юк ла! Бу Сания коега салкын суга киткәндер әле! Көне бигрәк эссе лә!»

Егет йөгерде дә йөгерде, тыела алмады.

Амбарлар янына җиткәч кенә тукталды, ярсу ат сыман тынын рәтли алмыйча буылып торды. Менә чирәмгә кырын яткан Нурулланың сыңар күзе елтырады, ап-ак чәчле Хәерлебәнатка охшаган ябык кына хатын кулын каш өстенә куеп килүчегә текәлде.

Исхак кинәт сискәнеп, дертләп китте.

Амбарлар өстеннән бик матур кояш карап тора иде. Ике амбар арасында күздән төшеп калып, иртә шытып чыккан көнбагыш сап-сары

чәчәк аткан. Гаҗәеп җылы, рәхәт көн. Тирә-якта шылт иткән тавыш юк. Дөнья шулкадәр якты, мәрхәмәтле, хәтта ике амбар арасына төшкән көнбагыш та кысылып булса да яшәргә, тереклек итәргә азаплана...

Менә җил искән сыман булды... Җир өстенә шомлы күләгә йөгерде, Исхак шаккатып як-ягына каранды. Чирәмнәр дә кара, көнбагыш чәчәге дә каралган, йортлар, агач яфраклары да кап-кара. Күтәрелеп карады, кояш та кара япма ябынып маташа.

— Кояш тотыла, — диде Нурулла.

Хәерлебанат озак карап торгач кына Исхакны таныды. Танычгач, үрсәләнеп кычкырып җибәрде һәм ябык, шыр сөяк куллары белән битен каплады.

Исхакка башка бер сүз дә, аңлатулар да кирәкми иде. Ана күкрәгеннән атылып чыккан шушы кыргый аваз аңа барын да сөйләп бирде.

— Кояш тотыла, — дип кабатлады Нурулла.

Амбар өстендә яман ямьсез итеп кошлар чыркылдаша иде.

## 9

Имәнле урам очындагы ничә еллар тып-тын утырган тәбәнәк, җимерек түбәле өйнең ала-кола морҗасыннан иртә-кичләрен сыек кына төтен чыга башлады.

Ул оч болай да котсыз, шөкәтсез иде. Үкәлчә киртәләрен ташып мичкә яктылар. Иннек капкасы да төтен булып күккә очты. Очы белән лапас-куралары, йорт җирләре таланып, йолыккаланып беткән. Урамга башлаш кырга инде ике ел сука кергәне юк. Ул тиз арада калдауга әйләнеп, аны юан-юан сабаклы биек шайтан таяклары каплап китте. Үткән-сүткән кешеләр бу шомлы урманны ләхәүләләрен укып кичәләр, елдан ел авылга якынрак ябырылып килүче бу чәнечкеле таякларга карап:

— Афәт килгән елларда котырына инде бу нәмәстәкәйләр.

— Күпме гомер итеп, шайтан таягының болай азынганын күргән юк иде, — дип шомланып сөйләшәләр иде.

Аш исе чыгарып сыек кына бөтерелгән төтен бу ташландык урамга җан өргән кебек булды.

Ерак җирдән кайткан сәфәрчеләр белән көрешергә килгән берәнсәрән кешеләр дә урамга урам төсе керттеләр.

Исхак чалгы алып килеп ишек алдын баскан алабута, кычыткаННарны чабып ташлады. Бер кызып киткәч, басу ягына да чыгып, нигезгә үк менеп житкән шайтан таякларын да кыярга тотынды.

Чаж-чож итеп, ярсып, ачуланып, күзләрен акайтып чапты да чапты. Тик шайтан таяклары бихисап күп иделәр, егетнең беләге талды, чалгысы үтмәскә әйләнде.

Исхак ат сорап идарәгә барды.

— Юк, — диде Гыйльми Салихы. — Сугыш елларында кайда булганнар алар? Килмешәкләргә түгел, эш кешеләренә дә ат юк.

— Атны миңа бир, — диде Исхак.

— Сиңа да юк.

Ат караучылар белән талашып идарә атын алды егет һәм ерак урманнан рөхсәтсез-нисез генә бер йөк усак әрдәнәсе кайтарып Нурулла-лар ишек алдына аударды. Үзләренә дип чыгарган, шунда Кондырак болынында кибеп яткан торфның да яртысын шуларга ташыды. Лапасның саман стенасын сүтеп, рәтләп яңадан күтәрде.

Бу җәһәттән эшләр көйләнде. Тик тәмам хәерчеләнгән авылга кайтып егылган Нурулла белән Хәерлебанатны көтелмәгән нужа каршылады. Акча-фәләнгә авыл арасыннан ризык табарлык түгел, булса да, бер



бадьян онга, бер чиләк бәрәңгегә төргәк-төргәк акча сорыйлар иде. Моны белгән авылдашлары:

— Нишләрләр инде болар? — дип чышын-пышын гына үзаралай сөйләшәләр иде. Нурулланың агай-энеләре бар иде. Бер катка шулар ярдәм итте. Калдык-постык оннан катламалар пешереп, Мәһибәдәр дә килеп киткәләде. Кайтучыларны кунакка да дәшеп караган иде — Нурулла да, Хәерлебәнат та бер авыздан баш тарттылар.

Нурулла районга барып кайтты һәм аларга авыл укытучылары белән рәттән аз-маз паек чыга башлады.

Исхак көн аралаш диярлек аларга кереп йөри иде.

Хәерлебәнатлар Нурулла янына исән-аман барып та житә алмаганнар. Юлда ук алар утырган поездга немец самолетлары бомба ташлаган. Сания шунда һәлак булган. Хәерлебәнат үз куллары белән кызын станциядә жирләп калдырып, карты янына ялгызы гына барып егылган.

Мәһибәдәр улының Имәнле урамына ниндидер яшерен кирелек белән тешләрен кысып барып йөрүен күрде. Хәерлебәнатларга ярдәм кирәген бик аңласа да, бу нәрсә аны бераз гына пошаманга да төшерде. Элек тә укырга өндәп йөргәнне, хәзер өзми-төтми Исхакны такырдата башлады. Көн туса:

— Сугыш вакытында ачтан үлмәгәнне, хәзер ничек тә чыдарбыз. Хөкүмәтнең башына да игелекле уй төшеп, налогларны да азрак киметмәсме әле... Күкәй-май сатып булса да, ярдәмсез калдырмам... Үзебез бәрәңге ашап та жан асрарбыз... Башың бар, укуың әйбәт, тырыш, шул мөртәт Гыйльми Салихларына баш биреп торма! — дип улын үгетләде.

Исхак элек укырга барам дип дәртсенеп йөри иде. Нуруллалар кайткач, аның күңеле беркадәр иләсләнде. Тормышның, яшәешнең анык кына юлы юк иде хәзер. Элек бар уйлар, бар планнар Саниягә барып тоташалар да төрле, матур якларга тармакланалар иде. Хәзер исә аның да Сания кебек югаласы, үләсе килгән чаклары булды.

Егетнең күзен, һич тә көтмәгәндә, Нурулла ачып бирде.

Нурулла бик йончып, бетәшеп кайткан иде. Ул күбрәк вакытын урын өстендә үткәрә. Ничә генә карасаң да почмак якта сәке өстендә ямаулы тышлы бәләкәй юрган белән төренгән ябык гәүдәне күрәсең. Исхак килеп кергәндә, ул бәләкәй генә елмайган төсле була иде. Шул ук вакытта аның килүе бу гаиләдә төзәлмәс яраларның авыртуын кузгата иде булса кирәк. Әллә шуңа, әллә энисенең үтә үк хупламавын сизенеп, ул аларга барып йөрүен сирәгәйтте.

Көзгә таба, институтка кереп кайткач, түзмәде, иртәгә китәсе дигән көнне, күрешеп чыгарга дип Бәнатларга китте.

Ул барып кергәндә, Хәерлебанат өстәл сөртеп маташа иде. Исхак, гадәтенчә, Нурулла ята торган почмакка күз салды. Почмак буш иде.

Егет сорау белән Хәерлебанатка текәлде.

— Бер урында ятып абзаң озак түзәме соң? Шунда өй артына чыгып киткән иде әле, — диде Хәерлебанат.

Исхак исәнлек-саулык алышканнан соң урам якка чыкты һәм басу як нигезендә нәнген учлап утырган Нурулланы күрде. Исхакны күргәч, аның чырае ачылып китте.

— Кайттыңмы, студент! — диде ул, шат тавыш белән. — Юллар уңдымы?

— Унды дияргә дә була, — диде егет, аның янына утырып. Агрономия факультетына кереп кайттым, Нурулла абзый.

— Ярый, ярый, — диде Нурулла канәгатьләнеп. — Бик ярый. Син батыр егет булып чыктың бит әле, агай!

— Нинди батырлык булсын инде? Башка институтларга керү авыррак диләр. Яшьләр авыл хуҗалыгына бик бармый...

— Менә, менә! — диде Нурулла җуплап. — Шулай ул!

— Башта бик курыккан идем... Русча да әллә кем түгел.

Нурулла урыныннан торды да чатанлый-чатанлый шайтан таягы урманына якын ук килде:

— Төнлә уянам да тыңланып ятам... Әгәренки тәмуг дигән нәрсә булса, аның җиле дә шулай шаулыйдыр дип уйлыйм. Коточкыч бит!.. Җиргә ятып җылыйсыларым килә... Көз бит, көз! Кыр тулы чүмәлә, кибән, ындыр тулы эскерт, ишек аллары тулы көшел, келәтләр тулы икмәк була торган иде. Көз җитә башласа, тәрәзәмне япмый идем мин... Һай, бу басулар!.. Кыр янында яшәсем килеп, шушы Имәнле очыннан күчмәдем дә мин... Һай, бу кырлар! Аларны адәм төсенә керткәнче чиең чыгар әле... Һай, бу кырларның туфраклары... Шундый бер чакта йөрәксенеп агроном булырга йөрисең икән, молодецтан башка сүз юк сина. Вәт. Их, егәрлегем булса мин.... Кыр тутырып бодай чәчәр идем... Офыктан офыкка бодай кыры булсын иде.

Аның шулай дәртсенеп, сыңар күзен ялтыратып, сыңар йодрыгын йомарлап, сыңар аягына басып шаулап-гөрләп утырган өй биеклеге шайтан таяклары янында ярсып йөрүе егетне җилкендереп җибәрде.

— Таң алдыннан бодай кырына чыгар идем... Җир иркәләгәнне шул-кадәр ярата бит ул... Назлы бит ул! Аны ятим итәргә ярамый, Исхак.

— Иртәгә юлга, Нурулла абзый.

— Сәфәр дисеңме? Кит, Исхак, бар, улым... Кыр җылый бит, басу җылый... Төн уртасында уянам да сәкедән сикереп төшәрдәй булам...

Егет шунда гына саубуллашып китәргә теләгән иде, Нурулла аны ай-ваена карамыйча өйгә алып керде.

— Әнисе, — диде ул, ниндидер йомшак, җылы тавыш белән. — Кодаларга барып кайтам дигән идеңме? Нихәлләрдә яталар икән. Үзләре нишләптер бу атнада күренмәделәр.

— Эштән бушамыйлардыр, — диде Хәерлебанат. — Кечкенәләре дә бар ич.

— Әллә барып кайтасыңмы дим? Менә Исхак белән без өй саклар идек. Бергә-бергә миңа да күңеллерәк булыр, ә?

Хәерлебанат кинәт кечерәеп калды һәм сүзсез генә җыена башлады. Алъяпкычын чишеп мич кырыендагы бауга элде, кучкардан җиделе сукыр лампа алып өстәлгә утыртты. Бит очларын гына калдырып озын чуклы, кыршылган шәлгә төренде.

— Әллә нигә аркам суыксынып тора. Мин кайтканчы китмә, Исхак. Өчәүләп чәй эчеп алырбыз.

— Китмәс, китмәс. Тыныч йөр, әнисе, — дип, Нурулла аны озатып калды.

Хәерлебанат чыгып киткәч, Нурулла учак алдына иелеп көл арасыннан күмер актарды, тапкач өрә-өрә нечкә генә чырага ут элдереп, лампа кабызды.

Өй эче тып-тын. Ерактан ишетелер-ишетелмәс кенә булып гармун авазы килде. Икесе дә әсәренеп аның тавышын тыңлап тордылар. Тик гармун күңелне җилкендереп бер-ике яңгырады да тынды. Кемдә булыр икән ул Имәнле урамында гармун? Тегенди-мондый трофей гына шыгырдатмыйлар ич, чын-чын тальян гармун!

Моң өзек-өзеклеге белән утырдашларга тагын да тирәнрәк тәэсир итте.

Менә Нурулла кинәт сикереп торды, стенага ябыша-ябыша мич буена барды һәм аралыктан тузанланган бер шешә тартып чыгарды. Аны бик пөхтәләп кенә чалбар балагына сөртте, саклык белән генә өстәлгә куйды. Аның кырына сапсыз ике йомры утыртты, бераз саргая башлаган яшел суган һәм шырпы кабы белән тоз чыгарды. Бераз уйланып торгач, өстәл астыннан юка гына ике телем ипи алды. Аның дәшмитынмый гына әзерләнүен күргәч, Исхак:

— Тоткан нәрсәм түгел, Нурулла абзый, — диде.

— Кыстаганым да юк ич әле.

Егет кызарынды.

— Син булдыра алмасаң үзем эчәрмен... Спирт бу! Бик сызлаган чакларында аяк сыларга дип тотам. — Нурулла шешәне күз турына китереп селкеп карады.

— Сиңа да бер тамчы салыйммы? — диде ул, тамак кырып.

— Кирәкми, Нурулла абзый, рәхмәт. Даруга дигән нәрсәңә корт булып төшәсем килми.

— Курыкма! Бетсә, белеш керәшеннәр күмүшкә кайнатып бирерләр әле. Шундый остарганнар, спиртең бер якта торсын.

Нурулла бик саклык белән генә, тамчысын да әрәм итмичә, ике йомрыга да спирт агызды. Үз йомрысын тотып, дога укыган кебек иреннәрен кыймылдатып торды, күзен йомып спиртны туп-туры бугазына койды. Чәчәде, кат-кат йөткеренде, сыңар күзеннән борчак хәтле яшь атылып чыкты һәм ябык бите буйлап йонлач иягенә тәгәрәде.

— Яшь чагында тоткалый идем мин бу каһәрне! Хәзер онытылган. Тончыктырды шайтан, — диде ул, шырт-шырт суган чәйнәп.

— Ә син нигә эчмисең?

Исхак кулларын тезе өстенә куеп, аннан күзен алмыйча утыра иде.

— Сизенәсеңдер, Хәерлебанат апаң жылый. Күрәсеңме икән, көн дә жылый. Жылагач жиңелерәктер аңа, мөгаен. Ир кеше жылый алмый шул. — Нурулла ябык, сөякчел кара йодрыгы белән күкрәген төйде. — Бөтен хәсрәте менә шушында аның. Жыя да жыя ир кеше. Жыелган хәсрәт, озак түгелмәгән су кебек, ачый да ачый, зәһәрләнә, йөрәк маен кимерүче агуга әйләнә. Тик аннан котылырга кирәк. Тере чакта йөрәгеңне хәсрәт кортына бирмәскә кирәк... Менә, җәфаны, тамакка бармаса да эчкән буласың шунда. Тик мин кайгымны онытырга эчә дип уйлама, болай гына... Мин яшим бит әле! Яшим, көтәм...

Ул шешәне күз турына китереп карады һәм йомрысына аз гына спирт агызды. Бу юлы чәчәмичә шома гына эчеп җибәрде һәм жиңе белән авызын сөртте. Бераздан аның күзе калайланды, бит очлары тимгел-тимгел кызарып чыктылар.

— Эчмим, дисең инде? Ярый, эчмә, апаем. Эчмә, син укы. Һәркемнең үз кәсебе булырга тиеш. Хәерлебанат апаң жылый, син гыйлем аласың, ә мин сирәк булса да эчәм. Салгалыйм, апаем... Кайгысын онытырга эчә димә, онытырга омтылмыйм... Яшим ич әле мин, тере кеше! Бер-бер жае чыгар әле. Ә апаң, әнә, жылый. Ир кеше бер тапкыр жылый һәм шуны гомере буе хәтерендә тота. Жылаганын онытькан ир —

ир түгел ул, ходай аңа сакалны ялгыш кына ябыштырган... Ир кешенең күз яше алтын бәясе тора аның. Аны әрәм итмәскә кирәк. Күз яше — йөрәк мае ди торган иде минем әти... Син аны белмисең инде... Бодай чәчәргә ярата торган иде, мәрхүм... Шула-ай! Бер җыладым мин, апаем, һәм шуны һич тә онытмам.

Нуруллаңың сыңар кулы һавада әллә нинди хәрәкәтләр ясап ала, аның ак күлмәгенең җиңе җилфер-җилфер килә. Аз гына сөремләнеп янып торган җиделе лампа аның кул хәрәкәтләрен күзәткән сыман әле уңга, әле сулга каерыла.

Баягы гармун тавышы тагын ишетелеп китте. Кайдадыр, берәр ишек алдында булды ахрысы, кыя-кыймас кына «Ялкын» көен уйныйлар иде. Нурулла торып түр тәрәзәне киңрәк ачып куйды. Өй артыннан ук башланган шайтан таягы плантацияләренең шомлы гөжелдәве килеп керде.

— Беләсең килсә, Хәерлебанат апаң минем янга килеп җиткәндә, бездә полный мәхшәр иде инде. Аптырашта калырлык бит, шутке што ли! Бөтен кеше ничек качарга белми йөргәндә, шалт итеп хатының килеп төшсен әле! Гомеремдә апаңа авыр сүз әйткәнем юк иде, бу юлы сабырым сынды, сүгенеп ташладым. Башта мин Сания авылда калгандыр дип уйлаган идем... Алай булып чыкмады... Тик бу юлы җыламадым мин, чыдадым.

Авылга кайтканнан бирле ул беренче мәртәбә Исхак алдында кызының исемен телгә алды.

— Инде килеп җиткән икән, берни эшләр хәл юк. Сугыш афәтеннән котылу өчен бергәләп әмәл эзләргә кирәк иде. Ашып-пошык кына китәргә булдык. Вагоннарга төялештек. Котылып торыйк илбасардан дибез. Ләкин язмаган икән: немец тимер юл күперен шартлаткан булып чыкты. Үзебезнекеләр шартлатып киткән дип тә сөйләделәр. Булыр, булыр! Андый чакта, барын да кем аңлап бетерсен! Кая карама, солдат, кая барма, качаклар, бөтен дөнья купкан. Болай бармас бу сугыш, бер-бер рәткә салырлар моны диешәбез. Өйгә кире кайттык. Юл тулы халык, урам тулы халык. Беркем бернәрсә белми, кыямәт!..

Бу урында Нурулла туктады, кулы белән өстәл өстендә карманып суган кыягы тапты һәм чәйнәргә дә онытып тагын сүзгә керешге:

— Станцага немецлар килде. Тик торганда, йонлач беләкләрен сызганып, кунакка килгән сыман атышсыз-нисез генә килеп керделәр. Исән калган йортларга кереп-кереп чыккаладылар да мотоциклларына утырып тыр-пыр узып та киттеләр. Ике-өч көн үтүгә яңа команда килде. Үгез-үгез солдатлар көлешә-көлешә фатирларга таралыштылар. Станцаны рәтләргә, водокачканы торгызырга керешәләр икән дип ишеттек. Аптырашта калдык, нежели озак кунакларга чамалыйлар икән, дибез. Хәерлебанат апаң белән киңәштек тә урманга таярга булдык. Ул якларның урманнары!.. Керсәң — чыгарлык түгел!

Исхак тетрәнеп китте.

— Яздан да калмаслар бу нәләтләр, бер кышны ничек булса да землянкәдә уздырырбыз, дибез. Бик китәсе килде... Күңел сизенгән икән... Күршемдә бер бик әйбәт белорус карты бар иде. Гомере буе машинист булып эшләгән кеше. Тоттым да киңәштем мин моның белән. Шулай-шулай, мәйтәм, Матвеич, урманга кыйрыкларга уйлыйбыз, дим. Ала-ай, ди бу. Миңа карап-карап тора. Немецларны кууга, язга әйләнеп кайтабыз, дим... Ә кем аларны куар дип өметләнәсең инде син, ди бу. Китмә син Нурулла Ахметович, ди. Син һәрьяктан гарип, сиңа кагылмаслар, бәлки. Ә нинди поездлар үткәнен, нинди йөкләр озатылганын карарга сыңар күз дә бик җиткән, ди. Менә миңа чынлап та урманга китәргә кирәк, ди. Ничек хәбәрләшеп торырга икәнен дә килештек. Калдык без...

Нурулла озак кына утка карап утырды.

— Олы якка өч солдат урнашты, без бәләкәй якка күчендек. Үз өебездә үзебез чит булып, үз илебездә үзебез кол булып яши башладык. Солдатлар шундый наяннар, кайтып керәләр дә аракы эчәләр, авыз гармунында сиптерәләр, кызлар белән шаяралар... Бервакыт апаң соң гына кайтып керде. Еракка, урман күленә суга барып йөри иде. Көндәгечә солдатлар өйдә шнапс чүмереп утыралар, мин кече якта, тәрәзә кырында утырам. Кинәт ишетәм, апаң «чыр-р!» иттереп кычкырды. Атылып олы якка чыктым. Апаңны караватка екканнар да чишендереп азапланалар. Барып ябышуга мине очыртып кына җибәрделәр...

Алар көләләр, ә мин җыладым. Түзалмадым, көчсезлегемнән, гариплегемнән хурлана-хурлана, әрни-әрни җыладым... Чак кына акылдан шашмадым мин ул чакта. Апаң исә эбигә әйләнеп калды...

Исхакның тамак төбе әрнеп кычыта башлады, иреннәре дерт-мерт сикереп-сикереп куйды, күз кабакларына ачы йөрәк мае — күз яше килеп тыгылды.

Нурулла өстәл астын ачты һәм матур тартмага салынган Кызыл Йолдыз ордены тартып чыгарды.

— Бусын миңа партизан булуым өчен бирделәр.

Егет салкын металлны кулына алды.

— Яши белмичә яшәлгән, — диде Нурулла, ютәлли-ютәлли. — Бер кыз гына гаилә өчен азрак булган. Тамырны кисте дошман. Үзе дә дөмекте дөмегүен.

— Нурулла абзый!

— Әү, апаем.

— Нигә син орден хакында моңарчы берәүгә дә сөйләмәдең? Колхоз идарәсендә-фәләндә сөйләсәң, җиңелрәк булыр иде.

— Ә-ә, юк! Миңа аерып кына җиңеллек кирәкми... Теләмим мин андый рәхәтне. Гыйльми Салихына барып зар сөйли торган егет түгел мин. Көтәм әле мин... Бер-бер җиңеллек килергә тиеш бит! Шундый эшәке, явыз дошманны җиңә алган халык белән Гыйльми Салихлары идарә итәргә тиеш түгел... Бу ятим кырларны эшкәртеп бодай чәчкәнне күрәсем килә минем. Тегермән ташы кадәр кайнар күмәчне күкрәгемә терәп кисәр көннәргәчә яшисем килә. Шуның өчен укырга кирәк сиңа, апаем. Ирекле булу өчен, хөр булу өчен барын да белергә кирәк.

Лампаның керосины азайды ахры, ут кечерәйгәннән-кечерәя барды. Иң элек почмаклар караңгыланды, стенада Нурулланың иләмсез, гарип шәүләсе уйнады-уйнады да ут чожылдап бөтенләй сүнде. Борынны яра, тынны туктата торган зәһәр ис чыкты.

Бүлмәдәгеләр аны сизмәделәр дә.

Тәрәзәдән салкынча җил керә. Шайтан таяклары акрын гына уфылдыйлар, көрсенәләр; чожтырдап үзара әллә нинди яман, әшәке хәбәрләр тараталар кебек. Өстәлдә караңгыда тонык кына ялтырап биш почмаклы Кызыл Йолдыз ята...

Исхакның күзе ак шәүлә булып торган йомрыга төште. Ул аны кулына алды, әйләндереп-әйләндереп торды да кинәт эчеп җибәрде. Әллә спирт тәэсир итте шунда, әллә чыдарлыгы калмаган идеме, баядан бирле күзне кычыттырып җыелып торган яшь бөртекләре сытылышып чыктылар. Бәхеткә каршы, караңгы иде инде, сыңар күз Нурулла берни дә күрмәде.

Егет аның йодрыгын эзләп тапты һәм бармакларын көч-хәл белән язып кулын кысты. Нурулла бөтен гәүдәсе белән калтырый, егетне дә калтырарга-дерелдәргә мәҗбүр итә иде. Акрын гына капка шыгырдады һәм сак кына йөткергән тавыш килде. Нурулла күлмәк итәгенә борынын сеңгерде һәм:

— Апаң кайтты, — дип пышылдады.

10

Нуруллалардан чыккач, ул нигәдер басу ягына борылды.

Кантарлы, тигезсез юл буйлап җил-җил барды да барды. Абынды, егылды, тезен авырттырды, тагын торып басты. Кулына нindидер чыбык килеп эләкте. Юньләбрәк караса, кабыгы туналган, пеше чыбык икән. Берәрсенең арбасыннан төшеп калгандыр, ахры...

Сыек чыбыкны һавада сызгыртып айкап карады да, егет ярсып-кызып тирә-якта өзлексез гөжелдәп утырган шайтан таякларының чукмар башларына чаж-чож суга башлады.

— Менә сезгә, менә сезгә!

Чукмар башлар сынып сыгылдылар, тик берсе дә өзелеп төшмәде. Иске сыза турына җиткәч, ул телефон баганасына сөялеп хәл алды.

Багана аны куркытырга теләгән сыман нәзек тавыш белән үкси. Дүрт яктан да иңләп килгән дошман явы кебек кара кыр шаулый, чыжлый, уфылдый иде.

Күк кап-кара. Калын-калын болытлар агылып-агылып йолдызларны сүндереп-каплап йөриләр иде. Ник бер генә зәңгәр күк, ачык урын күренсен...

Текә стеналар арасына кереп киткән юл шомлы, билгесез һәм куркыныч иде...

Шушы юллардан озатып калды бит ул аны...

Менә шушы юллардан!

Кал дип нигә инәлмәде икән?.. Китмә дип нигә ялынмады икән? Хәерлебәнат апасын нигә егыла-егыла үгетләмәде микән?

Нindидер бер көч аны авыл ягына борды. Моннан соң ул беркайда да туктап тормады, йөгерде дә йөгерде. Өенә кайтып егылганда ул хәлдән тайган иде.

Төн ката аның күзенә йокы эленмәде. Тән белән җан төне буе бәргәләнеп чыктылар.

Әйе, укырга кирәк.... Аягыңда нык басып торыйм дисәң, белергә кирәк...

Иртән Исхакның башы чатнап авыртты, кулбашлары сызланды, күз аллары караңгыланып торды. Ул ындыр түрендәге кое янына төшеп бил тиңентен чишенеп ташлады һәм тәне кып-кызыл булганчы сап-салкын су белән аяусыз ышкына-ышкына юынды. Җиңеләеп китте.

Ишек алдына кайткач, ул үзенең төнге юлдашы пеше чыбыкны күрде. Аның бер очы үлән суыннан яшелләнеп беткән иде. Тик ул кырларга сыек чыбык белән түгел, тракторлар үкертеп керергә кирәклеген егет яхшы аңлый иде. Исхак чыбыкны ачу белән өчкә-дүрткә сындырды да утынлыкка ташлады.

Айлар-еллар буе улын укырга әйдәкләп йөрсә дә, бүген Маһибәдәр үкереп елап калды:

— Ерак юлларга чыгасың, балам, юлларың уң булсын берүк... Сиңа үрелгән дошманнарның күзе томалансын... Сихәт бул. Тамагыңа аша... Ипиләреңне караштырып бар... Бик искәртмә... Күгәрсәләр дә әрәм-шәрәм итмә... Ризыклар бик кадерле, — диде ул кат-кат.

Исхак болдыр баскычында күн итеген дегет белән майлап азаплана иде. Әзерләнеп беткәч, ул әнисенә:

— Хәерлебәнат апалар белән бергә-бергә яшәгез. Җиңелрәк булыр,— диде.

Җил капка төбенә көтү куып кайтучы күрше-күлән җыелды. Маһибәдәр ни тырышса да күз яшьләрен тыя алмады.

— Хуш, балам. Юлларың уң булсын иде, ярабби...

— Сау бул, әнкәй. Сау булыгыз...

Ашлык илтүче малайлар йөкләрен кичтән үк төяп куйганнар иде.

Үргә менгәндә тәпили-тәпили, иңкү җирләрдә аз-маз утырып, Исхак кичкә кырын гына Чаллыга килеп җитте.

Олаулар акрын гына элеватор ягына таба менеп киттеләр, Исхак хушлашып, туп-туры пристаньга төшеп китте.

Пристань тирәсендәге кара болыт кебек халыкны күргәч, аның йөрәге жу итеп китте. Имтиханнар бирергә барганда да пароход көтеп, өч көн рәттән элеватор тавындагы бер апаның бакчасында сирень төбендә кунарга туры килгән иде. Ул чагында төннәр җылы иде ичмасам, хәзер бик кинәнә алмассың!..

Түбән төште. Пристаньга якын барырлык түгел. Ишек катыннан түргә кадәр инвалидлар, бала-чагалы ата-аналар әрдәнә-әрдәнә кысылышып ятканнар. Кая гына карама, кысанлык, кием-салымнар, ертык тышлы түшәкләр, агарган ябык йөзләр. Кешеләр, кешеләр, урыслар, татарлар...

Кая баралар алар? Үз урыннарыннан нигә купканнар?

Кая ашыгалар?

Сугыш быел гына тынган. Сугыш куптарып төрле якларга сибеп ташлаган кешеләр үз урыннарына урнашып бетмәгәннәрдер, ахры. Нервлар соң дәрәҗәдә киерелгән, йөзләр борчулы, тегендә дә монда урын өчен, кайнар су өчен ызгышып-талашып китәләр. Алама җиңнәрен селкетеп хәерчеләр йөри. Бер почмакта лач-лоч төкеренеп карта сугалар, акчалы уйныйлар. Талаш, кычкырыш, ызгыш...

Ул чемоданына ябышып озак кына йөренеп торды. Утырса, йоклап китәчәк иде. Ә йокларга һич тә ярамый. Пристань тирәсендә шикле кыяфәтле, юан-юан папирослар капкан, төймәле түбәле бәләкәй картузлар кигән үсмерләр урала иде. Тиккә генә күз елтыратып йөрмиләр икән, ары башта бер карчыкның чемоданын кычкыртып талап алып киткәннәр дигән хәбәр таралды. Тирә-яктагылардан берәү дә карчыкны яклап тавыш бирмәгән диделәр...

Үткән төндә дә рәтле-башлы йокы күрмәгән Исхак көч-хәл белән таңны аттырды. Кама ярына төшеп юынды, кушучлап май таплары йөзеп йөргән тәмсез, төче суны эчте. Чалбар балакларын какты, күн итеген үлән белән сыпырып тузаннан чистартты.

Билет кайгыртырга кирәк иде. Уралып йөри торгач, ул бер төркем яшьләрнең елгачы формасы кигән картрак агай белән кызып-кызып сөйләшеп торуларына игътибар итте. Яшьләр арасында Мәллә мәктәбендә күз күргән бер егет тә бар иде. Кызыксынып шулар янынарак барды. Яшьләр Казанның төрле мәктәпләрендә укучы студентлар булып чыктылар. Тәбәнәк карт агай пристань начальнигы икән.

Студентлар — чая халык, алар ниндидер приказларның номерларын атый-атый, үзләрен пароходка чиратсыз утыртуларын таләп итәләр икән. Аерата бер егет усаллана иде. Сыңар куллы, аксыл чырайлы бу егетнең теле-телгә йокмый, ул «параграф, закон, без сезне мәҗбүр итәрбез» дигән куркыныч сүзләрне аерата тәм табып, басым белән сиптерә генә иде. Исхак та кыяр-кыймасрак аларга барып кушылды. Җыелганнар аны ачыктан-ачык яратмыйча карадылар. Сыңар кул хәтта:

— Кая, кая тыгыласың? — дип аңа эндәште.

Һаман шул өс-башың өтелгән булуы гаепле! Исхак Казаннан килгән чакыру кәгазен чыгарып күрсәтергә мәҗбүр булды.

Пристань начальнигы:

— Законны үзем дә беләм. Тик минә аның студент дигәне эт өереннән дә күбрәк йөри, ә пароходы юк. Кайчан килә эле ул пароход? Пар белән йөрми бит ул хәзер, ...җылысы белән кыймылдый! — дип каты-каты сүгенеп, буяулары кубып беткән бер чалыш будкага кереп китте.

Сыңар кул:

— Закон бозарга рөхсәт юк! — дип кычкырып калды.

Карт шактый озак торып чыкты һәм:

— Тәртип белән генә кирәгез! Төнгә, Уфа пароходына, дүртенче класска, — диде.

— Койрык безнеке! Ур-ра! — дип кычкырдылар яшьләр.

Көтелмәгән мондый эшкә Исхак та бик куанды. Кара син аны, бу сыңар кул юкка гына бөҗырланып йөрми икән, егет кеше икән ич үзе!

Арт ишектән кысылыша-төртешә кассир янына эчкә үк үттеләр.

— Тәртип белән генә, студент иптәшләр, — дип чәрелди-чәрелди пристань начальнигы бусагага аркылы басып аларның документларын тикшереп торды.

Тар тәрәзәдән ымсынып кассир ягына карап торучы чираттагылар арт ишектәге хәрәкәтне күреп үкереп җибәрделәр:

— Чиратсыз билет саталар!

— Алланың кашка тәкәләре...

— Азындылар...

Кемнәрдер арт ишеккә килеп өелделәр:

— Ачыгыз!

Тавыш-гауга купты. Кассир кычкыра, начальник нидер аңлатып маташа, ишек күгәне дер-дер селкенә.

Башкалар нинди билет эләксә шуңа ризалашып китәләр иде, сыңар кул гына карулашты:

— Постой, постой, Ватан сугышы инвалидын койрыкка, салкын җилгә куасызмы? Студентлар арасында да төрле кеше бар, аера белергә вакыт, — дип үзеннән артка чиратка баскан Исхакка нәфрәтле караш ташлады. — Нигә барыбызга бер пичәт сугасыз?

— Каюта кирәк булса, бер атна көтегез! — дип акырды ике йодрыгын да һавада бутап начальник. — Туйган сездән!

Сыңар кул алай ансат кына тынмады, кемгәдер хәбәр итү белән янап, рәхмәт тә әйтмичә билетын түш кесәсенә тыкты.

Ишектән тагын бөялешеп чыктылар. Бая кычкырып торган билет көтүчеләр аларның чыгуын саклап торалар икән. Алар студентларга ләгънәт укып, ата-бабаларын, гүр такталарын искә төшерә-төшерә җанфәрман сүгенеп калдылар.

— Халыктан аерыла башлау менә шулай була инде, — дип көлде арадан бер студент. Башкалар аңа игътибар бирмәделәр, сөенешеп бер-берсенә билетларын күрсәтә, куанычларын уртаклаша башладылар. Сыңар кул бер читтәрәк торган Исхакка эндәште:

— Укырга кая кердем дидең әле син?

Исхак аны-моны уйлап тормады, билет алу шатлыгыннан ерылган авызын йомарга да онытып:

— Сельхозга! — дип әйтеп салды.

Сыңар кул кабатлап сорады:

— Кая, кая?

— Агрономия факультетына, — диде Исхак, бераз аптырап.

— Алдашмыйсыңмы?

— Нигә алдашыйм?

— Җүләр алайса, — диде сыңар кул шундук. — Беркатлы шыр тиле. Имтихан биреп йөрдеңме, әллә блат агай-эне якаңнан сөйрәдеме?

— Нинди блат? — диде Исхак, кинәт бик каты җәберсенеп. — Шәһәрдә минем беркемем дә юк. Имтихан бирдем.

Сыңар кулның кызыксынуы арта төште.

— Алайса, авылда берәр акыллы башы киңәш иткәндер. Югыйсә, ирекле баштан шунда барып керәләрме? Җәза йорты бит ул. Штрафная рота. Ә син сайлаган факультет — барак смертников.

— Беркем дә киңәш бирмәде, — дип мыгырдады Исхак. — Бардым да кердем.

Көлеп үк җибәрде сыңар кул:

— Мөгезсез сыер! Ай укыгач та үкчәңне ялтыратасың бит син аннан!

— Качмам!..

— Менә нәрсә, егет... Барып җитәбез дә документларыңны ул җәһәннәмнән алабыз. Аннары, туп-туры безгә! — диде сыңар кул оста гына тәмәке кабызып. — Мин үзебездә профсоюз лидеры. Җайлармын.

— Кая ул сезгә? — дип сорады Исхак, китә башлаган җиреннән туктап.

— Ике еллык юридик мәктәпкә, — диде горурланып сыңар кул. — Ике еллык, вәссәләм! Җитмәсә, юридик мәктәп бит әле ул. Ни пычагыма сиңа ул сельхоз? Колхозда интегеп җенең өзелмәдемени әле синең? Күтәрәм атлар торгызып, корчаңгы сыерлар астын тазартып туймадыңмыни? Законнарга буйсынып яшәүгә караганда, аларны үзең чыгару мактаулырак. Колагыңа киртлә, борынгылар сүзе бу.

Юрист, егетнең аптырашта калуын күреп, канәгатьлек белән көлеп куйды.

— Танышыйк әле, Мөнир абыең булам мин. Тазюков. Тыңла, егеткәй, ата-бабаңнан ишетмәгән киңәшне бирәм сиңа. Бездә барысы да шәбрәк. Стипендиясе дә, торак та... Ике ел укыйсың да тормышның хуҗасы буласың. Прокурор ярдәмчесе, яки судья. Кайсы районнан әле син?

Исхак әйтте.

— Бигрәк тә яхшы, сезнең районның прокурорын беләм мин. Әтинең якын дусты. Беләсеңме, прокурорлар районда ничек яшиләр?

— Белмим.

— Каз ашап кына торалар! — Сыңар кул авызын очлайтып сызгырып куйды. — Шуның өстенә, кая гына барма, почет! Акчасы мул, киеме бушлай... Тегесе-монысы... Хәтта райком да дерелдәп тора алар каршында...

— Шулаен шулайдыр, — диде Исхак, исе китмәгәнгә салышып. — Тик минем сезнең мәктәпкә барасым килми.

— Нигә? — диде сыңар күз бәбәген акайтып.

— Шулай.

— Тфү, чорт! Аның файдасына сөйлиләр, ә ул...

— Сез мине бөтенләй белмисез дә бит... Нигә үгетләп маташасыз? Нигә кыстыйсыз?

— Кикриксез әтәч... Кызганам синдәй чебешләрне... Барыбер качачаксың. Гомерең бушка узар. Түзсәң, бер ел түзәрсең. Ул институт егетләрен кызлар якын да җибәрмиләр.

— Миңа кызлар кирәкми, — диде саңгырау гына Исхак.

— Әкәмәт икәнсең син. Үз яныма бүлмәдәш итеп алырмын дигән идем. Мин сиңа укырга булышырмын, ә син минем вак-төяк эшләремне караштырырсың. Өлкән лейтенант иде абзаң сугышта, денщик белән яшәп күнеккән!

Исхак кып-кызыл булды.

— Ипи чиратында йөрергә яратмыйм, — диде сыңар кул.

— Күчмим, — дип кырт кисте Исхак.

Башка студентлар да шушы тирәдә уралалар һәм аларның сөйләшүен кәмит итеп тыңлап торалар иде. Исхакка бераз таныш кебек күренгән егет аның янына килеп:

— Дөрес сукалый бу төлке! — диде. — Нәрсә ул сельхоз? Кемгә кирәк ул хәзер? Бабайлар укымаганнар әле, иген икканнәр. Ул институтка башка җиргә үтә алмаган кара наданнар гына барып керә.

— Керсен! Мин дә шуларише! — дип кычкырды үртәлеп Исхак һәм чемоданын күтәреп бер читкә китте.

Мөнир Тазюковка да, менә бу студентка да юньләп торып җавап бирергә аның көче җитмәде. Аларның сүзләре янында үзенең дәлилләренең көчсез икәнлеген ул сизенде...

Теләкнең каян тууын сүзләр белән генә аңлатып буламени?..

Юк, юк, алар Исхакны аңламаслар иде. Ул бит авылда берәү генә, андыйлар районда да юктыр, бәлки. Татарстанында да ничә генәдер!..

Сөйли бирсеннәр, лыгырдасыннар, көлсеннәр. Кая ул аларга Исхакны аңлау!

Ни шайтаныма прокурор булсын ул? Мөнир Тазюков, ди. Бу фамилияне ишеткәне дә бар бугай анын... Кем малае булды соң әле бу Тазюков?..

Прокурор... Ялтыравыклы төймәле озын шинель кигән, карсак кына карт прокурорны имтихан бирергә баргач райүзәктә күргән иде ул. Күрер күзгә юаш кына бу кеше берсеннән-берсе кечкенә өч баласын ияртеп мунчадан кайтып килә иде.

Шуннан башкасын белми дә ич Исхак! Ниенә кызыксын ул аның? Каз яратуынамы? Ашавын тәмле ашый икән, ә нәрсә эшли соң ул? Ялтыравыклы төймәләре корсын, күркәмени ул кызылга кызыгырга?..

Уф, шушы Чаллы пристаненың баскычлары... Туктый-туктый менсәң дә бөтен буыннарның жегәрен ала...

Тукта, нигә менде соң әле ул монда?..

Ничек менә менмәсен, авыл тынлыгына күнеккән егеткә монда рәхәтрәк иде. Урын аулак диярлек, офыклар киң...

Бер читтәрәк, вакытсыз саргая башлаган тупыл төбендә, уф-алла арбалары житәкләгән кырма сакаллы, түгәрәк бүрекле татар агайлар җыелышкан. Ухылдап менеп житкән Исхакны да алар игътибарсыз калдырмадылар. Берсе килеп:

— Яшь егетне кая илтик? — дип сорады.

— Казанның үзенә, — диде Исхак, төксе генә.

Агай үпкәләмәде:

— Ә-ә, алай икән, — дип үз урынына китте.

Исхак бер читкәрәк барып чирәмлеккә утырды. Аяк табаннары гел басып торып, гел йөреп торып кызышканнар һәм гүлиләр иде. Утыру белән мәлҗерәтә, йокымсырата башлады. Исхак күзен көч-хәл белән ертып ачып Кама аръягына, зәңгәр урманнарга карарга тотынды. Барыбер оета, изрәтә иде. Менә Казан ягыннан ташбака кебек тәбәнәк пароход килеп чыкты. Пристаньдагы халык хәрәкәткә килде. Тау өстендәге арбалы агайлар да баскыч турына килеп бөялделәр. Пароход яман карлыккан тавыш белән сәламли-сәламли кара төтен болыты чыгарып килеп туктады. Савылып халык чыгарга тотынды. Текә баскычтан авыр-авыр төеннәр, сандыклар күтәргән ирләр, хатыннар менә башлады. Арада яшел гимнастерка якаларын чишеп жибәргән солдатлар, түшләрен орден-медальләр белән чуарлап бетергән офицерлар да бар иде. Исхакның кызыксынуы көчәйде, ул урыныннан торып баскычка табарак тартылды.

— Солдатлар кайта, солдатлар!

Җыелган халык та, арбалы агайлар да куанышып солдатларны сәламләделәр.

— Һай, исән кеше бер кайта шул ул!

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Әтиләр, уллар, кияүләр, ирләр кайта...

Тирә-яктагы бу чын җанлылык, ябык, саргайган йөзләрдәге саран куаныч яшьләре Исхакның арганлыгын беркадәр оныттырды, ул да балалар кебек сөенеп кайтучыларны күзәтеп торды.

Әйе, исән кеше бер кайта... Урап-урап, торып-торып булса да кайта...

Шул вакыт кемдер аның исемен атап эндәште:

— Әллә Исхак инде?

Үзе янына ук менеп баскан, текә баскычта шабыр тиргә төшкән, аксыл чырайлы яшь кенә старшинаны ул башта танымады. Аркасына нәни генә юл капчыгы аскан, күкрәгенә өч-дүрт орден-медаль таккан бу кеше таныш та, таныш та түгел иде.

— Яхшылабрак кара! — диде теге, Исхакны тәмам танып.
— Хөсәен!
Бу житү сакаллы кешене абый диярга дә кирәк иде, әмма иске гадәт буенча Исхак егетне исеме белән генә атады.
— Таныдың тагын. Син берәрсен көтеп торасыңмы?
— Юк, үзем китәм.
Сузган кулын ычкындырмыйча, Хөсәен Исхакны бер читкәрәк алып чыкты.
— Кая китәсең?
— Казанга, укырга. Ә син ничек? Бөтенләйгәме?
— Өмет шулай... Безнең яктан ат-мазар юктыр бит?
— Ай-һай белмим шул! Атлар калдымы икән?
— Синең пароход ничәдә китә?
— Төн уртасында гына әле! Билет кесәдә.
— Алайса, син миңа берәр олаучы эзләш инде.
— Эзләшәм, эзләшәм!
Туп-туры элеватор ягына сыптырттылар. Капка төбендә егермеләп ат торса да, юллары уңмады, берсе генә дә Куктау ягына кайтмый иде. Хөсәенгә монда кунарга туры киләчәк. Башта ул бик күңелсезләнде:
— Шушы булыр инде безнең якларның, — дип көрсенде. — Җәфа.
Фатир эзләп интегәсе килмәде аның, тагын шул пристаньга килделәр.
— Аска төшмик, — диде Исхак, тау башына килеп җиткәч. — Монда тынычрак.
— Үз түремдә түрә булып утырырмынмы әллә дигән идем!.. Аяклар сызлый...
Хөсәен фуражкасын салып тирдән юешләнгән чәчен кулъяулыгы белән сөртеп куйды.
— Олы кеше булгансың син, Хөсәен.
— Лейтенант юк җирдә, без генерал!
— Бу нинди тәре?
— Поляк ордены.
— Әллә кем булып беткәнсең, — диде Исхак көнләшеп.
Авыл хәбәрләре бәйнә-бәйнә сөйләшенде.
Исхак сугыш хәлләрен сорашты.
Сүз тагын авылга күчте. Сугыш — үткән-беткән, хәзер икесен дә киләчәк ныграк кызыксындыра иде...
Ничек яшибезме? Кем ничек булдыра ала... Урлашсаң — тук, урлашмасаң — юк. Менә шул. Иң кыска җавап... Бар, бар, бик шәп яшәүчеләр дә бар, бик кәйләр дә күп. Авыл ипигә туямы? Юк, кая ул, бәрәңгесенә тук булсаң, сөенәсең. Анысы да такы-токы. Ит, май налогка китеп бара.
— Председатель һаман шулмы?
— Шул инде шул, Гыйльми Салихы.
— Авыл белән шуна түзеп торалар икән...
Түзми нишлисең? Ир-ат юк. Эшкә ярарлык нибарысы алты ат бар, аларын да язын лапас өрлегенә күтәреп асып куялар. Сыерлар кысыр, күтәрәм. Җәй уртасына кадәр бер тамчы сөт бирмиләр. Сарыклар үз йоннарын үзләре ашап бетерәләр... Быелмы?.. Хезмәт көненә берәр йөз грамм арыш эләкмәсме дип өметләнгән идек, булмас ахры... Чәчелгән җир аз, налоглар күп. Шайтан таягы үскән җир өчен дә чиста ашлык тапшырырга кирәк.
— Синең авылдан ычкынуыңның сере аңлашылды.
Хөсәеннең ярым шаяртып кына әйткән шушы сүзе Исхакны рәнҗетте.
— Син минем нинди институтка баруымны беләсең ич, — диде ул җәберсенеп.
— Ярый, ярый, — дип кабатлады Хөсәен. — Дөрес уйлагансың. Сезнең елгылар бәхетлеләр. Чиратыгыз да җитте, сугыш та бетте. Укырга

кирәк анысы! Менә безгә тимәс инде ул. Әни карчык та бик бетәште дип яздылар, абыйның балалары да миңа өелеп калды...

— Кичке уеннармы? Булгалый... Тик элекке уеннар юк инде ул. Су буена вәкил төшерми... Җайдак куа чыга. Кулында камчы... Яшьләр авылдан кыяклауны карыйлар. Шөгер якларында нефть тапканнар ди. Шунда китә башладылар. Акчаны каералар ди анда...

— Сугышмы? Ишеткәнсеңдер инде... Берлинда? Булдым, булдым... Варшавада булдым... Госпитальда да яттым... Америка солдатлары белән дә очраштык... Ниндиләр, дип, озын-озын, тап-таза егетләр. Арада негрлар да байтак... Тел белмәгәч, әпә-чәпә, дип арка кагышып тордык шунда...

Хөсәен бертуктаусыз тәмәке пыскыта иде, хәтта Исхак та моңа игътибар итте:

— Тәмәкегә өйрәнеп кайткан син.

— Без янганчы, тәмәке янсын.

— Нишләргә уйлыйсың инде авылда, Хөсәен?

Хөсәен ашыгып кына җавап бирмәде.

— Бер-бер кәсебенә керешми булмас инде. Тамак туйдырырга кирәк бит. Казна хисабыннан чыктык хәзер!.. Сугышып карадык, яшәп карарга вакыт!

Исхакның ышанмыйчарак торуы күзенә чыкты ахры, Хөсәен кулы белән кискен генә һава ярып алды:

— Әллә ышанмыйсыңмы? Безгә дә рәхәт күрергә ярыйдыр бит?

— Шушы сүзләреңне Гыйльми Салихы белән вәкилгә әйтә күрмә.

— Әйтермен дә!

— Соңыннан үкенмәсәң ярый ла...

Хөсәеннең түшендәге орден-медальләре зарлангандай чыңгылдашып алдылар.

— Азрак ияк биетеп аласы иде. Син каршы түгелсеңдер бит?

— Мин һәрвакыт әзер!

Хөсәен солдат капчыгын чиште һәм бизәкле тышлы озынча калай банка чыгарды. Исхак үрелеп капчык эченә күз салды.

— Син каты борын маен ашыйсыңмы? — дип сорады Хөсәен, банканы ача-ача.

— Нинди каты борын?

— Тырышып йөгерә торган каты борын. Мырыйк-мырыйк, чук-чук-чук!

Исхак гөрләтеп көлеп җибәрде.

— Ашамаган кайда, — диде ул, селәгәен йота-йота. — Эләкми генә.

Үзе дә чемоданын ачып пешкән күкәй, бер чеметем тоз, бер-ике баш суган чыгарып куйды. Газета кисәге җәеп табын ясадылар. Тәмләп ашарга керешәбез дигәндә генә алама-шалама киемле биш-алты кеше аларны урап алдылар.

— Солдат, сатлык шпигең юкмы?

— Акча да бирә алабыз, спирткә дә алышабыз.

— Йөрмәгез әле! — дип ачуланды Хөсәен. — Ач күзләр, сыпыртыгыз моннан!

Шалама кешеләр китмәделәр, эренле күзләрен ялтыратып, иснәнеп һаман шул тирәдә бутaлдылар.

Исхак уңайсызланды, Хөсәеннең исе дә китмәде.

— Йөриләр шунда, әрсез алабайлар... Юл буена утырып кына ашар хәл юк, хәзер килеп җитәләр!

Старшина оста гына итеп ипи телде, аңа калын гына итеп май якты, күкәй әрчеде.

— Тәмлеме?

— Шома бара, терәлеп тормый,— диде Исхак ясканып, майлы ипигә

тешләрен батыра-батыра. — Авылда мондый ризык эләкмәс сиңа. Иң зур сый итеп ушкай коймагын ашарсың!

— Нәрсә, нәрсә? — дип сорады Хөсәен, ашыкмыйча чәйни-чәйни.

— Ушкай коймагы.

— Ничек пешерәләр аны?

— Бәрәңгене калын-калын итеп теләләр дә күмере тартылган кайнар мич төбенә тезеп куялар. Шәп тә булып пешә инде!

— Түзәрбез, күрмәгән баш түгел...

— Баш түзә дә, корсак ашарга сорый шул, — дип көлде Исхак.

Тамаклар туеп, капчык-чемоданнар бәйләнгәч, Хөсәен берне кабызды да башын кыйгайтып кына сорап куйды:

— Имәнле очында ниләр бар? Нурулла абзыйлар ни хәлдә?

Исхак сискәнеп китте.

— Яшәп яталар шунда, — дип мыгырдады ул.

— Апалар Сания турында язганнар иде миңа. Шул хәбәр дөрес булып чыктымы?

— Дөрес.

— Ярата идем мин ул кызны! — диде Хөсәен, кинәт кенә. — Әйбәт кыз иде... Дөньяда андый кыз юктыр да бүтән.

Хөсәеннең сүзләрен Исхак исе китеп тыңлады.

— Шәп кыз иде, — дип дәвам итте ул. — Җырлаган тавышы әле дә булса колак төбемдә... Курск янында яраланып егылдым... Беттем, мин әйтәм... Тирә-якта атыш, кырылыш, гарәсәт! Бу тәмугта кем мине йолкып алыр, дим... Кинәт колак төбемдә аның җыр тавышы. Була бит шундый кешеләр, күңеленә мәңгегә кереп утыралар!.. Теге чакта, сугышка хәтле үк, мин аңа хатлар да язгалаган идем... Әхмәт Ерикәйдән күчереп бер-ике шигырь дә кыстырдым...

Болары Исхак өчен яңалык иде.

— Җавап язмады язуын миңа... Бер тапкыр да язмады. Барыбер ярата идем мин аны... Апаның хатын алгач ышанмадым. Кайтышлый Белоруссияне кичеп чыктык. Алар торган станцага кагылып чыктым... Сораштым да, тик белүче генә табылмады. Тамырын корткан фашист ул җирләрнең...

Кама өстенә тиз-тиз генә караңгылык җәелде, ерактан, аръяктагы караңгы урманнар артыннан салкынча җил исте. Шатыр-потыр килеп, аллы-артлы куышып моторлы көймәләр кайтты. Сирәк-мирәк кенә ак, кызыл маяклар кабындылар. Аста вокзал янында, аккордеон тарта башладылар. Бик кызганыч, йөрәк өзгеч нәзек тавыш белән татарча җырлыйлар иде. Җырчы сузып кына бер куплетын бетерде дә шунда ук русча җырларга тотынды.

— Сукыр солдат ул, — дип аңлатты Исхак, — ике күзе дә янган, карарга куркыныч... Бая да күргән идем мин аны... Тамак туйдыра...

Ике егет янәшәләп, бер-берсенең җылыларын тоеп шактый вакыт утырдылар. Хәзер алар гади юлчылар, якташлар, авылдашлар гына түгел, аларның икесенә дә бик кадерле уртак серләре бар иде. Хөсәеннең дә олы егет булып Исхакның башыннан сыйпасы, юатасы килде. Тик олыларча тезләрен кочаклап, еракларга, караңгыга текәлеп утыруы бу үсмернең инде шактыйдан зур кешегә, кайгы һәм хәсрәтне үзенә иярткән кешегә әйләнүен әйтеп тора иде.

Сукыр солдат тагын татарча җырлап җибәрде, аның тавышы җанны әрнетеп күзгә яшь китереп тутыра, йөрәкләрне сыза, тетрәтә иде.

— Көз житте дә мени әле? Салкын... — диде Хөсәен, иңбашларын җыерып.

— Су жиле менеп житә, — диде Исхак.

Менә аста җыр тынды. Вокзал тирәсе мең тавыш белән тонык кына гүли. Кемнәрдер тынмыйлар, баскычтан менеп-төшеп йөриләр. Исхаклардан ерак та түгел, койманың теге башында, егет белән кыз басып

торалар. Егет кызны кочаклый, кыз рәхәт итеп, гөлдердәтеп көлә. Исхак авыз эченнән генә җырлый башлады, Хөсәен дә карлыкканрак калын тавыш белән аңа ялганды.

Чәчәкләр күп,
Ләкин чәчәк өзмим,
Табу өчен шундый ислесен.
Мин тапканчы шундый бик ислесен,
Гөл үсмәсен,
Җил дә исмәсен.

— Кем чыгарган икән бу көйне?

— Белмим, — диде Исхак.

Тагын озак кына сөйләшми утырдылар, иреннәре ачытканчы тәмәке тарттылар.

— Юк, — диде Хөсәен, тешләрен кысып. — Без яшәргә тиеш әле. Гыйльми Салихларының муенын борып яшәргә... Югыйсә менә, ярты Европаны урап чыктым... Шәһәр-авылларны, юлларны карадым. Без дә яшибез дип төтен чыгарып йөрибез икән, селкенеп... Хәзер болай бармас, тормыш яхшы якка үзгәрергә тиеш.

Сүзгә мавыгып китеп югарыдан пароход килгәнен дә абайламый калдылар. Сузынкы, яңгыравыклы гудок Исхакны дертләтеп җибәрде. Ул каударланып сикереп торды:

— Пароход килә!

— Килә шул... Сине озатып куйыйм булмаса, — диде Хөсәен, капчыгын биштәрләп асып.

— Кат-кат менеп йөрү авыр булыр бит.

— Барыбер төнлә монда утырып булмый. Ябышып катарсың. Аста солдатлар да бардыр әле. Иптәшләр...

Төшә башладылар.

— Капчыгыңны үзем күтәримме?

— Җиңел ул, — дип кулын селкеде Хөсәен. — Кайбер ачарбаклар кебек мал төяп кайтмадым! Таланган малга кызыкмыйм мин.

Аска төшкәч, озак кына пароход янына үтә алмый тордылар. Ишле халык дәррәү кузгалып арлы-бирле чайкала иде. Бала-чагалар чырылдый, хатын-кыз зинһарлап юл сорый, ирләр терсәкләре белән теләсә кемне дөмбәсләп сүгенәләр... Бер кырыйда яшь-җилкенчәк чут-чут үбешә...

Беренче гудок булды, икенчесе. Матрослар акыра-бакыра трап буйлап мичкә тәгәрәтәләр иде. Исхак мең бәла белән эчкә керде, тончыктыргыч сасы исле дүртенче классны үтеп койрыкка чыкты. Үзе кебек үк агач чемоданнар кочаклаган, дәү киндер капчыклар аскан агайлар-апалар кысылышып аңа идәннән, үз яннарыннан, урын бирделәр. Ул утырган җирдән генә сузылып Хөсәенне эзләп тапты. Хөсәен дебаркадер култыксасын сарган кешеләр арасыннан сузылып елмаеп тора иде.

— Утырдыңмы? — дип кычкырды ул.

— Утырдым, утырдым! Казанга җиткәч, кыймшанып кына булырмы!

Койрыкка һаман кешеләр өстәлә торды. Төркем булып баягы студентлар кереп кысылдылар.

Исхакка беркадәр ямансу, күңелсез булып калды. Ул үзенең авылдан, күнегелгән тормыштан аерылуын, яңа җиргә, яңа кешеләр арасына барып көн күрергә тиешлеген төшенеп, укырга барырга ризалашуына үкенде. Ичмасам, тормыш авылда үз көенә бара иде... Хәзер ничек булачак?..

Мөнир Тазюков бәләкәй генә кара чемоданын койрыкка кертеп торса да, бераздан аны кереп алды. Йөри торгач икенче класстан каюта эләктергән икән.

Озакламый, ул икенче кат палубасында күренде. Өс-башын алыштырып, ак күлмәгенең якасын костюм өстенә кайтарып, чибәрләнеп,

олысымакланып киткән иде ул. Зур-зур капчыклар, чабаталы, ябык чырайлы татар бабайлары, ямаулы киң бәбәйтәкле күлмәкләр киеп, чачаклы иске шәлләргә төренгән татар апайлары арасына кысылып, күзләрен елтыратып утырган Исхакка карап, Тазюков эре генә көлемсерәде. Сүз катарга уйлады, эндәшмәде. Икенче классның иркен палубасында вак-вак кына атлап йөргән мәһабәт ханымнарга, камыш көрсиләрдә атынып папирос көйрәткән кешеләргә үзенең татар икәнлеген, әнә шул койрыкта утырган, мең мәшәкать белән нужа куып юлга чыккан авыл кешеләре белән кан кардәш икәнлеген күрсәтәсе килмәде аның.

Студентлар аңа нидер кычкырдылар. Ул тиз-тиз генә койрык турыннан китте. Икенче класс палубасына рөхсәтсез менгән бер малайны матрослар типкәлиләр иде. Башкалар белән ул да көлә-көлә шуны тамаша итә башлады...

Пароход өзек-өзек кенә тагын бер кычкыртты да, уфылдап, дерелдәп Казан ягына юл алды...

Мәһибәдәр төннең-төн буе укынып, йоклый алмый ятты. Төн уртасында убыр шикелле ишек алларын әйләнеп керде. Чәй кайнатып эчте. Бушап калган өй эче шыксыз, куркыныч иде. Мич арасы сандугачлары — чикерткәләр уздырышып сайрадылар. Тол калган өйдә Мәһибәдәргә бердәнбер иптәшләр хәзер шулар иде.

Нурулла да төн буе йокламады. Ул хыялланып әле тәрәзәне ачтырды, туңып, әле яптырды, кем беләндер сөйләшеп, бәхәсләшеп ятты. Чыпчык күкәе хәтле генә калган кара йодрыгын селкеп кемгәдер янады да...

Куктау өстендә җылы төн булса да, Кама җиле койрыктагы егетнең сөякләренә үтеп керде. Кыска бушлатка никадәр төренсә дә Исхак дер-дер калтырый иде.

— Шәкертнең җилән кыскарак икән, — дип көлешә-көлешә, агайлар иске бишмәт белән аның тезләрен төрделәр.

Икенче катта музыка уйный, салон ресторанда шампанское бөкеләре шартлый, кызып алган Мөнир Тазюков буялган керфекле чибәр кыз белән быдыр-быдыр нидер сөйләшә иде.

Исхак үзенә терәлеп утырган ябык хатынның тән җылысыннан изрәп күзләрен йомды...

## II

Мөнир Тазюков дөресен әйткән иде.

Шәһәрдә мең уңайсызлык, йөз кыенлык сагынып көтеп торган икән Исхакны.

Тору урыннары кысан — бер бүлмәдә кырык кеше яшиләр. Үткенрәк егетләр бүлмәне «карда» дип, анда торучыларны «алашалар» дип йөртәләр... Ашарга-эчәргә дә бик чамалы — студент карточкасына тигән ризык олы телдән үтә дә, кече телгә җитми, теш арасында уралып югала... Стипендия акчасына нибарысы ике буханка икмәк тия. Ә Исхак кебек егетләрнең ике буханка ипине бер утыруда ашый торган чаклары...

Җыелган халык бик чуар. Күпчелек чыннан да башка вузларга үтә алмагач, ничарадан бичара гына монда кереп, вакытлыча оялап ятучылар. Алар авыл хуҗалыгы, крестьян дигән сүзләрне ишеткәндә яратмыйча борын җыералар...

Укырга дип сугыштан кыҗрап кайткан өлкәнрәкләр дә бар биредә. Тик алар Исхак кебек быел гына мәктәп бетереп килгән ыбыр-чыбыр белән ваксынып тормыйлар, лекцияләр бетүгә үк туп-туры китапханәгә чабалар, кара төнгә кадәр шунда калып утыралар. Аларның киемсалымнары да әйбәтрәк, ашау-эчүләре дә түзәрлек, ай саен профсоюздан талоннар алып торалар. Тора-бара алар бәләкәйрәк, уңайрак бүлмәләрне сайлап, аерылып чыгып беттеләр, болындай шыр бүлмәдә та-

ракан кебек мыжгылдап шырдый-бырдыйлар гына калды. Болай да әлле-сәлле генә торган тәртип, өлкәннәр киткәч, тәмам чыгырыннан чыкты. Төне буе йоклау юк, өстәл тирәли утыралар да карта сугалар, тәмәке пыскыталар, бертуктаусыз кызлар турында гайбәт саталар.

Боларның берсен дә сөймәгән, кызлар кебек тыйнак Исхак бик тиз малайларның көлкесенә әйләнде. Чыгып китсә, аның койкасына одеял астына утын пүләне салалар, күн итекләренә чыра, иске кәгазь тутырып куялар иде. Бүлмәдәшләре арасыннан сердәш табалмады Исхак. Кырык кеше арасында ул япа-ялгыз иде.

Ташлап качар чакларда, аны әнисеннән килгән хатлар гына тыйлыктырып торды. Улының хәл-әхвәлен, кичерешләрен сизгән кебек, Мәһибәдәр өзми-төзми хат җибәреп торды. Һаман шул авыл, колхоз хәлләреннән дә үзенә күрә яңалыклар табып, тәмле итеп, матур итеп яза иде ул.

Әнисенең хатларын укыр өчен генә ул гарәп хәрефләрен яхшылап өйрәнде, чөнки малай чагында, бишенче класста булган хәл аның күңеленә сеңеп калган иде. Ул әнисеннән үз исеменең гарәпчә язылышын сорап белде дә, коймаларга, класс такталарына «Исхак», «Исхак» дип язып йөри башлады. Бер көнне класс житәкчесе, ала күзле Мәрдия апа, малайны җилтерәтеп директор янына алып керде. Стена, коймаларны пычраткан өчен эләгә инде дип торганда, аны... «Ни өчен коръән хәрефләрен өйрәнәсең?» дип тетәргә тотындылар. Кайсы җирең кычыта...

Ә монда, университет каршында ачылган татар бүлегендә, гарәп телен фән итеп өйрәтергә керешкәннәр. Мәллә мәктәбен бетереп, шунда укырга кергән районлаш егетләре Исхакка гарәп алфавитын биреп үк җибәрделәр.

Университетта татарча бик әйбәт әдәбият түгәрәге эшли икән, иптәшләре Исхакның элегрәк шигырь-мигырьләр белән кызыксынуын белеп, шунда чакырдылар.

Әйләндереп теккән иске солдат бушлатын (әнисе узгынчы солдаттан бер капчык бәрәңгегә алмаштырып алып калган иде) курка-курка гына гардеробка тапшырып вестибюльдә як-ягына карангач, Исхак чамасыз каушау тойды.

Коридорларда тыз-быз йөрүче студентлар да, түшәмдәге утлар да, бүлмәләрнең исе дә үзгә, башка иде монда. Гөжелдәшеп чит ил студентлары үтеп киттеләр, һәйбәт бүрекләрне баш очларына гына утыртып чибәр киенгән кызлар йөренделәр. Бодай арасындагы кара әрем кебек, бик авылча киенгән, татар бүлеге студентлары аерылып тора иде.

Алар арасына барып сыенгач кына Исхакка бераз җан керде.

Әдәбият түгәрәге узачак аудиториягә барып керделәр. Башланырга байтак вакыт бар икән әле. Аудиториядәге пианино янында сызылып кына чыгып килгән кара мыеклы, бөдрә чәчле яшь егет бик бирелеп уйнап утыра иде.

Мадьяр егете! — дип пышылдадылар Исхакның белешләре.

Бераз музыка тыңлап утырдылар. Тагын өч-дүрт венгр студенты керде, алары да алмаш-тилмәш пианино уйнап карадылар, чәлдер-чәлдер нидер сөйләштеләр, бәхәсләштеләр, ахры. Аларның шулай каушамыйча, рәхәт итеп, үзләрен хуҗа сизеп йөрүләре, утырган берсенең музыканы белүе, килеш-килбәтләре Исхакка зур тәэсир ясады. Бу инде авыл хуҗалыгы институты студентлары түгел! Венгрларның үз телләреннән тыш өч-дүрт телдә теттереп сөйләшүләрен ишеткәч, аның гаҗәпләнүе соң дәрәҗәгә җитте.

Түгәрәкнең утырышын тәбәнәк кенә, озын чәчле, какча йөзле бер студент ачты. Студентлар янына күкрәгенә Кызыл Йолдыз ордены таккан җирән чәчле, кып-кызыл йөзле бер шагыйрь да килгән иде. Сүзне иң элек аңа бирделәр. Тере шагыйрьне күргәч, Исхак әсәренеп аннан күзен алмады.

Җирән чәчле шагыйрь кулларын бутый-бутый, бик каты кычкырып, кемнедер ышандырырга теләгән сыман «Бәхет турында» поэмасын укып чыкты.

Тыңлаган саен, Исхак аптырашкарак калды. Бу абыйның бер дә авыл күргәне юк микән әллә, дип тә уйлады.

Түбә саламнары кубарылып беткән Куктау авылын күз алдына китерде. Шул Куктау егетләренең караңгы, яңгырлы төннәрдә чәчүлек орлык та калдырмыйча, келәт бураларын кырып-себереп, икмәк төяп юлга чыгуларын хәтерләде. Кулына кыска камчы тоткан вәкил озатып кала иде аларны... Ә бу поэмадагы егетләрнең авызлары ерык, тамаклары тук, бик кинәнеп гармун кычкырталар, ду китереп җырлыйлар. Исхакның авылдашлары бер вакытта да гармун күтәреп эшкә йөрмиләр иде... Бигрәк тә быел, сугыш беткән елда... Кая ул!.. Көзен мең нужа белән илтеп тапшырган игеннәрне язгы чәчү алдыннан бәләкәй чаналарга төяп, дәүләт амбарларыннан кире колхозга алып кайталар иде...

Шушы булдымы инде авыл егетләренең бәхете?..

Шагыйрь абыйсы белән бәхәскә кереп тормады Исхак, әмма башкалар күтәрелеп кул чапканда тик кенә утырды, тиле кеше кебек ялтйолт як-ягына каранды.

Тагын кемнәрдер шигырь укыдылар, кул чаптылар, бер-берсен макташтылар. Шигырьләрдә тормыш бик көйле, бик матур, «дөньяда бердәнбер» иде...

Исхак университеттан эче пошып чыкты.

Пианино уйнап утырган егет, венгр егете, аның күз алдына килепкилеп китте... Ничек алай? Аларда да әле генә сугыш бетте... Ничә еллар буе Венгриядә фашистлар хөкем сөрде. Кайчан, ничек өйрәнде икән ул?

Көнләште Исхак. Аның әнисе ничә еллар хыялланып, унике телле гармун да ала алмады бит! Югыйсә, улмы инде эшләми, улмы инде тырышмый?

Нигә алай була икән? Нигә шушы кадәр тигезсезлек?

Тормышның кемнәре юк... Нинди бәхетле балалары бар. Барын беләләр, чит тел өйрәнергә дә вакыт тапканнар, музыкасын да өйрәнгәннәр, башкасына да маһирлар... Ике аяклы, ике куллы кешеләр...

Менә Исхак институтны тәмамлар, диплом алыр. Тагын шул ук радиосыз, электрсыз караңгы Куктау авылына кайтып китәр. Тырнак төпләре канаганчы шайтан таяклары белән сугышыр. Икмәк үстерер. Аны Чаллыга илтеп тапшырыр. Тагын чәчәр, тагын урыр, тагын... Ә бу шәһәрләр, зур урамнар, якты электрлар, уңайлы квартиралар, пианинолар, көяз егетләр барысы да монда калыр. Исхак үзе генә түгел, аның балалары да, оныклары да музыканы белмәсләр. Чөнки алар, Исхакның үзе кебек үк, черек-чарык бүрәнәләреннән җил өреп торган тәбәшәк түшәмле Мәллә мәктәбендә генә укырлар. Ялгыш-моңгыш кына күңелләрендә бер нур балкып, чит тел өйрәнергә тотынсалар: «Әһә, нигә син бу телне өйрәнәсең әле? Әнә, рус телен яхшылап өйрән, шул җиткән сиңа!» дип тетмәсен тетәрләр...

Колхозларда Гыйльми Салихлары баш булып утырганда...

Мәктәпләрдә дә аның сыңарлары очраганда...

Юк, юк, болай уйларга ярамый! Туган җиреңнән олы булмаска кирәк! Туган җиреңә сүз белән дә, күңел белән дә хыянәт итәргә ярамый. Исхак алга гына түгел, артка да карарга тиеш! Аның ата-бабалары кем булганнар? Ә ул кем булып, кайларда укып йөри, белем ала. Шул Гыйльми Салихларына баш бирмәс өчен, аларга охшамас өчен укый ич ул! Аның балалары тагын да арырак китмәсләр дип кем әйтә ала.

Ямьсез уйлар белән янәшә йөрергә ярамый. Укырга кирәк, укырга, укырга... Олылар шулай дигәннәр...

Шәһәрнең кызыктыргыч вәсвәсәләреннән ирекле-ирексез читтә генә, узбаш көн күрә иде ул.

Бер яз аның тормышына көтелмәгән үзгәреш кертте...

Жылы, әйбәт көн иде. Бер төркем егетләр белән Исхак Иделгә су коенырга төште. Теге онытылмас көннән соң Исхак егетләрдән, малайлардан кача-кача Күктау буасында йөзәргә өйрәнгән иде инде. Я бик иртә, я бик соң килеп ул үрдәк кебек чумарга, буаны иңли-иңли колач салырга остарды. Авылда аңа тиңдәшләр юк иде хәтта. Суны бик яратса да Иделгә төшү бик сирәк эләгә иде, кызыгып Маркизга ук чыгып киттеләр. Башта авызларын ачып яр буйларын сарган ярым ялангач кызларны караштырып йөрделәр. Аннары комлы ярны сайлап чишенеп ташладылар. Алардан ерак түгел бер кырыйдарак биш-алты кыз шаугөр килеп туп чөяләр иде.

Исхакның киң күкрәгенә, сылу, килешле гәүдәсенә иптәш егетләре дә игътибар иттеләр.

— Бокска йөрергә кирәк сиңа, егет! — диде берсе, аның озын кулларына карап.

— Көнгә ничә буханка ипи бирәләр анда? — дип көлде Исхак. Очлы күзле кызлар да аны күреп, бер-берсенә төртешеп кенә көлешеп, сөйләшеп алдылар. Аларның туплары егетләр ягына ешрак тәгәри башлады. Егетләр бу чакыруны кабул иттеләр һәм сикерешеп торып туплы уйнарга тотындылар. Исхак уйнамады, ул кырын ятып күзләрен кыса төшеп Идел өстенә карады. Бераздан башкаларга эндәшмичә генә суга кереп китте. Кызлар төркеменнән дә шунда ук ике кыз аерылды, алар да колачларын еш-еш салып Исхак артыннан йөзә башладылар. Бераз эчкә кергәч кызларның берсе артта калды, икенчесе йөзә-йөзә шактый эчкә керде һәм чалкан ятып акрын гына агарга кереште. Исхак борылып чыкканда, кыз аңа эндәште:

— Ярдәм итегез әле, зинһар. Мин бик ардым.

Исхак аңа кулын сузды, икәүләшеп сүзсез генә йөзә башладылар.

Агым шактый көчле икән, кергән җирләреннән шактый арырак түбәндә ярга чыктылар.

Кыз яшькелт башлыгын салып чәч очларын сыга-сыга:

— Сез булмасагыз нишләр идем? — дип рәхмәт укыды. Чәчләре матур иде кызыйның, елкылдап тора, күзләре дә зәңгәр, сөрмәле, шуның өстенә алар ихлас беркатлылык белән текәлеп карыйлар иде. Исхак аның сүзләрен чынга алды һәм:

— Моннан болай алай эчкә кермәгез, — диде.

Бергәләп иптәшләре янына киттеләр.

— Сез коенырга еш йөрисезме? — диде кыз, егеттән күзен алмыйча.

— Кая ул! Сирәк-мирәк төшкәлибез.

— Нигә сирәк төшәсез? — диде кыз, үзенең беркатлы, хәйләсез күзләрен зур ачып. — Коену бик файдалы бит. Мин кыш көне дә һәркөн бассейнга йөрим.

— Җәй көне мин Казанда булмыйм да диярлек. Авылга кайтам. Ә анда су булган елны була, булмаса юк.

— Сез студентмыни? Кайда укыйсыз?

«Башланды допрос!» дип уйлады Исхак кызга хәтере калып. Кинәт аның исенә Мөнир Тазюков килеп төште.

— Авиация институтында, — диде ул, ялганлап.

— Әйбәт институт, — диде кыз, ачыктан-ачык куанып. — Егетләр өчен аннан да күркәм мәктәп юк. Ә мин медичка.

— Ничәнче курста?

— Өченчедә.

— Мин дә өченчедә бит!

Чишенгән урыннарына барып җиттеләр. Исхакның иптәшләре суга кереп тулганнар иде.

— Әйдәгез, безнең кызлар белән танышасызмы?

Исхак кып-кызыл булды.

— Рәхмәт, — дип мыгырданды. Кыз аның уңайсызлануын шундук сизенеп, аны артык кыстамады, үзе ялт кына иптәшләренә карап алды да:

— Алайса мине көтегез, бергә кайтабыз! — диде.

Исхакның иптәшләре берәм-берәм судан чыгып:

— Асыл кошны эләктереп кал! — фәлән-төгән дип, уенын-чынын бергә укмаштырып үгетләргә тотындылар.

Тәки бергә кайтырга туры килде!

Үзе белән бергә укучы кызлар белән бакчага чыгып утырганы бар аның. Якташ кызларын кинодан озата да барды. Ләкин менә шулай, икәүдән-икәү генә, якташ та, класслаш та түгел чибәр кыз белән көпә-көндез, бөтен шәһәр күз алдында ул беренче тапкыр бара...

Уңайсыз иде аңа, читен иде, аяк атлаулары үзгәрде, тыны буленде, теле тотлыкты, әллә ничә тапкыр кызның аягын авырттырып үк туфлясына басты. Шулай көч-хәл белән Маяковский урамына, медицина институтының торак йортына кайтып җиттеләр.

Танышкан иптәшләре, кызы булсын, егете булсын, иң әүвәл, Исхакның аз сүзлелегенә игътибар итәләр иде. Бу чибәр кызның аңа исе дә китмәде. Егет телен тешләп барганга да җәберсенми ул, тота да теләсә нәрсә хакында үзе сөйләргә ябыша, бик вак кебек күренгән нәрсәләрне дә үтә кызык, мавыктыргыч итеп сөйләп бирә иде. Аның сөйләшүендә мактануның, шапырынуның әсәре дә юк, һәрнәрсә чама белән генә телгә алына, бөтенесе дә үз урынында һәм җитәрлек дәрәҗәдә генә иде.

Ошады бит кыз Исхакка!

Моңарчы кызлар белән танышып йөрү түгел, алар турында телгә алырга да яратмаган, шәһәр кызларын күрсә җиде чакрым сыпырта торган юаш Исхакның үтә чибәр медичка белән танышуы студентлар арасында дан булды. Исхакның практик дәресләрдән соң учхоз хәтле җирдән Казанга кайтып-килеп йөрүен, юк акчасын бар итеп кызны киноларга чакыруын алар акылларына сыйдыра алмадылар:

— Ничек? Исхак Батуллинмы? Булмас ла...

— Һе, юаштан юан чыгар дигәннәр...

Кайбер мутрак егетләр бармак янадылар:

— Тымызык күлдә корт уйный!

Башта Исхак та үз-үзенә ышанмыйча йөрде. Ничек булды соң әле бу? Ничек? Кемгә кирәк иде мондый танышлык! Идел буе шәһәрләренең берсендә бердәнбер кыз булып иркә генә үскән кызга нигә студент-агроном?..

Бер-ике атна үткәч, егетләр Исхакны кыса башладылар:

— Давай, таныштыр кызың белән!

— Үзең генә медичкалар белән йөрмә.

Тик егет ашыкмады... Үзең дә чынлап торып танышырга өлгермәгәндә кая ул... Барган саен: «Моннан ары болай йөрү ярамый, барам да бөтенесен дә Идага сөйләп бирәм!» дип күңеленә ныгытып барды Исхак. Барды, ләкин кыз үзенең гадилеге, кече күңеллелеге белән аның телен бәйләде дә куйды...

Ида исә аны-моны һич уйламады, торган саен кыюрак була барды һәм бер көнне Исхакны үзләренең гомуми торагына танцага чакырды.

Егетнең коты алынды. Ничек? Медичкалар арасына танцагамы? Юньле-башлы костюмы да юк, танцасы да өчле тугызлы гына. Юк, юк, бара алмыйм, эше дә күп, укыйсы да бар... Имтиханнар бирү бик авыр...

Кыз, егетнең ай-ваена карамастан, чакыруында булды, иң гаҗәбе, егет җиңелдә, ризалыгын бирде.

Исхакны бөтен бүлмә белән әзерләделәр, киендерделәр...

— Кәҗә сукмагын салып кайт әле, без дә шунда йөри башларбыз. Аларда сылу кызлар буа буарлык!..

Тулай торакка килеп житкәч тә ул уйларына ирек биреп тормады, кыю гына эчкә керде. Ишек төбендә аны швейцар хатыннар туктаттылар. Калын пыялалы күзлек кигән юантык кына хатын егетнең студентлык билетын әйләндереп-әйләндереп карады да:

— Сез кем янына килдегез? — дип сорады.

— Егерме икенче бүлмәгә.

— Кызлар тора ич анда! — диде гаҗәпләнеп швейцар.

— Миңа Батыршина Ида кирәк, — диде егет, бурлаттай кызарып. Аның уч төбе кычыта башлады, яңаклары кызышты.

Юан хатын янындагы иптәшенә нидер пышылдады, Исхак баскычтан менә башлауга алар һич тәкәллефсез, тартынмыйча ук кычкырып сөйләшергә тотындылар:

— Ул да монда үрмәли бит, авыл бете! — диде җирәнеп кенә юантык хатын.

— Сельхоздан килеп йөрүче юк иде сыман. Бу малай тилергәнме әллә?

— Кызын әйт син аның, кызын! Шундый чибәр, затлы семья кызы, шыр җүләр икән!

Исхакның күңеленә кылт итеп Мөнир Тазюков килеп төште. Әүлия булган икән, төлке!..

Ул кызлар бүлмәсенә ишек шакырга онытып та барып керде. Кемдер куркыныч тавыш белән «ай!» дип кычкырды, башкалар куркышып ишеккә борылдылар. Ишек янына эленгән бәләкәй көзге каршысында бөтерелеп торган Ида егетне җиңеннән эләктереп коридорга алып чыкты:

— Син нәрсә? Кызлар алдында мине көлкегә калдырып йөрисеңме?

Кызның чырае ачулы иде.

— Гафу ит, Ида.

Кыз бераз тын алгач, егетне башыннан аягынача карап алды:

— Нәрсә булды? Күңелсез хәбәр алдыңмы?

— Сөйләшәсе сүз бар.

— Нинди сөйләшү? — дип көлде кыз, тәмам тынычланып. — Бүген якшәмбе, танцалар көне.

— Ида, — диде Исхак һаман түбәнгә карап. — Әллә танцага кермибезме дим?

— Нигә? Бии белмисеңме?

— Йөреп кенә килик. Һава да бик матур... Мондый көндә бүлмәдә утыру гөнаһ булыр.

Ида сабырсызланып уйга калды. Аның егет белән мактанасы килә иде. Тик Исхакка нидер булган ахры, бу килеш танцада да сынатыр гына. Шулай да бераз ялындырды кыз:

— Иптәшләр ни әйтер? — дигән булып ык-мык килеп торды.

Урамга чыктылар. Кызган асфальт исе килеп торган тротуарда халык мыж.

— Кая барабыз? Парккамы?

— Анда да кеше күптер, — диде Исхак.

Эзли торгач теләгәннәрен таптылар, аулак бер скверда буш эскәмия бар иде. Дөрес, аның бер аягы какшаган, эскәмия атынып-атынып куя, тик сак утырганда исән-имин ял итәрлек иде.

— Я, тыңлыйм, — диде кыз, коры гына.

— Ида, — диде Исхак, авыр сулап, — мин сиңа ялганладым.

— Кайчан?

— Беренче очрашканнан бирле алдап киләм.
— Ничек?
— Мин авиация институтында укымыйм, Ида.
— Кайда соң?
— Сельхозда.
Иданың озын керфекләре тетрәнеп алдылар, ул муенына салган шарфның чукларын йолыккалый башлады.
— Булса соң? Булса соң... — дип кабатлады бераздан.
— Шуның өчен оялам мин синнән, — диде егет, кинәт җиңеләеп.
— Тилекәй, — дип көлде кыз. Аның сөрмәле күзләре хәтәр генә яналар иде.
— Әйдә, танцага! — диде ул, ясалма җилбәзәклек белән.
Каян дәрт кергәндер, каян көч өстәлгәндер Исхакка, ул танцада оста биеп бөтен кызларның һушын алды. Ида да очып-очып кына йөрде. Тик ул нигәдер егетне иптәш кызлары белән таныштырырга онытты...
Өч көннән соң йомыш табып Исхак учхоздан тагын Казанга кайтты. Алар теге шигъриятле эскәмиядә очрашырга тиеш иделәр. Аерата дәрт, ашкыну белән көтте егет сөрмәле күзле Иданы... Озак көтте. Тик кыз килмәде. Телефон автоматтан кызның гомуми торагына шалтыратып карады. «Өйдә юк» диделәр. Аптырап Маяковский урамына үзе китте. Атылып икенче катка менде, ишекне шакыды һәм бүлмәгә керүгә иң элек Иданы күрде. Кыз әлеге дә баягы көзге каршысында ясанып-бизәнеп бөтерелә, аның кырында түземсезлек белән үкчәләрендә әйләнгәләп яшь кенә лейтенант көлемсерәп тора иде...
Иданың куркулы ак чыраена карап ул барын да аңлады...
Үз-үзен әрләп, үртәлеп гомуми торакка кайтып керсә, иптәшләре аңа:
— Батуллин, сиңа хат! — дип кычкырдылар.
— Кемнән? — диде ул.
Хат авылдан, әнисеннән иде.
Ул хатны да алмыйча түшәмгә карап озак кына чалкан ятты. Җәберләнгән, мыскылланган, тапталган иде егет күңеле. Иданың танца вакытында ялагайланулары, төчеләнүләре күз алдына килеп китте. Бөтенесе ялган, кылану гына булган икән.
— Ялган, ялган, ялган!
Барысы ялган, дөнья да, кешеләр дә, менә бу бүлмәләр дә, трамвайлар зыңгырдап уза торган урамнар да...
Менә бу хат кына чын...
Иң элек гадәттәгечә сәлам-каләмнәр киткән иде. Аннары өй эчендәге хәлләр, апаларыннан килгән хат-хәбәрләр, күрше-күкерт... Күктау авылының газетасы дип атый ул әнисенең хатларын...
Хатның иң соңындагы хәбәр аны сикереп торырга мәҗбүр итте: «Моратша Хөсәене өченче көн кәләш алып кайтты. Фазлый Фәрихәсен алып кайткан. Ике көн ду иттеләр, бүген менә туй итәләр, имеш... Безнең сыман сыңар ябалакны чакырып маташмадылар... Югыйсә, кода кешеләр иде дә бит...»
Ничек? Хөсәен өйләнгәнме?
Әле кайчан гына элеватор тавында «Мин аны яратам!» дип утырган кеше.
Исхак бик моңайган чакларында Хөсәенне исенә төшерә һәм «бу дөньяда без әле икәү» дип юанып та куя иде. Ә менә Хөсәен өйләнгән. Җирән чәчле, тәбәнәк кенә юантык Фәрихәне алган. Авыл ду килгән...
Дуслыкка, аның истәлегенә хыянәт иткән иде Хөсәен.
Юк, юк, Исхак гомерендә дә ул эшли алганны эшләмәс. Дус, сөйгән кешеңә хыянәт итәргә һич тә ярамый икән. Ярамый, ярамый! Үлсәң үл, яшәсәң яшә, әмма дус истәлегенә хыянәт итмә!

Ида белән танышып зур хата, ялгышлык эшләде ул. Шуның явыз үче булды аңа ул кыз...

Әйдә, Хөсәен өйләнсен! Туй итсен дә, ду килсен!

Ә ул берүзе калса да, Күктауда гына түгел, бөтен Рәчәйдә берүзе калса да...

Булсын!

## 12

Юк, Мөнир Тазюков дөресен әйтмәгән икән.

Беренче курстан ташлап качмады Исхак институтны, әйбәтләп кенә икенче курсны да тәмамлады, өченчене дә бетерде.

Ялгышты Мөнир Тазюков! Ида Батыршина егетне мәсхәрәләп, какшау аяклы эскәмиядә бакчада утыртып калдырса да, Исхак тәкате корып трамвай астына ташланмады. Элеккегә караганда сүзгә саранланды, кырысракка әйләнде.

Егетләр эшне сизенделәр, Исхактан егылып көлделәр.

Бусын ул Иданың хыянәтеннән дә авыррак кичерде.

Күңеленең иләс-миләслеген, канәгатьсезлеген ул ел да туган якларына кайтып җиңеләйтеп килә иде. Язгы-җәйге практикасыннан ул туп-туры Күктауга юнәлә, кайткан көнне үк ташын уттай кыздырып мунча яга, тирә-күршеләрдән буш таслар, мичкәләр җыеп дөнья хәтле су ташый. Аннары ике себерке тотып мунчага бара. Исхак чабынганда мунчада берәү дә чыдый алмый иде. Ул уттай кызу таш өстенә чиләге белән су коя, эсселектән чыдаша алмыйча яткан ташлар шарт та шорт ата-ата түшәмгә сикерешәләр, ап-ак пар бөтерелеп төрле якка ыргыла, ә Исхак алмаш-тилмәш ике себеркесенең яфрагы коелганчы чабына...

Мунчадан соң бер самовар чәйне эчеп бетерә дә эшкә ябыша.

Үҗәтләнеп, ныгытып, ярсып эшли ул.

Эше һәрвакыт муеннан була.

Ни дисәң дә ике йортка бер үзе...

Инеш буена төшеп тирес суга. Торф чыгарырга кул алмашка Кондыракка бара. Лапас-кураларның тишек-тошыгын сылап, өрлек-казыкларны ныгытып чыга. Агач сука тартып күрше-тирәгә бәрәңге ярышырга йөри. Я бик кич, я бик иртә урлап-урлап кына чокыр-чакыр буйларын, куентыкларны чабып кайта. Утын, печән авылның зур ихтыяҗлары!

Буш вакыт таба алса Хөсәеннәргә дә бара. Аларга керә дә тезләрен кочаклап сәкедә утыра. Сирәк-сирәк Хөсәенгә ияреп су буена төшә. Сыек кына барган кичке уенга читтән генә шаһит булып тора. Аның гадәтен белгән кызлар әйлән-бәйләнгә чакырмыйлар, үсмерләр читтә генә көләләр:

— Байгыш бит ул! Пешмәгән егет!

Күктауда аны иң нык көтеп торган кеше Нурулла була.

— Әйдүк, әйдүк, шәкерт тә житешеп кайткан икән. Кая, әнисе, казан ас, аш салып җибәр. Шәкерт өйрәсенең сыеклыгы дөньяга данлыклы, — дип егетне оялта-оялта түргә үк утырта. Хәерлебәнат кунак сые итеп бәрәңге боламыгы болгата, Нурулла чәй эчкәнне дә көтмичә сорашырга тотына.

— Ничек соң, апаем, дөньяда ни хәбәрләр бар? Мин монда газеталарны караштырып барам да, бер дә ачык кына итеп язмыйлар. Алга барабыз да алга барабыз, артка әйләнеп карарга вакыт та юк! Кайчан соң крестьянга бер-бер җиңеллек килеп җитәр икән? Төчкергән өчен дә налог каералар бит, апаем. Авыл бик бетәште, җир корыды... Җирнең аның үч алып куя торган гадәте дә бар. Түзмәс бит ул, бичаракай, берзаман безне адәм көлкесенә калдырыр... Кайчан шушы Гыйльми Салихы кебек бакыр бугазларны куу башланыр??! Кайчан бу җәһәннәм урманнарын сөреп ыргытырлар. Әгәренки хөкүмәт шушы җирләрдән үзенә тулаем файда ала торган булса, бездән ул кадәр үк сорамас

та иде бит. Ничек була соң инде бу? Сугыш беткәнгә ничә ел үтте, хәлләр бик хөртинкә ләбаса. Җир анакай үзенең хуҗаларын бер дә саклап алып кала алмаган микәнни?

Нәрсә әйтсен Исхак?

Үзенә күз текәп, җавап көтеп торган шушы гарип партизанның күңеленә хуш килерлек нинди хәбәрләр алып кайтты соң ул?..

— Менә... иртәгә... Кондыракта торф чыгара башлыйбыз...

Нурулла сизгер иде, ул егетнең нинди хәлдә калганын сизә һәм сүз тыгызлыгын акрын-акрын йомшата иде. Гәпне башка якка борып җибәрә, Исхак җиңел сулап куя.

— Ә-ә, алаймы, апаем? Украинага фәлән хәтле трактор җибәргәннәр дисенме? Безгә дә килеп җитәр әле... Кирәк, кирәк, апаем, Украина, Белоруссияләрне кортты инде ул немец мәлгунь!.. Тик чүтеки безгә дә бер елмаерга иде бит. Крестьянның күңеле катканны күтәргә ярамый. Күп бөгелгән агач шартлап сынып та куя ул!

Чәй эчелгәч, алар икәүләшеп өй буена чыгалар. Хәерлебәнат та сабыр гына аларга иярә. Елдан-ел биегәя, әрсезләнә, куера барган шайтан таягы урманына өчәүләшеп карап торалар. Урман тонык кына гөжли, ә зәп-зәңгәр күктә, җиргә төшәргә курыккан кебек тургайлар иңриләр.

— Чү, — ди Нурулла сыңар кулын сыңар күзе өстенә куеп, — ишетәсеңме, апаем? Бодай кыры өстендә тургайларның тавышы бөтенләй башка иде. Ишетәсеңме, болары ничек сузып-сузып җылыйлар?..

Озак карап торганнан соң Нурулланың күзеннән эре-эре яшь бөртекләре тәгәрәп чыгалар...

Ялгышты Мөнир Тазюков! Үзен шушы кырлар, шушы нужа көтеп торганын елдан-ел яхшырак белсә дә, Исхак институттан китмәде. Дөрес күрәзәлек итмәде юрист!

Ул үзе әллә кайчан укып бетергәндер инде. Мәктәбен ике еллык дигән иде бит. Кайда үскән казларның ботын кимереп, илнең кайсы почмагына оя корды икән?..

Дүртенче курс белән дә хушлашты Исхак.

Бу курстан соң аларның иң җитди, иң авыр практикалары уза. Студентлар шул практикадан чын агроном булып кайталар. Кемнең нәрсәгә булдыклы икәнен шушы ел күрсәтә.

Кар китәр-китмәстә Исхак әнисеннән хат алды. Сискәндерде бу хат егетне...

«Әллә ничек билем дә сызлап, күз алларым караңгыланып тора. Төнәген иртән коедан су алганда егылып та киттем... Гел ятып торам, сине төшемдә күрәм, балакаем...»

Ул сорашып-белешеп торды да район үзәгенә баручы беренче самолетка утырып Күктауга кайтып төште.

Әнисенең чире дә ул кадәр үк булмаган икән, сагынып, борлыгып-каңгырып тордым да кинәтрәк язып ташладым, дигән булды. Иң зур яңалыкны Исхак әнисеннән телдән ишетте:

— Хөсәенне колхоз председателе итеп куйдылар!

Нурулланың авызы колакта иде:

— Чукындырдык теге мөртәтне, — диде ул, Исхакны күрүгә.

Хәерлебәнат юеш кулларын чиста тастымал белән сөртә-сөртә басынкы гына күрешә дә:

— Алай ук каты әйтмә, әтисе. Вакыты җиткәндер, — диде.

Нурулла аның сүзләрен ошатмады:

— Нигә аны майлап-җайлап төчеләнеп сөйләргә? Ирләр сүзе көмеш кебек чыңгырдаган чын булырга тиеш. Ир сүзе — ирек! Районнан килгән вәкил Салихны төшертмәскә ничек тырышты? Күп еллар эшләгән, тәҗрибәле кадр, янәсе. Авыл хуҗалыгын белә, житәкче эштә кулы ныгыган. Фәлән-фәсхет... Сикереп тордым да «Каян беләсез сез аны?»

дип кычкырдым. Беләм бит, вәкил дигәне дә аның май заводы директоры... Ике тапкыр сүз алып сөйләдем. Башта Гыйльми Салихының яраннары: «Синең эш ипине тирескә әйләндереп яту!» дип сүз бирми маташтылар. Апаңны өйгә йөгерттем. Алып кил әле, энисе, җәлт кенә Кызыл Йолдызны! Аңа да сәндерәдән төшәргә бик вакыт! Күкрәккә тактым да сәхнәгә мендем. Кызыл партизанга сүз бирмәскә не смеете, мәйтәм! Гыйльми Салихы да сыңар медален асып килгән булган. Кызыл Йолдызны сатып алгансың син, исерекбаш, ди бу! Кычкырына. Аны тыңлаучы юк, бөтен кеше миңа караган. Житәр, мәйтәм, илне имәр өчен генә кеше өстеннән начальник булулар. Вәкил кычкыра, Салих кыңгырау шалтырата. Колак та салмыйм тегеләргә. Сөйләп бетердем, халык тып-тын утыра. Әй, менеп киттеләр берзаман чылбырдай тезелеп теге мөртәтнең яраннары, әй сайрыйлар, әй мактыйлар, оҗмах кошы ясадылар да куйдылар. Күрдеңме, ди, вәкил кырык резьбалы муенын бора-бора. Демократия сине якламый, ди. Их, мәйтәм, булмады бу. Тагын атылып мендем сәхнәләренә. Кешеләрнең күзләренә төртә-төртә Салихның авылга ясаган зыяннарын санап күрсәттем. Жүләр сез, дим, күзегезгә пес итәләр, ә сез куанышып «ходай яңгыр бирде» дип утырасыз. Кыздым, тузындым, ахырда кузгаттым халыкны...

— Үзең дә өч көн сөйләшә алмас булып карлыгып йөрдең анналы, — дип шелтәләде Хәерлебанат.

Нурулла йөткерә-йөткерә кече яктагы чиләктән су барып эчте:

— Кирәк чакта тамак кына түгел, баш китсен! Риза-бәхил! Хөсәен яшь кеше, ару егет, күсе булып авылны кимереп ятмас. Һай, кайчан шушы Имәнле очларын сөреп ыргытырлар инде...

Кичке караңгы белән, Хөсәен Исхакларга килеп житте.

— Кайттыңмы?

— Күрәсең.

— Юллар бик начармы?

— Тәпиләргә була.

— Исхак, — диде Хөсәен, атна буе кырылмаган куе, кара сакалын тырмап,— әниеңнең авырып торуы бер сәбәп кенә. Сине, асылда, мин чакырткан идем.

Исхакның кашлары җыерылды.

— Син быел яздан ук практикага китәбез дигән идең. Үзең беләсең, безнең агроном да, чурт та юк. Кайт син безгә агроном булып! Минем белем ягы бик такыр...

Мәһибәдәр кече якта улының керләрен уудан туктап, кулларын алъяпкыч астына яшереп олы якка чыкты.

— Безгә андый олы эшне тапшырмыйлар бит. Тәҗрибәле агроном янына гына җибәрәләр.

— Каян табасың аның андыен? МТСта баш агроном бар, ну ул бит безгә кунак булып кына килә!

— Син кызма әле алай.

— Нибуч кызарсың! Өч-дүрт көн аяк өсте йоклап йөрим. Чәчүгә төшәргә вакыт, келәтләрдә орлык заты юк. Утыр да җыла.

— Җылашырга мине дә чакырырга булдыңмы?

— Орлык табу минем маза! Син кайт кына. Кирәк икән институтыңа пичәтле кәгазь язам. Райкомнан да язу алырга була.

Ошады бу тәкъдим Исхакка.

— Сөйләшеп карармын, — диде ул.

Мичтән тәмле бәрәңге исе чыгып таралды. Шуны тозга мана-мана иписез, шикәрсез генә чөгендер чәе эчтеләр.

Исхак Казанга кайту белән декан янына керде. Декан шундук аңлап алып, егетне ярты сүздә бүлде:

— Принципта мин каршы түгел. Тик сез фәлән районга билгелән-

гән инде. Әгәр авылыгыздан ашыгыч запрос җибәрсәләр, уйлап карарбыз, — диде.

Егет кесәсеннән пичәтле кәгазен чыгарып ук салды.

Май бәйрәменә Исхак колхозга кайтып та төште.

МТСның баш агрономы аны колхоз идарәсенә алып килде. Калдырып киткәндә бер генә сүз әйтте:

— Эшлим дисәң авызыңны ачып утырма. Райком ягыннан нинди җил исүен сагала. Җиле дә, болыты да, яңгыры да шуннан килер. Яшенле давылы гына булмасын. Анысыннан саклан. Күтәреп алып китәр дә дөмбердәтеп җиргә бәрер...

— Болай яуган гади яңгырга игътибар итмәгәндә дә буламыни? — дип шаяртырга теләде Исхак. Тик баш агроном аны аңламады, ул бик күптәннән елмаюны оныткан кеше иде.

Моңарчы болай гына Кыяр таулары, Кырынды өсләре, Сарык юллары булып йөргән кырлар-басулар Исхак өчен кинәт кенә чәчүлекләргә, көтүлекләргә, сазламыкларга әйләнделәр, шакмакларга-гектарларга бүленделәр.

Тик мондагы эш, колхоздагы хәлләр алар укыган китаплардан никадәрле ерак! Туфракларның нинди икәнлеген беркайда да язып беркетмәгәннәр, чәчү әйләнешенең планнары юк. Барлы-юклы тиресне шунда, фермалар, кардалар янындагы чокырга гына түгеп килгәннәр. (Бәләкәй чана тартып еракка илтеп йөри алмассың!)

Хөсәен белән Исхак үйга калдылар.

Ул беренче көннәр, беренче адымнар, беренче планнар... Авылның бөтен кайгы-хәсрәте, нужасы Исхак өстенә кара болыт булып ябырылды...

МТСтан: «Трактор көтмәгез. Булса да ике-өч көнгә генә эләгер. Атлардан максималь файдаланыгыз. Ат җитмәгән урыннарда мөгезле эре терлек җигегез. Алар да җитмәсә, кул белән казыгыз», дип кисәттеләр.

Исхак көне буе чабып арса да, кичләрен Нуруллаларга кагылып чыгарга вакыт таба. Төннең кайсы вакытында кермәсен, Нурулла аны йокламыйча каршы ала, өйдә генә ятса да барын белеп, төшенеп тора иде.


— Орлык җитмиме? Трактор бирмиләрме? Чәчкеч ремонтларга күмер юкмы? Түзәргә туры килер шул, оланнар... Кем дә булса берәү ут сызыгын йөгереп узарга, үз башын иң беренчеләрдән ядрә астына куярга тиеш. Егетлек әнә шул инде. Гыйльми мөртәтләре йодрык белән төеп япкан халыкның авызын киләшчә белән түгел, бодай калачы белән ачыгыз. Сүз әйтергә куркып торган, үз күләгәләреннән өркүче калтыравык затлар түгел ич алар, игенчеләр! Тормыш тоткалары... Һай игенченең изгелекләре!.. Тырышыгыз, егетләр, тырышыгыз... Ирлек — тырышлык ул. Ил алдында да, җир алдында да йөзебез ак булсын.

Күп җәфалардан, күп сөйләшүләрдән, ялынулардан, ялварулардан, куркытулардан соң гына МТСтан трактор килде. Тракторчыга бәрән суйдылар, килүенә эссе мунча яктылар, иң чиста өйгә фатир төшерделәр. Сөрсен генә, эшләсен генә...

Имәнле очына башлаш калдау җиргә — шайтан таягы урманына бөтен авыл чыкты. Карты-корысы, бала-чагасы да калмады. Чалгылар, көрәкләр, тырмалар, хәтта очлы таяклар да ходка китте. Бер трактор, алты ат, йөзәрләгән кеше өч көн, өч төн тынмадылар. Сөрделәр, казыдылар, йолыктылар, тырмадылар. Кишәрлек артыннан кишәрлек шайтан таягы урманы ава торды. Кура-мазарны шунда җир өстендә яндырдылар.

— Сездә нәрсә яна? — дип утызар чакрым ераклыктагы авыллардан телефон шалтыратып сорадылар.

— Нужа яна, нужа! — дип җавап бирде Хөсәен.



Чәчүчеләр килеп беренче эзне сызу белән басуга чатанлый-чатанлый Нурулла килеп керде. Ул муенына тубал аскан, тубалында орлык белән бергә бер дистә күкәй иде.

— Бодай — тереклек тоткасы — ишелеп үссен! Тәгәри-тәгәри урырлык, бил бөгеп җыярлык булсын! Туфрак басмасын, җил алмасын, хәере белән, игелеге белән. Туклык еллар килсен, крестьянның ашы куе, өреле булсын... Ел килсен, җил килсен, яңгыр сипсен. Иплэп, иплэп, менә шулай, менә шулай!

Шайтан таякларының янып күккә очканын күреп карчык-корчыклар җиргә ауный-ауный еладылар:

— Бу көннәрне дә исән-амән күреребез бар икән, ярабби. Рәхмәтләр яусын сиңа, ходаем... Бу көннәрне дә күреребез бар икән!

Трактор җирне районга бара торган юлга буйлай итеп сөргән иде, Исхак чәчкечне агротехника кагыйдәләренә туры китереп, сөргәнгә аркылы йөрттерде.

— Ял иткән кыр, бәрәкәте белән уңсын инде.

— Орлыгы ваграк ваграгын, әмма тук, ядрә кебек...

Егерме сигезенче май төнендә болытлар куерды. Чәчүдән соң җир өстенә беренче тамчылар коелды. Хөсәен белән Исхак яшелчә бакчасында кайнашалар иде, түзмәделәр, кырга киттеләр. Кыр башында ялан баш, ялан өс Нурулла йөри иде. Ул сыңар учы белән яңгыр тамчыларын тота да сирәк чәчләре сыланган маңгаен юешли, үзе балалар кебек кычкырып-кычкырып көлә, куана.

— Бал ява бит, егетләр, бал ява. Туклык ява, тормыш ява... Ай, табигатьнең кодрәтләре... Заказ бирсәң дә болай вакытлы булмас. Бодай күпереп кенә чыга инде...

Болытлар куерып тоташка әйләнделәр, салындылар һәм яңгыр кыйгачлап коеп ява башлады.

— Безгә кирәгез, безгә! Шыкланып торыгыз!

Хөсәен белән Исхак лапас астына кереп берәрне көйрәттеләр дә су үтә башлагач, кәнсәләргә йөгерделәр. Хәерлебәнат болдырга чыгып кычкырып калды:

— Самоварым кайнап чыкты!

Яңгыр бертуктаусыз төне буе яуды. Бодай басуына күләвекләр җыелды, ерганаклар әрле-бирле тулганып, күбекләнеп бураэна араларында үзләренә эз саптылар. Таң алдыннан яңгыр туктады, ялтырап кояш чыкты. Чыкты да өч көн рәттән көйдереп-көйдереп кыздырды. Өч көн туктаусыз эссе җил исеп торды. Зәңгәрләнеп торган басу өстендә тургайлар аяусыз чырылдадылар. Күз текәп тилмереп, бөтен авыл көтсә дә, бодай тишелмәде. Басу өсте такталанып каткан иде.

Өченче көнне кич белән авылга вәкил килеп төште.

Исхак басудан бик пошынып кайтып идарәгә барып кына кергән иде, өстәл артында утырган Мөнир Тазюковны күргәч бусага янында туктап калды. Мөнирнең өстендә әйбәт зәңгәрсу костюм, чырае тук, кыяфәте олысымак иде.

— Менә безнең практикант, яшь агроном Исхак Батуллин,— дип таныштырды Хөсәен.

Тазюков хәтерләргә тырышып нидер уйлады да елмаеп:

— Без танышлар,— дип кулын сузды.

— Сез ничек бу якларга килеп чыктыгыз?— дип сорады Исхак дымлы, йомшак кулны яратмыйча гына кысып.

— Иптәш Тазюков безгә районнан җибәрелгән вәкил,— дип аңлатты Хөсәен. Үзе ым белән генә: «Я, ничек?» дип сорады. Исхак башын чайкады: «Начар!»

Вәкил нидер сөйли иде, Исхак аның сүзен бүлдереп дорфа гына:

— Бодай тишелми әле менә,— дип куйды.

— Ничек тишелми? Орлык начармы?

— Яңгыр катырак явып китте дә шуннан тоташ җил, эссе башланды. Җир катты,— дип төшендереп бирде Хөсәен.

— Тишелер,— диде нигәдер көлемсерәп Тазюков.— Сез карагыз аны, килгән көннән үк миңа казус белли, ягъни сугышырга сәбәп чыгарып ятмагыз. Мин районда да сугышып туйган. Сезгә ял итәргә килдем.

Ул шунда ук үзе урнашачак фатир турында сораша башлады.

Хөсәен аны фатирга алып китте. Ишек төбенә җиткәч, Тазюков тәмле исле папирос кабызды һәм кашларын, иренен берьюлы хәрәкәтләндереп Исхакка карап елмайды:

— Менә тагын очраштык... Укулар ничек бара соң?

— Бодай тишелми әле, бодай!— диде өметсезләнеп Исхак.

Тазюков иңбашларын сикертеп кенә куйды.

Исхак тагын кырга китте. Эссе мич башы кебек кырда сирәк-мирәк билчәннәр, эт эчәгеләре генә тишелеп маташа иде. Иелә-иелә эзләсә дә, ул зәгыйфь, яшел шытымнарны күрә алмады. Җирне биш-ун урыннан актарып карады. Бодай борынлаган, тик зәгыйфь үсентеләрдә җар-тактаны җимерерлек көч юк иде...

Иртән тагын шунда... Иелгән башлар, зур ачылган күзләр...

— Юкмы?— ди Хөсәен.

— Юк,— ди Исхак, учында коп-коры туфракны учлап.— Хәзер бу тактада вак-вак тишекләр ясалган. Дым минуты, секунды белән туп-туры һавага очып тора. Бодай тишелә алмас.

— Нишләргә соң?

— Тырмаларга кирәк.

Бу сүзне шыпырт кына алар янына килеп җиткән Нурулла әйтте. Хөсәен белән Исхак борылып карадылар.

— Ничек тырмалыйсың аны, Нурулла абый? Орлыкны өскә чыгарып, тамырларын өзеп бетерәчәк бит ул аның.

— Нурулла абый дөрес әйтә,— дип җупләде Исхак.— Тырмаларга, тактаны ватарга кирәк.

Киңәш белән Тазюков янына бардылар. Мөнир үзе дә озакламый басуга килде, акрын гына тарантастан төште, иелеп бармак очлары белән җирне тырнап карады.

— Ашыкмый торыгыз,— диде ул.— Бер-ике көн көтегез. Үсемлекнең көчен барыгыз да беләсез. Асфальт ташларны тишеп чыга ул. Көн яктысына тартыла.

Кич белән Исхак Хөсәеннәргә китте.

— Бодай әрәм була!

Иртән иртүк бар булган атларны җыеп тырмага чыгардылар, кул тырмалары белән хатын-кыз Имәнле очына җыелды. Тырмачы малайларның атларны каулап җир өстенә кереп китүләре булды, юрттырып Тазюков килеп җитте.

— Нәрсә эшлисез? — диде ул, тыныч кына.

— Тырмалыйбыз, — диде Хөсәен. — Үзем җавап бирермен.

Кич белән идарәдә ашыгыч җыелыш җыелды.

— Авыл хуҗалыгын текә күтәрү өчен, дөрес, акыллы житәкчелек кирәк, — дип башлады сүзен Тазюков. — Монда ике уйлау булырга мөмкин түгел. Закон барыбыз өчен дә бер. Дөресме ул, ялгышмы, анысын беребезнең дә тикшереп торырга хакы юк. Менә бирелә яшь агроном, практикант утыра. Фәнчә әйтеп күрсәтсен әле ул: чәчелгән бодай кырын бер атнадан соң тырмаларга ярыймы, юкмы?

Идарә членнары (ферма мөдире, тавык караучы Ниса апа, янгын сараенда эшләүче Гыйльметдин бабай һ. б.) башларын түбән иеп тын гына утырдылар. Исхак урыныннан торды да:

— Хөкем чыгарырга ашыкмыйк, бодайның тишелеп чыкканын көтик, — диде.

— Юк,— диде Тазюков.— Безне нәтиҗә түгел, безне бүгенге көн, хәрәкәт үзе кызыксындыра! Дөрес эшләдеме Моратшин? Хата эшләде. Колхоз председателен урыныннан алырга, ә практикантның политик һәм фәнни ялгышлары турында институтка хәбәр итәргә кирәк. Карарбыз, диплом бирерләрме аңа анда, әллә кәҗә билеты тоттырырлармы. Безнең ялгышырга хакыбыз юк, безнең юлыбыз ачык, барыр юлыбыз бер генә!

Исхак идарә членнары да сүзгә катышыр дип көткән иде, алар нидер ык-мык килеп мөгердәшteләр дә сүзне МТСның баш агрономы алды:

— Иптәш Тазюков хак әйтте. Безнең ялгыш атларга хакыбыз юк. Чәчүлек өстенә авыр, тимер тырмалар кертү наданлык. Наданлык кына түгел, җинаять. Тырмалаган тәкъдирдә дә бүрәнәләргә сирәк-сирәк кадаклар кагып җирнең өске ягын гына бераз ерттырып чыгарга иде.

— Тырмаламаган булсак, бөтен уңыш әрәм була иде. Болай ичмасам өмет бар. Тишелеп чыкканын көтик, — диде Исхак киреләнеп.

Тазюков карар чыгарырга ук базмады. Идарә членнарының сүзсез генә каш астыннан карап утырулары аны бераз шикләндерде. Бер-ике көн көтәргә булдылар.

Бер көн үтүгә кыр өстендә нәни генә яшькелт кыяклар күренде, ике көннән алар ишәйделәр, кыр ягымлы төс алды. Исхак санап чыгарды һәм МТСка хәбәр итте: тишелеш әйбәт!

Атна узар-узмаста МТС зонасына кергән авыллардан Күктау колхозында иң әйбәт тишелеш икәнлеге ачыкланды.

Исхакның түбәсе күккә тиде.

Мөнир Тазюковны алай гына егарлык түгел иде:

— Хата сүз сөйлисез, иптәш Батуллин,— диде ул.— Бер колхозда тишелешнең әйбәт булуы безнең экономиканы хәл итми. Ә бер колхозда закон бозуга юл кую — безнең эчке тәртипне тарката! Шуның өчен Моратшин гаепле дә!..

Бәхетсезлеккә каршы, тәҗрибәсез чәчүчеләр бодай басуында байтак кына чи урыннар калдырганнар иде.

— Район үзәгеннән килә торган юл буенда ни кыландыгыз сез? Адым саен казус белли! Чарасын күрегез! — дип кызды Тазюков.

Печәнгә төшкәндә халык бик өзелә дип Хөсәен биш-алты центнер бодай калдырткан иде. Елый-елый диярлек чи калган урыннарга шуны сибеп чыктылар.

Һавалар корыга китте дә соң чәчелгән орлык бөтенләй шытым бирмәде.

Ах, ул еллар, ул еллар! Исхакның гомергә дә онытасы юк сугыштан соңгы ул елларны. Кемгә генә барып кагылма — төзәлеп бетмәгән күңел ярасы. Кемгә генә барып кермә — ачлык, ялангачлык... Кече якка керерлек түгел, казанда чөгендер яфрагы катнаш яшь бәрәңге сабагы кайный...

Печән өстендә Хөсәен:

— Их, теге бодай булса, ичмасам бер-ике көн эшчеләремне туя ашатыр идем, — дип ачыргаланды.

Кырынды өстендә арыш агара башлау белән, Исхак Хөсәенгә кинәш белән керде.

— Хөсәен, беренче ашлыкны дәүләткә тапшырыйк та, шунда ук колхозчыларга аванс чыгарыйк.

Яшь председатель аптырап авыр сулады.

— Идарә членнары белән сөйләшик. Юкса минем муенны сындырырлар, — диде ул. Район прокуроры Тазюковны нindидер эш белән өлкәгә чакырып алганнар иде. Идарәдә бирик дип тә, бирмик дип тә бер сүзгә килә алмадылар.

— Нужа икәнлегебезне беләсең, Хөсәен, үзең баш, үзең чамала инде, — диделәр анда.

Тәвәккәлләделәр: урып-сугып алты атка төяп олауларны Чаллыга озаттылар да җан башы исәбеннән һәр хуҗалыкка биш-алты кило арыш бүлеп бирделәр. Тегермәнгә барып йөрер түземнәре калмаган иде кешеләрнең, чормаларда кыш буе күгәреп яткан ярма ташлары худка китте, ярма ташы булмаганнар арышны көйледә төйделәр. Бөтка-лар, өйрәләр пеште. Күе өйрәләр! Ул көнне Күктауда бәйрәм булды.

Гыйльми Салихы тирән чокыр янына чыгып вәкилнең районнан килүен ике көн көтте. Башка вакытларда да ул Тазюковны шунда көтеп ала, чышан-пышан гына яңалыкларны түгеп аудара да үзе әллә кайлардан урап кына авылга кайтып керә иде.

Бүген ул Тазюков белән тарантас түренә утырып кайтты. Берәүдән дә курыкмый иде ул бүген. Кемнән курыксын? Хөсәен үзе утырган ботакны үзе кисеп төшерде, бетте...

Шуңа күрә Гыйльми Салихы вәкил күренүгә үк сүзне текә башлады:

— Тегеләр хөкүмәткә каршы эш оештырдылар.

— Ну-у?

— Дәүләткә дигән икмәкне әрәм-шәрәм итәләр, таркаталар.

Тазюков Имәнле очына юрттырып, кара коелып барып керде. Гыйльми Салихы йөгерә-чаба кешеләрне җыелышка куарга тотынды.

Кешеләр бик озак җыелмый тордылар. Инде Хөсәен өй борынча йөреп чыккач кына, берән-сәрән килгәли башладылар. Җыелышта бер мәсьәлә генә куелды:

«Колхоз председателе Хөсәен Моратшинның җинаять эшләре».

Иң элек Тазюков речь белән чыкты. Кайнарланып, дәртләнеп сөйләде ул. Чирек сәгатьне халыкара хәлләргә багышлады, аннан соң гына ил эчендә бара торган көрәшкә күчте. Хөсәеннең хуҗалыкны эчтән таркатуын, партиягә һәм халыкка турыдан-туры каршы баруын ышандырырлык дәлилләр белән сурәтләп бирде. Клубтагылар зәһәр төтен чыгара торган түтәл тәмәкеләрен пыскытып шым гына тыңлап утырдылар. Хатын-кызлар арасында хисләнеп күз яшен сөртеп алучылар да булды.

Һәйбәт, үткәзеп сөйли иде Тазюков!

Җыелышны да Тазюков үзе алып барды. Гәрчә үзенең чыгышыннан соң Моратшинның язмышы хәл ителгән дип санаса да, ул:

— Кем сүз алырга тели? — дип сорамыйча булдыра алмады.

Берәү дә кул күтәрмәде.

Исхак иң арттагы рәттә Нурулла белән бергә утыра иде. Иелгән, сүзсез-өнсез гәүдәләргә карап аның коты чыкты.

— Я, кемнең сүзе бар? Сөйләгез, сөйләгез! Һәркемгә ирек.

Тазюков шулай дип әйтүгә фуражкасын учында изеп иң алдагы рәттә утырган Гыйльми Салихы чәчрәп чыкты да председательне тетә башлады.

Исхак көч-хәл белән түзеп утыра, ул туктаусыз аскы иренен тешли, йодрыкларын йомарлый, күзләреннән ут чәчә иде. Аның талпынып-талпынып куюын күргән Нурулла:

— Сабыр ит, апаем, сабыр. Көт бераз. Югыйсә, үзеңне тотып ашарлар, — дип үгетләде.

Исхак үзенең уң ягында баш иеп, күмелеп утырган ферма мөдиренә:

— Нигә дәшмисез? Нигә Хөсәенне якламыйсыз? — дип эндәште.

— Батып баручыга салам бөртеге ярдәм итми бит, апаем. Аны дөбердәтеп урыныннан төшерәчәкләр, күрәсең ич. Ә минем яшисем бар әле, алты баламның тамагын туйдырасым бар, — дип пышылдады.

Синең тамагың өчен дә, синең алты balаң өчен дә тырышты лабаса Хөсәен! Син шуны да күрмәс хәлгә килдеңмени? Ялгыз-ялгыз сөйләшкәндә кеше төсле генә уй да йөртәсең, нигә кеше арасында куянга әвереләсең син, мөдир, алты бала атасы!..

— Түз, апаем, түз, — дип ялына иде Нурулла үзе дә тик кенә утыра алмыйча. Әллә үзен үгетли, әллә егетне, бусын бик аңлап та булмый иде.

— Әрәм итәләр бит әйбәт кешене!

Гыйльми Салихы һаман сөйли иде.

Нурулла кинәт бүреген идәнгә бәрде дә:

— Авылдашлар, ышанмагыз бу кешегә! — дип акырды.

Гыйльми Салихы ялт итеп күтәрелеп карады, чырае каралды, ул зәһәр, янаулы тавыш белән:

— Нәрсә бугазыңны киерәсең? Әллә мин синең бетле сарыгыңны урлап суйганмы? — дип сорады.

Бик таныш тавыш иде бу Нуруллага... Кайчандыр, күп еллар элек, караңгы төндә, келәтләр янында нәкъ шушы тавыш шулай ук янап кычкырган иде бит...

Нурулла сыңар кулын алгарак сузып, күзе һәм күз урыны белән дәһшәтле карап сәхнәгә узды. Аның агач аягы шыгыр-шыгыр килеп зарланып барды.

— Авылдашлар, нишләдегез сез?.. Ни булды сезгә? Нигә күзегезне күтәрергә куркып утырасыз? — Ул Тазюковка һәм Гыйльми Салихына төртеп-төртеп күрсәтте. — Сезнең кайгыгызны уртак итәрлек кешеләрме алар? Сезнең кайгыгыз — ил кайгысы лабаса! Сез тук булсагыз — ил дә тук. Сез көр күңелле булсагыз — ил дә шат. Дәүләткә икмәк, диләр. Дәүләт сез ич инде! Эшчеләр һәм крестьяннар дәүләтендә яшибез бит! Сез барыгыз да шул дәүләт кешеләре. Хөсәен дә, әнә Хифасулла карт та, башкалар да. Нигә Хөсәенне Гыйльми Салихына өзгәләргә бирәсез?

Тазюков ап-ак агарынып сикереп торды:

— Молчать!

Исхак та аягүрә басты, ул клубтагылар атылышып сәхнәгә менәрләр, Нурулланы яклап күмәкләшеп кычкырырлар дип көтте. Ләкин зал кузгалмады, зал тып-тын иде. Ишек төбе ягына гына идәнгә чүгәләгән Хифасулла карт буыла-буыла ютәлли, аның кырма кара сакалы мәзәк кенә селкенә иде...

Тазюковның кычкыруын үзенчә аңлаган Гыйльми Салихы Нурулланың аягыннан аска тарта башлады, шулчак тегесе агач аягы белән Салихның маңгаена китереп төртте...

Моратшинны урыныннан алдылар.

Ике-өч көн үтүгә, районнан ябык машина килеп, Нурулланы утыртып алып киттеләр. Гыйльми Салихы, тагын бер-ике кеше прокуратура-

га шаһит булып йөри икән дигән имеш-мимешләр таралды. Исхак Нуруллланы эзләп районга барды. Казанга озатылды диделәр.

Ул туп-туры Хөсәеннәргә кайтып керде.

Кич иде. Яңа гына кырдан салам өюдән кайткан Хөсәен гәләфи чалбар киеп, ялан аяк, ялан өс, ялан баш ишек алдында ак комганнан пырхылдый-пырхылдый юына иде.

— Хөсәен, — диде Исхак, каты итеп. — Иртәгә районга барабыз.

— Нәрсә кырырбыз анда? — диде Хөсәен, читәнгә эленгән киң, матур чигелгән сөлгегә үренеп.

— Алайса әйдә өлкәгә!

— Анда барып нәрсә кыра алырбыз? Сиңа ышанырлармы, миңамы? Әллә прокурор Тазюковкамы? Монда синең сүз дә, минем сүз дә үтәчәк түгел. Инде председатель кемгә кирәк, шул йөрсен. Миңа житте, — диде Хөсәен сүрән генә.

Исхак кырт борылып чыгып китте. Хөсәеннәрнең капкалары шартлап ябылып калды.

Димәк, берегез дә йөрмисез инде?

Берегезгә дә кирәк түгелме?

Ярар!..

Ул ашыгып өенә кайтты. Җыена башлады. Әнкәсенә дә аңлатып тормады. Таң атканын да көтмәде, көнчыгыш як бераз агара башлау белән юлга чыкты. Маһибәдәр җир үкереп капка баганасын кочаклап калды...

Казанга кайткан көнне үк, ул декан янына керде һәм барын да сөйләп бирде. Декан тәҗрибәле, акыллы кеше иде. Ул егетнең тырышлыгын, дөреслеген, тугрылыгын белә иде. Аны-моны әйтмәде:

— Ярар, әгәр шулай тыныч кына үтсә, безгә дә әйбәтрәк булыр, — дип кенә куйды.

Декан яныннан чыккач та, Исхак Черек күлгә китте. Бәләкәй тәрәзәләргә шакып, сорашып йөрде. «Бездә андый кеше юк», диделәр. Бер барды, ике барды, өч. «Судка районына озатылды», диделәр. Бер көнне аны дежурный бүлмәсенә чакырып керттеләр. Анда яшь кенә көяз лейтенант утыра иде.

— Кеме буласыз сез ул кешенең? Улымы?

— Юк.

— Туганымы?

— Түгел.

— Кеме соң?

— Дусты.

Лейтенант бер як яңагы белән генә көлеп куйды.

— Сезнең дустыгыз, — диде ул, басым ясап, җәмәгать урынында хулиганлык ясаганы өчен биш елга хөкем ителде.

Исхакның йөрәге өзелеп төшкән кебек булды:

— Ничек? Ул бит... әйбәт кеше! Орденлы партизан! Кайда ул хәзер?

— Тамбов бүреләре янында.

Ике ай үтәр-үтмәстә Исхак сары кәгазьгә тырмаланган хат алды. Хат Казагыстаннан, Нурулладан иде.

Вокзалга көнлекче булып ялланып эшләп йөрүне моңарчы чит итеп йөргән Исхак шул көнне үк эш эзләп китте. Унбиш көн үткәч бәләкәй янчык белән түтәл тәмәкесе, карточкага алган дүрт йөз грамм шикәр һәм башка вак-төякләр тутырып Казагыстанга беренче посылкасын салды...

Хәзер ул теше-тырнагы белән авылга китмәскә тырыша иде. Ничек кенә булса да, нинди сәбәпләр табып булса да шәһәрдә калырга кирәк!.. Авылны, аның кешеләрен, аларның өметсезлектә иелгән башларын, куркынган күз карашларын күрмәс өчен ул әллә ниләр бирер иде

хәзер калада калырга, калада югалырга, беркем сине белмәсен, эшлә дә эшлә!..

Күп йөри торгач, декан ярдәмендә, ул авыл хуҗалыгы министрлыгына эшкә урнашты.

Шуннан бирле Куктау авылына бер тапкыр да кайтмады...

13

«Яндык» дип Маһибәдәрдән шөбһәле телеграмма алган минутта ук Исхакның карары әзер иде инде: әнкәсенең соңгы тереге дә бетте, инде карыша алмас, аны тизрәк шәһәргә алдырырга кирәк!

Ниһаять, карчыкның кирелеге җиңелде, ике арада шактый озакка сузылган бәхәскә ут чик куйды.

Һәрнәрсәнең бер начар ягы, бер әйбәт ягы була.

Исхакның уе хәтта әнә шуңа барып житте. Өйләре януга көенмәде ул, исе дә китмәде, чакырып телеграмма сугарга дип почтага керде. Телеграфка кергәч кинәт ниятен үзгәртте, «үзем кайтам» дип хәбәр салды.

Ни дисәң дә, әнисе алай ордым-бәрдем кыйлана торган кеше түгел, ансат кына ризалашмас, сүз ике булмасын өчен, иң яхшысы, үзенә кайтып килергә кирәк.

Самолетка утырып очарга мөмкин булса да, сәфәре ялга охшасын дип, ул пароходка утырып китте. Пристаньга килеп төшкәндә дә, машина әрҗәсендә жилләнеп барганда да аның күңеленә ярма бөртеге дә икеләнү килмәде. Куктауда бер-ике көн юанырга, калдык-постык агайне белән хушлашырга да юлга чыгарга!

Ялын да шуңа чамалап биш көнгә генә алды ул. Отпускасы көзгә таба, яшелчә-жимеш өлгергәндә булачак егетнең. Ә хәзер шушы биш көн эчендә Исхак туган авылы белән соңгы исәп-хисапны өзеп китәргә тиеш. Гәрчә ул исәп-хисап әллә кайчан өзелгән, аның Куктау белән бердәнбер бәйләнешы булып карт әнисе генә калган иде.

Кайтып кереп әнкәсенең чамадан тыш бөкрәйгән жилкәсен, кайгынужадан нуры коелган төссез күзләрен, ап-ак чигә чәчләрен күргәч күңеле тулды егетнең, телгә килгән сүзләре дә шул мөлдерәмә тулы күңелдә батып калдылар. Карчыкны кинәт сүз белән аяктан егарга кыймады Исхак, тыелды, әңгәмәне юри ерактан башлап китте, сәфәрмазар турында сүз дә кузгатмады.

Хәерлебәнатларга барырга дип газетага төргән шәлне култык астына кыстырып урамга чыккач, ул тәрәзә аша карап калган әнисенең жан ачуы белән үзенә текәлүен, нидер әйтергә жыенуын тойды. Мондый караш кайткан көнне үк Бәнатларга китеп барган өчен генә түгел иде. Ничә еллар кайтмый йөргән улының күңел эретерлек бер сүз дә әйтмичә ташлап чыгып китүенә рәнжүдән туган иде бу кырыс күз карашы...

Чыннан да, нигә шулай каты кыланды соң әле Исхак?

Әнкәсен юатырга, бер-ике сүз белән генә булса да алдап, юмалап куярга кирәк булгандыр? Яхшы сүз жан азыгы, диләр бит.

Күңеле: «Тукта, борыл!» диде. Акыл: «Ярамый! Бер тотынгач сындыр инде син!» дип боерды.

Шунсыз барып чыкмас. Ике сөйләшерлек булмасын. Бу жәһәттән аның тәҗрибәсе житәрлек. Бүген әйтмәсә, барыбер иртәгә беләчәк. Ул әйтәчәк сүзләр аңа карап кына ачылыкларын жуймаячаклар бит. Үз ананны да ялган өмет белән жылытып яшәтмәссең инде...

Ни генә булса да, әнкәсе нинди дәлилләр китерсә дә аның ниятен үзгәртерлек көч Куктауда юк. Казанда да юк андый көч. Бу турыда кат-кат уйланган, үлчәнгән, күптән кисәргә вакыт.

Бара-бара ул кинәт сискәнеп китте. Гаҗәп! Имәнле очына дип чыккан кеше Урта урамга, янган йортлар янына килеп җиткән иде. Исхак шаркылдап көлеп җибәрде, килгәч-килгәч борылып китә алмады, күзәтергә, караштырырга тотынды.

Йорт урыннарын, ишек алларын чүп-чардан арындырганнар, баз эчләрен чистартканнар. Бер-ике урында тәмле кабык, яңа бүрәнә исе чыгарып буралар агарып утыра. Мал-туар таптап бетермәсен өчен, бәрәңге бакчаларын килбәтсез таш коймалар белән әйләндергәннәр.

Исхак үзендә бер уңайсызлану тойды. Ничек ансат кына «әйдә, янса — янсын!» дип әйтә алды икән ул! Ярый, ул үз әнкәсен шәһәргә дә алып китсен, ди. Ә менә бу кешеләр, күршеләр, авылдашлар нишләргә тиешләр? Ишле гаиләсен җитәкләп Хифасулла кая китсен?..

Менә аларның өй урыны..

Монда адәм кулы тимәгәнлек күренеп тора. Янган нәзек бүрәнәләр аркылы да торкылы караеп яталар. Ярым җимерек ала-кола мич кичке караңгылыкта авызын ачып иснәнеп утыра. Исхак ишек алдына кергәч, мич авызыннан шыраулый-шыраулый песи килеп чыкты. Егет дерт итеп китте.

Байтак кына басып, уйланып торганнан соң, ул ызаннар буйлап бәрәңге бакчасы аша ындыр түренә кадәр барды. Кое өстендәге мүкләнгән авыр тактаны күтәреп карады. Кире урам якка менде.

Ваемсыз гына, Индонезия көенә сызгырынып йөргән егет үзендә эчке бер үзгәреш, сызлану, юксыну тойды.

Шушы ич инде аның бала чагын алып калган җир...

Шушы ишек аллары.

Ямь-яшел чирәм була торган иде элек монда. Хәзер барын да көл, тузан-туфрак басып киткән.

Монда кыяр бакчасы, монда Вильданнар сарае...

Менә бу баганада ул дүрт яшь чагында әтисе аның буен үлчәп, киртләп куйган иде. Ул да янган...

Теге шалама песи һаман мыраулап йөри.

— Перес, кит моннан!

Күзен ялтыратып йөргән песине егет таш ата-ата куа башлады.

— Перес, перес!

Тик мәче ул куган якка урамга чыкмады, кыска койрыгын болгыйболгый аны үртәп бәрәңге ызаннары арасына кереп качты.

Исхак көлгә, тузанга буялган чалбар балакларын иелеп кага-кага урам ягына чыкты.

Монда хисләнеп, вакланып торырга ярамый. Нигә онытылып беткән нәрсәләргә игътибар бирергә? Шәһәрдә аның үз тормышы бар, үзе нигез салган тормышы. Квартирасы, һәйбәт эш урыны. Аны яраталар, ул да үз тормышыннан бик канәгать... Кайтты, карады, булды... Янган, беткән... Бер йорт кына түгел, шәһәрләр, илләр янып көл, тузан-туфрак астында калганнар. Онытылганнар!.. Кешеләр тарихларына борылып карарга оялалар. Яхшы якларын белмиләр, яман якларыннан хурланалар... Бер Исхактан гына калмаган... Бары да булгандыр, үтте-китте!

Исхак эре-эре атлап Имәнле урамына таба бара иде. Чаттан борылганда, яшь кенә өч кыз очрап аңа сәлам бирделәр:

— Исәнмесез, Исхак абый.

Ул аларны танымады, караңгы иде инде, тик исемен атауларына гаҗәпләнде: онытмадылармыни әле аны?

Йортлары сирәгәйгән Имәнле очы кап-караңгы иде инде. Сирәкмирәк йортларда гына ут яктысы бар. Соңгарак та калмады микән инде ул?

Исхак капканы шыгырдатып ачып ишек алдына керде. Болдыр баскычлары атынып-какшап торалар иде. Ишек киләсенә үрелгәндә ул

йөрәгенең гадәттәгедән ныграк тибүен тойды. Ишек эчтән бикле иде. Егет сак кына бер-ике кат шакып куйды.

Хәерлебанат егетнең тавышыннан танымады, куркынган шөбһәле тавыш белән:

— Кем, кем дисең? — дип сорады.

— Исхак бу, Исхак! Оныттыгызмени, Бәнат апа, — дип кычкырды егет тамак төбенә тыгылган җылы төерне көчкә йотып.

Шуннан соң гына бик кутәрелде, бусага артында ап-ак озын күлмәк кигән карчык күренде. Оялдында кул биреп күрештеләр дә өйгә керделәр.

Өстәлдә һаман шул ук җиделе лампа яна, караңгы кече яктан яңа пешкән ипи исе килә. Чыбылдык чаршау төшеп торган агач караватта ике ипи табагы тезелеп утыра. Өстәл янында да ике урындык. Өстәлдә дә ике агач кашык. Бөтен өй эче кунак көткәндәге кебек чеп-чиста, җыештырылган, бизәлгән иде. Хәерлебанат бусагадан атлауга лыпылдап урындыкка утырды. Исхак түшәмгә җитәрдәй булып идән уртасында басып тора иде. Ул елмаеп:

— Ни хәлләрегез бар, Бәнат апа? Авырмыйсызмы? — дип сорады.

— Әйбәт, бик әйбәт,— диде карчык, ашыгып.

Исхак тагын ни сорыйм икән дигән кебек авыр сулады.

— Әйбәт... Безнең шул инде, әлеге дә баягы, әле абзаңнан хат алган идем. Шул бахыр кайтып төштеме әллә дип торам. Капка тавышын ишетәм, йөгереп чыгарга хәл юк. Дөнья дигәнең картайта икән.

— Нурулла абыйның кайтырга исәбе бармы әллә?

— Хөсәенне председатель иткәч, кайтам дип язды... Шунда складта каравыл тора иде бит. Караганда каласында. Бу араларда матурматур төшләр дә көреп торды, син кайтырга булган икән. Я, үзең ни хәлләрдә йөрисең? Бик олысы булдыңмы инде?

— Ничек олысы?

— Түрәләрнең олысы булдыңмы дим... Ерагайдың ич, кайтмыйсың. Артыкка китте, үпкәләмә. Абзаң гомере буе шулай тиле-тәүкәл булды инде ул!..

Сүзнең шушы юнәлештә дәвам итүе егетне бераз коралландырды, ул пиджагын чишеп җибәрде, күлмәк изүен ычкындырып, галстугын бушатып алды.

Карчык теге якка чыкты, кыштыр-мыштыр чәй әзерли башлады. Самоварын ут яктысына чыгарып, бакыр чүмеч белән су тутырды, күмер салды, мич алдына тезеп куйган вак-вак чыралардан берничәсен алып шырпы сызды.

— Кайчан кайттым дидең әле?

— Бүген генә әле, Бәнат апа.

— Ут сине дә чакырдымы?

Егетнең маңгае дымланып китте. Тишек самовар торбасыннан гүелдәп менгән ялкын телләре кече як ишегендә басып торган озын, ак карчыкны саргылт яктылык белән коендырдылар.

— Ут, Бәнат апа, ут кайтарды.

— Әнкәңне алып китәсеңме? Үзебезгә чакырган идем дә мин аны, никтер, киләсе килмәде. Алып китәсеңме инде үзең?

— Уйлашырбыз инде, — дип ялганлады Исхак.

Карчык аның ялганын ап-ачык сизде, учы белән авыз читләрен сөртеп башын чайкады.

Ул арада самовар мырлый башлады, пар бөркеп кайнап та чыкты. Хәерлебанат уфылдап аны өстәлгә китереп утыртты, сапсыз, бизәкле тәтәй йомрыга чәй коеп Исхакка таба этәрде.

— Балы белән эч. Нурулла кайта дигәч Зөләйха апаң бал китереп киткән иде.

Исхак калак очына гына эләктереп бал капты, мактады, бал чыннан да бик тәмле, хуш исле иде. Бал тәме дә, сапсыз йомры да аңа бик күптәннән таныш иде. Хәерлебәнат үзе чәйгә кагылмады да диярлек.

— Дөньялар тынычмы? — дип сорады ул бераздан.

— Тыныч дияргә була, — диде Исхак.

— Шулай була күрсен берүк...

Егетнең күзе үзе алып килгән төенчеккә төште, ул шатланып газетаны сүтеп ташлады:

— Мин сиңа бүләк алып кайттым, Бәнат апа, күчтәнәч.

Йомшак зур ырынбур шәлен кулына алып әйләндереп-әйләндереп карагач, карчыкның күңеле җебеп төште, ул яшь аралаш елмаеп:

— Рәхмәт инде сиңа, кирәкми иде, рәхмәт инде! Олылагансың... Теге вакытта абзаңны да бик карадың... Язып торды ул миңа. Барын да язып торды. Үзеңнең дә тормышың бар ич. Алай ук расходланырга кирәкми иде. Өйләнмәдеңме әле? — диде.

Исхак башын чайкады, Хәерлебәнат сулкылдап елап җибәрде. Җиз самоварның гайрәте озакка бармады, ул акрын-акрын сүрелде, сапсыз чынаяктагы чәй суынды, тик бал савытыннан балачак исе килә, кече яктан әллә нинди истәлекләр, хатирәләр уятып яңа ипи исе аңкый иде.

Сөйләшеп утырдылар.

Күңеле тулып никадәрле генә рәхмәтләр укымасын, сөенмәсен, Хәерлебәнат элеккеге кебек ягымлы, ачык түгел иде. Исхак моны сизде.

Саубуллашып чыккач та, ул туры өйләренә кайтты.

Зөләйха апаларының өендә дә ут яна, ачык тәрәзәдән ир кеше тавышы килә иде. Әхмәдулла абзый кайтканмы әллә? Куна-төнә чүнниктә ята дигән иде бит әнкәсе...

Керсә, түрдә үк, ашъяулык өстенә эре-эре тамырлы ябык кулларын куеп аларның элекке күршеләре Хифасулла карт утыра. Өстәлдә самовар гөжелди, әнисе чәй чынаяклары, прәннек-кәнфит кебек коры-сарылар тезгән, Исхакның күчтәнәчләрен тараткан.

— Кайттыңмы, агроном? Менә синнән башка гына чәйләп утырабыз әле,— диде карт, урыныннан купмыйча гына кытыршы кулларын сузып.

Хифасулланың кулы да, аның тәкәллефсез генә агроном дип атавы да, шулай соң булуына карамастан, үз өендәге кебек бер дә читенсенмичә чәй эчеп утыруы да ошамады Исхакка. Маһибәдәр улының караңгы чыраен күреп сорап куйды:

— Ни хәлләр, улым?

— Баш авыртып тора, — диде Исхак. Чыннан да ул берьюлы авыраеп, сырхаулап китте.

— Баллап каты чәй эчеп кара, сыер ялагандай булыр, эзе дә калмас,— диде Хифасулла, керле кулъяулыгы белән битен сөртә-сөртә.

— Кемгә ничек бит, — диде Исхак. — Төнгә каршы каты чәй эчү зарарлы.

Хифасулла дәү авызын ерып елмайды.

— Кайтмаганга күпме булды инде, күрше?

— Байтак булды инде, Хифасулла абзый, — диде Исхак иснәнеп.

Карт алдындагы күмәч бөртекләрен әйбәтләп кенә учына җыйды да башын артка ташлап авызына капты, сирәк керфекле күзләрен кыса төшеп йотып җибәрде, рәхмәт укып өстәл яныннан торды.

— Алай икән, алай, — дип сузды карт.

— Исхак, — диде кинәт кенә Маһибәдәр,— Хифасулла күрше яңа хәбәр белән килде әле. Хөсәен янган хуҗалыкларның бөтенесенә дә

бушлай бүрәнә юнәткән, түбәгә шифер да булачак, имеш. Кадак-мадагын да бирәләр, ди.

— Нигә бирмәсеннәр? Барын да бирерләр, заманы шундый,— диде мактанган сыман Хифасулла.

Исхакның бу сүзләргә исе китмәде, ул ә дә димәде, җә дә димәде, тик кенә утырды да утырды. Хифасулла уенчак, шаян тавыш белән шәһәр хәлләрен сораштырды, капылт кына урыныннан торды һәм бер колакчыны көеп беткән бүреген басып киеп ишеккә юнәлде:

— Сыең өчен рәхмәт, Маһибәдәр күрше. Исхак син дә исән бул.

Маһибәдәр аны капкага кадәр озата барды, ялварып нидер сөйләде, Хифасулла көлеп җавап бирде, сүзләрен Исхак аңламый калды. Бераздан Маһибәдәр өйгә керде.

— Улым, сиңа чоланга җәйгән идем, шунда йокларсың,— диде ул.

— Рәхмәт, әнкәй. Чыннан да үлеп йокым килә, — дип Исхак чыгып ятты.

Ана кулларын күкрәгендә кушырып, бик гаҗәпләнгән күз белән аны озатып калды.

Чоланда тып-тын һәм бик рәхәт иде. Кояш исе килеп торган салкынча түшәккә башын салып ул озак кына иркәләнеп ятты, баш авыртуы җиңеләйде, күңеле тынычланды.

Хөсәен аның кайтуын ишеткәндер, мөгаен...

Нигәдер килмәде.

Кем икән ул хәзер?

Нинди икән?

Хифасулла картка ни калган тагын? Хөсәен җибәрмәгәндер бит аны?..

Олы гәүдәле картның нык кына җәберсенеп чыгып китүен, әнкәсенең улы өчен гафу үтенеп аның артыннан гарьләнеп теркелдәвен хәтеренә төшереп, Исхак чытырдатып күзләрен йомды...

Кайтып йөрисе калмаган.

Нигә кайтырга иде? Урта урамга нигә барып йөрергә? Аннан башка да хәл иткәннәр ич әнә! Бүрәнәсе дә була, ди, шиферы да, башкасы да...

Димәк, Хөсәен эшне нык йөртә башлаган...

Аның күз алдына үз өй урыннарындагы көл килде. Җилләр тузгытып, яңгыр юып бетерер инде ул көлләрне...

Кайтасы калмаган! Хәзер Бәнат апасы да аны яратмыйча калды. Күрше Хифасулла да үпкәләде, әнкәсе дә гел рәнҗеп тора. Әнкәсен телефонга гына чакыртасы иде дә, әйбәтләп аңлашасы иде.

Әйе...

Һәркем үзенчә хаклы. Үз каланчаларыннан караганда, аларның барысының да Исхактан ризасыз булырга нигезләре бар. Закон да, әхлак та алар ягында. Тик әнә шул каты законнар да, әхлак нормалары да егетне Күктауга кайтара алмадылар...

Гомере буе җиргә ябышып яткан Нурулла да әллә кайдагы җәһәннәмдәге ком оясында — Карагандада каравылда ята. Кайтмый...

Әле законнардан өстен, бурыч кушуыннан да көчлерәк, нәфрәттән дә гайрәтлерәк бер хис бар бит. Ул — мәхәббәт.

Җиргә мәхәббәте суынды бит Исхакның, җир кешеләренә ышанычы какшап, аларны сөйми башлады.

Моңа кем гаепле?

Заманмы?

Күктаумы?

Исхак үземе?

Юлларның кайсы чәбәләнешендә, елларның кайсы киселешендә югалттың син үз улларыңны, авыл?

Бик күпләр сине ташладылар ич.

Тик Исхак бүген алар хакында уйламый. Ул уйларында да үзе генә. Берәү генә.

Аның йокы белән тартышып яткан зиһене кинәт ачыкланды, кайчандыр студент вакытта бик тырышып өйрәнгән инглизчә шигырьләр хәтергә калыктылар:

As unto the bow the cord is,
So unto the man the woman,
Though she bends him-she obeys him;
Though she drows him-yet she follows.
Useless each without the other.

Әйе...

Җәя белән җәя бавы — ир белән хатын шикелле. Бау — җәяне тартса да, үзе аңардан аерылмый. Бау — җәяне бөксә дә, үзе аңа буйсына. Берсеннән берсе аерылсалар, бернигә дә ярамыйлар...

Хак әйткән Лонгфелло!

Җәя белән җәя бавы...

Ир белән хатын...

Игенче белән җир...

Алар арасында мәңгелек дуслык, бергәлек, аңлашу булырга тиеш. Берәм-берәм алар бернигә дә ярамыйлар!..

Кинәт уйларны бүлеп лапас ягыннан таза тавышлы әтәч кычкырды, аңа башка әтәчләр кушылдылар...

Йокы таң алдыннан гына килеп җитте, тын гына чоланга керде һәм егетнең гәүдәсен изрәтеп, аңын, хәтерен үзе белән алып чыгып китте.

Икенче көнне аның башы авыртты. Ул беркая да чыкмады, ишек алдында йөреп керде, тагын чоланга кереп ятты. Урта урам ягыннан тук та тук балта тавышы килгән кебек булды.

Тук та тук...

Юнышалар...

Эшлиләр...

Ул әнкәсе белән дә, Зөләйха апасы белән дә юньле-башлы берни дә сөйләшмәде.

## 14

Кояш баер-баемастан бүселә башлаган көн тәмам ямьсезләнде. Әллә каян гына чыккан болытлар киң, ертык итәкләрен жилфердәтә-жилфердәтә шәфәкъ утын сүндереп бетерделәр, җиңгән сыман масаеп, тиз-тиз шуыша-шуыша зәңгәр гөмбәзне капладылар.

Караңгылык көндәгегә караганда күп иртәрәк төште.

Зөләйханың күңеле яңгыр буласын сизенгән икән. Карты, ялгызым күңелсез дип, ни ялынса да, ул бүген умарталыкта калырга риза булмыйча авылга кайткан иде. Өй арасында тегене-моны караштырып йөрде дә болдырда тезен кочаклап утырган Исхакка агач бадьян белән көнбагыш чыгарып бирде.

— Өйдә мин барга читенсенәсеңме әллә? Мә, тик утырганчы, айбагар яр. Авыз алдарга ярый ул. Эч пошуың басылыр. Былтыр үзем кагып, үзем киптереп куйган идем.

— Эчем пошмый, Зөләйха апа.

Зөләйха, мин беләм, аңлыйм, дигән кебек башын селкеде.

Көндезге сөйләшми йөрүләрдән тәмам гаҗиз булган Маһибәдәр кулларын алъяпкычы астына тыгып, иңкәеп, тәрәзә янына утырды. Зөләйха аңа:

— Исхакка чоланда салкынрак булмасмы икән. Яңгыр бик шәп яварга тора, — дигәч тә җавап бирмәде. Тыштагы караңгылык белән

ул да акрын гына ойый, онытыла кебек иде. Зөләйха соравын кабатлады. Маһибәдәр анда да:

— Хәере белән килсен! — дип кенә куйды.

— Нәрсә килсен?

— Яңгыр килә диден түгелме? Хәере белән булсын, дим. Үткәреп яусын иде әле. Үлән тамырлары корыган.

Маһибәдәр һаман тәрәзәдән күзен алмады. Исхакның бөкрәеп утыруы аның күңеленә авыр бер моң тудыра, сызландыра иде. Нишләп утыра инде? Караңгы төшеп беткәнне көтәме?

— Шушы юрганны чыгарыйммы әллә үзенә?

— Чыгарма. Туңмас. Җылынып йокласы килсә, җылы кочак табар! — диде Маһибәдәр ачулы гына.

Зөләйха Маһибәдәргә болай гына, сүзгә чакырып кына эндәшкән иде, соңыннан үкенде, тавышсыз-тынсыз гына чоланга чыгып керде...

— Тагын Хәерлебәнатларга китеп олагыр инде, — дип сукранды Маһибәдәр. Аннары озаклап кына ян сәкегә урын җәйде. Бераздан, авыр, сырхау аякларын сөйрәп ишек алдына чыкты. Болдырда беркем дә юк иде. Исхак кече капканы ябарга онытып чыгып киткән, капка кинәт искән җилдән шап-шоп бәрелгәләп тора. Маһибәдәр аптырап урамга ук чыкты. Җил тузан уйната. Исхак күренмәде. Маһибәдәр капканы көч-хәл белән ябып кире керде, улы калдырган җылы урынга утырды.

Киткән! Тагын шуларга киткән! Саташып йөрүеннән туктамаган икән. Җитәр! Моңа чик куярга вакыт! Кеше бусагасында аунаучы ятим булса да, ул ана! Чәнчелсен бүрәнәләре, яңа өйләре, моннан китәргә вакыт җиткән икән. Берсе дә кирәкми, аңа улы гына булсын. Исхагы!

Ул әрнүенә түзә алмыйча тагын капкага барып ябышты, келәне күтәрүгә капка үзеннән-үзе ачылып аны бер якка китереп сылады, ябык кул аркасына дәү бер тамчы төшеп чәчрәде. Күзләрен чекрәйтеп, усалланып урамнардан улын эзләде ул. Ерак юллардан үтүче машиналарның уты үртәп уйнады. Йокымсыраган тауларны зәңгәрсу, сихри нурга бизәп яшен чартлады. «Ходаем, үзең сакла! Яңгыр алдыннан гына бу бала тагын нишләп йөри икән?»

Хәерлебәнатларга китмәде Исхак. Тик утырып күңеле авырайганнан соң, болай гына, хәрәкәттә азрак җилләнергә ниятләп кенә, урыныннан кузгалган иде. Башта ул Урта урамга борылды. Караңгыда тычкан уты кебек тонык кына ялтыраган ак бура янында аңа бер көчек иярде. Җан иясе койрыгын болгап аның хәсрәтен бүлеште. Исхак аның ягымлы чыраен кесә фонаре белән яктыртып йомшак сыртын сыйпап торды. Көчек уйнаган булды, шат тавыш бирә-бирә чалкан ятты, иркәләп кенә Исхакның бармакларын капты. Аргы баштан:

— Актүш, Актүш, маһ-маһ! — дигән чакыру килгәч, алпан-тилпән чаба-чаба караңгылыкка кереп чумды. Каяндыр, мич авызыннан булды ахры, песи мыраулаган тавыш килде. Егет:

— Пес, пес, — дип кат-кат чакырып караса да, мәче күренмәде. Тавышы да тынды. Урамда башка җан иясе очрамады. Бөтен җирдән аз гына көек исе катыш усак кайрысы исе килә иде. Исхак урам буйлап бераз баргач, су буена төшә торган тыкрыкка борылды. Читән коймаларга үрелеп үскән колмак тәлгәшләре туктаусыз искән җилдә җилфердиләр, кемнәрдер койма артына посканнардыр да аңа кул болгап калалар төсле. Колмакларга карап шигәеп кенә барганда, ул йомшак бер түмгәккә абынып чак кына тәкмәрләп төшмәде. Яктыртып караса, бозау икән. Өен тапмыйча адашып тыкрыкта кунарга калган. Исхак аны авылга таба куып җибәрде.

Су буенда төн тәмам куерып җитте. Ул күпер култыксасына таянып су тавышын озак кына тыңланып торды. Вак ташлар, сирәк камышлар

арасыннан ага да ага су. Менә шушы тәбәшәк таулар итәгеннән ялтырап кизләү булып чыга да Минзәләгә барып кушыла. Минзәлә шушы бәләкәч инешне куенына алып Ыкка илтә. Ык белән аралашып Күктау суы Камага барып башын сала. Күктау авылы суы... Кама-Идел өсләрендә йөрүчеләр дә, Идел станцаларыннан электр көче белән завод-фабрикаларда эшләүчеләр дә Күктау авылы тавыннан челтери-челтери килеп чыккан нәзек тавышлы, сап-салкын сулы нәни кизләүне бар дип тә белмиләр инде. Ә бу кайчаннан бирле армый-талмый Минзәләгә, Ыкка үрли.

Кешеләр дә шулай түгелмени? Күктауда туалар, ныгыйлар, үсәләр һәм Идел-Камалар буйлап еракка таралалар. Кем чирәм җирләргә дип кыбырсып юлга чыга, кем Пермь якларына барып яллана, шунда, сыек булса да, бәхетен таба, тормышын рәтли. Инеш саекмаган кебек, авыл да үз урынында. Еллар үтүгә яңа буынны үстереп чыгара гына тора. Алар да Исхак кебек үк авылларын оныттылар микән? Бик күп ич алар төрле өлкәләрдә. Элек авылдан читтә йөргән бер зимагур Нурулла гына булган...

Тау өстендә бер-бер артлы күк гөрселдәде. Бер яктан, болытлар авырлыгына түзә алмыйча ыңгырашкан күк уфылдап бетерә алмый, икенче якта яшен чыбыркысы шартлый.

Уйлар һаман шул бер тирәгә әйләнеп кайттылар. Онытылыр өчен хәзерге минутта ялгызлыктан котылырга, кешеләр янына барырга кирәк иде.

Тик су буйлары урамнар кебек үк буп-буш иде. Бу бушлык күңелне авырттыра, кыйный иде. Кайчандыр бу урыннарда яшьләр әйләнбәйлән уйныйлар, бии торганнар иде. Кая китеп беткәннәр соң алар? Яңгыр куркыткынмы аларны?

Аның шиген кире каккан сыман әллә кайдан, түбән яктан ахры, бик матур бер җыр ишетелде. Күк гөлдердәгән авазлар вакыт-вакыт җырны өзәләр, аның кайсы яктан килүен белергә комачаулыйлар иде. Ләкин җырчы ул өзелеп яраткан, кайчандыр шушы су буйларында «ул» җырлаган җырны җырлый иде. Күк күкрәп өзелгән урыннарын егет үзе ялгады.

> Зәңгәр күлмәкләрнең чын зәңгәрен,
> Җилләр алыр, җилгә әлмәгез.
> Яшьли ярлар сөю бигрәк авыр,
> Яшьли ярлар сөя күрмәгез.

Җырлаучы каядыр бара кебек. Тавыш бер көчәя, бер кечерәя, тагын ныгый да сүнә, югала. Исхакның бәгыре телгәләнде, беләкләренә, аркасына каз тәне чыкты.

> Чәчәкләр күп,
> Ләкин чәчәк өзмим,
> Табу өчен шундый исләсен.
> Мин тапканчы шундый бик ислесен,
> Җил исмәсен, гөл дә үсмәсен!

Урманда, болында, юлда тыңланган җырлар кешенең гомер юлындагы вакыйгаларга, истәлекләргә бәйләнеп күңелгә нык уелып, сеңеп калалар. Алар чын сәнгать югарылыгында башкарылмасалар да, тантаналы шартларда тыңланган бик күп җырларга караганда үтемлерәк, тәэсирлерәк булалар.

Гомере буе күңелен кузгатып торган көйнең менә шушында, шашып-шашып яңгыраган күк белән ярышуын ишетү Исхакны тетрәтте.

Кинәт очып киткән сандугач кебек, кыз капылт югалды, тавышы тынды. Исхак яңакларын чытырдатып кысып күпер култыксасына ябышып, тыңлап, көтеп торды. Күз алдыннан гына аллы-кызыллы утлар тәгәрәде. Болытлар яшен шартлавын «Уф-фа-фа! Ха-ха-ха!» дип

тәкрарлыйлар иде. Тау сыртлары, әрәмәләр бу көчле тавыштан куркып калтыраналар, тәбәнәкләнә баралар.

Беркем дә юк. Әллә төш кенә булдымы? Юк, өн бит, өн! Менә күпер, шырпылы култыксалар. Әнә инеш чылтырый. Бакалар кычкырып куя.

Ә кыз кайда? Нигә җырламый ул? Нигә тавыш бирми?

Егет аяк очларына гына басып күпердән чыкты. Тирә-як бер генә секундка көмеш сыман нурга коенды да тагын караңгылык басып китте.

Табасы иде аны!

— Әй!

Беркем дә юк. Исхак абына-сөртенә юлга төште. Кыз юлдан үтмәгәндер бит? Егет кесә фонарен кабызып олы юлдан чаба башлады. Бераз баргач мышкылдап туктады. Әгәр кыз кире якка үтеп киткән булса? Аның тавышы төрле яктан килә иде бит!

Лап-лоп аяк тавышлары кирегә йөгерделәр.

Төн һаман мәкерле рәвештә куерган кебек, яшеннәр тагын да усалланып ялтырыйлар, яныйлар. Алар, төн караңгылыгын җыярга теләгәндәй, өч япьле сәнәк булып югарыдан түбәнгә кадалалар да, суалчан төсле бөгәрләнеп, җиңеләеп офыкта сүнәләр. Караңгылык тагын хаким була.

— Әй! Әй!

Исхак юл буйлап шактый йөгергәч туктап тын алды, юлдан авылга таба борылды һәм тәкәрлек түмгәкләренә абына-абына инеш буйлап бара башлады. Менә таллык. Бу вак әрәмәлеккә алар Сания белән еш кына киләләр иде. Шул әрәмә артындагы текә ярдан ул Саниягә керәшә балалары алып күрсәткән иде. Яр карлыгачлары аның иңбашларына орына-орына, тилмереп кычкыра-кычкыра очканнар иде. Кошларны кызганып Сания бик озак елаган иде. Икенче көнне алар кесәләренә тары тутырып килеп керәшәләргә сиптеләр.

Көз көне сыер эзләргә барганда яр өстендә үсеп утырган тарыларны күреп Исхакның исе киткән иде. Димәк, керәшәләр ояларына кул тыккан дошманнан ризык алмаганнар. Дус белән дошманны аера белгәннәр!

Йоклыйлармы икән алар?

Әллә бүгенге күк күкрәве аларга да тыңгылык бирмиме?

Ул сакланып кына ярга таба атлады һәм чак кычкырып җибәрмәде, яр өстендә аякларын түбәнгә салындырып яшь кенә бер кыз утыра иде. Ул Исхакны күптән күргән булса кирәк, фонарь яктысыннан күзләрен учы белән каплап, тыныч кына тавыш белән:

— Нәрсә югалттыгыз, Исхак абый? — дип сорады.

— Югалттым шул, яшьлегемне җуйдым, — диде егет, сүзне уенга алып.

Кыз көлеп куйды.

«Ул җырлаган!»

— Бу экиятне ишеткәнем бар. Ләкин ул җавапны тормыштан өметен өзгән калтыравыклы карт биргән бит.

Исхак та көлеп алды.

— Тау итәгендә чапкан утны күргәч, ниһаять, җен белән очрашам икән дип куандым әле, — диде кыз.

— Сез үзегез су кызы түгелме?

Кыз тагын тыйнак кына көлеп алды:

— Әллә ошаганмын? Юк, юк шул. Ярулла кызы мин. Беләсезме?

— Ярулла абзыйнымы? Белә идем.

— Чынлапмы? — диде кыз куанып. — Ә мин аны белмим. Рәсемен генә күргәнем бар. Анда да тоныж кына төшкән. Тезе тишек чалбар кигән. Кырда, сабанда төшергәннәр үзен.



— Сез биредә нишлисез? — дип сорады Исхак, як-ягына каранып.

— Яшен яшьнәвен саныйм, — диде кыз, исе китмичә генә. — Биш минутка туксан тапкыр яшьнәде. Күп бит, Исхак абый, әйеме? Төрле-төрле үзләре. Күкнең җиде каты күренә кебек. Сез төнге яшенне яратасызмы?

— Бу турыда уйлап караганым юк.

— Алайса, сез ялгызлыкның нәрсә икәнен белмисез, — диде кыз, олыларча җитдилек белән.

— Минме? — диде Исхак, шаккатып.

— Ялгыз кеше табигатьнең әнә шундый күренешләрен ярата ул. Җилне, давылны, яшенне, буранны... Ялгыз кешегә дә яшәү өчен иптәшләр кирәк түгелмени?

— Менә ничек?.. Сезнең янга утырырга мөмкинме?

— Яр чыдатса, утырыгыз, — диде кыз, тагын көлеп. — Тик фонарегызны сүндерегез. Күзне сукырайта...

Егет кызга якын гына барып утырды.

— Сез үзегез генәме монда?

— Әйе.

— Нигә болай ялгыз йөрисез?

— Авылда берүзем генә бит мин.

Егет кызның җавабын аңламады. Нигә алай диде соң әле ул? Яшен яктыртканда Исхак аның яңагын, көмешсу чәчләрен, нидер пышылдаган кабарынкы иреннәрен күреп кала.

— Авыл уеннарын күрәсем килгән иде. Нигә бик тын соң әле бүген?

— Кем уйнасын? Яшьләребез юк, — диде караңгылыктан төшенке тавыш.

— Нигә булмасын? Менә сез бар ич,— диде шаяртып Исхак.

— Мин берәү генә бит. Сугыш елларында балалар тумаганнар. Хәзер менә шул елгыларның уйнар чаклары житте. Ләкин алар юк. Тыңлагыз әле, су буе тып-тын!.. Әнә, миңа иптәшкә күк кенә күкри! Мин кырык өченче елда туганмын. Әти яраланып кайткан булган...

Исхак кулын ак марля белән муенына асып йөргән зур авызлы, сары мыеклы кешене хәтерләде. Аны сугыш беткән көнне генә Чехословакиядә үтергәннәр дип сөйләгәннәр иде. Нурулла сөйләгән иде, ахры...

— Менә шуңа яшьләр дә юк, — дип дәвам итте кыз. — Яшьтәшләрем дә юк. Бала чактан берүзем. Укырга кердем — берүзем. Икенчедә — берүзем. Өченчедә — берүзем. Дүртенчедә дә — берүзем. Беләсезме, Исхак абый, бик-бик кыен икән ул. Бергә-бергә уйныйсы килә, салам эскертләрендә ауныйсы килә, гөрле-качышлы чабышасы килә. Бишенче класска кадәр шул бер партада берүзем утырып укыдым. Бишенчегә Мәлләгә йөри башладым. Бер класста алты бала идек. Минем беренче яшьтәшләрем, тиңдәшләрем иде алар. Башта бик кызык булды. Бер-беребезгә карашып тик утырабыз. Соңыннан шундый дус-

лаштык... Тик үсә төшкәч бигрәк тә ямансулата. Анда бергә, монда кайттым исә тагын ялгыз...

Кыз тукталып торды һәм шатланып:

— Йөз дә утыз ике! — дип кычкырды.

Тагын чартлап яшен яшьнәде.

— Бусы йөз дә утыз өченче! — диде кыз, кинәт юашланып һәм баягы сүзенә кайтты:

— Каядыр барасы, кемнедер күрәсе килә, нидер җитми. Яшьләр бик яшь, олылар бик олы. Үз ишләрем юк, утырам менә шушында.

Егет, үзе дә сизмәстән, кулын сузып, кызның кайнар бармакларын эзләп тапты.

— Исхак абый, ә сез нишләп монда йөрисез?

— Мин дә ялгыз бит. Берүзем.

— Нигә?

Егетнең Сания хакында беркемгә берни сөйләгәне юк иде. Сорасалар, кызыксынсалар да серен берәүгә дә ачмады ул моңарчы. Тик менә бүген, әчкерсез турылык белән йөрәк фаҗигасен ачып салган шушы кызга барын сөйләп бирәсе, кайгы-хәсрәтен уртаклашасы килде аның.

Бу кыз Исхакны аңларга тиеш!

Ул барын да белергә хаклы....

Исхак моңарчы үзен генә «берәү» дип йөргән икән...

— Нигә сөйләшмисез, Исхак абый?

— Сөйләрмен, тик мин сезнең исемегезне дә белмим бит әле.

— Сания.

— Сания! — дип кычкырып җибәрде Исхак.— Бу җырны каян өйрәндегез?

— Бәнат апа өйрәтте... Матурмы?

— Матур җыр.

— Исемем ямьсез минем, — диде кыз тагын көлеп.

— Исемегез дә бик матур. Тик мин үз тарихымны сезгә иртәгә сөйләрмен инде. Яңгыр төшә башлады.

Кыз сикереп торды.

— Чыннан да сөйләрсезме?

— Чыннан да.

— Ә сез кайчан китәсез?

— Иртәгә китмим әле.

— Берсекөнгәме?

— Белмим.

Кыз тагын көлде.

— Нигә көләсез?

— Әни тагын орышыр инде. Ул мине бик үк акыллыга санамый.

— Мине дә!

Алар тиз-тиз атлап инеш буйлап киттеләр. Күпергә җитәрәк, кыз туктап Исхакка карады:

— Чыннан да сөйләрсезме?

— Сөйлим, Сания...

Ян тәрәзәдән сузылган ут яктысына килеп кергәч кенә, Исхак, төн уртасы күптән авышса да, әнкәсенең йокламыйча үзен көтеп торуын аңлады.

— Әнкәй, нигә йокламыйсың?

— Ана йокысын балалар ияртеп алып китәләр.

Маһибәдәр урыныннан кубып улының юеш муенын кочаклады.

— Улым, балам, ходай хакы өчен ялварам, китик без моннан! Үз яныңа алырга авырыксынсаң, апаңнарда яшәрмен. Ялгыз интектем, тәкатем корды. Сабыр канатларым сынды. Гомер буе ялгыз ябалак булып интегәсем килми. Китик!

— Ни сөйлисең син, әнкәй?

— Синең болай байгыш булып йөрүеңә күңел түзә алмый! Тагын Бәнатларда утырдыңмы әллә?

— Юк, әнкәй, мин аларга бүген бөтенләй бармадым. Маһибәдәр улының алдамавына күнеккән иде.

— Тагын аз гына авылда торыйк әле, әнкәй... Аз гына...

Ана нәрсә әйтергә дә белмәде, улын кочаклап мышык-мышык елады да елады.

— Иртәгә, әнкәй, иртәгә! Бүген бәй-бәй итәргә кирәк!

Исхак оялдындагы урындыкны аударып чоланга керде, почмактагы калай бактан зур чүмечкә тутырып су эчте. Түшәккә капланды.

Такта түбәгә тып та тып килеп яңгыр тамчылары төште. Лапас ягыннан әтәч тавышы яңгырады...

Авыл бимазалы йокыга талды. Имәнле очындагы тәбәшәк өйдә дә ут сүнде.. Өстәл өстендә ашъяулык белән капланган аш ашалмаган килеш калды. Нурулла да кайтмады, Исхак та кагылмады...

Әнкәсе сыер саварга торганда, Исхак та уянды. Атылып ишек алдына чыкты. Күк йөзе чалт аяз. Кызыл керфекләрен сирпеп оялып кына кояш чыгып килә. Егет бит яулыгын эләктереп су буена төшеп китте.

Куе булып төшкән чык хәтфә чирәмлекне суга манган. Ямь-яшел чирәм өстеннән кемдер саз ярып кайткан пычрак арба белән үткән. Тәгәрмәчтән төшеп калган зур-зур балчык кантарлары яшел җирнең кабарып торган күкрәгенә кап-кара эз булып ятканнар.

Тик бу эзләр беренче яңгырга кадәр генә! Җылы, җәйге яңгырлар тагын яварлар да, бәбкә үләннәрен саргайтып яткан кара кисәкләрне юып алып китәрләр...

Ул тиз-тиз юынды, тыкрыктан йөгереп диярлек кайтты, ару күлмәген киеп көзге каршысына басты, чәчләрен тарады, әнисенә карап бер көлде дә урамга чыкты.

Йортлар өстеннән күренгән кояшка күзен кысып текәлеп торды да туп-туры Хөсәеннәргә таба китте.

*1959—65 еллар. Казан.*



*Галимҗан Латыйп*

## Ташлар ни сөйлиләр

Бала туды.
Кояш иртәдән
Ак нур белән юды дөньяны.
Яңа кеше
Ап-ак бинада
«Разбой салып»
Бик нык елады.

Кычкыр әйдә,
Көчең җиткәнчә,
Барлыгыңны белдер дөньяга.
Тик дәү булгач,
Акыл утыргач,
Син сыкрана күрмә,
Елама!

Сөендер син күргән-белгәнне,
Әткәң-әнкәң,
Кордашларыңны.
Уят әйдә,
Уят йокыдан
Айга менәр юлдашларыңны.

Син дөньяга килгән бу бина
Төрмә булган әлек, беләмсең!
Монда булган хәлләр ялгышып та
Төшләреңә керә күрмәсен.

Ике язмыш бер үк ташларда.
Ә соңгысы
Шундый ак аның,
Зинданчылар сүгенүен түгел,
Ишетә ул тәүге сулышын
Яңа туган сабый баланың.

## Пермь төрмәсендә

Декабристлар килеп туктадылар
Этап белән төрмә алдына.
Таш капчыкның авыр ишекләре
Ачыла да
Тагын ябыла.

Утларны да ныграк яктырттылар,
Чигенсен дип төнге күләгә.
Төн үткәнче нәрсә булмас дисең,
Декабристлар кунган төрмәдә.

Богауларны ычкындырмый гына
Йоклатырга боерык бирелде.
Сакка куйды палач солдатларын,
Сакка куйды ташны,
Тимерне.

Көч дигәнең тимер богау аша
Керә кебек тәнгә саркылып.
Ниләр генә эшләмәсен тиран,
Төшә җиргә,
Төшә яктылык!

Декабристлар Себер китсә китте,
Гүзәл итеп күрде дөньяны.
Йокымсырап яткан Россияне
Сискәндерде богау чыңнары.

## Көзге кояш

Көзге кояш
Җиргә бик тә якын сыман,
Ләкин үзе
Кырык яшьлек хатын сыман.
Елмая да саран гына,
Салкын гына,
Кереп китә
Юеш болытлар артына.

Ә җир көтә,
Кешеләр көтә,
Кошлар көтә.
Урман, кырлар
Көтә-көтә арып бетә.

Зарыгудан
Яфракларга сары төшә,
Әйтерсең лә
Дөнья лимон суы эчә.

## Капкалар

Капкалар төрле булалар —
Тимере, такталары...
Гел йозак, сак астында да
Тоталар капкаларны.

Булдылар шундый капкалар —
Керделәр, чыкмадылар.
Адымнар мич авызына
Терәлеп тукталдылар.

Белә дөнья Освенцимны,
Бухенвальд капкаларын.
Кеше ашаучы гитлерлар
Киереп ачкан аны.

Мондый капкаларга кеше
Аяк басмасын иде!
Мондый капкаларны дөнья
Кабат ачмасын иде!

## Синең җырың

*Робертино Лореттига*

Робертино, синең җырларыңны
Тыңлыйм да мин,
Киләчәген күрәм Италиянең,
Матурлыгын күрәм дөньяның.
Каян алдың,
Кемнәр бүләк итте,
Бу кадәре гүзәл моңнарны.

Зәңгәр күкләр.
Кояш.
Магнолия.
Язгы гөрләвекләр.
Тынгы белмәс диңгез ярлары.

Барысы да
Барысы да әйбәт!
Тылсым көче бар бу җырларда.
Әкияттәге канатлы ат сыман
Оча күңел иркен кырларга.

Синең җырың җырсыз күңелләрне
Ефәк белән төрә шикелле,
Синең җырың салкын ташларга да
Җылы сулыш өрә шикелле.

Синең җырың
Җәйге рәшә кебек,
Кошлар кебек җитез канатлы.
Хәтерләтә сыман
Бәхет өчен
Атакага барган солдатны.

Робертино, җырла!
«Ямайка!» дип,
«О кояшым, минем кояшым!».
Елмайсыннар җирдә барлык йөзләр,
Йөрәкләрдә ялкын уянсын.
«О кояшым, минем кояшым!..»

●

Барыр юлың шома булсын диеп,
Теләмәгез миңа теләкне.
Юллар мине алга барырга да,
Түзем булырга да өйрәтте.

Алып киткән юллар алып кайтса,
Авырлыклар барысы онытыла.
Бәхет дигән нәрсә йөрми читтә,
Ул бары тик туган йортында!

●

Мин бер мескен татар идем диеп,
Җырламадым һәм дә җырламам.
Тау-ташларны ярган бабаларым,
Зарланмаган алай дөньядан.

Аяк өсте үлә белгән халык
Бервакытта калмас мескенгә.
Мескенлекләр алар хас булалар
Ялагайга, түбән кешегә.

●

Үстерә бакчаны Кәрим
Тәрбияләп, ашлап кына.
Пешәр-пешмәс алмаларны
Малайлар гел ашап тора.

Ләкин моңа һич кенә дә
Бакчачының исе китми.
Беләсезме, малай чаклар
Минем дә бар иде бит, ди.

КОНКУРСКА КИЛГӘН ӘСӘРЛӘР

*Галимов*

# ПЛАН

*(Скетч)*

КАТНАШАЛАР:

Совхоз директоры.
Баязитов — бүлекчә управляющие.
Сафин — комсомол секретаре.
Илгиз — укучы.
Секретарь кыз.

Директор үз бүлмәсендә ялгызы. Телефон шалтырый.

Директор *(телефонга).* Әйе, исәнмесез, иптәш Хәлиуллин... Ә? План? Металлолом җыю планы? Юк бит, иптәш Хәлиуллин, юк... Каян алыйк соң? Вәгъдә дисезме? Бирәсезме, дип... Иптәш Хәлиуллин, иптәш Хәлиуллин!.. *(Трубканы колагыннан ала, аңа аптырап карап тора.)* Сөйләшергә дә теләми... Бүген кичкә планыгызны тутыру турында рапорт бирмәсәң, үзеңә үпкәлә, дигән була. Тьфү! *(Кнопкага баса. Секретарь кыз керә.)* Управляющийны.

Секретарь чыга. Баязитов керә.

Баязитов. Исәнмесез, иптәш Хәмитов.

Директор. Хәлләр шәптән түгел, иптәш Баязитов. Әле генә Хәлиуллин шалтыратты. Сезнең аркада районда металлолом җыю планы тоткарлана, ашыгыч чаралар күрмәсәгез, ди... Вообще, анысын үзең дә аңлыйсың инде... Кыскасы, менә шул: бүген кичкә чтобы...

Баязитов. Һаман шул бер балык башы икән. Каян алыйк соң, иптәш Хәмитов? Актарылмаган почмагыбыз, тапшырылмаган бер черек кадагыбыз калмады...

Директор *(аны бүлеп).* Мин моны күп ишеттем инде. Ә тегендә ишетү түгел, тыңларга да теләмиләр, беләсеңме? Я тимер-томыр, я урының, диләр. Күпме тулмый анда план?

Баязитов. Дүрт тонна.

Директор. Шул дүрт тонна тимер-томырны таба алмыйсызмы?

Баязитов. Каян табасың... Аның планы 15 тонна иде бит... Тегесен дә әле...

Директор *(урыныннан торып).* Сүзне шушының белән бетердек. Я дүрт тонна металлолом, я...

Баязитов. Иптәш директор...

Директор. Хватит болтовня белән мине юатырга. Менә өстәл, менә телефон. Теләсә нинди кешене, теләсә нинди машинаны эштән бушат. Әмма... *(Чыга.)*

Баязитов *(арлы-бирле йөренә)*. Вәт проблема, ә?! Ни эшләргә соң, ни эшләргә? *(Кнопкага баса. Секретарь керә.)* Комсомол секретарен.

Секретарь чыга, Сафин керә.

Ну, и комсомол! Нәрсә карыйсыз сез, ә? Бөтен районда бер без калганбыз. Дүрт тонна тимер-томыр таба алмыйсыз, ә? Гражданнар сугышы елларында комсомол кулына корал алып, яшь Совет илен саклады, ә сез бер машина тимер-томыр җыеп тапшыра алмыйсыз. Оят кирәк, оят!

Сафин. Үзегез дә беләсез бит... Ничәмә ничә тапкыр өмә ясап карадык.

Баязитов. Миң райкомол секретаре түгел, миңа коры отчет кирәкми, тимер-томыр кирәк. Аңладыңмы?

Сафин. Ни эшләргә дә белмим инде.

Баязитов. Менә өстәл, менә телефон сиңа. Теләсәң нишлә, әмма бүген кичкә дүрт тонна тимер-томыр җыелган булсын. *(Чыга.)*

Сафин *(арлы-бирле йөренә)*. Вәт проблема, ә? Ни эшләргә соң, ни эшләргә? *(Трубканы ала, номер җыя.)* Мәктәпме? Сафин бу. Совхоз директоры булмәсенә дружина советы председателен — Илгиз Хановны җибәрегезче. Рәхмәт. *(Трубканы куя.)* Ничегрәк сүз башларга икән?

Илгиз керә.

Илгиз. Мине син чакырдыңмы, абый?

Сафин. Әйе. Менә нәрсә, Илгиз, сезнең ярдәмегез кирәк. Бөтен район алдында мәсхәрәгә калабыз. Дүрт тонна металлолом табарга кирәк.

Илгиз *(коты очып)*. Дүрт тонна?

Сафин. Әйе, дүрт. Һәм бүген үк. Аңлыйсыңмы?

Илгиз. Юк бит ул, абый. Без инде бөтен җирне чистартып бетердек. Ял көне саен йөрибез бит.

Сафин. «Юк» дип түгел, «есть!» дип җавап бирергә кирәк. Син бит пионер. Ә пионерның кем икәнен беләсеңме? Пионер ул — Павлик Морозов, Леня Голиков, Володя Дубинин. Пионер ул — комсомолның алмашчысы! Ә сез? Бөтен мәктәпкә дүрт тонна тимер-томыр таба алмыйсызмы? Оят кирәк, иптәш Ханов, оят! Бөтен дружинагызга кара тап төшерәсез.

Илгиз. Юк бит ул, абый...

Сафин. Нәрсә юк?

Илгиз. Тимер-томыр.

Сафин. Пионер булмаганны да таба. Сез дә табыгыз, тап! Шуны да таба алмагач, нинди пионер сез, нигә дип кызыл галстук тагып йөрисез! Позор, валлаһи, позор! Ярый, шушының белән бетерәбез. Менә сиңа өстәл, менә телефон. Теләсәң ни эшлә, әмма бүген кичкә дүрт тонна тимер-томыр җыелган булсын. Шунсыз күземә күренмә. *(Чыга.)*

Илгиз *(арлы-бирле йөренә)*. Ни эшләргә соң, ә? Ни эшләргә?! *(Уйланып тора да, атылып чыгып йөгерә.)*

Директор керә. Кнопкага баса. Секретарь керә.

Директор. Баязитовны.

Секретарь чыга. Баязитов керә.

Я, ничек?

Баязитов. Бөтен өмет комсомолда.

Сафин керә.

Я, иптәш Сафин, эшләр ничек?
Сафин. Бөтен өмет пионерларда.

Илгиз йөгереп керә.

Директор
Баязитов } *(аны сарып алалар).* Я, ничек?
Сафин

Илгиз *(шат).* Булды!
Директор. Молодец! Молодец! *(Трубканы ала.)* Район үзәге, иптәш Хәлиуллинны... Иптәш Хәлиуллин! Күпме дисезме?.. *(Илгизгә.)* Күпме?
Илгиз. Бер трактор.
Директор *(трубкага).* Бер трактор... *(Илгизгә.)* Кайдан, ничек җыйдыгыз? ди.
Илгиз. Җыймадык, бөтен мәктәп белән сүттек.
Директор *(трубкага).* Җыймаганнар, сүткәннәр. *(Нәрсәнедер төшенә барып, Илгизгә.)* Нәрсәне сүттегез?
Илгиз. Тракторны.
Директор *(кычкырып).* Нинди тракторны?
Илгиз. Кичә генә ремонттан чыккан ДТ не!
Директор *(трубкага).* Иптәш Хәл... Хәлиуллин, булды!

●

Яшьләр иҗаты

# Клара Булатова



*Мин 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында туганмын.*

*Әнием әдәбият укыта иде. Мин аның көнлек дәфтәрләрен шигырь белән язганын, җыр, шигырь альбомнары тотканлыгын беләм.*

*Җырлар, шигырьләр ятратуым шул йогынтыдандыр. Тормышның бөтен серен җырга күчерәсе, матур җырларны халык күңеленә ятышлы итеп тормышка бәйлисе иде.*

*Мин соңгы елларда Әлмәт районының Колшәрип авылында мәктәптә эшләдем. Әнием кебек үк тел-әдәбият укыттым.*

*Быел укуымны тәмамлау өчен университетка килдем.*

## Дөньяларның бигрәк матур чагы

Колшәрипнең таулы тирә-ягы,
Тау җилләре җитез, йөгерек.
Дөньяларның бигрәк матур чагы —
Кырда иген килә өлгереп.
Җәй үзәге кызу килгән бугай,
Аҗагайлы көннәр тиз үткән.
Хәзер инде тау иңендә бодай
Өченче кат буын сикерткән.

Урманнарда җиләк уйдыклары,
Мәтрүшкәләр бөрки хуш исен.
Нинди гаҗәп! Җәйнең бөтен ягы
Шул аланга тулган диярсең.
Зәй буйларын кем куллары чиккән,
Исле үләннәр белән бизәлгән.
Юк, болардан мин аерылып китсәм
Бер көнгә дә читтә түзәлмам.

Җырлы урман, иген уңар кырлар,
Һәр ягында илнең күп күбен.
Тик шулай да минем өчен болар
Бигрәк якын, бигрәк үз бүген.
Тау артына кояш төште тагын,
Күләгәләр ятты юлларга,
Ә дөньяның бигрәк якты чагы —
Иген җитеп килә кырларда.

## Язлар алда

Чук тәлгәшле каеннары белән,
Камышлары белән ярдагы,
Кайнар яшьле кайгылары белән,
Сагышлары белән җандагы,

Әле генә кар юрганын салган
Яшел уҗым белән кырдагы,
Яңа гына үргә менеп барган
Дәртле җыры белән юлдагы, —
Бар байлыгы белән

Ничек инде
Җирне шулай ташлап китәсең?
Әй, җиңел дә күңел, галәм гизә
Хыял җиле, кая илтәсең?

Әнә, язлар җитә:
җиргә кара!
Уйсу төшләр һаман кар әле,
Язлар алда,
синең ул язларда
Яңгырыйсы җырың бар әле.

## Эңгер-меңгер җитеп килә

*(Кичке этюд)*

Эңгер-меңгер җитеп килә
Бөтерелеп җил уйный.
Җилдә яңгыр исе килә
Яварга, ахры, уйлый.

Эленке-салынкы тора
Авырайган күк йөзе.
Явар да кебек бу яңгыр,
Яумас та кебек үзе.

Бер шук малай
Яңа җәйгән
Юлны үтә йөгереп,
Асфальт өстендә тузанлы
Эзе кала беленеп.

Караңгымы төшеп килә
Болытлы әллә шулай.
Җилдә яңгыр исе килә
Яварга уйлый бугай.

●

Мин төш күрдем бүген.
Җан тетрәткеч
куркыныч төш:
син үлгәнсең, имеш.
Дөнья шуны,
никтер,
исе китми,
тыныч кабул итте.
Тик мин өзгәләндем.
Өндәгедәй тоеп бар әрнүен
җаным телгәләнде.
Ә өндә бит
сиңа
ничә тапкыр
үлем теләдем мин,
буыннарым тартып,
чәчләремне йолкып
өзелеп теләдем мин.
Кешеләргә сине
«Ташлады», —
дип түгел,
«Үлде»,— дип сөйләдем.

Хыянәтеңнән
үлемең
җиңелрәк
булыр кебек иде.
Назга хаклы тәнем
торатаһ булып катты,
күкрәгемә авыр кургаш ятты.
Йөрәккә боз туңды
синең хыянәттән...
Әнә шунда сиңа
үлем теләдем мин.
Шуннан бирле
кешеләргә сине
«Юк!» —дип сөйләдем мин,
«Үлде» — дидем.
«Алыштырды»,
«Ташлады», — димәдем
һәм төшемдә бүген
үлгәнеңне күрдем.
Миннән башка һичкем
кайгырмаган, имеш.
Ул да шунда иде,
яныңа үткәндә
башкалар күк чигенеп
урынын миңа бирде.

Әкрен генә килеп
өстеңә иелдем.
О, никадәр кадерле бу гәүдә.
— Китмә!
Китмә җирдән!
Бу тормышта калган
бар нәрсәне,
кайтып,
бүлеш минем белән.
Өч көн гомерем минем
әгәр алда икән —
көн ярымын
сиңа бирәм.
Бу сүзләрне сиңа
өндә
әйтмәдем мин.

Ничә еллар үткән.
Мин төш күрдем бүген,
син үлгәнсең, имеш.
О, нинди төш!
Ничә еллар үткән,
Бу җаныма
күпме исем
килеп кагылган да,
күпме исем киткән,
алар сине
алыштырмаган да,
күммәгән дә икән.

# *Рифгать Закиров*



*Татарстанның Актаныш районы Усы авылында 1938 елда туганмын.*

*Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, колхозда эшләдем. Соңыннан Минзәлә механизаторлар мәктәбендә укып, Киров исемендәге совхозның Усы бүлекчәсендә тракторчы булдым. 1959 елдан бирле Гремячинск шәһәрендә ике ел бульдозерда эшләп, аннан шахтага төштем. Шахтада өч ел эшләгәч, авырып пенсиягә чыктым.*

*Әдәби иҗат эше белән күптән шөгыльләнәм. Авылда торганда район газеталарында шигырьләр бастыра идем. Берничәсе «Татарстан яшьләре» газетасында да чыкты.*

*Күп язам, күп укыйм. Тик язганнарымның күбесе үземә ошамый. Һәр язганым кемнедер кабатлый сыман...*

*Поэзиягә кечкенәдән үк гашыйк. Яхшы шигырь язган шагыйрьләргә чын күңелдән баш иям.*

## Кары катлы-катлы

Кайберәүләр: «Үги кызга[1] җитү
Сиңамы соң, юләр!
Кышын чәчәк эзләп кеше кырга
Чыгамы соң? — диләр. —
Энем, тормыш «Унике ай» түгел,
Кары катлы-катлы...»

Әмма кызык булса булыр икән
Яшәү шушы чаклы! —
Йөрмәгән дә булыр идем ич мин
Карга бата-чума,
Ышанмасам яз чәчәге җыеп
Алып кайтуыма...

[1] Үги кыз — «Унике ай» әкиятендәге үги кыз.

## Күзге пейзаж

Табигать йөзендә
Моң һәм аптырау:
Иртәләрен инде
Төшә ак кырау.

Су эчәргә килгән
Акбүз ат сыман,
Елга буйларында
Йөзә ак томан.

Урактан соң ялга
Талган Кыр батыр.
Тик чыпчыклар гына
Оча пыр да пыр...

## Кышкы иртә

*(Этюд)*

Зәңгәр иртә. Күктә йолдызлар да
Сүнеп бетмәде әле,
Шыгырдаша инде урамнарда
Кое сиртмәләре.

Билдән карга баткан авыл таңга
Карап басып тора.
Таң яктысы, энә, төн карасын
Куа, ашыктыра...

Тирә-якка җәелә моржалардан
Чыккан төтен исе.
Барысы гади, тик шулай да җанга
Якын бөтенесе.

## Яратмасаң качмас идең

*Вәсимәгә*

Мине күрсәң болан баласыдай
Ник качасың болай?
Качармын да, ахры, котылырмын
Дип уйладың бугай.

Тик ялгыштың: качып син «элмәккә»
Үзең килеп кердең. —
Сөюеңне белми идем әле.
Хәзер инде белдем...

## Урман шаулый

*Һ. Такташка*

Урал чыршылары шаулап куя.
Хәтерләтеп Тамбов усагын.
Ә ак каен нидер көткән кебек
Моңсу тора, җәеп кочагын.

Кергән саен шушы урманнарга
Әллә нишләп җирсим, юксынам;
Урман шаулый, аның бу шавында
Иң кирәкле бер көй юк сыман...

## Чын дус

Юллар күрештерде, таныштырды...
Юллар тартып алды —
Аерылыштык, тик күңелдә якты
Истәлеге калды.

Бу дуслыкны онытмыйдыр ул да.
Мине сагынадыр...
Чөнки дусны табу кыен булса,
Югалтуы авыр.

## Ялгыз каен

Давыл чыкса сыкрый ялгыз каен
Чайкала ул бөгелә-сыгыла, —
Авырлыклар килгәч таянырга
Дуслар эзли сыман тоела...

## Шунсыз булмас

Төн булсаң йолдыз булырмын,
Көн булсаң — якты кояш...
Җил булсаң давыл булырмын,
Барыбер минсез булмас!

Елга булсаң мин каршына
Ятармын диңгез булып.
Гомерең әрәм итә күрмә
Дөньяда минсез торып.

## Кышкы төн

Көне буе ап-ак күбәләктәй
Очып уйнаклаган
Ак кар инде әнә ботакларга
Төшеп кунаклаган.

Тирә-якта моңсу зәңгәр тынлык,
Авыл йоклый күптән;
Ай нурында җем-җем итеп бары
Энҗе ява күктән.

Якты кырда күзне камаштырып
Көмеш нур тирбәлә.
...Мондый сихри төннәр бездә генә—
Бары бу тирәдә.

## Мин таптым да, югалттым да сине

Ничә еллар буе
таныш түгел
Йөзләр арасыннан
эзләгәнне,
таптым — барысын аңлап
Бер күз карашыңнан...

Хыялымда күпме йөргән сурәт
Ул син идең — беләм.
Нинди бәхет булыр иде яшәү
Бергә синең белән!

Әмма... барысын да хәл итте
сиңа
Таба бер атлавым:
Шул ук карашыңны син бүтәнгә
Тагы кабатладың...

...Мин таптым да, югалттым да сине,
Әйтү генә ансат...
Әмма тагы да авыр булыр иде,
Бергә тора калсак?!

*Гариф Гобәй*

# Коръән серләре

## Алтынчы бүлек

«Мөритләр дә, мөртәтләр дә
синең иҗат...»

*Насыйр Хөсрәү.*

### I

### «СЕЗГӘ ДИГӘНЕ ТЕГЕ ДӨНЬЯДА»[1]. «АЛЛА КЕШЕНЕ СЫНАР ӨЧЕН ГЕНӘ ҮТЕРӘ». «ӘЮП ПӘЙГАМБӘР ТҮЗГӘН, СИН ДӘ ТҮЗ».

Тәкъдир, язмыш. Күрәчәк тә диләр. Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый. Язмыштан узмыш юк. Тәкъдиреңдә ни язылган — шуны күрәсең. Өчесе дә бер.

Сугышка бәйләп сөйләгәндә, без язмышның пәйгамбәргә нәрсә өчен кирәк булганын күргән идек. Ләкин бу мәсьәләнең бер ягы гына әле. Язмыш-күрәчәк уйдырмасы Мөхәммәт өчен көнкүрештә сугыштагыдан да кирәгрәк була.

Эш шунда ки, ислам динен кабул иткәндә ярлы-ябага, кол кеше, барыннан да бигрәк, көнкүрешләрен җиңеләйтүне күздә тота бит. Алда күренгәнчә, Мөхәммәт тә аларга гел шуны вәгъдә итеп килә. Ләкин итә генә. Сүзе бар, үзе күренми әле... Ичмасам, теге ахыр заман дигәне дә озаклады, әллә булмый инде... «Көтегез, мин дә сезнең белән көтәм», дигәненә биш былтыр бит инде. Көтеп ала алмыйча, күпме кеше дөнья куйды... Әнә үзенең дә инде бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә, дигәндәй...

Мөхәммәт зарны ишетә, күрә. Хөкүмәт эшләреннән, сугышлардан форсат тапкан саен ахыр заманның инде бусага төбенә җитеп килүе турында сөйләнә. Үтертеп җәннәтен мактый. Ә мул тормыш дисәгез, була ул, хәзер, хәзер...

«Кем дә кем бүләкне бу дөньяда алырга тели, без аңа бу дөньяда бирәчәкбез,— ди ул, алласы исеменнән,— ә кем теге дөньяда тели, аңа бүләк теге дөньяда».

Ләкин шуны белеп тор, әй мөселман, белеп тор һәм алданып куйма. Фани дөнья рәхәте теге дөнья рәхәтләре белән чагыштырганда чүп тә тормый:

«...Чын ләззәт — теге дөнья. Бу дөньядагы ләззәт — алдавыч ләззәт... Бу дөньяда яшәү — үзе дә әле ул алдавыч ләззәт кенә». «Биредәге фани дөнья — мәзәк кенә, уен гына. Чын тормыш теге дөньяда».

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 139, 182 аятьләр.
«Тимер» сүрәсе, 19—20 аятьләр.
«Урмәкүч» сүрәсе, 64 аять.)*

---

[1] Ахыры. Башы 1—5 саннарда.

Илһам бер килсә килә бит ул. Мөхәммәт бу кисәтүен тирәнәйткәннән тирәнәйтә барып, гарәпнең хатынын, бала-чагаларын да алдавыч ләззәтләр җөмләсенә кертә. Хәзер аларны хәтта «күңел аздыргыч» ди.

Белмәсәгез белегез, «Сезнең мал-мөлкәтегез дә, бала-чагаларыгыз да күңел аздыргыч кына. Бөек бүләк — алла хозурына баргач».

«Кешеләр хатын-кызга, бала-чагага, алтын-көмешкә кызыгучан, кешеләр йөгерек атларга, мал-туар көтүләренә хирес. Ләкин болар фәкать-фәкать дөнья өчен генә, чын ләззәт — алла хозурына баргач».

Аннан сезнең ул хатын, бала-чагаларыгыз сезнең өчен куркыныч та әле:

«Иманлы кешеләр! Сезнең хатыннарыгыз, балаларыгыз арасында сезгә дошман кешеләр бар. (Булуы мөмкин генә дә түгел — бар! — Г. Г.) Алардан саклана күрегез».

*(Коръән, «Алдашу» сүрәсе, 14—15 аятьләр, «Гыймран» сүрәсе, 12 аять.)*

Фәкыйрь-фокара, кол кеше фани дөнья ләззәтенә күз уйнатмасын өчен Мөхәммәт ниләр генә, нинди әкиятләр генә уйлап чыгармый! Әлбәттә, үзе түгел, алласы:

«Без бераүләрнең мөлкәтен күп иткәнбез икән, бер дә кызыкмагыз. Муса заманында Карун исемле бер байга без малны хисапсыз күп итеп биргән идек. Амбар ачкычларын гына да әллә ни хәтле кеше күтәреп йөрмәле иде. Малга хирес кешеләр аңардан үлеп көнләшә иделәр, безнең дә шундый байлыгыбыз булсачы, дияр иделәр... Шуннан без Җиргә Карунны йорты-ние белән кабып йотарга куштык. Моны күреп, аның малына кызыккан кешеләр, ярый әле, Карун урынында булмадык, алла биргәнгә шөкер итеп торырга кирәк икән шул, диештеләр».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 36 аять, «Хикәя» сүрәсе, 76—82 аятьләр.)*

Ягъни мәсәлән, әгаһ бул, әй мөселман! Дөнья малының әнә шундые да була аның...

Моңа каршы гарәпләр:

— Әй син әйт аллага, безгә андыен бирмәсен, әйбәтен бирсен,— диләр.

Мөхәммәт бүтәнчә әйтә алмый:

— Аңламагач та аңламассыз икән,— ди ул.— Җәннәт хәтле җәннәт бизәкләрен фани дөньяның ялган бизәкләренә ничек алыштырмак кирәк?

— Байларныкы да ялганмы?

— Ялган.

— Әй алар зарланмый үзе...

— Әйе, әйе... син әйт аллага, безгә дә хәзергә шул чын түгелен генә биреп торсын байларныкы ишесен...

Фәкыйрь кешенең уен бу дөньяның «ялган бизәкләреннән» читкә дүндерү, җәннәт ләззәтләре белән юату Мөхәммәткә кадәр дә бар. Коръәнгә кадәрге дин китаплары, хосусән Инҗил бу турыда аеруча гыйбрәтле итеп яза. Иң әйбәте — фәкыйрь яшәү инде аның,— ди ул,— кара аны, ялгыш баеп китә күрмә... Әй-йе, ул мескен байларның хәлләре теге дөньяда яман да мөшкел булачак: «Дөя инә күзеннән үтсә үтәр, бай җәннәткә керә алмас».

*(Инҗил, Марк, 10 бүлек, 25 нче җөмлә.)*

Мөхәммәткә бу аять бик тә охшый һәм ул Мәккәдә чагында ук инде, шул аятькә нигезләп, менә нәрсә дип әйткән була:

«Зиннәтле рәхәт тормышны без бу дөньяда теләгәннәргә тутырып бирәчәкбез. Алар һичнәрсәгә мохтаҗ булачак түгелләр. Аның каравы теге дөньяда аларга җәһәннәмнән гайри нәрсә булмаячак. Хәтта әнә бу дөньяда кылган гамәлләре дә аларга берничек тә файда итмәячәк».

*(Коръән, «Һуд» сүрәсе, 18—19 аятьләр.)*

Тагын шул мәгънәдә җавап бирергәме? Ләкин бу бит мөселман бае никадәр генә тәкъва булмасын, теге дөньяда җәһәннәм төбеннән чыга алачак түгел дигән сүз! Ярамый, моның өчен байлар рәхмәт әйтмәс!.. Хәзер Мөхәммәт ярлылар белән колларны кайгырткан кебек итеп, үзегез өчен әйтүем, дигән кебек... болай ди:

«Сез игелекне бу дөньяда телисез. Алла сезгә теге дөньяда бирергә тели».

Ләкин халык моңа һавадагы торнага караган кебегрәк карый.

Укучы төшенгән булса кирәк, алла (чыны: Мөхәммәт) бу аятьләрне бүләкне фани дөньяда бирә алмавын, «кара халык»ның күлмәгендәге 40 ямауны 39 га да калдыра алмавын томалау өчен сибә. Бер үк вакытта «кара халык»ның, ярый алайса, фани дөнья үтәр дә китәр, мәңгелек йортка күчкәч бирерсең, дигәнен өмет итә. Ләкин халык бүтәнчәрәк әйтә:

— Шулайдыр,— ди ул, әдәп сакларга тырышып,— ләкин ачтан кырылабыз бит, пәйгамбәр...

Моңар каршы «күктән» шундый вәхи төшеп житә.

«Түзегез, гыйбадәт кылыгыз. Алланың ярдәмен гыйбадәт кылудан эзләгез, түзүдән эзләгез. Алла түзүчеләр беләң! Без бит сезне сынар өчен генә ач-

яланга ч итәбез, сынар өчен генә ачтан үтерәбез. Түзгәннәрне яхшы хәбәр белән шатландыр».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 150 аять.)*

Әйтерең бармы!.. Моны да яхшы хәбәр димәсәң!.. Ач-ялангач итә, ачтан үтерә... Ничек шатланмыйсың да, ничек елый-елый бер ходайга рәхмәтләр әйтмисең!.. Аннан сынар өчен кирәк ди бит...

Әлбәттә, монысы да сәер ярым сәер. Үзе җир астында йөргән кырмыскаларга хәтле күреп торам, хәтта аларның уй-теләкләрен беләм, ди, ә безне белми, безне сынарга кирәк. Шул сынау өчен динле итте, сынау өчен намаз укыта, ураза, хаҗ, садака... Сынар өчен яһүдләр белән кырылыштырды, Кораешлар белән сугыштырды, ун ел буена сугыштан кайтып кергән юк. Әле һаман ышанмый, һаман сыный!.. Иа, читен лә аңлавы бу алла дигәннең хикмәтләрен...

Мөхәммәтнең түзәргә, ачтан үлгәндә дә зарланмаска өндәгән аятьләренә көч-куәт бирү теләге белән, соңга таба дини язучылар, «Пәйгамбәрләр» сүрәсенең 83—84 аятьләренә нигезләп, түбәндәге әкиятне уйлап чыгаралар:

Борын-борын заманда Әюп дигән пәйгамбәр бар иде. Бай дигәндә дә бай. Куйлары 7 мең, дөяләре 3 мең, алтын-көмеш бихисап. Көннәрдән бер көн аллаһ тәгалә Шайтан ләгыйнгә моның мал-туарын һәлак итәргә боера.

— Баш өсте, алла! — Шайтан бу эшкә рәхәтләнеп алына. Кырга чыгып, бер кәррә сулыш өрүе була,— Әюп пәйгамбәрнең бөтен мал-туары егылып үлә. Шуннан Иблис ләгыйн тиз генә бер көтүче кыяфәтенә керә дә мәчеттә намаз укып утырган Әюп пәйгамбәр янына йөгерә:

— Малларың һәлакәткә очрады, пәйгамбәр.

Әюп әз генә дә уфтанмый. Алла үзе бирде, үзе алды, хәерле каза булсын, ди.

Шуннан алла Иблискә Әюп пәйгамбәрнең игеннәрен һәлак итәргә куша.

— Баш өсте, алла! — Иблис ләгыйннең, басуга чыгып, бер кәррә сулыш өрүе була,— Әюпнең бөтен игеннәрен сәмум җиле ялап кына ала. Шайтан монысын да Әюпнең үзенә килеп әйтә. Әюп янә, алла үзе бирде, үзе алды, хәерле каза булсын, ди.

Хәзер алла Шайтанга Әюпнең бала-чагаларын һәлак итәргә куша. Шайтан күз ачып йомганчы пәйгамбәрнең балаларын буып ташлый. Монысын да Әюпнең үзенә килеп хәбәр итә. Әюпнең тагын шул җавап: «Алла үзе бирде, үзе алды, хәерле каза булсын...» Әюп пәйгамбәр өенә дә кайтып тормый, балаларын күмәргә дә бармый (менә бу ичмасам, аллаяр, менә бу ичмасам изге!), намазын дәвам итә...

Моның белән дә алдыра алмагач, Иблис ләгыйн алла боерыгы белән Әюп пәйгамбәрне авыруга сабыштыра. Тәмам бетәшә Әюп. Бөтен тәне — эрен, сары су, мыж корт... ул сасыны әйтеп бетерә торган түгел... Хезмәтчеләре түзә алмыйча, ташлап чыгалар. Ниһаять, халык пәйгамбәрне шәһәрдән куа. Әнә шунда да зарланмый Әюп пәйгамбәр. Ниһаять, Иблис ләгыйн, алла әмере буенча, бик чибәр яшь егет кыяфәтенә кереп, Әюпнең хатынын аздырырга керешә!.. Монысына да түзә Әюп:

— Хәерле каза булсын...

Ә алла Әюп пәйгамбәрне нигә шулай газаплый дип беләсез? — Адәм балаларының нинди түзем икәннәрен күрсәтеп, фәрештәләрне шаккатыру өчен! Фәрештәләр: һа-а, диләр, ай-яй, диләр, үлеп шаккаталар. Ә алла исә Әюп пәйгамбәргә түземлегенең әҗерен бирепме бирә. Мал-туары тиз көндә элеккегә караганда ике өлешкә җитә. һәлак булган угыллары урнына хатыны янәдән 20 угыл табып бирә.

Гыйбрәтле дигәндә дә гыйбрәтле әкият икәнен исбат итеп торуның кирәге бармы? Әюп пәйгамбәрнең шундый түзем икәнен фәрештәләргә күрсәтеп шаккатыру өчен алланың бер гөнаһсыз ун сабыйны будыртып үтертүе, шуның белән аналарының бәгырен пәрә-пәрә китерүе, халык ачтан үлеп яткан бер заманда 7 мең куйны, 3 мең дөяне кырып салуы үзе генә дә ни тора, әйе бит!? Ә бу изге эшне алланың Иблис ләгыйннән эшләтүе, алла башы белән шул мәлгуньнең ярдәменә мохтаҗ булуы?!. Пәйгамбәр башын күтәрә алмыйча чирләп ятканда, аның хатынын Шайтаннан мәсхәрә иттерүе... Хәер, алланың андый хикмәтләренә укучы күнеп беткәндер инде... Аннары хәзер мәсьәлә аллада да түгел. Дин әһелләре бу әкият белән мөэмин-мөселманны Әюп пәйгамбәр көненә калганда да зарланмаска, түзәргә үгетлиләр. Янәсе, бәлкем алла сине дә сынар өчен вә һәм дә фәрештәләрне шаккатыру өчен генә ач-ялангач калдыргандыр... Алласына ышангач, монысына да ышанырга кирәк, әлбәттә.

## 2

## ПӘЙГАМБӘР БИТЛЕГЕН САЛА. «ПАТШАЛАР, ТҮРӘЛӘР АЛЛАНЫҢ ҖИРДӘГЕ КҮЛӘГӘЛӘРЕ». «ӘКРЕН-ӘКРЕН ХӘЙЛӘСЕНЕ КИТЕРӘДЕР КӨЙГӘ БУ...»

«Түзегез, чын ләззәт җәннәттә» уйдырмаларыннан сәхәбәләрнең бер ишеләре юаныч табалар. Инде шуңарга тәкъдир уйдырмасын да китереп өстәгәч, пәйгамбәрнең позициясе байтак ныгый. Ул хәзер, тәкъдир уйдырмасын корал итеп, бер дә тартын-

мыйча, үзенең чын йөзен ача. Аның төп теләге сәүдә, базарларның тәүге шанын кайтару бит, шуны тәрәкъкый иттерү. Ә бу — берәүләрне бөлдерү, ачлы-туклы яшәтү хисабына икенчеләрне баету юлы белән генә мөмкин. Мөхәммәт хәзер моны ачыктан-ачык әйтә. Әле кайчан гына «Хатын-кызлар» сүрәсенең 44 аятендә, «Ачыклау» сүрәсенең 9 аятендә «Алла кешеләрне тузан бөртеге кадәр дә җәберләми», «Без тормыш кирәк-яракларын һәрбер сораган кешегә тигез бүлеп бирербез», дип шапырынган алла (чыны пәйгамбәр), күзен дә йоммыйча:

«Алла үзе теләгән кешегә (генә) ярдәм итә. Ул бөек, ул рәхимле бит, ул шәфкатьле бит»,— ди. «Без үзебез теләгән кешеләргә (генә) тормыш кирәк-яракларын мул итеп бирәбез»,— ди эле тагын.

*(Коръән, «Рим кешеләре» сүрәсе, 4 аять; «Күк күкрәү» сүрәсе, 13 аять, һ. б. сүрәләр, һ. б. аятьләр.)*

Шулай итеп, бөек шагыйребез әйтмешли, «әкрен-әкрен хәйләсене китерәдер көйгә бу».

Безнең заманда булса, моны эшләгән кешене самодур диярләр иде. Мөхәммәткә болай дип әйтүче буламы-юкмы, мәгълүм түгел. Мөхәммәт исә алласы исеменнән гарәпләргә шуны әйтә. Һәм сезгә ялган, миңа чын — ул бу мәсьәләдә тагын да тирәнгәрәк кереп, алдагы аятьләренә шундый койрык тага:

Алла сезгә әйтергә кушты,— ди Мөхәммәт.— «Кешеләрнең бер ишеләрен югары дәрәҗәле итеп, икенчеләрен түбән дәрәҗәле итүче без үзебез,— диде, бу хәл кешеләрнең бер ишеләре икенчеләренә хезмәт итеп торсыннар өчен кирәк, диде».

*(Коръән, «Бизәкләр» сүрәсе, 31 аять.)*

Инде монысы — оятсызлыкның чигенә чыгу икәнен, колбиләүчелекне, эксплуататорларны яклау, кара халыкны күзенә карап талау, канын эчү икәнен заманының аек фикерле кешеләре Мөхәммәтнең күзенә терәп әйтәләр. Ләкин пәйгамбәрнең бәхәсләшеп торырга теләге дә, вакыты да юк. Алда Сирия, Иран, Ирак. Афганы да кул җитмәс җирдә түгел... Хәзер Мөхәммәтнең уй-теләкләре шул илләргә юнәлгән. Сүзне кыска тота. Ике төрле аңларга урын калдырмаслык итеп, катгый рәвештә кисәтеп куя:

«Ә инде алла берәүне түбән дәрәҗәле иткән икән, аны һичкем, һичкем югары күтәрә алмый» — бетте китте.

*(Коръән, «Хаҗ» сүрәсе, 19 аять.)*

«Халыкның үлчәве алла кулында. Алла бәгъзе халыкны күтәрер, бәгъзесен төшерер. Кыяматкәчә шул рәвештә кылыр».

*(370 нче хәдис.)*

Ягъни, байлар белән булышма, коллык чылбырларын өзәргә маташма, барыбер эш чыгара алмассың. Теге бай икән, бу аның язмышы. Син ярлы — монысы синең язмыш. Бу мин уйлап чыгарган нәрсә түгел, хак тәгалә сүзе. Ул инде бу хакта борын заман ук, Идрис пәйгамбәрне җибәреп, кешеләрне ярлыларга, байларга, түрәләргә, әмирләргә, патшаларга аерып куйган. Алланың бу хөкеменә каршы бару — үтә хилаф, үтә язык эш булыр иде... Ә нәкъ синең түбән дәрәҗәдә булып, нәкъ мөнын югары дәрәҗәдә булуы — язмыш эше. Күрәчәк. Тәкъдир. Башыңны аска бөк тә ләббәйке дип тик тор. Зарланудан, алла биргәнгә риза булмаудан да зур гөнаһ юк, ишетсен колагың! Аннан синең алла хөкеменә риза булмыйча, мыек кабартып йөрүләрең синең үзең өчен бер дә файдалы түгел.

Чөнки:

«Патша һәм солтаннар (безнең күзгә генә синең белән минем күк булып күренәләр — Г. Г.) алар алланың җир йөзендәге күләгәләредер. Бер кеше патша һәм солтаннарны хөрмәт итсә, аны алла да хөрмәт итәр, хурласа, аллаһ тәгалә аның үзен дә хур кылыр».

*(491 нче хәдис.)*

Күрдегез, кая китереп җиткерде пәйгамбәр үзенең шәригатен!.. Бу бит патшалар белән солтаннар — кимендә пәйгамбәр дәрәҗәсендәге изге вә илаһи затлар дигән сүз. Коръәнгә һәм Мөхәммәткә ышансаң, рәхим итеп, монысына да ышан, әй мөселман! Ышан һәм, кара аны, ул солтан вә патшаларга тел-теш тидерә күрмә, нәразыйлык күрсәтмә. Киресенчә, алла үзеңне хөрмәт итсен дисәң, бик әйбәтләп хөрмәт ит үзләрен!..

Коръәнгә кушып, пәйгамбәр бу рухтагы хәдисләрне яңгыр урынына яудыра. Патшалар белән солтаннарны гына түгел, һәрбер түрәне, эш башындагыларның һәммәсен кадер-хөрмәт итәргә боера. Аларны җил-яңгырдан саклый:

«Эш башындагыларга буйсын, сүзләрен тыңла. Хәтта ул кешеләр кечкенә башлы кол булсалар да», ди.

Пәйгамбәр хәтта аларны аерып йөртергә дә кушмый. Уптым илаһи:

«Барча түрәләргә буйсын», ди.

*(124, 116 нчы хәдисләр.)*

Ул инде хәзер ярлы-ябагайны мыскыл итүдән дә тартынмый. Һәм башы бу юнәлештә эшләгәндә пәйгамбәр әдәби образларны ярыйсы ук оста куллана:

«Яхшы утырдаш белән яман утырдашның охшашы — исле май төягән кеше белән өргеч өрдерүче тимерче кебидер. Исле май төягән кешенең маен сатып алып файдаланырсың, аңардан хуш ис табарсың. Әмма тимерче янында торсаң, киемең яндырырсың, начар ис табарсың».

*(269 нчы хәдис.)*

Мөхәммәт бу чорда инде сәясәт кешесе буларак, үз сыйныфының кешесе буларак, үсеп килгән дәүләт башлыгы буларак, кешеләрнең югарыга-түбәнгә бүленүләренең нигә кирәк икәнен, түбәннәрнең югарылар өчен тир түгүе, бил бөгүе зарур икәнен, шулай булмаган сурәттә югарыларның һәлак булачагын яхшы аңлый. Ул, хәтта, сыйныфлар булмаса, диннәр дә, ислам дине генә түгел, бер дин дә булмас иде дигән фикерне бик ачык итеп әйтә. Менә аның бу хакта алла авызы белән әйткән үз сүзләре:

«Әгәр алла берәүләрне икенчеләре белән тотып тормаса, (ягъни ярлы байга хезмәт итеп тормаса — Г. Г.) монастырьлар, чиркәүләр, синагоглар һәм мәчетләр җимерелеп бетәр иде».

*(Коръән, «Хаҗ» сүрәсе, 41 аять.)*

Бераз тыныш ясап алу өчен күктән җиргә төшик әле.

Түбәннәр югары менә алмас, югарылар түбән төшә алмас, ягъни, берәүләрнең икенче берәүләр өчен тир түгеп яшәүләре — мәңгелек закон дигәне акланмады, ә менә мәчетләр, чиркәүләр турында әйткәне раска килде. Җир шарындагы халыкларның өчтән бере яши торган социалистик илләрдә «түбәннәрнең югарыларны тотып торуы» бетерелү белән бер үк вакытта монастырьлар, чиркәүләр, синогоглар, мәчетләр җимерелде.

Кайберәүләрнең бу урында мыек астыннан көлеп, җимерткәч... диюләре мөмкин. Алдагы аятьне кайтадан укыгыз, бу Коръәнгә каршы килү. Икенчедән, «җимерткәч» асылда дошман сүзе, обыватель сүзе. Дөрес, Советлар хөкүмәте диннәр белән дус түгел. Чөнки хөкүмәт диннәрнең, Мөхәммәт әйткәнчә, түбән сыйныфларның өстен сыйныфларга тирләрен түктерү, билләрен бөктерү өчен уйлап чыгарылган чара икәнен белә, аның хезмәт халкы өчен кирәксез икәнен, зарарлы икәнен, агулы афиюн икәнен белә. Шулай да җимерттерми, берәүне дә, һич берәүне дә дин мәсьәләсендә көчләми. Әйтергә кирәк, көчләү юлы белән дин ташлату мөмкин дә түгел. Алла, Коръән һәм Мөхәммәткә ихлас күңеле белән ышанган мәчет картына, уйнап кына: аллаһнан ваз кичмәсәң, җиде кат тиреңне туныйбыз, дип әйтеп кара әле син. Ул сиңа: 70 тапкыр тунатырга әзермен, әмма ләкин алладан ваз кичәр хәлем юк, бигайбә, энем, диячәк. Һәм ул үзенчә хаклы. Бигрәк тә аның инде бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә дә булса. Намусыма каршы барып, фани дөньяда тагын бернечә ел яшәүгә караганда, нәтиҗәдә мәңгелек җәһәннәм кисәве булуга караганда, шәһит китеп, хәзер кабергә керәм дә ятам, ә күземне ачып җибәрүгә кыямәт һәм мин җәннәттә, дип уйлый ул.

Андый ихлас күңелдән ышанучы түгел, алланы, уза китсә, ике гаеттә һәм берәр бәла-казадан котылу әзләгәндә генә искә алучы да, иманы яныл беткән шәм төпчеге кебек менә сүнәм — менә сүнәм хәленә килгән кеше дә диннән алай ансат кына ваз кичми. Ә шуннан алла булып куйса, ди ул. Курка. Әйтәсем килгәне: кешенең динен, обывательләр әйткәнчә, җимерттереп булмый. Диннән ваз кичү өчен, аңар, әүвәл башлап, Коръәннең үзен белергә кирәк. Юк, мәчеттә мулла сөйләгәнен түгел, Мөхәммәт язганын, менә хәзер сезнең белән без тикшерә торганын. Тагын элементар рәвештә генә булса да, табигать законнарын өйрәнергә кирәк. Өйрәнергә һәм чагыштырып карарга. Коръән, мәсәлән, Кояшны тәңренең бирмеш көне кичен сасы суга төшеп баный, ди бит. Ә фән, беркая да, беркайчан да баемый, ди. Хәер, бу очракта кайсы хаклы иде икәнен белү өчен хәтта фәннең дә хаҗәте юк. Июль башларында Казанда Кояш баюга Владивостокка шалтыратып сора, бездә кояш чыкканга бер сәгать инде диярләр. Котып белән хәбәрләшә алсаң, шалтырат. Бездә Кояш чыкканга өч ай инде, тагын өч айсыз да батмый әле, диярләр. Менә шулай, бер ягыңа фәнне куеп, муллаларның тикшерергә, шикләнергә кушмаган дигюләреннән курыкмыйча, тикшереп чагыштырып кара әле... Соңгы 40—45 ел эчендә диннән ваз кичүчеләрнең күбәюе — шул рәвештә тикшерүнең, тикшерүдән курыкмауның татлы җимеше. Революция булу белән фән, техника серләре әз-мәз генә булса да, кешенен ихтыярыннан тыш булса да аңына үтеп керде. Кеше (әлбәттә, кешенең уйларга курыкмаганы) чагыштырып, үлчәп карады һәм... илаһи дигән, гомер буена табынып килгән Коръән бу кеше каршында тузга язмаган әкият булып калды. Ул мәчеттән ваз кичте, диннән ваз кичте. Тора-бара бу — массовый хәрәкәткә әйләнде. Обыватель, әлбәттә, монда да мыек астыннан көлеп, өстән кушкач, диде. Коръән белән шәригатьне биш бармагы кебек белгән, бөтен гомере шуларны өйрәнеп, шуларны өйрәтеп үткән мәшһүр мөхтәсип, атаклы мулла, мәрхүм Рәсүлев моннан ничә генә ел элек телевизор аша ислам динен фаш итеп чыгыш ясаган көннәрдә дә шулай — «өстән кушкач», диделәр. «Кил, сөйлә, акча бирәбез, киреләнсәң, әшең харап дигәннәр икән аңар... Болай ул үзе үтә динле кеше икән...»

Ә нигә муллаларның бөтенесе ваз кичми соң? Ваз кичмәүчеләр ике төрлегә бүленә. Беренчеләре: Коръәннең төбенә төшеп җитмичә, үзе кебек надан мулладан гына укып мулла булучылар, яки әтиләре мөселман булганга гына мөселман булып йөрүче, асылын белергә теләүдән куркып яшәүче фанатиклар. Андыйлар турында шагыйрь Сәгыйть Рәмиев (ул үзе дә мулла улы) революциягә кадәр үк инде бик тә образлы итеп болай дип әйткән иде:

«Аталар сөйли бабадан ишетеп,
Балалар шуны хуплыйлар...»

Һәм без бу ишеләрне әллә ни гаепләмибез. Безне икенче төрлеләр борчый. Һәм без боларын гафу итә алмыйбыз, хәтта дошман күрәбез. Ник? Чөнки аның үзенең алла, Коръән һәм Мөхәммәт белән алыш-биреше өзгәнгә биш былтыр. Ә көн дә биш тапкыр халыкны мәчеткә җыеп агулавын дәвам итә. Ник? Моңар җавапны халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай бирде. Шагыйрь бу ише муллаларның вөҗданнарын май каплаган булуны, күңелләрендә утлары сүнгән булуны әйтеп, шигырен мондый сүзләр белән тәмамлады:

«Йөриләр бу кешеләр сөйрәлеп һәр дәм бәлешләргә,
Теләнми нишләсеннәр: кабилият беткән эшләргә».

Муллалар шулайдыр... Ә гади мәчет картлары? Әби-бабалар? Гомумән динле кешеләр? Укучы иптәштә мондый сорау туачагын белеп, мин хәзер үк җавап бирел китүне тиеш таптым.

Бездә кешеләрне динлеләргә, динсезләргә аерып йөртү юк. Динсез дә, динле кеше дә Конституция нигезендә бик хаклы буларак бер үк хокуклар белән файдалана. Ул динсез белән бер сафта торып революция ясады, илне Гитлер баскыннарыннан саклады, хәзер бер сафта торып, коммунизм төзү эшендә эшли. Әйбәт эшли. Безгә динле иптәшләрнең колхоз-совхоз кырларында, завод-фабрикаларда башкаларга үрнәк күрсәтүләре билгеле. Кайтадан әйтәм, динле кеше — безгә ят түгел, ләкин шул ук вакытта, аңар дин мәсьәләсендә кайбер хакыйкатьне әйтү безнең бурыч.

Укучым, гафу, бераз читкә кителде.

Диннән ваз кичүнең бернинди дә өстән әйтүләр буенча эшләнмәгәнен исбат итү өчен тагын бер дәлил. Безнең гасыр — һәртөрле диннән, һәртөрле аллалардан ваз кичү гасыры. Һәр илдә, бигрәк тә укымышлы илләрдә шулай. Мәсәлән, Франциядә 1900—1945 еллар эчендә һәр өч руханиның берсе, 45 меңнең 15 мене, руханилыктан ваз кичте, алладан ваз кичте. Ә халык үзе? Эшче кварталларда бу процесс искиткеч көчәйде. Анда хәзерге көндә халыкның нибары йөздән бере чиркәүгә йөри. Бу мәсьәлә белән кызыксынучы галимнәр, болай барса, 30—40 ел үтү белән илдә бер рухани, бер динле кеше калмаячагын әйтәләр. Уйлап карыйк, Франциядә, дин — хөкүмәтнең терәге булган Франциядә, руханиларның диннән ваз кичүләре — өстән кушу буенча эшләнә дип әйтергә зәмин бармы? Ә Италиядә? Анда соңгы елларда гына да берничә мең рухани шулай ук чиркәүне ташлап чыкты, алладан ваз кичеп кенә калмады, күбесе Коммунистлар партиясенә керде![1] Италиядә, дин — хөкүмәтнең терәге булган Италиядә, руханилар бу адымны өстән кушу буенча атлыйлар дияргә зәмин бармы? Юк андый зәмин. Зәмин — су белән ут килешә алмаганы кебек, фән белән диннең килешә алмавында. Зәмин — чорыбызның атаклы шагыйре Һади Такташ әйткәнчә, ике миннең берсе җинүдә, мүк басканын, тутыкканын таза, сау акыл җиңүдә.

Тагын төп мәсьәләдән аерылдык. Сүзебез түбәннәр югарыларны тотып торырга тиеш булулары турында иде бит әле. Аек фикерле кешеләр Мөхәммәтнең бу кешелексез кануннарына каршы борын заманда ук баш күтәрәләр. Мөхәммәттән нибары 300 ел соң яшәгән бөек таҗик шагыйре Гомәр Хәйям Коръән боерыгы буенча патшалар, әмирләр, байлар рәхәте өчен генә яшәргә мәҗбүр ителгән хезмәт ияләренең аһ-зарын чагылдырып, җир йөзендә бөтен кешеләр өчен тигез-рәхәт тормыш турында хыяллануп, аллага болай дип эндәште:

«Синдәгедәй кодрәт булса миндә әгәр,
Бу дөньяны сүтәр идем, җимрер идем.
Бар адәмнәр тигез-рәхәт яши торган
Бүтән дөнья иҗат итеп бирер идем».

Шул ук заманнарда яшәгән икенче бер бөек таҗик шагыйре Әбү Мансур Дәкыйкый, тәкъдир, язмыш уйдырмаларына каршы чыгып, аллага тагын да кыюрак сүзләр белән хитап итте:

«Һәр ярлыга хәерчелек киеме биреп,
Алтын кием кидердең һәр явызга.
Үзең төсле явызларны сөясең син,
Шәфкатьле син шундыйларга фәкать, дөнья».

---

[1] «Известия», 1964 ел, 101 сан.

3

## «СИН БИРҮЧЕ ЯМАНЛЫКНЫ, МИН КЫЛУЧЫ». «САКЛАНУ — ТӘКЪДИРГӘ ФАЙДА ИТМИ». ТӘКЪДИР ТАЯГЫНЫҢ ИКЕНЧЕ БАШЫ

Тәкъдиргә ышану Мөхәммәт уйлап чыгарган нәрсә түгел, бу хорафат гарәпләрдә әллә кайчан бар. Мөхәммәт исә аны «камилләштерә» килеп, кешенең кул-аягын, миен, бөтен барлыгын чылбырлап куя. Кешене үз ихтыяры белән кыл да кыймылдата алмый торган мәхлук итеп күрсәтә:

«Без кешеләрнең язмыш кошларын муеннарына тагып куйдык», ди ул алласы исеменнән.

(*Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 14 аять.*)

Алай гына да түгел. Синең язмышың үзең туганчы ук күктәге Ләүхелмәхфүз исемле тактага язылып куелган, шунда язылганнан тыш син селкенә дә алмыйсың, әй бәндә! Дөньяда кылачак яхшы гамәлләрең дә, яманнары да язылган анда.

«Кешенең күңеленә бозыклыкны да, яхшылыкны да салучы алла үзе». «Сезнең җаннарыгызга үзегез туганчы ук язылып куелган язмыштан гайри бер нәрсә дә булачак түгел».

(*Коръән, «Кояш» сүрәсе, 8, «Тимер» сүрәсе, 22 аятьләр.*)

Җан ияләре генә түгел, җансыз нәрсәләр дә алла кушуы буенча хәрәкәт итә: «Алла рөхсәтеннән башка агачтан яфрак кына да өзелеп төшми».

(*Коръән, «Хайван» сүрәсе, 59 аять.*)

Тәкъдирдә бичара куянны кайсы ерткыч кайчан ботарлап ташлаячагына кадәр язылган. Бүген төнлә кайсы төлке ятимә карчыкның кайсы тавыгын буып алып чыгып китәсенә хәтле язылган. Әнә бер чебен тәрәзә пыяласына кунып битен юып торамы? Аның битен ничә тапкыр сыйпыйсына кадәр язылган. Башта уң аягы белән сыйпарга дип язылган икән, суңы белән сыйпый алмый инде ул битен. Борчаның синең кай төшеңне тешлисе, күпме каныңны эчәсенә кадәр язылган. Мөхәммәт булып Мөхәммәт үзе дә фәкать алла кушканны гына эшли ала. Хәтерегездәдер, ул Мәккә кяферләренә, мин илче генә, диде, мин сезгә алланың сүзләрен җиткереп торучы гына, диде... Үз ирке белән йөрү хокукы Мөхәммәт белән алланың иң явыз дошманы булган Иблис ләгыйнгә генә бирелгән. Аннары теге мәҗүсиләр патшасы Зөлкарнәйнгә, аңа да гомерендә бер генә тапкыр:

«Зөлкарнәйн кояш баешына килеп җитеп, кояшның баеп суга батканын күрде. Сасы су янында кешеләр дә бар иде. Без Зөлкарнәйнгә әйттек: «Иа, Зөлкарнәйн, син ул кешеләрне теләсәң тотып җәзала, теләсәң мәрхәмәт кыл дидек».

(*Коръән, «Мәгарә» сүрәсе, 82—84 аятьләр.*)

Сүз дә юк, кешене бу рәвешчә бөтенләй ихтыярсыз итеп күрсәткән тәкъдир уйдырмасы Мөхәммәт пәйгамбәргә сугыш кырында әйбәт хезмәт итте. Ярлыны байларга буйсындыруда, коллык богауларын ныгытуда хезмәте аеруча зур булды. Гарәбстан туфрагына сәүдә капиталының тәүге шаның кайтаруда шулай ук. Ләкин бу әле тәкъдир таягының бер башы гына иде. Тиз арада, дөнья йөзендә мин дә бар бит әле дип, аның икенче башы калкып чыкты. Монысы белән Мөхәммәт пәйгамбәр, үзе дә сизмәстән, ислам диненең тамырына сукты. Уйлаудан, фикер йөртүдән, Коръән белән бәхәскә керүдән шүрләгән мөселман хәзер болай диде: бәс язмыш икән, язмыштан узмыш юк икән, күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый икән, бозык юлда йөргәнем өчен мине хөкем итеп буламы? Эчәм, тартам, урлыйм, талыйм, суям. Моның өчен мине хөкем итеп буламы? Юк. Чөнки бу минем язмыш. Син мәктәп яшеңнән бирле намазлык өстендә, кулыңда тәсбих, телеңдә зекер. Моның өчен сине мактап буламы? Юк. Чөнки бу — синең язмышың. Син дә, мин дә «муеныбызга тагылып куелган язмышыбыз» кушканча йөрибез, күрәчәгебезне күреп йөрибез Без икебез дә сәхнәдәге артистлар. Сценарийда, сиңа ашагач, амин итәргә дип язган икән, син амин итәсең, аңа чебенләп алырга диелгән икән, ул, бөтен шартын китереп, чебенли. Ник амин итмәдең, ник чебенләдең, дип битәрләргә режиссерның хакы бармы? Менә атом. Ясаучысы аны дару итеп ясаган икән, рак чирен дәвалый, бомба итеп ясап, шәһәр өстенә ташлый икән, берничә мең кешене әһ тә итәргә бирмичә, кырып сала. Нигә рак чирен дәваламадың, нигә кешене һәлак иттең диярга ясаучының хакы бармы?

Тәкъдир, язмыш дия-дия, Мөхәммәт кешене һичбер нәрсәгә ихтыярсыз итеп, сәләтсез итеп калдыра. Катлаулы техниканы, спутникларны, атом коралларын, ракеталарны әйткән дә юк, калкан ясауга, кием тегеп киюгә дә кеше үз акылы белән ирешә торган түгел, бу эшләргә кешене алла үзе өйрәтә. Хәтерегездәдер, бу гыйлемлекне өйрәтү өчен махсус пәйгамбәрләр җибәрде. Идрис белән Давытны.

(*Коръән, «Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 80 аять.*)

Кеше үз акылы белән үзенә сукмак кына да сала беләчәк түгел, сукмакларны дөньяны яратканда алла үзе салып куйган.

*(Коръән, «Бизәкләр» сүрәсе, 9—12 аятьләр.)*

Хәтта әнә күләгәләр дә алла иркендә. Күләгә ул, беләсегез килсә, әйбердән төшми дә әле, мөстәкыйль зат:
«Күрмисеңмени, алла ничек итеп күләгәләрне озынайта. Әгәр теләсә, ул аларны бер килеш калдырыр иде».

*(Коръән, «Форкан» сүрәсе, 47 аять.)*

Мөхәммәт үзенең бу ялгышын үзе төшенгәндерме, төртеп күрсәтүче булгандырмы — гомеренең азагында сискәнеп китә. Каш ясыйм дип, күз чыгарганмын бит! Бозык кеше: «Дәшмә, пәйгамбәр, аллаң үзе мине шушы көнгә төшерде»,— диячәк бит! Хәзер Мөхәммәт үзенең алласы өстеннән җаваплылыкны алып ташларга теләп, тәкъдир мәсьәләсенә үзгәреш кертмәк була.
«Юк, яхшы гамәл генә алладан, яманы кешенең үзеннән», ди ул хәзер.

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 81 аять.)*

Ләкин, менә бәла, бу аятькә пәйгамбәрнең хәдисләре каршы килә:
«Начар, әхлаксыз кеше анадан ук шундый булып туа,— дип кычкырып тора аның хәдисләре.— «Һәрнәрсә (яхшысы-начары) алланың тәкъдире беләндер», «Ана карынында чакта алла нәрсә тәкъдир итсә, шул, әлбәттә, булмый калмас».

*(184, 621, 246 нчы хәдисләр.)*

Әлбәттә, сез бу хәдисләрне хәзерге мулла абзыйларыгыз авызыннан ишетмәссез... Әйдә, шайтан алсын, мулла абзыйларны уңайсыз хәлгә куймас өчен, без дә бу хәдисләргә күз йомып үтик. Начарлыкны, соңгы аятьтә әйтелгәнчә, кешенең үзеннән дип фараз кылыйк.
Ләкин, бу шул ук сүз булып чыга түгелме соң? Менә бергәләп уйлап карыйк.
Яхшылык алладан. Рәхмәт аңа моның өчен. Ә мин начар. Бусы өчен кемгә ләгънәт? Анысы синең үзеңнән.— Ярый. Ә соң алла миңа яхшы булырга кушмагач, мин нишләргә тиеш? Яхшы белән яман арасында бүтән нәрсә юк бит. Бәс шулай булгач, фәкыйрегезгә ихтыярсыз яман кеше булып калырга туры килә түгелме соң? Анысы бер хәл. Бер үк вакытта (менә бәла!) яманлык кешенең үзеннән дию — бик әйбәтләп язмыш дигәнең дә, муеннарыбыздагы язмыш күгәрченең дә, Ләүхелмәхфүзең дә, күрәчәгең дә юкка чыгара бит! Бер үк вакытта Мөхәммәт алласының дуамаллыгы, явызлыгы тагын да ачыла төшә! Хәер, Мөхәммәт алланың бу сыйфатын яшерергә уйламый да:
«Без,— ди ул, алласы исеменнән,— берәр халыкка явызлык эшләргә телибез икән, эшләми калмыйбыз инде».

*(Коръән, «Күк күкрәү» сүрәсе, 12 аять.)*

Алла явызлыкны нәрсәгә нигезләп эшли? Нигә сине яхшы юлда йөртә дә, нигә мине начар юлга чыгарып җибәрә? Җитмәсә, нигә мин шуның өчен җәһәннәмдә янарга тиеш? Нигә? Хак мөселман, әлбәттә, мондый сорау бирми. Дөресрәге, ул бу турыда уйларга да курка. Шикләнү була бит... Ә шикләндең — син кяфер.
Ләкин Мөхәммәт ничек кенә куркытмасын, арада кыю җаннар табыла. Юк, хәзер генә түгел, Мөхәммәттән нибары 300 ел соң яшәгән, ислам диненең даны ярты Җир шарын чолгап алган заманда яшәгән әлеге бөек таҗик шагыйре Гомәр Хәййям үзе дә аллага ышанганы хәлдә, курыкмыйча, аңа шундый сорау бирә:

Бар кылдың да, ходай, минем җисемемне син,
Язып куйдың эшләячәк эшемне син.
Үзең язган гөнаһларны кылган өчен
Җәһәннәмгә кер син, кеше, дисеңме син?

Ул заман өчен гадәттән тыш кыю бу шагыйрь бераздан инде менә нәрсә ди:

«Базлар уйды, тозак корды ходай юлга
Һәм чыгарып җибәрде ул безне шунда.
Безнең кайда хур буласын белде, көтте.
Шул явызмы безне утка хөкем итте?!»

Гомәр Хәййямнан да элегрәк яшәгән бөек иран-таҗик шагыйре Насыйр Хөсрәү аллага болай дип мөрәҗәгать итә:

«Син бирүче яманлыкны, мин — кылучы.
Арабызда, уйлап баксаң, аерма аз.
Мин начармы? Димәк, синең иҗат шундый,
Ошамыйммы? Ник яраттың, ошамагач?

Кем чәчте соң җиргә гөнаһ орлыкларын,
Кем үстерде? Үзең булмый, кешемени?

Нигә безгә шундый яман язмыш бирдең?
Мәхшәр көндә мәсхәрәләр өченмени?

Сорый торган сүзләр миндә тагын күп тә,
Күренеп тора сораганны яратмавың.
Нигә миңа тел бирдең соң алай булгач,
Нигә мине хайван итеп яратмадың?

Насыйр Хөсрәү, Гомәр Хәйям, Әбү Мансур Дәкыйкый. Дәһи, зирәк, үтә кыю бу өч ирнең сөякләрен эзләп табып баш орасы килә.

Мөхәммәт ясаган тәкъдир таягының бу башы, шул рәвешчә, Мөхәммәтнең үз башына гына сугып калмады. Гарәп, үзбәк, татар, әзербәйҗан, казакъ, кыргыз, башкорт һ. б. халыклар өчен, фәкыйрь-фокара өчен генә түгел, гомум халык өчен, аларның тәрәккыяте өчен бу таякның зыяны әйтеп бетергесез зур булды.

Тәкъдир «бүкие» бу кадәр куркынычлы булмаган милләтләр югарыга, яктыга, мәдәниятка үрелде. Дәкыйкый, Хөсрәү, Хәйям, Әбүгалисина кебекләр дә мәйданга шул әләмне күтәреп чыгарга теләде. Ләкин андыйларның кулларына суктылар, авызларын томаладылар.

— Мөэмин мөселман бу дөньяга тәрәккыять өчен түгел, мәдәният өчен түгел, ахирәткә әзерләнер өчен килгән. Сөннәтең булса, тәһарәтең булса, биш вакыт намазыңны үтәп барсаң, уразаңны калдырмасаң, шул җиткән дин ислам әһеленә. Теге дөньяга баргач, дөнья гыйлемен беләсеңме дип сорамаслар, иман сорарлар. Агаһ бул, әй мөселман, шунысы какшап куймасын! Пәйгамбәребез үзенең хәдисләрендә әнә нәрсә дигән:

«Кеше дөньяны сөйсә, ахирәтенә зарар итәр. Ахирәтене сөйсә, дөньясына зарар итәр. Фани булган нәрсәгә караганда, бакый (мәңгелек) булган нәрсәне ихтыяр кылыгыз».

*(«Җәвамигыль кәлим», 283 нче хәдис.)*

Һәм кылалар. Дөньяга бөтенләй кул селтәүчеләр, аңа җирәнеп караучылар, дөнья рәхәтеннән, ашау-эчүдән, кием-салымыннан, гаилә тормышыннан ваз кичеп, мәгарәдә яшәүчеләр барлыкка килә. Чәч-сакал гомер китәрелмәгән, тырнак киселмәгән, күзләр эчкә баткан, кулда тәсбих, намазлыкка тезләнгән дә ахыр заман җиткәнне көтеп, иреннәрен лепелдәтеп селкенә-селкенә тәсбих тартып утыра. Тик ачтан үләр чиккә җиткәч кенә чыгып, хәер өстәп керә... Нәкъ Коръән кушканча яшәүче бу әрәм тамакларны, соры кортларны дин башлыклары изге җаннар дип, аллаярлар дип, аллага якын бәндәләр дип игълан итә. Бәс андый булгач, аларның догалары да, өшкерү-төкерүләре дә кабул булмый калмый торгандыр... Боларның мәгарәләренә һәр яктан сукмак салына. Төенчекләрдә иң затлы азыклар, кием-салым... Инде аларның бик сөйкемле исемнәре дә бар — дәрвиш. Дәрвишләргә сорау үсә, нәтиҗәдә, алар урман гөмбәләре кебек ишәяләр. Өшкерү-төкерү, дога, киләчәктән хәбәр бирү... Даннары ислам динен кабул иткән бүтән илләргә дә тарала, һәм алар даннары артыннан үзләре дә килеп җитәләр. Өс-баш һәмишә әүвәлгечә, ләкин кием эчләренә зур кесәләр тегелгән... Дөньяга караш та үзгәргән хәзер. Ул инде ахыр заман көтми, киресенчә, озын гомер тели. Ризыкның затлысын, түшәкнең йомшагын тели. Һәмишә борынгы традицияне саклап, өйләнмәгән, ләкин күзләр майлы... «Суфи суган сөймәс, күрсә кабыгын куймас» — бу аларга атап чыгарылган мәкаль... Исемнәре дә шундый хәзер аларның — суфи.

...Кеше дөньяны сөйсә, ахирәтенә зарар итәр...» «Мөэмин мөселман бу дөньяга ахирәтенә әзерләнү өчен генә килгән...» — бу сүзләрнең тәэсире әйтеп бетергесез аяныч булды.

Моның иң характерлы мисалы — Мөхәммәтнең туган иле, Сәгуть Гарәбстаны. Сәясәт тә, әхлак та, шәригать тә Коръән булган бу илдә феодализм соңгы елларга кадәр яшәп килде, анда колбиләүчелек әле дә бетерелгәне юк. Колларны базарларда саталар. Кыз балалар мәктәпләре яңа күренә башлады. Үзенең укытучылары юк дәрәҗәсендә аз, чит илләрдән килеп укыталар. Илдә бер кино, бер театр юк. Дәүләтнең төп килере — хаҗга килүчеләрдән алына торган җыем булып, дөнья күләмендә кризис башлану белән, диниләрнең сафлары сирәгәю белән, кайчандыр чишмә булып бәреп торган бу килер дә бер зәгыйфь тамчы хәленә калды... Чит илләрдән кяферләр килеп нефть табып бирмәгән булсалар, Мөхәммәт өммәте бүген бөтенләй кызганыч хәлдә булыр иде.

Ә бездә? Безне дә шул язмыш көтә иде.

Башка милләтләр табиплек гыйлеменә омтылды. Алар үрнәгендә бу гыйлемне алга сөрүче безнең сау, акыллы кешеләребезгә җавап, мәсәлән, табиплык мәсьәләсендә мондый булды:

Бөтен дөнья табиплары җыелып килсә дә, синең гомереңне озынайта алачак түгелләр. Аннан гомерне озынайтырга йөрү — үзе хилаф эш. Барыбер алла язганча булып чыга. Тагын шуны хәтерлә, әй мөэмин мөселман! Озын гомерне алла кешегә гөнаһыны күбрәк җыйсын өчен генә бирә. Һәм аллага сукыр ышану белән ышанган хак мөселман Коръәннең бу уйдырмаларына ихлас күңелдән ышанып, Коръәннең күрсәтмәләрен төгәл үтәп килде. Бер мисал. Революциягә кадәр Казан университетын ике

елга бер татар яки башкорт егете тәмамлап чыгу, революциягә кадәрге Казан губернасында 456 врачның нибары ун-унбише генә татар булу, ун кешенең тугызы надан булу, адрес яздыру өчен күрше рус авылына йөгерү, күп авылларда, бистәләрдә үзенең хәтта пыяла куючысы, тимерчесе булмау, тик бер бабачысы белән сөннәте үзенеке булып, аның да пәкесен кяферләрдән ясатып алу... Бөтенесе-бөтенесе — тәкъдир «букиенең» җимешләре.

Бөек татар-башкорт шагыйре Мәҗит ага Гафуриның бу хәлгә ачынып язган шигыре искә төште:

«...Ашарга аш таба алмый фәкыйрьләр,
Киемнәре ямалган — бу да «тәкъдир»,
Бүтәннәр алга киттеләр — бүтән эш,
Мөселман артта калды — бу да «тәкъдир».

Хәзер алай түгел инде. Мулла-монтагайның иң диндар, иң кара эчлесе дә тәкъдиргә ышанып, тәкъдир колы булып, күктән төшкәнне көтеп ятмый. Үзе мәчеттә, мәет өстендә «мажик балаларының» күзләренә яшь китерерлек итеп, тәкъдир турында сөйли, укый, ә үзе шуңа ышанмый. Бер дә арттырып әйтүем түгел, әйе, ышанмый. Баласы авырый башласа, Әюп пәйгамбәрдән үрнәк алып, «үзе бирде, үзе алды»ны көтеп ятмый, юрганга төреп, шайтан арбасы (такси) яллап, иң әйбәт докторга йөгерә. Имеш, «иҗтиһат итәргә, хәстәренә кирәргә кушкан»... Төнгә калганда, күрәчәкне күрми — гүргә кереп булмый дип, караңгы тыкрыктан кайтмый, кешеле, якты урамнан әйләнә: имеш, «саклангaнны саклармын дигән...» Ә карап баксаң, димәгән! Коръәндә андый сүз юк. Киресенчә, Мөхәммәт бу турыда менә нәрсә ди: «С а к л а н у т ә к ъ д и р г ә ф а й д а б и р м ә с».

*(991 нче хәдис.)*

И җ т и һ а т и т ә р г ә к у ш у д а, х ә с т ә р е н ә к е р е р г ә к у ш у д а ю к К о р ъ ә н д ә. Болар һәр икесе тәкъдир-язмыш-күрәчәк экиятләренә соңыннан ничарадан-бичара кушылган койрыклар һәм алар, беренче нәүбәттә, дин әһелләренең, бигрәк тә хәзерге муллаларның үзләренең дә тәкъдир экиятенә ышанмауларын, моңа инде «мажик балаларын» да ышандыра алмауларын бик ачык рәвештә исбат итәләр.

Һәм мондыйларга ышандыра алмау, иске чалбар балагын сүтеп тарайткан кебек, Коръәнне, шәригатьне ничек тә саклап калу теләге белән заман шартларына яраклаштырып үзгәртү хаҗәтлеген китереп чыгарды.

Берничә мисал. 1912 елда гына әле «Дин вә мәгыйшәт» журналының 6 нчы саны фуражка, шапка, пальто, щиблет киеп йөргән кешене кяферләр дип сүккән иде. Ә бүген? Пәйгамбәр үзенең Коръән аятьләре, хәдисләре белән пәрәнҗәсез хатыннарны зиначы хатыннар белән тиңләгән иде. Ә бүген? Бездәгене әйткән дә юк, төрек илендә, саф мөселман илендә, моннан биш ел элек пәрәнҗәне салып ташлауга өндәү башланды. Юк, коммунистлар түгел, моны дин башлыклары үзләре күтәреп чыкты. Мөфтиләр, мәдрәсә галимнәре, кинотеатрларга барып, сеанс араларында пәрәнҗә ташларга өндәп чыгыш ясыйлар, муллалар шуңа мәчеттә өндиләр. Батлис шәһәренең губернаторы Саба Пәрвиз әфәнде, пәрәнҗә салуны таләп итеп, указ чыгара. Бу турыда Истамбулның «Ватан» газетасы 1960 елгы сентябрь санында язып чыкты.

Шәригатьнең рәсемнәргә, сыннарга булган карашын исегезгә төшерим. Чәй тартмасында кытай рәсеме була иде. Хак мөселман өйгә кертүдән алда кытайның башын кырып ташлый иде. Шул ук «Дин вә мәгыйшәт» журналы (1912 ел, 17 нче сан) «Сурәт булган урында намаз уку мәкрүһтер, сурәт вә рәсемнәрне өйдә тоту мөселман кешегә гамма и голәма иттифакы илән хәрамдыр», дип язып чыкты. Ә бүген? Иң дингә, иң аллаяр абзый сурәтнең җансызын гына түгел, җанлысын карар өчен кинога чаба, телевизордан кяферләрнең бот күтәреп биегәннәрен карап утыра. У-у, хәсис, ди ул, ә үзе торып китми, утыра. Бу хәл бүген бездә генә түгел, ислам диненең бишеге булган Гарәбстанда да шулай. Мөхәммәт пәйгамбәр белән хәзрәте Галинең рәсемнәре Каһирәдәге алтын мәчетнең түрендә урын алдылар.

Иң кызыгы ураза. Революция алды елларында гына әле илдә ураза тотмаучыны белсәләр, өеннән адәм мәсхәрәсе итеп өстерәп чыгып урам буенча рисвай итеп йөртүләр еш булып тора иде. Әби патша ураза тотмаучыларны суктырырга боерып, махсус указ чыгарды. Ә бүген? Бүген ислам диненең бишеге булган илләрдә уразаның зарарлы икәне, аны тоту рухи гына (?) булырга тиешлеге турында җитди рәвештә сөйләнүләр башладылар.

Бу дулкын безнең СССР ярларына да килеп бәрелде. Янәмәсе, ураза тоту сәламәтлегеңә зарар итәр булмаса гына фарз гамәл. Уйлап карыйк, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр ач тору кемнең генә сәламәтлегенә зарар итми икән? Шахтерның? Нефтьченең? Уракчының? Слесарьның? Шоферның? Тракторчының? Кибетченең? Бу үзе тотмасаң да ярый дию белән бәрабәр түгелме соң? Бәхәссез, шулай. Мөфтиебез Шакирҗан Хәялетдин җәнапләре 1961 елгы фәтвәсендә моны үз теле белән әйтеп бирде. Ураза эшчегә, колхозчыга гомумән тиеш гамәл түгел, диде ул. Тик хәзрәтләребез әлегә кадәр бу турыда эчтән тынып киләләр. Ник? Җавабы ачык: уразасы булмагач, авыз ачтырулар да булмый, бәйрәм ашлары да, бәйрәм садакалары да...

Ә корбан чалу? Элек ул важип иде. Ягъни чалмау — гөнаһ. Хәзер сөннәт кенә. Ягъни чалсаң — савап, чалмасаң — гөнаһысы юк. Сөннәткә утырту да шулай. Ник? Күктә яңа төрле указ чыкканмы әллә? Юк, әлбәттә.

Алайса эш нәрсәдә соң? Дин, шәригать үзенең позицияләрен нигә шулай бер-бер артлы ташлап кача? Бу бик аңлаешлы. Фән бик каты һөҗүм итә бит. Мәсәлән, шул ук уразаның сәламәтлеккә зарарлы, эшкә зыянлы гамәл икәнен хәзерге фән алдында һичбер төрле илаһи сүзләр белән дә инкарь итәргә мөмкин түгел. Фән яктылыгында хәзер хәтта аллага ышанган кеше дә уйлый башлады: минем ач торуымнан, сусыз интегүемнән, сәламәтлегемне какшатып, эшемә зарар китерүдән аллага ни файда икән соң? ди ул хәзер.

Шәригатьнең бүтән гамәлләре белән дә эш хәзер шулай тора. Шунлыктан, кеше бөтенләй диннән бизмәсен өчен, шәригать ташламалар ясарга, Коръән һ. б. дин китапларына хыянәт итеп булса да, үзенең гамәлләрен җиңеләйтергә, кайберләрен бөтенләй бетерергә мәҗбүр.

Коръәндәге, Тәурат, Инҗилләрдәге тузга язмаган әкиятләр белән дә хәзер шул ук хәл. Фән һәм тарих дәлилле фактлар белән стенага китереп терәгәч, руханилар ул әкиятләрне дә заманга яраклаштырырга мәҗбүр булдылар. Туфан әкиятен генә искә төшереп үтик. Коръән, Тәурат, Инҗилләр, бөтен дөньяны су баскан, Җир йөзендә фәкать Нух үзе дә өч улы белән киленнәре генә калды дигән әкияткә тырышып-тырышып безне ышандырып маташканнар иде бит. Ә бүген? Фән андый хәлнең булмаганын, була да алмаганын исбат иткәч, чал тарих аның Ассирия халкыннан кергән әкият икәнен әйтеп биргәч, руханилар, үз сүзләре белән әйтсәк, хәйләи шәргыйгә керештеләр. Имеш, Ассириянеке бүтән, ул чыннан да әкият, ә Коръәннеке чын... Коръәндә бәян кылынган туфан бөтен җир йөзендә түгел, фәкать бер Нух кавеме яшәгән илдә генә булган... Менә эшләр кая китте, дусларым!.. Илебезнең могътәбәр муллалары, мәшһүр дин галимнәре бу хакта «Шура» журналының 1912 нче елгы 6, 9, 13, 23 саннарында язып чыктылар.

Бу хакта күп язарга мөмкин булыр иде. Тагын бер генә мисал — Мәрьям ананың йөккә калу мисалы.

Күп гасырлар үтү белән мәдәният үсеп, оятны белә башлаган дин галимнәре Коръәннең бу әдәпсез әкиятен оныттырырга теләп, Мәрьям ананың ничек балага узуы, Гайсәнең ничек дөньяга килүе турында бүтән төрле әкиятләр, җөмләдән берсе шундый әкият уйлап чыгардылар.

«Мәрьям ирде анасы,
Һич юк ирде атасы;
Әнбияләр әяны,—
Җилдән тугмыш ирдия».

*(«Хәзрәте Мәрьям разияллаһе ганһә» китабы.)*

1963 елның декабрендә Уфа шәһәрендә Советлар Союзының Европа өлешеннән һәм Себер өлкәсеннән килгән казыйларның, мөхтәсипләрнең, имам хатипләрнең, мәхәллә мөтәвәллияте рәисләренең зур мәҗлесе булып үтте. Бу мәҗлестә диния нәзарәтенең рәисе — безнеңчә әйтсәк, дин башлыкларының иң зурысы — мөфти Шакир Хәялеттин әфәнде дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы 22 сорауга җавап бирде. Җавапларның күбесе диннең заманга яраклаша баруы турында сөйлиләр. Мин бирегә мисал өчен фәкать берсен, һәм мөэмин мөселманның чәчен үрә торгызырдаен фаш итәм.

Сорау: Кибетләрдә сатыла торган туң май, маргарин, комбижир кебек тазалыклары шикле булган ризыкларны ашарга дөресме?

Җавап: Дәүләт үзенең магазиннарында халыкка зарарлы пычрак нәрсәләр сатадыр дип гакыл һич сыйдырмыйдыр. Маргарин белән комбижирны ашау мотлака дөрес.

Бу җавабы белән, Коръән ноктаи нәзарыннан караганда, башлап, мөфти хәзрәтләре үзе җәннәттән мәхрүм булган булса кирәк. Ник дисәң, дуңгызны әйткән дә юк, сыер белән сарыкның гына да бисмилла әйтми суелганын ашау («Сыер» сүрәсе, 168 аять нигезендә) хәрамның да хәрамы бит. Ә комбижирда чыкылдап торган чучка мае 7 процент!

Әле бетмәде. «Хөкүмәт зарарлы, пычрак нәрсәләр сатмас...» дисез сез, мөфти әфәнде. Әй матур итеп әйткәнсез дә соң! Ә аракы? Сыра? Тәмәке? Бу нәрсәләр хөкүмәт кибетләрендә тулып ята түгелме соң? Алар да зарарлы түгелмени инде хәзер?..

Фән үзенең ачышлары белән стенага китереп терәгәч, руханилар шәригатьне әнә шул рәвешчә заманга яраклаштырып килә-килә Коръән белән фән дус, диюгә кадәр барып җиттеләр. Бик яхшы. Димәк, сез мулла абзыйлар, кешенең моннан миллион ел элек хезмәт нәтиҗәсендә эволюция юлы белән барлыкка килгәненә ышанасыз? Бер үк вакытта 7.565 ел элек алла Адәмне туфрактан әвәләгән, Хаваны кабыргадан ясаган дигәнгә дә ышанасыз? Җирнең түгәрәк булуына ышанасыз, бер үк вакытта Коръәннең җир палас кебек тигез, аны үгез күтәреп тора дигәненә дә ышанасыз?

Йомшак кына итеп әйткәндә, икейөзлелек, Коръәнгә хыянәт бу, абзыйлар. Бүрәнәләре мүртайган, кыйбла якка кыйшайган, стеналары буаз бия корсагы кебек бүселеп чыккан, түбәсе чергән, миче ишелгән иске йортны терәүләр куйгалап, балчыклар сылаштыргалап, акбур белән агарткалап саклап калырга маташу — файдасыз көчәнү.

# Соңгы сүз

«Дин, шәригать — чи тирәдер,
тарткала үз файдана».
*Г. Тукай*

## 1

## КОРЪӘННЕҢ УҢАЙ ЯКЛАРЫ ЮКМЫНИ?
## ПӘРИ БАШКА — ҖЕН БАШКА.
## АТНАГА БЕР «НА ТРОИХ» ЯРЫЙМЫ?
## «КҮЗЕҢ ЙОМГАНЧЫ ТӘҮБӘ ИТЕП ӨЛГЕРСӘҢ, СИН ҖӘННӘТТӘ».

Икеләнүчеләр генә түгел, хәтта киртә сикергәннәрнең, гел тискәре якларын язгансың, ул Коръәннең бер дә уңай яклары юкмыни? диюләре мөмкин.

Бар. Ләкин ничек, ни дәрәҗәдә? 70 градус эссенең дә файдалы ягы бар. Туңмыйсың, комында «ә» дигәнче күкәй пешеп чыга. Ләкин анда тереклек итү мөмкин түгел. Иген үсми, кешене киптереп үтерә. 80 градус суыкның да файдалы ягы бар. Тирләтми, чебен-черки бимазаламый, ләкин анда шулай ук тереклек итү мөмкин түгел. Иген үсми, юлга чыксаң, катып үләсең. Коръәннең уңай дигән яклары белән дә эш шулай тора.

Коръәндә һәр мөселман, менә безнең дин нинди шәп, дип мактанып йөргән өч-дүрт урын бар.

Беренчесе. Коръән урламаска, кеше үтермәскә куша. Бик әйбәт, бик изге, бик күркәм сүз. Ә кемнекен урламаска? Мөселманныкын, фәкать мөселманныкын. Кемне үтермәскә? Мөселманны, фәкать мөселманны. «Мөселманнар илән сугышмагыз», «Мөселманнар илән сугышу начарлык, кяферлек». «Мөселманнар бер-берсенә кардәш бит. Тату яшәсеннәр, бездән куркып торсыннар».

*(Коръән, «Бүлмәләр» сүрәсе, 10 аять.
«Мең дә бер хәдис».)*

Пәйгамбәр 317 нче хәдистә «куркып торсыннар»ның уен сүз түгел икәнен ачыклап, болай ди:

«Алла исеме белән ант итеп әйтәмен: бер мөэмин икенче бер мөэминга золым кылса, хак тәгалә кыямәттә ул кешедән үч алыр».

«Мөселманны үтерергә ярамый. Моның өчен мәңгелек җәһәннәм».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 95 аять.)*

Ә кяферне, ягъни дөньядагы тугыз кешенең сигезен, хәзерге исәптән 2 миллиард 700 миллион кешене, золым кыйл, рәхәтләнеп тала, үтер. Моның өчен сиңа саваптан гайри нәрсә юк. Ерак барып йөрисе түгел, пәйгамбәребез моның үрнәген үзе күрсәтеп үлде бит. 10 ел буена ул кылычын кулыннан бер генә көнгә дә төшерми. Плеврит чире белән газапланып үлем түшәгендә ятканда да әле ул кяферләр белән сугышу турында хыялана:

«Кяферләрне кайда очратсагыз, шунда тотып үтерегез».— Аның соңгы сүзе шул була. Васыятен әйтергә өлгерми, ә моны әйтергә форсат таба. Хәтта ничек-ничек үтерергә икәнен дә әйтергә онытмый:

«Кяферләрне кайда очратсагыз, шунда муеннарын кылыч белән чабып өзегез. Тәмам җиңеп чыккач, төенне ныклап төйнәгез».

(Коръән, «Мөхәммәт» сүрәсе, 4 аять.)

Алла (чыны Мөхәммәт) гомумән талаш-кырылыштан, кешеләрнең үзара кан түгүләреннән тәм таба. Ул үзенең сүрәләрендә кайта-кайта, хөр кеше өчен хөр кеше үтереп, кол кеше өчен кол кеше үтереп, хатын-кыз өчен хатын-кызлар үтереп үч алырга боера.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 173 аять.)*

Ягъни синең әтиең минекен үтергән өчен, мин сине үтерергә тиеш булам. Синең улың мине, минем улым синекен, синең онытың минекен... Шул рәвешчә, нәселләребез кырылып беткәнче!..

Мулла абзыйлар, хәзер боларның практик мөмкин түгел икәнен төшенеп, «пәйгамбәребез ул васыятьне шул заман өчен генә әйткән», диләр. Гөнаһлы буласыз бит, мулла абзыйлар! Икеләтә гөнаһлы буласыз. Беренчедән алла (үз сүзләре белән әйтсәк): «Бер кайчан да үз боерыгын үзгәртми». Икенчедән, һичбер сүрәне шул заман өчен генә дими, киресенчә, Җир йөзендә бер генә дин, ислам дине генә калганчыга кадәр сугышырга боера.

*(Коръән, «Табыш» сүрәсе, 40 аять.)*

Уйлап карыйк. Шуннан соң урлама, үтермә дигән матур сүзләрнең гамәлдә бирәр төрле әһәмияте каламы? Кала, ләкин тискәре яктан. Мөхәммәтнең бу васыятьләренә турылыклы булыйк дисәк, бакый иман белән үлик дисәк, без хәзер, өйләребездән дәррәү кубып чыгып, очраган бер урыска һөҗүм итәргә тиеш булабыз. Заводта, шахтада, трамвайда, кинотеатрларда, мунчада, кяфер кайда бар — шунда.

Ләкин Мөхәммәтнең бу васыятеннән, без түгел, безнең ата-бабаларыбыз ук ваз кичкән. Моннан ярты гасыр элек үк инде бөек шагыйребез Габдулла Тукай менә нәрсә дип язып калдырган:

«Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать гадәт вә әхлак алмашып,
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек,
Без туган бер җепкә бергә тереклеп».

Мөхәммәтнең явыз хыялы түгел, бөек шагыйребезнең изге сүзләре акланды. Тарихи бергәлек бетмәде. Рус белән бергә сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып, бер җепкә тезелеп яшәгән татар халкы, башка халыклар белән бергәләп, илдә революция ясады, бөтен дөнья революциясенә нигез салды. Ислам диненең бишеге булган гарәп илләре дә бүтән хәзер. Тәрәкъкыят дошманнарының кяферләр түгел, ханнар, әмирләр, ахун, ишан, мулла-монтагай икәнен аңлаган гарәп хезмәт ияләре, хан сарайларын көлен күккә очырып, социалистик ил халыкларына, беренче чиратта, үзләренә өлкән туган итеп сайлап алган Ленин токымына, бер-бер артлы килеп кул бирәләр. Юк, Мөхәммәт васыятьләрен гарәп булып гарәп ташлады инде.

Икенчесе. Коръән, зина кылма, ди. Бик әйбәт, бик изге, бик мөбарәк сүз. Ә һәр мөселманга дүрт хатын белән торырга рөхсәт итү, хәтта шуңа үгетләү, вакытлы никах буенча теләсәң ничә кызга кул салырга рөхсәт итү зина булмый нәрсә соң ул?! Мөхәммәтнең үзенең берьюлы тугыз белән торуы, шулар өстенә кол хатын-кызлары белән торуы — зина булмый нәрсә икән соң ул?! Әлбәттә, зина, тик изге Коръән белән законлаштырылган зина.

Шулар өстенә, законлаштырылмаган зиналар була бит әле. Андыйлары турында пәйгамбәр, дөрес, баштарак бераз нәгърә органдай итә, ләкин агаенене нәүмизләндерүдән өркепме, ничекме,— бик тиз кайтып төшә. Инде ул нәфесне тыюга өндәми генә түгел, ничек итеп судан коры чыгарга өйрәтә. Мәсәлән:

«Бер күрше хатын белән зина кылуга караганда,— ди Мөхәммәт,— күрше булмаган ун хатын белән зина кылуның гөнаһысы җиңелрәктер».

*(645 нче хәдис.)*

Ягъни, әгәр син расчетлы ир икәнсең, үзенә зина өчен хатын-кызны берничә йорт ары китеп эзлә. Берне, икене, бишне, унны... Үзе ун, үзенең гөнаһысы бернекеннән дә җиңелрәк!.. Һәм бу «җиңелрәк» тә әле. Кыямәт көн һәрбер зинабеттингә кагылмый. Аллаһ тәгалә кыямәт өчен зиначы агаененең фәкать картларын гына җәзалаячак. Моны безгә пәйгамбәребез үз авызы белән әйтә. Ике төрле уйларга урын калдырмаслык итеп әйтә:

«Кыямәт көн өч төрле бәндәгә рәнҗеткүче газап булыр,— ди ул,— ялганчы түрәгә, ярлы тәкәбберге, карт зиначыга».

*(367 нче хәдис.)*

Ә бит әле, зина чутындагы хәдисләрне җентекләп өйрәнеп чыксаң, (алла бер рәхим шәфкать кылыйм дисә, кыла инде ул!) картларның да хәлләре бөтенләй өметсез түгел икәне ярылып ята. Мин моны шул ук «Мең дә бер хәдис»нең 105 нчесенә таянып әйтәм. Бу хәдистә Мөхәммәт:

«Алла, кыямәт көн зиначы картларны фәкать берачулану белән чикләнәчәк», ди.

Уйлап карыйк. Бу хәдисләр зинабеттиннәрнең зинадан туктавына этәргеч булулары мөмкинме?

Хәдисләрнең аракы чутындагылары да кызык кына. Пәйгамбәребез бу мәсьәләдә дә тоткан җирдән сындырмый. Алдарак бәян кылынганча, гомеренең азагында каты итеп куйганнан соң да, әле бу мәсьәләдә үзенең өммәтенә зур ташлама ясый, эчкечеләрнең бөтенесен дә җәһәннәм тишегенә бөтереп тыкмый. «Даими рәвештә эчүче кеше (генә) җәннәткә керә алмас», ди ул.

*(368 нче хәдис.)*

Ә бәйрәмдә бер эчкәнне даими дип әйтеп буламы? Юк. Получка көн бер кәефләнеп алганны? Атнага бер «на троих»ны?

Уйлап карыйк, бу хәдисләр кабак тастымалының тәүфикъ табуына этәргеч булыр дип өмет итеп буламы?

Менә шулай тикшерергә керешсәң, Коръән, хәдис һәм тәфсирләрнең иң ак дигәннәренең дә морҗа капкачы кебек кара икәне фаш ителә.

Әйтергә кирәк, Мөхәммәт әнә шулай ике төрле сөйләнүләре белән шәригатьнең төп гыйбадәтләреннән саналган намаз, уразалар турындагы кануннарны да ике төрле аңларга юл калдырган.

Мәсәлән, шул ук пәйгамбәр сүзләренә нигезләп язылган Бәдәвам китабы:

«Кемдер намазын куйган —
Адәм түгел ул, шайтан,
Эт, дуңгыздан ул яман,
Аллаһ дигел бәдәвам»,—

ди.

Ә 542 нче хәдистә бөтенләй башкача:

«Бар нигъмәтенә шөкерана кылып ашаган кеше — авырлыгына сабыр итеп ураза тоткан кеше дәрәҗәсендәдер».

452 хәдис исә хәтта менә нәрсә ди:

«Алланың биргән нигъмәтләренә шөкерана кылып ашаган кеше, авырлыгына чыдап, ураза тоткан кешедән саваплырактыр».

535 хәдис уразаны бик ук өнәп бетермәүчеләр өчен тагын да кулайрак:

«Бер көн гыйлем эстәү — өч ай ураза тотудан хәерлерәктер».

Инде гыйлем эстәргә дә иренсәң, рәхим ит, тагын да кулайрагы бар:

«Бернччә адәмнәрнең кич илә уяу торып гыйбадәт кылуларының файдасы — фәкать йокы калдырудан гыйбарәттер. Мәшәкать илә тоткан уразаларының файдасы — ачлык, сусызлык кына булыр». Монысы инде — тотмасаң да ярый гына да түгел, тоту зарарлы дию, шулай түгелме?..

Мөхәммәтнең шәригате гомумән әнә шулай, керәле дә чыгалы. Шуңа күрә борын заманда ук инде, «шәригать бер карыйсың — кыл кебек нечкә, икенче карыйсың — балта сабы кебек юан», дигән әйтем таралган. Һәм бертөрлерәк халык, безгә шунысы да ярап торыр дип, балта сабы буенча гамәл итә торган булган.

Гөнаһлар турында гомумән әнә шундыйрак хәл. Яңа әвәләп куелган, беренинди тормыш тәҗрибәсе булмаган Адәмне юклы-барлы гөнаһысы өчен алла әнә нинди газапларга дучар иткән иде бит. Нух заманында әти-әниләре иман китермәгән өчен имчәк балаларына хәтле батырып үтергән иде; хайваннарны, урман-кырларны һәлак иткән иде. Инде килеп, Мөхәммәт үзенең хәдисләрендә кешенең гомере буена җыелып килгән тау-тау гөнаһыларыннан ничек ансат котылырга икәнен әйтеп бирә:

«Биш вакыт намазның охшашы — ишек төбеннән аккан су кебидер, — ди ул. — Адәм баласы шул суда һәр көн биш тапкыр госел коенса, аның тәнендә кер калмас. Шуның кеби биш вакыт намаз да бәндәнең һичбер гөнаһларын калдырмас».

*(736 нчы хәдис.)*

Безнең кебек кешегә көн саен биш вакыт намаз да ансат гамәл түгел шул, дисең икән, рәхим ит, аны менә нәрсә белән алыштырырга була:

«Бер кеше кырык хәдис ятласа, — ди Мөхәммәт, — мин ул кешене үземнең шәфәгатемә алырмын». Ә моны инде аллага әйтеп, барча гөнаһларыңны бетертермен, дигән мәгънәдә аңларга кирәк.

Инде кырык хәдис ятларга да авырсынасың икән, менә мөнысын чамалап карыйсың:

«Ике мөселман йолкышып (?) кул бирешсәләр, сәламәтлекләре өчен аллага хәмед әйтсәләр, һәм бер-берсенең гөнаһларын ярлыкауны сорасалар, һәр икесенең гөнаһлары ярлыканыр».

*(75 нче хәдис.)*

Монысы да мәшәкатьле дисең икән, бер нишләмисең, тәүбәгә генә киләсең:

«Гөнаһлардан тәүбә кылган кеше — бер дә гөнаһлы булмаган кешедер».

*(346 нчы хәдис.)*

Ягъни көндез кычкыртып талыйсың, суясың, көчлисең, яла ягасың, дөньяда нинди кабахәтлек бар, берсен дә калдырмыйсың, кичен тәүбәгә киләсең, ә иртән бисмилла әйтеп, өйрәнгән һөнәреңә яңадан керешәсең. Пәйгамбәр хәдисләреннән әнә шул килеп чыга.

Ә алла? Алланыкы, беләсегез килсә, тагын да рәхимлерәк, тагын да колакка ятышлырак. Менә нәрсә ди ул:

«Колларым минем! Алла бөтен гөнаһларны гафу итә. Чөнки ул гафу итүче, чөнки ул мәрхәмәтле».

«Колларым минем! Алланың рәхмәтеннән өмет өзмәгез; алла бөтен гөнаһларны гафу итүче. Тик алла җәза биреп өлгермәс борын, тәүбә итәргә генә өлгер».

*(Коръән, «Төркемнәр» сурәсе, 54—55 аятьләр.)*

Биредә мәсьәлә фәкать шунда гына. Кем өлгеррәк булып чыга: алламы, синме. Алланың бу мәрхәмәтле аятен «Җәвамигыль кәлим»нең 296 нчы хәдисе тагын да ачыграк итеп аңлатып бирә:

«Кеше җаны алына башлаганчы тәүбә итсә, аллаһ тәгалә аның тәүбәсен кабул итәр».

Мин болай дип уйлыйм, бу аять вә хәдисләрне укыган яки тыңлап утырган һәрбер угыры, һәрбер юлбасар, һәрбер көчләүче, һәрбер үтерүче:

— Бакчы! Кара, үз кеше икәнсең ләбаса син, алла дус!..— диярдер кебек.
Әйтегез, мулла абзыйлар, Коръәннең тагын кай урыннарын әдәп үрнәге итеп күрсәтә аласыз?

Халыкның билгеле бер өлеше алла, Коръән һәм Мөхәммәткә әлегә кадәр ышанып яши икән, бу — я аның культурасы түбән булудан, белеме җитмәүдән килә, я (мәсәлән, татар, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, әзербәйҗан кебекләр) Коръән сүзләре ят телдә булып, мәгънәсен белмәгәнлектән, эчендә яткан серләренә төшенә алмаганлыктан килә. Дөрес, мәчеттә мулла һәр халыкның үз телендә сөйли. Ләкин сайлап кына. Бу китапта фаш ителгән җирләрен исә гарәпчә генә укып китә. Мөселман бичара, бернәрсә аңламаган хәлдә, мулла укыганның бөтенесен илаһи күреп, селкенә-селкенә амин күтәреп утыра. Ә менә ул Коръән һәр мөселманның, шул җөмләдән татар халкының, үз телендә булса?..
Революция алды елларда Казанның һәм Уральскиның кайбер хәзрәтләре намазны татарча үтәү, догаларны татарча уку мәсьәләләрен күтәреп чыгалар. Хәтта Коръәннең үзен ана телебезгә тәрҗемә итү мәсьәләсе кузгала. Чыннан да, алай иткәндә, кеше нәрсә дип дога кылганын белер, нәрсә укыганын белеп укыр иде. Югыйсә, әгүзе ди, бисмилла ди, аллаһеәкбәр ди. Ә нәрсә соң ул аллаһеәкбәр? Әгүзе-бисмилла нәрсә? Ләкин бу прогрессив тәләккә каршы «Дин вә мәгыйшәт» журналы 2 ел буена бер туктаусыз нәгърә ора. Габделкәрим Атнагулов дигән бер бәндә: «Коръәнне тәрҗемә иткән кеше аны мәхкәм сарайлардан чыгарып, тишек капчыкка тутыручыга охшыйдыр», — дип яза. Шул ук журналның шул ук елгы беренче саны, тәрҗемә иткән тәкъдирдә, Коръән иске чүпрәккә әйләнәчәк, ди. Фанатик муллалар гына түгел, аңлы, белемле укымышлылар, шул җөмләдән, алтын приискасының хуҗасы олы шагыйрь Закир Рәмиев (Дәрдемәнд) һәм аның агасы Шакир Рәмиев каршы төшә.
— Бу нишләвегез сезнең, динебезне харап итәсез бит?! Куегыз, куй...— диләр алар. Алар бик белеп әйтәләр: Коръәннең бөтен илаһилеге, бөтен изгелеге безнең халык белмәгән телдә булуында бит аның. Нәтиҗәдә, Духовное собрание карагруһ муллаларның гозерләре нигезендә, инде тәрҗемә ителеп мәтбагада басылып яткан Коръәннең дөньяга чыгуын туктата. «Дин вә мәгыйшәт» — үлемнән алып калганнар диярсең — шундый шат. Үзенең 1912 нче ел 14 санында: «Әлхәмделиллаһи, бу көнгә кадәр ходай тәгалә безләрне бу бәладән саклады», — дип язып чыга.
Муллалар, дин сакчылары, үзләренчә, әлбәттә, хаклы булганнар. Чыннан да, Коръәннең теләсә кай җирен, шул исәптән Ибраһим, Нух, Лут кыйссаларын мәчеттә мулла мысыр мәкаме белән укып җибәргәндә халык елый-елый тыңлый. Ә шул ук мулла шул ук сүрәләрне татар телендә укысын әле!.. Ибраһимның үз хатынын Мысыр патшасына биреп тору бәрабәренә фәләнчә куй, фәләнчә алтын-көмеш алды дигән җирен, яки «кунакчыл» Лут пәйгамбәрнең үз кызларын бозык ирләр алдына чыгарып ташлаган җирен... Тәэссорат бөтенләй бүтәнчә булыр иде генә түгел, халык, муллабыз киртә сикергән дип, яки акылына зәгыйфьлек килгән дип, мәчетенә йөрми башлар иде, ә инде тәнкыйть күзе белән караудан курыкмаучылар, бәхәссез, диннән ваз кичәр иде.
Сүзләремә һәмишә шикләнеп караучыларга мин Коръәннең халык арасына иң күп таралган сүрәсен, иң изге, иң илаһи саналган Ясин сүрәсенең тулы тәрҗемәсен тәкъдим итәм. Аны намаз артыннан да укыйлар, мәет өстендә, каберлекләрдә укысаң, савабы аеруча зур. Ләкин кай җире генә саваплы икән соң аның? Бигрәк тә үлеп яткан кешегә аның ни шифасы тияр икән? Менә игътибар белән, тәнкыйть күзлеге киеп, үзегез укып карагыз.
«Ясин. Зирәк Коръән белән ант итәм, син, (Мөхәммәт) әлбәттә, туры юлдагы илчесең. Бу Коръән әтиләре дингә өндәлмәгән кешеләрне өндәр өчен җибәрелгән хакыйкать. Ә алар (Коръәнне) санга сукмый. Күпчелек өчен (безнең) [1] сүз раска килде, ә алар иман китермиләр. Без аларның муеннарына, иякләренә тиеп торырлык итеп богау салдык. Алар башларын күтәреп йөрергә мәҗбүр. Без аларның алларына да, артларына да киртә кордык, томалап куйдык, алар (дөрес юлны) күрмиләр. Аларны өндәсәң ни дә, өндәмәсәң ни, барыбер инанмыйлар. Син фәкать искәрмәгә (?) ияргәнләрне генә, яшерен рәвештә шәфкатьле алладан курыкканнарны гына өндә. Андыйның гафу ителәчәген, (андыйга) бөек бүләк биреләчәген әйтеп шатландыр! Без бит үлгәннәрне терелтәбез. Аларның дөньяда нинди эшкә бирелгән булуларын, калдырган эзләрен төгәл язып барабыз. Син аларга шәһәр кешеләре турында гыйбрәтле вакыйганы сөйлә. Менә аларга илчеләр килде. Менә без аларга ике кеше җибәрдек. Ә алар бу кешеләрне ялганчы диделәр, шуннан без (илчеләргә) ярдәмгә өченче кеше җибәрдек. Бу өч кеше әйтте: «Без сезгә илче (булып килдек)», — диде. Тегеләр әйтте: «Сез безнең кебек кешеләр бит. Рахман бернинди хакыйкать ачмаган, сез ялганлыйсыз!»
Болар әйтте: «Безнең сезгә җибәрелгәнебезне алла белә. Безнең бурыч (ул әйткәннәрне) сезгә дөрес килеш тапшыру». Тегеләр әйтте: «Без сездә начар галәмәт күрдек! Әгәр туктамасагыз, без сезне таш белән дөмбәсләрбез. Без сезгә интектергеч җәза бирәчәкбез». Болар әйтте: «Галәмәтегез үзегезгә булсын, сез чиктән ашкан кешеләр».
Һәм (шулчак) шәһәрнең (икенче) башыннан (бер) кеше ашыгып килде. Ул әйтте: «Әй кешеләр, илчеләргә иярегез! Сездән бүләк сорамаучыларга, туры юлда торучыларга иярегез!

[1] Җәяләр эчендәге сүзләрне, сүрә аңлашыла төшсен өчен, үземнән өстәдем — Г. Г.

Ничек миңа үземне бар кылган (алла)га табынмаска, хозурына сез барыгыз да әйләнеп кайтачак (аллага ничек табынмаска диде). Мин үземә бер алладан гайри аллалар аламмы соң? Әгәр рахман миңа усаллык теләсә, аларның яклашулары мине йола алмаячак, алар мине коткара алмаячак. Ул чакта мин бит иң ялгыш юлга кергән булачак. Чынлыкта мин сезнең аллагызга иман китердем, мине тыңлагыз».

Аңар әйтәләр: «Җәннәткә кер!» Ул әйтә: «О, әгәр минем кешеләрем алламның мине ни өчен гафу иткәнен һәм ни өчен мине хөрмәтле кешеләрдән иткәнен белсәләр икән!

Һәм без аның халкына аның үзеннән соң күктән бертөрле дә гаскәр җибәрмәдек. Җибәрәбезме соң, без андыйлардан түгел лә!»

Шушы бер генә кычкыру ишетелде, һәм менә алар сүнде.

Йа бичара коллар! Кайсы гына пәйгамбәр килсә дә, алар аны мыскыл итәләр. Үзләренә чаклы яшәгән никадәр буынны безнең һәлак иткәнебезне күргәннәре юк микәнни аларның? Үзләренең алар янына кайта алмаячакларын белми микәнни алар?

Чынлыкта алар бөтенесе дә безнең хозурыбызга киләчәк. Моның галәмәте — җансыз җир. Без аны терелттек, аңардан сез ашый торган орлык (үстереп) чыгардык. Без, җимешләрен алар ашасын өчен, җирдә пальма һәм виноград бакчалары ясадык, чишмәләр чыгардык. Алар рәхмәт әйтмәсләр микәнни? Җирдә үсә торган һәр нәрсәне һәм аларның үзләрен, һәм алар белми торган нәрсәләрне пар-пар итеп бар кылучыга дан!

Алар өчен галәмәт — төн. Без төн өстеннән көнне алабыз — һәм (шулчак) алар караңгылык эчендә калалар. Кояш үзе өчен билгеләнгән җиргә кадәр йөзә. Рахманның, Кодрәт иясенең әмере шундый. Ай өчен дә без барып туктый торган җир билгеләп куйдык. Ул азакка таба карт пальма ботагы хәтле бөгелеп кала. Кояшка айны куып җитәргә ярамый, төн дә көнне узып китә алмый, һәркайсы гөмбәз буенча йөзә.

Алар (кешеләр) өчен гыйбрәт — аларның токымнарын (йөк) төялгән корабларда йөртәбез. Без аларга утырып йөрү өчен (атлар, дөяләр, ишәкләр) бар кылдык. Әгәр теләсәк без аларны батырабыз. Әгәр без мәрхәмәт итмәсәк, без рөхсәт итмәсәк, аларга беркем ярдәм итә алмаячак, аларны коткаручы булмаячак.

Ә үзегездән алда булган һәм үзегездән соң булачак (һәлакәттән) куркып торыгыз, (шулай итсәгез) бәлкем, (гөнаһларыгыз) гафу ителер дигәч — тыңламыйлар. Алланың галәмәтләреннән кайсы гына галәмәт килсә дә, алар йөзләрен боралар.

Үзегезгә алла биргән байлыктан садака бирегез, дигәч, имансызлар иманлыларга әйтәләр: «Нишләп соң аларны без ашатыйк, әгәр теләсә, алла аларны үзе ашатыр иде», диләр һәм алар әйтәләр: «Әгәр сүзләрегез хак икән, сез вәгъдә иткән (кыямәт) кайчан (була)», диләр. Алар бер кычкырып куюдан гайри бернәрсә дә ишетәчәк түгел. Аларның васыятьләрен әйтергә яки гаиләләре янына кайтырга вакытлары булмаячак. Быргы кычкырту белән алар каберләреннән (кубып) үзләренең аллалары янына омтылачак. Башыбызга кайгы төште! (Тыныч) яткан урыннарыбыздан безне кем кузгатты? диячәк алар. Рахманның вәгъдә иткәне (әнә) шул (инде), илчеләр сезгә дөрес әйтә килделәр! Фәкать бер тавыш ишетелер, һәм алар бөтенесе безнең алга килеп басар (дип).

Ул көнне бер җан иясенең дә хәтере калырлык булмас, һәркемгә гамәленә күрә бирелер. Җәннәткә кергәннәр үзләренең яхшы гамәлләре өчен рәхәт чигәр. Алар хатыннары белән күләгә (астындагы) яфракларда кырын ятачаклар. Алар өчен анда җиләкҗимеш һәм һәр сораган нәрсәләре (булачак). Сәлам! диячәк рахман аларга. Гөнаһлылар, бүген (иманлылардан) аерылыгыз! (диячәк). Адәм балалары! Шайтанга баш имәгез дип әйттем түгелме мин сезгә? Ул бит сезнең усал дошманыгыз (димәдемме?), миңа гына гыйбадәт кылыгыз, бу—туры юл (булыр димәдемме)? Ул (шайтан) бик күп халыкларны юлдан яздырды. Сез шуны да сизми калдыгызмы?

Сезгә вәгъдә ителгән җәһәннәм — (менә) шушы. Иман китермәгән өчен бүген шунда яна бирегез. Ул көнне без аларның авызларына печать ябыштырабыз. Безнең белән аларның куллары сөйләшер, кылган эшләре турында аяклары шаһәдәтлек бирер. Әгәр теләсәк, без аларның күзләрен (дә) томалар идек. (Ләкин) Алай итсәк, алар берсенберсе узып йөгергәндә юлны ничек табарлар? Әгәр теләсәк, без аларны икенче кыяфәткә кертер идек, һәм алар алга бара алмаслар иде, кире дә кайта алмаслар иде.

(Без) озын гомерле иткән бәндәләребезнең гәүдәләрен бөкрәйтәбез. Шуларны күреп тә алар акылга утырмаслар микәнни?

Без аны (Мөхәммәтне) шигырь язарга өйрәтмәдек һәм бу аның өчен ярый торган эш (тә) түгел. Бу фәкать кисәтеп кую һәм исән кешеләрне өндәү өчен һәм кяферләрнең сүзләрен аста калдыру өчен ачык (итеп язылган) Коръән.

Безнең алар өчен үз кулларыбыз белән бар иткән һәм (соңыннан) үзләре хуҗа булган хайваннарны күргәннәре юкмы әллә аларның?

Без аны аларга буйсындырдык. Алар аларның (ул хайваннарның) бер ишеләрен ашыйлар, бер ишеләренә атланып йөриләр. Аңардан кешеләргә файда һәм эчемлек. (Шулай була торып та) алар шөкер итмәсләр микәнни?

Алар үзләренә алладан гайри аллалар табып алганнар. (Шул аллаларның) үзләренә ярдәм кулы сузуларын өмет иткәннәр. Ләкин ул аллалар, алар өчен әзер гаскәр булсалар да, ярдәм итә алмыйлар. Аларның сүзләре сине хафага төшермәсен, без аларның нәрсәне яшергәннәрен дә, нәрсәне ачык калдырганнарын да беләбез.

Кеше безнең аны тамчыдан ясаганыбызны үзе күрмимени? Ә юк, ул мотлака дошман! Ул үзенең нәрсәдән яратылганын онытып безгә каршы килә. Ул әйтә: «Череп

таралган әгъзаларны кем терелтсен? (ди). Әйт: аларны беренче тапкыр кем ясаган булса, шул терелтер, чөнки ул (үзенең) бөтен мәхлукларын белә.

Ул (алла) шулдыр ки, кайсы сезгә яшел агачтан ут чыгара һәм менә сез шуннан үзегезгә ут аласыз. Җир һәм күкләрне бар кылган алла шундыйларны (тагын да) бар кыла алмасмыни? Әйе, ул зирәк акыллы бар кылучы! Ул берәр нәрсәне теләсә, «Бул!» гына ди, һәм була (да куя).

Һәр нәрсәне үз хөкемендә тотучы (алла) га дан! Сез барыгыз да аның каршына киләчәк!»

Бөтен ясин менә шул: бераз дингә өндәү, гадәттәгечә, алланың ялынуы, өркетүе. Нәрсәгәдер өндәп йөргән ике кешегә ярдәмгә алланың тагын бер кеше җибәрү әкияте. Һәм (монысы безнең өчен яңалык) алланың үзе авызы белән: миннән башка аллалар да бар, дип әйтүе. Калганы җен дә аңламаслык табигать күренешләре турында кыргый дигәндә дә кыргый, надан дигәндә дә надан мәгълүмат. Тагын нинди дер яшел агачтан ут чыгару... Үлеп ятучыга яки үлгән кешегә шул кирәкмени?

Бәлкем «ясин» дигән сүзнең үзендә гаять тирән мәгънә яшеренеп ята торгандыр? Анысының исә бөтенләй мәгънәсе юк. Я — гарәп әлифбасындагы соңгы хәреф — е хәрефе исеме; син — 13 нче хәреф — с хәрефе исеме.

Иң мәшһүр, иң илаһи, иң саваплы дип йөргән сүрәбез әнә шулардан гыйбарәт.

Әйтергә кирәк, Коръәннең эчтәлеге белән бергә, әдәбилеге дә, күбесенчә, гаять түбән.

«Әй төренгән кеше. Күп димәсәң, бөтен төн басып тор, яртысын басып тор. Яки шуның беразын кимет, яки өстә һәм матур итеп Коръән укы. Без сиңа авыр сүз җибәрәбез. Төнлә торуның тәэсире көчлерәк».

*(Коръән, «Төренгән кеше» сүрәсе, 1—6 аятьләр.)*

Нәрсә бу? Хәтта гарәп теле белгән кеше дә моңардан һичнәрсә аңламый, әлбәттә.

Ә Мөхәммәт үзе Коръәне турында гаять зур фикердә.

«Бөтен кешеләр, бөтен җеннәр (хәтта җеннәр — Г. Г.) бергә җыелып керешсәләр дә, мондыйны яза алмаслар иде», — ди ул.

*(Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 90 аять.)*

Мөхәммәт уенча, Коръәндә юк нәрсә юк. Җирнең өстендәге һәм эчендәге җанлы, җансыз әйберләр, судагы һәм күктәге җанлы, җансыз әйберләр бөтенесе-бөтенесе анда язылган. Коръән бөтен гыйлемне, бөтен кануннарны үзенең эченә алган.

*(Коръән, «Кырмыска» сүрәсе, 77 аять;*
*«Хайван» сүрәсе, 38 аять.)*

Ягъни, дөньяда шул Коръәндәгеләрдән гайри нәрсә эзләмә дә, юк та, булачак та түгел. Утырып йөрергә, йөгеңне тартырга кирәкме? Әнә сиңа ишәк белән дөя, җилкәнле кораб. Җир йомшатырга дисәң, әнә агач сука, таш китмән. Өеңне яктыртырга чыра... Көлке, ләкин гаҗәп түгел. Менә алла чыннан да булып, бу аять чыннан да аның сүзе булса, әйе, гаҗәп булыр иде. Ул чакта без аңа Коръәндә язылмаган, ә дөньяда тулып яткан, җирдә, суда, һавада булган мең вә миллион төрле җанлы-җансыз әйберләрне күрсәтеп, ә бу нәрсә, таңрем? дияр идек. Синең Коръәнеңдәгедән башка менә мондый гыйлемлекләр дә бар әле бу дөньяда, дип, йөзләрчә даһилар, меңнәрчә бөек кешеләр язган искиткеч акыллы китапларны күрсәтер идек.

Мөхәммәт тагын алланың (чыны — үзенең) теле бай булуга мөкиббән. «Алланың сүзләрен язып бетерергә бер диңгез карага янә бер диңгез кара кушсаң да җитмәс иде», ди ул. Ул да түгел, бу кадәресенә дә хәттин ашып хәйран калган сәхәбәләрне тагын да күбрәк хәйран калдыру теләге белән:

«Җирдәге барлык агачлар каләмгә әйләнсә дә, шушы диңгез — җиде диңгез карага әйләнсә дә, алланың сүзләрен язып бетерә торган түгел», ди.

*(Коръән, «Мәгарә» сүрәсе, 109 аять, «Локман» сүрәсе, 26 аять.)*

Әлепне таяк дип белмәгән сәхәбәләр нишләгәндер, без хәйран калмыйбыз, көләбез генә. Әле ике диңгез — әле җиде — үзе җитди кеше сүзе түгел. Ә Коръәнне язу өчен җиде диңгез түгел, бер шешә кара да җитә. Шулай ук дөньядагы бөтен агачларны киссп, каләм ясап тору да хаҗәт түгел. 2 тиенлек каләм җитеп беткән.

Мөхәммәт шаккатырырга исәп тотып язуда оригиналь түгел. Мәсәлән, мокатдәс Инҗил шундый сүзләр белән тәмам була:

«Гайсә кылган эшләрнең бөтенесе китап итеп язылган булса, ул китап дөньяга сыймас иде».

Борынгы Көнчыгыш әдәбияты хыялга гомумән искиткеч бай. Оча торган паласлар, канатлы атлар, бер төн эчендә энҗе-мәрҗәннән, асыл ташлардан хан сарайлары салып куючы гыйфритләр, күз ачып йомганчы шәһәр-авылларны мәмләкәтнең бер башыннан икенче башына күчереп куючы җеннәр... Коръәндәге шаккатризмнар да шундый ук

фантазия жимеше. Алла, чыннан да булып, сүзе җиде диңгез кара белән язып бетереп булмаслык булса, Коръәнне җыен тузга язмаган әкият белән тутырмас иде. Аның уннан тугыз өлешен Тәураттан, Талмуттан, Инҗилдән, Забурдан күчереп язмас иде. Бер үк аятьне кырыкмаса кырык мәртәбә кабатламас иде. Үзенең җиде диңгез кара белән дә язып бетереп булмастай лексиконындагы яңа, матур, илаһи сүзләр белән бизәр иде. Һич югында, Коръәненә берәр исем табар иде. Коръән — нибары уку дигән сүз генә бит ул. Асылы — яһүдләрнең корърә дигән сүзе. Һәм «Корърә»нең дә мәгънәсе — уку. Ә нинди китап уку китабы түгел? Рус балаларының уку китаплары да уку (чтение) исемле. Дөрес, Коръәннең каләм шәриф (изге сүз), кәләмулла (алла сүзе) кебек исемнәре дә бар. Ләкин аларын Мөхәмммәттән бик күп соң дин башлыклары уйлап чыгарганнар... Пәйгамбәрләр белән фәрештәләрнең исемнәре Коръәнгә еврейләрдән, яһүд дин китапларыннан кергәнен әйткән идек. Алланың үз исемнәренең дә күбесе башка теләрдән. Сүзгә шулай бай булса, алла үзенә әлбәттә, бүтән исемнәр табар иде. «Алла» бит ул мәҗүси гарәпләр алласының, ягъни Кәгъбәдәге 360 алладан берсенең исеме. Рабби исә яһүдләр алласының исеме; дөресе — равви. «Минем укытучым» дигән сүзгә туры килә. Рахман — Мөхәммәтнең иң куркыныч көндәше булган Мөсәйлимә пәйгамбәр хыял иткән алла исеме. Тәңре — мәҗүси диндәге монголлар алласының исеме. Тагын әгәр сүзе шулай күп булса, үзен олылату, мактату өчен берәр илаһи сүз ясар иде. Аллаһе әкбәр — гарәп телендә бик гади сүз бит ул, алла бөек дигән сүз. Патшалар да, ханнар да, хәтта писарьлар да Мөхәммәт заманында бөек. Юк, алланың (чыны Мөхәммәтнең) җиде диңгез кара да җитмәслек сүзе юк. Ул хәтта гарәпнең күп кенә гади, матур сүзләрен дә белми. Бөектән югары даһи сүзе бар. Мөхәммәт исә алласын мактаганда әнә шул сүзләрне дә күрми үтеп китә. Безнең кешеләр үз телләрен рәтләп белмәү аркасында ят сүзләр кыстырып сөйләшергә мәҗбүр булган кебек, Коръәнен фарсы, яһүд, юнан сүзләре белән чуплап бетерә.

Бәлки, алла ул җиде диңгез кара белән дә язып бетереп булмаслык сүзләрен теге дөнья өчен саклый торгандыр? Шунда баргач, китереп чыгарып безне шаккатырмакчыдыр? Юк, Коръән һ. б. дини китаплар моны беравыздан инкарь итә. Ахирәттә алла беркем белән бер авыз сүз сөйләшмәячәк. Җәннәт әһелләре алланың нурын гына күрәчәкләр. Бу кадәресе дә бөтен гомергә бер мизгел генә булып алачак.

Мөхәммәт уенча, аның Коръәне шул кадәр камил, ул: «Әгәр Коръән алла сүзе булмаса, кешеләр аңардан, мөгаен, бик күп каршылыклар табар иделәр», — ди.

Никадәр наивлык! Коръәндәге табигать белемнәре, табиплык белемнәре — наданлык үрнәге булу белән бергә каршылык булмый нәрсә соң?

Соңгы сүзем сезгә, мулла абзыйлар. Үз итеп әйтүем, халыкка Коръәннең, хәдисләрнең, тәфсирләрнең үз мәнфәгатегезгә хезмәт итә торган урыннарын гына түгел, бөтенесен укыгыз, безнең кебек рәттән укып күрсәтегез. Әйтергә кирәк, сезгә моны мин генә әйтмим, әнә алла үзе дә шулай куша. Кушып кына да калмый, менә нәрсә ди әле ул тагын:

Без җибәргән аермачык вәхиләрне яшереп яткыручыларга алланың, дәхи дә фәрештәләрнең, дәхи дә җеннәрнең каһәре төшәчәк... Коръән сүзләрен яшереп яткыручылар белән аллаһ тәгалә ахирәттә сөйләшеп тә тормаячак, аларның корсакларын җәһәннәм уты белән тутырачак.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 154, 169 аятьләр.)*

Күрдегез, болай яшереп ятуыгыз өчен сезгә алланың гына түгел, фәрештәләрнең, хәтта җеннәрнең дә каһәре төшәчәк. Анысы бер хәл әле, корсакларыгызны җәһәннәм уты белән тутырачак. Кабат әйтәм, гафил булмагыз, мулла абзыйлар, минем киңәшне тотмасагыз, алла кисәтүенә колак салыгыз. Җәһәннәм уты — бәлеш түбе түгел... Ә, юк, мәет өстенә уку белән котыла алмыйсыз. Мәеткә сезнең ул укуыгыздан сөт тә юк, йон да юк. Сез аны мәчеттә укып карагыз, яки бәлеш ашарга баргач. Гарәпчәсен түгел, татарчасын. Татарга гарәпчә уку, ул барыбер яшереп яткыру хөкемендә бит. Гарәпчә телә әлхәм сүрәсен укы син аңа, телә җиде бабасына җитеп сук, ул барыбер, амин хәзрәт, диячәк. Тагын шунысы, гарәпчә уку белән сез аять саен гөнаһка батып бетәсез. Сүзләрне дөрес әйтмисез бит сез.

Үзегез әйтмешли, сүзебез күп иде, мохтәсәр әйләдек. Төшереп торыйк хәзергә шул урында пәрдәне.

Һиҗрәтнең бу ягында 13 ел буена сузылган басып алу сугышлары әз какшатмагандыр. 14 хатын, җарияләр, кол кызлар җегәрне әз алмагандыр — Мөхәммәт 63 яшенә чыгу белән гүр иясе була. Дин юлында фокус күрсәтеп йөрүдән бүтәнне белмәгән Муса белән Гайсәне үз янына күккә ашырган алла, Мөхәммәт хәтле Мөхәммәтне, үзенең беренче дустын, үзеннән кала дөньяда беренче затны бу хөрмәттән мәхрүм итә. Аның гәүдәсен, һәр гарәпне күмгән кебек, табутка салып җиргә күмәләр.

Ник?

Алланың бу сәер хөкемен күреп, Мөхәммәтнең пәйгамбәр икәненә шик тотмасыннар өчен, дини язучылар берничә йөз елдан соң шундый әкият уйлап чыгарганнар. Имештер, Мөхәммәт үлем түшәгендә соңгы сулышын сулап яткан минутта Газраил килеп керә дә, теләсәң үтерәм, теләмәсәң кыяматкача яши бир, бу кадәресен алла синең үз иркеңә куярга әйтте, ди. Һәм, имештер, Мөхәммәт, үзен ничек алып калырга

белми зарый-зарый елаган хатыннарына, аның урынына үзләре үләргә әзер торган сәхәбәләргә карап-карап тора да, мөселманнарның Мәдинә өстенә болыт булып күтәрелгән аһ-зарын тыңлап тора да, әем, мин үләм, ди.

— Мәйлең,— ди Газраил һәм пычагын пәйгамбәрнең бугазына сызып җибәрә.

Ләкин биредә дини язучыларның бу әкиятләре белән каш ясыйм дип күз чыгарулары ярылып ята. Чөнки болай гына әле Мөхәммәтнең үләргә теләвен берничек тә аклап булмый... Шуннан язучыларның шомарганраклары бу әкияткә шундый койрык өстиләр:

...Газраил пәйгамбәребезнең җанын алырга торганда, Җабраил очып килеп керә. Ул, һәрвакыттагыча, Мөхәммәткә башта алланың сәламен тапшыра, аннан әйтә:

— Әй пәйгамбәр, анда оҗмах ишекләре ачып куелды, фәрештәләр сафка тезелде, хур кызлары зар-интизар булып, синең изге җаныңны көтеп калмактадырлар, — ди.

Мөхәммәт тә бу хәбәргә бик мәмнүн булып, мөбарәк күзләрен йома... Ягъни пәйгамбәребезнең тәне генә ундүрт хатыны белән рәттән җирдә череп ята, ә җаны күптән хур кызлары кочагында инде...

*(Кассас-әл-әнбия, 462—464 битләр.)*

Мин әз генә алда пәрдәне х ә з е р г ә шушы урында төшереп торсак та ярар, дидем. Әйе, пәрдәне фәкать төшереп торырга гына мөмкин, бөтенләй төшерергә ярамый. Һич тә ярамый әле. Дөрес, Мөхәммәт үлем түшәгенә ятыр көннәре алдыннан язган аятьләренең берсендә: «Бүген мин сезнең өчен дин мәсьәләләрен язуны, үземнең сезгә булган рәхим-шәфкатемне тәмамладым», — ди.

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 5 аять.)*

Ләкин белеп әйтми. «Рәхим-шәфкате» генә тәмам була. Ә дин мәсьәләләрен язуны пәйгамбәр әле башлап кына калдыра. Пәйгамбәр үлгәндә әле хәзерге ураза да юк, намаз да хәзергечә түгел, иртә-кич кенә. Бер мәлне көнгә хәтта бер генә кәррә була.

«Намазны кояш баеганда укы. Ә Коръәнне таң атканда. Ул чакта укысаң, шаһитләр була».

*(Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 80—81 аятьләр.)*

Биш вакыт намаз ислам гаскәре Иран илен басып алганнан соң гына, анда киң таралган мәҗүси бер зороастр диненнән керә. Пәйгамбәр заманында хәтта мәчетләр дә бүтән, алар түбәсез булалар. Сәхәбәләрнең кайдадыр түбәле мәчет салганнарын ишеткәч, пәйгамбәр күтәрелеп бәрелә. Бер-бер артлы дүрт аять индереп, түбәле мәчеткә кереп намаз укудан тыя, анда намаз укуның бернинди әҗере юк, кешеләр анда гөнаһларыннан пакьлана алачак түгелләр, ди.

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 108—111 аятьләр.)*

Пәйгамбәр исән чакта бер хөтбә, бер догалык булмый. Хаҗ да хәзергечә үк булмый әле. Гөшер, фытыр, зәкятьләр дә хәзергечә түгел. Шәригать, хөкем кануннары бөтенләй диярлек юк дәрәҗәсендә. Ә шәригать турында дин галимнәре үзләре үк, Коръән шәригатьсез яши алмый, шәригать Коръәнсез дә яши ала, диләр. Һәм бу хакыйкатькә якын.

Аннан Мөхәммәт вафатыннан соң ислам динендә төрле мәзһәбләр барлыкка килә бит әле. Төрле илләрдә барлыкка килгән мәзһәбләр, Коръәнне һәркайсы үзенчә аңлап, ислам дине эчендә үз шартларына яраклаштырылган агым төзәләр. Кайбер мәзһәбләрдә Мөхәммәт арткы планга чигеп, алда әйтелгәнчә, аның урынын чәһреярлардан берсе — хәзрәте Гали ала. Пәйгамбәрлек дәгъва итүче яңа шарлатаннар пәйда була. Тагын шунысы игътибарга лаеклы. Мөхәммәт үлгәндә җир шарының кечкенә генә бер ноктасын биләп торган ислам, бара-тора монголга, кытайга, Идел буена, Казан ханлыгына кадәр килеп җитә, бөтен Европага җәелә.

Кем дә булса, без төшергән пәрдәне күтәреп, шуларның һәрберсен бәян кылырга алынса иде.

Китапның төп чыганагы — Коръән үзе, аннары «Тәурат» белән «Инҗил», «Талмут», «Кассас-әл-әнбия», тагын «Кассас-әл-әнбия» (Рабгузи), «Әнба-әл-әнбия», «Тарих-әл-әнбия», «Тәфсир Ногмани», «Мөхәммәдия», «Мең дә бер хәдис», «Җәвамигыль кәлим», «Гасре сәгадәт», «Гакаид», «Хәзрәте Мөхәммәт», «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Бакырган» китабы һәм түбәндәге китаплар:

1. Л е н и н В. И. Диннәр турында фикерләр. Җыентык. 1936.
2. М а р к с К., Э н г е л ь с Ф. Диннәр турында. Мәскәү, 1955.
3. А б д у л л а е в М., Г а д ж и б е к о в С. «Поговорим об исламе». Махач-Кала, 1962.
4. А м б а р ц у м я н В., академик. Наука о вселенной и религия, 1964.
5. Атеистик календарь. Мәскәү, 1964.

6. Вашингтон И. Мөхәммәтнең тормышы. Инглизчәдән рус теленә тәрҗемә. Мәскәү, 1885.
7. Гыйльми атеистик сүзлек. Мәскәү, 1964.
8. Исәнбәт Н. Исламның дөньяга карашлары. Казан, 1926.
9. Хәким Н. Исламның килеп чыгуы. Өфе, 1926.
10. Катанов Н. Сказание иностранцев о Казани. Казань, 1879 г.
11. Климович Л. Ислам. Мәскәү, 1962.
12. — » — Хатын-кызлар һәм ислам.
13. Коблов Я. Лев Толстой и мусельмане. Казан, 1901.
14. Крывлев И. Инҗил хикәяләре. Мәскәү. 1959.
15. Массэ А. Ислам. Французчадан тәрҗемә. Мәскәү, 1961.
16. Опарин А., академик, «У истоков жизни». 1964.
17. Остроумов Н. Нәрсә ул Коръән. Ташкент. 1883.
18. Соловьев В. Мөхәммәт. Петербург, 1896.
19. Таксил Л. Мәзәк Тәурат. Французчадан рус теленә тәрҗемә. Мәскәү, 1961.
20. Таксил Л. Мәзәк Инҗил. Французчадан русчага тәрҗемә. Мәскәү, 1963.
21. Твен М. Җирдән хатлар. Инглизчәдән рус теленә тәрҗемә. Мәскәү, 1962.
22. Феодосиев А., академик, Философия и естествознание. Москва, 1964.
23. Чыгтай. Исабәт. Казан, 1914.
24. Ярославский Е. Тәурат. 1959.
25. Авторлар коллективы. Дин турында әңгәмәләр. Мәскәү, 1962.

---

## *Хуҗа Насретдин мәзәкләре*

### ХУҖА ҺӘМ СУДЬЯ

Бер бай туй үткәргән. Ул судьяны туйга чакырырга дип Хуҗаны җибәргән. Хуҗа, гадәте буенча, һич тартынмыйча судьяның өенә барып кергәч, судья ачуланып Хуҗага:

— Мине туйга чакырырга синең кебек ишәкне җибәрмәсә, байның башка юньлерәк кешесе юк идемени? — дигән.

Хуҗа судьяга:

— Әфәндем! Бай үзенең барлык хезмәтчеләрен кешеләр чакырырга кушты, — дип җавап кайтарган.

### ТЕШ СЫЗЛАУ

Көннәрдән бер көнне Хуҗа битенә яулык бәйләп йөри икән. Берәү, аны күреп:

— Әй Хуҗа, сиңа ни булды? — дип сораган.

— Минә өченче көн инде тешем бик каты сызлый, — дип җавап биргән хуҗа, чыраен сытып.

— Ул сызлый торган тешең минем авызымда булса, мин аны әллә кайчан алдырып ташлаган булыр идем, — дигән теге кеше.

Хуҗа да:

— Дөрес, ул сызлый торган теш синең авызыңда булса, мин дә шулай эшләгән булыр идем, — дигән.

### ТЕЛ БӘЛАСЕ

Хуҗа капка төбендә басып торган вакытта, атка атланган бер кеше узып бара икән.

— Әй туган, кил, бераз ял ит, кунак булып китәрсең, — дигән аңа Хуҗа.

Шул сүзне генә көткән кебек, теге кеше йортка килеп тә кергән һәм:

— Я Хуҗа, атымны кая бәйлим соң? — дип сораган.

— Минә, минем тик тормаган озын телемә бәйлә, — дигән Хуҗа.

Җыючысы А. ӘХМӘТ.

# Дуслар жыры

## Риза Халид

*Хәрби училищены тәмамлау белән, Риза Халид Ленинград шәһәренә җибәрелә. Ватан сугышы елларында ул, Ленинград күген фашист козгыннарыннан саклап, зенит частьларында хезмәттә уткәрә.*

*Ләкин командир тормышының тагын бер серле ягы була: ул сугышчы гына түгел, ә шагыйрь дә. Симферополь педагогия институты студенты Р. Халид үзенең беренче шигырьләрен сугышка кадәр бастырып чыгара.*



*Тормыш тәҗрибәсе белән бергә шагыйрьнең әдәби осталыгы да үсә, чыныга. Аның инде күп кенә китаплары әдәбият мәйданына чыга. Рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләре «Звезда», «Нева», «Звезда востока», «Советский воин» журналларында, «Литературная газета», «Советская Россия», «Комсомольская правда», «Красная звезда» һәм «Ленинградская правда» газеталарында басылып килә.*

*Риза Халидның берничә шигыре, безнең телгә тәрҗемә ителеп, 1965 елда, «Казан утлары» журналының 8 санында басылып чыккан иде. Быел Татарстан китап нәшрияты аның шигырьләрен китап итеп чыгарырга әзерли.*

*Журналыбызның бу санында без, Кырым шагыйре Риза Халид белән укучыларыбызны тагын да якыннанрак таныштыру өчен, аның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

### Ак төннәр

**Тик көньяк төннәрен**
**Күрдем мин яшь чакта,**
**Ул төннәр карарак**
**Сумала, зәйтүннән [1].**

**Ә сугыш елында**
**Юлыктым бу якка —**
**Айсыз да, ах, нинди**
**Якты бу ак төннәр.**

**Мин зенит тубымнан**
**Ут ачтым дошманга,**
**Нәфрәтем кайнады**
**Алсу йөз, яшь канда.**

**Онытмам залплар**
**Яңгыраган төннәрне,**
**Киң Марс кырында [2]**
**Яралы гөлләрне.**

---

[1] Зәйтүн җимеше турында сүз бара.
[2] Марсово поле — Ленинградтагы бер мәйдан.

Күп тапкыр үзгәрде
Исүе җилләрнең...
Өстемнән бураннар
Үттеләр атлыгып...
Ләкин бу ак төннәр
Күңелдән китәрме? —
Һаман күз алдымда
Гаҗәеп яктылык.

Сез миңа җыр кебек,
Яз кебек миңа сез.
Кипмәс бер чишмәдәй
Гел илһам бирәсез.
Шатланып каршылыйм
Мин сезнең килүне,
Моңаеп озатам
Мин сезнең сүнүне.

Тормышым бирердәй
Мондый һәр төн өчен.
Карыймын Неваның
Балкыган көмешен.

Җыр белән легендар
Шәһәрне кочам мин.
Табигать сафлыгын
Шәраптай эчәм мин.

Дулкыннар уйныйлар,
Җыр әйтә акчарлак,
Тоям мин, ул да көр
Тавышка сөенә.
Кул суза бакыр җайдак,
Бу төнне алкышлап.
Сарайлар баш ия
Ямьле яз күгенә.

Шөһрәте тиңсез бу
Ак төннәр алдында
Башымны иеп мин
Тагын җыр тезәмен.
Юлымны яктыртты
Яшьлегем таңында —
Мәңгегә аларны
Онытмам — сизәмен!

## Чишмә

Урман читендә бар карт бер имән,
Канаткайлары җиргә үк иңгән.
Тора коллардай кәкре ботаклар
Ирләрчә берсен-берсе кочаклап.

Тамыры төбеннән саф су ургыла.
Тар үзән буйлап чылтырап ага.
Моңын тыңласаң, йөрәккә ял була,
Суы, кул тыксаң, өшетеп ала.

Дымыннан бөтен үзән яшәргән,
Нур чәчеп, чәчәк атканнар гөлләр.
Кем дулкынланмас якты хисләрдән
Искәндә монда иртәнге җилләр?!

Имән шаулаган чишмә янында
Мин дә беразга тукталып калдым.
Күпме уй үтте минем аңымнан,
Шунда иң татлы хыялга талдым.

Дидем: и шагыйрь, тылсымлы җырың
Тамчыдай чиста һәм тәмле булса,
Туфракка сеңгән шул чишмә суы
Кебек йөрәккә, күңелгә тулса,—
Аһәңле җырың, сөйгән кызыдай,
Боек егетнең күңелен ачар.

Озын юлларда, кояш кызса да,
Кичә алыр ул сахра, тау аша...

Яшь кебек бөллүр су туктамаса,
Беренче сөю чәчәге сулмас.
Җырыңнан халык шатлык, дәрт алса,
Шагыйрьгә шуннан зур бәхет булмас.

## Нәзакәт

Кешенең зиһене чиксез бер дәрьядай,
Дәрьяда вак кына утраулар булалар.
Истәлек уйларым, иркле кошлардай,
Әйләнеп утраулар өстенә куналар.

Бер уйдан йөрәгем бүген һич арынмый...
Яшь идем, дорфалык булгандыр мең кәррә.
Бәгырен телгәләп, әрнетеп алырлык
Авыр сүз, сизмәстән, әйттем мин әнкәмә.

Күп көзләр һәм язлар кичтеләр шуннан соң,
Алышынды урманнар һәм таулар һавасы,
Тик һаман бик тирән, упкын дип уйларсың,
Йөрәкнең, вөҗданның төзәлмәс ярасы.

Кайчакта дусларның бәгыренә тиярлек
Катырак берәр сүз әйтергә дисәм мин,
— Улым бу синме соң? дип әйткән сүзләрен
Ишетеп әниемнең, сүземне кисәм мин.

Әйтәмен үземә:
— Хәлеңә сал син күз,
Йөзеңнән качтымы кояшның нурлары,
Я синең күңелдән чыктымы шулай тиз
Әниеңнең күз яше катышкан җырлары?!

Шул вакыт торам да, телимен ялынырга:
— Гафу ит, әнкәем, гафу ит,— диярга.
Мең шөкер шул чакта өйрәнеп калуыма
Нәзакәт алдында башымны ияргә.

Күп көзләр һәм язлар кичтеләр шуннан соң,
Алышынды урманнар һәм таулар һавасы.
Тик һаман бик тирән, упкын дип уйларсың,
Йөрәкнең, вөҗданның төзәлмәс ярасы.

ӘНВӘР ДАВЫДОВ тәрҗемәләре.

## Тынлыкны яратмыйм

Боз кебек тынлыкны мин мәңге яратмыйм,
Шау-шулы тауларны, кырларны сөям мин.
Җил исмәс урманда мин сулыш алалмыйм,
Үземне җансыз бер нәрсәдәй сизәм мин.

Үрмәләп тар, текә сукмаклар, юллардан,
Күкләрне терәткән тауларга менәм мин.
Шул горур кальгадәй [1] кыялар башыннан
Үткер күз лачындай бар якны күрәм мин.

— Кил монда! — ди миңа киң, ерак офыклар,
Кичелмәс тауларның ачы җил-бураны.
Талса да бу юлда аяклар һәм куллар,
Мин телим туктаусыз тыңларга шуларны.

Көйдерсен ут-кояш ташларын кыяның,
Ажгырсын бураннар! Мин чыгам юлыма...
Йөрәгем: — Сөялләр басса кул-аягың,
Яшәүнең кадерен аңларсың! — ди миңа.

Урнашып көндез дә, төнлә дә шул тынлык,
Сузылса гомергә... Әйтегез, кай заман
Өндәүле җырымнан җиңелер гамьсезлек,
Туктаусыз агылыр тәнемдә таза кан?!

## Миндә—синең йөрәгең

Һәр мәлне хәтердә
Калдыру мөмкинме?
Мин беләм: онытылмас
Андый мәл ләкин бар.
Сүз бирдем: — Онытмам,
Диеп мин, ул көнне,
Җил кебек очса да
Канатлы ай, еллар...

Хәтерлим: чәчәккә
Төрелгән тирәкләр
Мөсафир кошларга
Кочагын җәйгәндә,
Шатланып типтеләр
Безнең яшь йөрәкләр
Гүзәл кыз — вожатый:
— Сафка бас! — дигәндә.

Җанымнан газизрәк
Анамдай эндәшеп,
Ягымлы елмайды
Шулчакны ул миңа.
Аңымда шул килеш
Калды ул урнашып,
Бәйләгән чагында
Галстук муеныма.

Алды үз сафына
Соңыннан комсомол.
Бирелде партбилет
Фронтта — ут эчендә.
Саклады ләкин мин:
«Һәр вакыт әзер бул!» —
Дигән зур өндәүне
Һәркайчан исемдә.

Пионер өйрәтте
Ватанны сөяргә,
Каһарман комсомол —
Гел алда булырга.
Партиям өйрәтте
Көрәштә җиңәргә,
Тынычлык байрагын
Кулларга алырга.

Белмимен: булсам да,
Кай җирдә, кай якта,
Кайтсам да илемә,
Барсам да чит җиргә...
Яшьлекне бизәгән
Гади ал галстукка
Тормышым, бәхетем
Бәйләнгән гомергә.

Пионер никадәр
Таза көч синдә бар.
Гел алга! Тик алга! —
Синең бар теләгең.
Кунса да башыма
Ак кардай кыраулар,
Бел: минем күкрәктә
Синең яшь йөрәгең!

ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәләре.

[1] Кальга — крепость.

## Таң атканда

Таң атканда карадым күк йөзенә,
Болытлардан миңа ак ай күренде.
Тәрәзәмне ачып куйдым, өемә
Җилләр рөхсәт-фәлән сорамый керде.

Җилләр, җилләр, урман-таулар кичкәнсез,
Зәңгәр диңгезләрдән сулар эчкәнсез.
Сезне каршы алам мин чын күңелдән,
Хуш киләсез, узыгыз әйдә түрдән.

Бу җилләрне чиксез чүлләр истергән,
Кил, сөйләшик, дустым, җилләр белән без;
Алар безгә шатлык җыры китергән,
Бөркет җыры безгә таныш, беләбез.

Әгәр без ул җырны аңлый белмәсәк,
Болытлардан бармы безнең аерма?
Әгәр җырга шатланмаса, көлмәсә
Бармы дәрте ир егетнең җанында?!

Җырдан канатланып айларга юл ач,
Җырсыз гомер — җимешсез бакча бит ул,
Җырсыз йөрәк фәкать чыпчыкка охшаш,
Ул чырылдый гына, бар белгәне шул.

Ләкин безнең йөрәк һич андый булмас:
Киләчәкнең бөек рухы бар анда,
Ул таң чәчәгенә һәм җилгә охшаш,
Кояш күк нур чәчә ул якты таңда!

## Диңгез култыгында

Бөллүр су тирбәнми, көзгедәй яп-якты,
Дулкыннар ярлардан тын гына чигенә.
Иртәнге җәй җиле диңгезне кузгатмый,
Ә кояш нурлары туктаусыз сибелә.

Чуерлы тар сукмак нәкъ ярдан башлана,
Урманда югала, атылган ук сыман,
Күк йөзе зәп-зәңгәр атластай, ә һава
Шундый саф, хуш исле, дөньяда юк сыман.

Һәм горур каршылый сезне бу сукмакта
Тантана тынлыгын саклаучы тирәкләр, —
Гүяки полкта иелеп ал байракка,
Тез чүгеп ант итә каһарман йөрәкләр.

Гүяки бу җирдән — күңелдән мин тоям —
Кремль эченә тәүге кат керәм мин,
Гүяки мавзолей тирәли баскычтан
Әкертен төшәм дә Ильичны күрәм мин.

Ямь-яшел агачлар сарган бу урында,
Ин түрдә урнашкан даһиның шалашы.
Уйласам гаҗәеп гомереӊ турында —
Шатлыктан түгелә энҗедәй күз яшем.

Һәйкәлгә баш иям, җәйге таӊ яп-якты,
Бу җирдә үземне илһамлы тоям мин.
Ленинчы отрядның мин дә бер солдаты,
Һәм шуӊа үземне бәхетле диям мин.

Тылсымлы тауларның түбәсе бик биек,
Һәм зәӊгәр диӊгезнеӊ төпләре бик тирән.
Мөмкинме бездәге сөюне үлчәмәк?
Биек ул таулардан, тирән ул диӊгездән.

## Заман

Меӊләгән чишмәләр
Елгага әверелеп
Диӊгезгә
Атлардай ашыгып агалар.
Таллар да үсәләр
Гел өскә үрелеп,
Очлары
Биек күк гөмбәзен кагалар.

Кечәге шуышкан
Бала да иртәгә
Аякка басар да
Китәр ул йөгереп.
Көн килер, ул шуннан
Үрләрне үтәр дә,
«Син!» диеп эндәшер
Галәмгә, үз күреп.

Заман ул йөгәнсез:
Гел алга омтылып,
Космоска юл тота;
Тоткарсыз зур заман.
Атлый бит, күрәмсез,
Йолдызга күз кысып,
Баягы яшь «малай»
Бетонлы юллардан.

Ә алда, шат кояш
Нурында тураеп
Ракета төбәлгән
Зәӊгәр күк йөзенә.
— Кил, очырт, күккә аш,—
Дип карый елмаеп ул
Батыр атлаучы
Егетнеӊ күзенә.

●

Әйтәсеӊ: аударып мәрмәр таш кыяны,
Мәһабәт тауларны кичәр бу сүзләрем.
Бөркеттәй очырып чиге юк хыялны,
Иӊ ерак йолдызның ачармын серләрен.

Сүзем юк, кодрәтле икәнсеӊ бигрәк тә,
Ләкин мин ышанмам, мактанчык юлдашым,
Әгәр син сүзеӊне үткәреп йөрәккә
Чыгара алмасаӊ бер тамчы күз яшен.

●

Тамчылар елларча тамса бер туктамый
Корычтай нык ташны тишкәли һәм вата.
Аӊла син, үпкәле сүзләреӊ нәкъ шулай
Йөрәкне телгәли, рәнҗетә, сыкрата.

Бик яхшы беләсең, тамчыда йөрәк юк:
Аның бар теләге — тамарга, агарга,
Ә бездә йөрәк бар һәм бездә теләк күп, —
Нигә соң аларны утларга ягарга?!

●

Үпкәлисең дә син әйтәсең кайчакта:
« — Инде син миңа, — дип, — лаек дус түгелсең.
Сүнмәде мәхәббәт, мин янам учакта,
Син исә сүрелгән бер зәгыйфь күңелсең...»

Акланмыйм, кем белә, тугрыдыр сүзләрең,
Тик син дә уйла бер уйның хаклысын:
Яктырып янармы иде соң йөрәгең,
Төшмәсә аңарга сөюем чаткысы?

●

Кыяның чал башы болытка күмелгән, —
Тырмашам мин аңа, йөрәгем алына.
Ләкин дә карасам шул биек түбәдән
Күңелем куанып ашкына, талпына.

Син исә менмәдең мәһабәт тауларга,
Атлыйсың гел туры, төз генә юлдан.
Әгәр дә күз ташлап бу үткән юлларга
Карасаң, күңелеңне боз каплар, туган!

●

Иңенә күкләрне күтәргән таш кыя,
Очына бакканда әйләнде башым.
— Йолдызлар чүленә кил! — диде ул миңа,
Җавабым шул булды:
— Мин әле яшьмен!

Заманы шул хәзер, космоска «Син!» дибез,
Мин күрәм ак юллар зәп-зәңгәр күгемдә,
«Марска!» дип шлемлар кигәндә инде без,
Ул кыя миңа тик бер кибән күк кенә.

●

Юлларга, эзләргә яттылар ак карлар,
Уздылар бураннар... Ә минем уемда:
Бер хат та язмадың син ерак яклардан...
Ә хәзер килгәнсең, чәчәкләр кулыңда.

Ник тирән һәм уйчан күзләрең сулды?
Сөю дә, ялкын да, дәрт тә юк аларда:
Я, телсез чәчәкләр ник кирәк булды?
Ташла син, ичмасам аларны алдама!

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

Бөек Октябрьның 50 еллыгына

*Абдулла Юсупов,*

запастагы инженер-подполковник,
1919 елдан КПСС члены.

# ПОЛКТАШЫМНЫҢ ЯКТЫ ЯЗМЫШЫ

## 1. Таныш исем, таныш кушамат

1958 елны Шамил Усмановның сайланма әсәрләре аерым китап булып басылып чыкты. Язучының туганнары, Габдрахман белән Йосыф, бу китапның титул битенә «Революция юлында көрәштәшегез Шамил Усмановның истәлеге булсын» дигән сүзләрне язып, миңа бүләк итеп бирделәр.



Язучының исеме, аның әсәрләре озак вакытлар хаксызга онытылып торды. Шуңа күрә мин аның «Легион юлы» әсәре белән шуннан соң гына, беренче кат басылып чыгуына утыз еллар үткәч кенә, яхшылап таныша алдым. Татар әдәбиятында гражданнар сугышы темасына язылган зур күләмле әсәрләрнең иң беренчесе булган бу повестьның художество сыйфатлары һәм анда сурәтләнгән онытылмас вакыйгалардан да бигрәк, мине шул вакыйгаларда турыдан-туры катнашучы кешеләр кызыксындырды. Чөнки «Легион юлы» әдәби әсәр генә түгел, шул ук вакытта ул тарихи хезмәт тә. Без анда атаклы полководец В. К. Блюхер, күренекле партия эшлеклесе А. А. Коростылев, батыр командир А. Е. Левашев кебек тарихи шәхесләр белән бергә, Ш. Усмановның көрәштәш иптәшләре һәм дуслары образларын да күрәбез. Аларның исем-фамилияләре дә, сугышчан юллары да нәкъ чынбарлыктагыча бирелгән.

Повестьта сурәтләнгән геройларның берсе, әле Сәет, Гәрәй исемнәре белән, әле Гайфи фамилиясе яки Наполеон кушаматы белән йөртелгәне мине аерата үзенә җәлеп итте.

Минем күптәнге танышымның исем-фамилиясеме икән әллә ул?

Түбәндәге юлларны укыгач, шикләнүләрем бөтенләй юкка чыкты...

*«Сәет белән без бала чактан ук таныш,— дип язган автор аның турында.— Бергә укыдык. Ул яшьтән үк шундый җанлы, сүзчән иде. Батырлыгы, терелеге өчен без аны, шаяртып, Наполеон дип атый идек. Шул исем аңарда сакланып килгән. Башта, Оренбургта чакта, ул агитатор иде. Бара торгач, пулеметны өйрәнеп, пулеметчик булды».*

Әйе, исемнәрнең очраклы туры килүе генә түгел иде бу. Язучы минем полкташым пулеметчы Сәетгәрәй Гайфетдинов турында сөйли. Аны да шул ук исем, шул ук кушамат белән атап йөртә торганнар иде бит... Язучының биргән характеристикасы да аны, аның хәрәкәтләрен, аңа хас сыйфатларны күз алдына китереп бастыра...

*«Сәет кулында пулемет тотылган кош шикелле сикерә... Сәет пулеметның суы кайнап чыкканын, атылган буш гильзаларның күп булып өелгәнен сизми. Аның бөтен дикъкате алга юнәлгән. Ул каршыга килгән дошманның һәрбер хәрәкәтен тотып алырга тора. Килүчеләрнең җилкәләрендәге алтын погоннар аның күзен яндыралар... Кинәт пулемет туктады. Сәет, гадәтләнгән җитез хәрәкәт белән, аның капкачын ачып карады. Ул максимын биш бармагы шикелле яхшы белә. Аның һәрбер капризы белән таныш. Патрон кәкрәйгән. Ул бик зур җитезлек белән патронны алып ташлады. Капкачны шап итеп япты. Машинасының төймәсен басты. Пулемет туктавына алданып аякка баскан офицерлар тезмәсе, чалгы белән кискән шикелле, авып китте... Максим тагы туктады.*

*— Ә, шайтан, сиңа ни булды тагын! — дип, Сәет пулеметның капкачын ачты. Канал кибеп ярылган иде. Сәет урыннан сикереп торды. Як-ягына каранды. Берничә офицер, штыкларын сузып, аның өстенә киләләр иде...»*

Минем полкташым Сәетгәрәй дә нәкъ шушындый салкын канлы һәм бер үк вакытта бөтен дөньясын онытып үз эшенә бирелүчән иде. Шулай итеп моннан илле еллар элек булып үткән вакыйгаларны сурәтләгән повестьның герое минем танышым булып чыкты. Һәм повестьта сурәтләнгән вакыйгалардан бераз соңрак «Наполеон» белән танышуым, аның белән бәйле күренешләр берәм-берәм күз алдымнан узды...

## 2. Кыю егет, батыр командир

1920 елның җәендә Верный (хәзерге Алма-Ата) шәһәрендә башланып киткән фетнә Җиде Су районына урнашкан Өченче Төркстан дивизиясенең ышанычсыз икәнлеген күрсәтте. Бу фетнәне бастыру белән җитәкчелек иткән, элегрәк Чапаев дивизиясенең комиссары булган Д. А. Фурманов дивизияне бүтән ышанычлырак частьлар белән алыштыруны таләп итте. Ләкин бу таләп үтәлмәде, чөнки Төркстан фронты гаскәрләре Ферганә һәм Бохарадагы сугышлар белән мәшгуль иде. Көзен Бохара әмираты тар-мар ителде. 20 елның ахырында Ферганә үзәнлеге дә басмачылардан чистартылды. Беренче Аерым Идел буе татар бригадасы (ул вакытта инде 4 нче Төркстан бригадасы дип исемләнә иде) Җиде Су районына күчәргә приказ алды.

Беренче татар укчы полкы Җиде Суга 1921 елның март ахырында күчеп килде һәм Пишпәк (хәзерге Фрунзе) шәһәренә урнашты. Казанда оешкан һәм Уралдан Бохарага, Бохарадан Ферганәгә кадәр сугышчан юл үткән Мулланур Вахитов исемендәге бу полкның сафлары шактый сирәгәйгән иде. Бәхеткә каршы, нәкъ шул вакытта Татарстаннан ярдәмгә җибәрелгән частьлар килеп җитәргә ерак калмаган иде. Бригада командиры миңа (ул вакытта мин Беренче татар полкының

комиссар ярдәмчесе идем) һәм Беренче батальон командиры Җамал Усмановка аларны каршы алу эшен тапшырды.

Марш батальонының кызылармеецларын без Җиде Су һәм Сыр-Дарья өлкәләре чигендә, берничә километрларга сузылган Карабалта авылында, очраттык. Отряд кечкенә-кечкенә төркемнәргә чәчелеп килә, һәм хәрби дисциплинаның эзе дә юк иде. Казанда урнашкан Запас Армиянең резервларны бик яхшы әзерләвен без белә идек һәм, бу тәртипсезлекне күреп, бик гаҗәпләндек.

— Мондый хәлдә мин аларны Пишпәккә алып керә алмыйм,— диде патша армиясендә фельдфебель булып хезмәт иткән Усманов һәм батальонның тәртипсез хәрәкәтен туктату өчен Карабалта читенә атлы ординарецларны сакка куйды. Аларга Карабалтадан бер генә гаскәрине дә чыгармаска боерык бирелде.

Бу чара үзенең нәтиҗәсен күрсәтте, марш батальоны авылга тупланды. Шул ук кичне Җамал Усманов батальонның команда составын җыйды. Батальондагы тәртипсезлек, башбаштаклык турында бик кызу сөйләшү булды. Усманов командирга иртә белән авыл уртасындагы мәйданга батальонны сафка тезергә боерды.

Командир Татарстандагы ачлыкны искә төшерде, тимер юлда бер ай буена кичергән газаплар, ике йөз километр чамасы юлны җәяүләп узу турында әйтте. Өстәвенә, озак вакытлар ачлык белән җәфа чиккән бик күп сугышчылар, җирле халыкта бик яхшы кунак булгач, эч киту белән чирләгәннәр.

— Сафка тезү аларда ризасызлык кына тудырыр,— диделәр командирларның күбесе.— Барган килеш барсыннар инде шул көе...

Бу сүзләр болай да ачулы Усмановның ачуын гына арттырды.

— Бригада сугышчан өстәмә көчләр көтә,— диде ул, җене чыгып.— Ә сез тәртипсез халык төркеме куып китерәсез...

Аннары ул беравык дәшми торды да кинаяле итеп, акрын гына тавыш белән:

— Хәер, отрядны сафка тезүнең сезнең өчен шундый зур проблема икәнен белмәдем,— дип өстәде.— Сезнең арада моны хәл итәрлек бер генә командир да булмас микән?..

Марш батальоны командирлары тын калдылар.

— Мөмкинлек бирсәгез, мин сафка тезәм аларны,— дигән кыю тавыш бу авыр тынлыкны бозды. Барыбыз да тавыш ишетелгән якка карадык. Арткы рәттән тәбәнәгрәк кенә буйлы, үткер, җитез карашлы бер егет аягүрә баскан иде.

— Кем ул?— дип сорадым мин янымда утырган батальон комиссарыннан.

— Наполеон,— дип җавап кайтарды комиссар, йөзен чытып, һәм, аның тәкъдименә җитди игътибар бирмәскә кирәклекне аңлатып, кулын селтәп куйды.— Документлары буенча Сәетгәрәй Гайфетдинов ул, званиесе — краском.

— Ни өчен аны болай санга сукмыйсыз?

— Җилкуар егет, партизанщинадан аерыла алмый,— диде комиссар.— Шуңа күрә без аны командирлыктан төшердек.

Без шулай сөйләшкән арада, Усманов батальонны сафка тезү эшен Наполеонга тапшырырга ризалык белдерде. Моңа батальон командиры да ачыктан-ачык каршы килә алмады...

Иртән, билгеләнгән сәгатьтә, Усманов белән бергә мәйданга чыктык. Кызылармеецлар тәртипсез рәвештә төркемнәргә җыелып торалар, шаулашалар иде.

— Димәк, Наполеон да булдыра алмаган,— дияргә дә өлгермәдем, колакларны ярып, әче сызгыру тавышы яңгырады. Сызгырган тавышка борылып карасак, Гайфетдиновны күрдек. Мәйдан тынды.

— Солдат мәктәбен үткәнлеге күренә моның, — дип куйды Җамал, канәгатьләнеп.

— Братва! — дип кычкырды Наполеон, боерык тавышы белән. — Сарык көтүе булып йөрүебезне кайчан туктатабыз? Җиде Су кулакларыннан мыскыллатмыйк!.. Минем команданы тыңла — становись! — һәм Гайфетдинов иңбашы тигезлегендә уң кулын сузып, халыкка аркасы белән борылды.

— Абый кеше, бүтәнчә ярамасмы соң? — дип, чытык йөзле бер сугышчы Усмановка мөрәҗәгать итте.

Җамал җавап бирмәде.

— Ни сорап торасың? Күренеп тора: иске режим кешесе бит ул! — диде икенчесе.

Икенче яктан бүтән тавышлар ишетелде:

— Агай-эне, җәмәгать, командир үз кешебез бит — Наполеон!..

— Кушаматы белән әйтмә инде, ичмасам, Сәетгәрәй диген.

— Күп сүлисез, егетләр. Тезелергә кушты ич, әйдә!..

Кызылармеецлар шулай сөйләшә-сөйләшә, акрынлап сафка тезеләләр. Гайфетдинов сафка тезелгән сугышчылар алдына чыгып басты.

— Даешь равнение! — дип кычкырды ул һәм флангка килеп сафларның тигезлеген тикшерде.

— Смирно!

Һаваны ярып, Сәетгәрәйнең яңа командасы яңгырады. Аннары ул, төз атлап, Усманов янына килде дә батальонның тезелүе турында рапорт бирде.

Бу кыю егетнең Корсиканың бөтен дөньяга танылган бөек улы белән һич кенә дә охшашлыгын күрмәдем мин. Буйга да ул зур түгел, званиесе дә бик кечкенә. Бүтәннәрдән киеме белән дә аерылып тормый. (Ә ул вакытта һәркем өчен уртак хәрби форма юк иде әле. Кайсыбыз ничек тели, шулай киенә идек.) Шулай да бүтән командирлар, званиеләре белән аннан олыраклар, булдыра алмаганны гадәти генә итеп, бик җиңел генә башкарып чыкты. Дисциплинаны бар дип тә белмәгән шулкадәр халыкны нәрсәсе белән генә сихерли алгандыр ул? — бу минем өчен сер иде. Соңрак аның белән якыннанрак танышкач кына, мин моңа төшендем.

Усманов Сәетгәрәйгә, ординарецлар командасыннан алып, ат бирде. Һәм батальонны Пишпәккә алып баруны аңа тапшырды.

Батальон Карабалтадан оешкан төштә чыкты. Колонна артында атлы арбаларда авырулар бара иде.

Юлдагы икенче торак пунктына керер алдыннан Гайфетдинов батальонны туктатты һәм:

— Үз-үзегезне тәртипкә китерергә! Җыр башлаучылар колонна алдына! — дип команда бирде. Авылга дәртле җыр белән килеп кердек.

Шамил Усманов повесте герое белән ике елга якын сузылган хезмәтем шулай башланып китте.

* * *

Җиде Суга без Анненков, Бакич, Дутов бандалары тар-мар ителгәннән соң килдек. Алар Көнбатыш Кытайга качып, бөтенләй юк ителүдән котылып калдылар. Хәзер аларның чикне бозып, диверсияләр эшләве мөмкин иде. Шуңа күрә Совет — Кытай чиген даими күзәтү астында тотарга кирәк иде. Тянь-Шань тавы артындагы Кашгария Төркстанга карата диверсия оештыруның үзәге иде. Хөсәен Мәүлүтов командалыгындагы Өченче татар полкы Токмак шәһәренә урнашты һәм Җиде Су өлкәсенең эчке районнарына уза торган олы юлны саклау аның төп сугышчан бурычы иде. Боам тарлавыгы аша аларга ярдәм итү эше безнең Беренче полкка йөкләнде.

Безнең полк Пишпәктән билгеләнгән урынга килеп җиткәч тә, Сәетгәрәй Гайфетдинов бер төркем командирлар белән Боам тарлавыгы районына рекогносцировка ясау өчен җибәрелде. Тарлавыктан Җиде Су үзәнлегенә таба ыргылып Чу елгасы ага. Елганың һәр ике ягында Алатау кыя булып күтәрелә. Зур-зур ташлар, өскә төшәрдәй куркыныч булып, асылынып торалар.

— Ул-бу хәл була калса,— диде Сәетгәрәй, рекогносцировкадан кайткач,— тарлавыкның көнчыгыш ягына өч-дүрт пулемет куеп, бөтен дивизияне тоткарлап торырга була.

Әмма гражданнар сугышы беткән иде инде һәм, бәхеткә каршы, акларның дивизияләренә каршы торырга башка туры килмәде. Төркстанда тынычлык урнашты, күп милләтле Җиде Су халкы социалистик тормыш төзү эшенә кереште. Безнең алда да хәзер, хәрби бурычлардан да бигрәк, тыныч тормыш бурычлары тора иде. Хәзер монда Совет хөкүмәте иске колониаль режимны, халыкларның экономик тигезсезлеген бетерү буенча житди чаралар үткәрә башлады. Бу чараларның иң беренчесе — җир-су реформасы булды. Ә ул вакытта җирләр һәм арыклар 1916 елда кыргыз-казакъ күтәрешен бастырган вакытта коралланып калган кулаклар кулында иде әле.

Без реформаны үткәрүдә кораллы көч кулланмадык. Шулай ук читтә дә калмадык. Реформа үткәрүчеләр арасында безнең вәкилләр дә бар иде. Менә шуңа күрә дә кулак реформага, Совет хөкүмәте үткәргән бүтән чараларга каршы баш күтәрергә батырчылык итә алмады. Бу ярдәмебез өчен җирле казакъ халкы безнең командирларны «тамыр» дип олылыйлар иде. Сәетгәрәй Гайфетдинов та җирле халыкның хөрмәтле «тамыр»ы булды.

Җәй узды. Сентябрьдә Төркстан фронты командующие бригадага инспекция ясады. Инспекциядән соң бригада штабын таратып, полкларны Дүртенче Төркстан дивизиясе карамагына бирделәр. Шуның белән хәрби бурыч та үзгәрде, участоклар да алышынды. Яңа позицияләргә урнашу өчен Беренче татар полкына, Пишпәктән Кополга кадәр Җиде Су чүлләре, дәлалары аша җәяүләп алты йөз километр авыр юл үтәргә кирәк иде.

**Җиде Суның җидесен дә**
**Үтәрбез туктамыйча.**
**Туган илнең чикләрен**
**Сакларбыз йокламыйча,—**

дип җырладылар сугышчылар походта. Һәм, чыннан да, безнең полкка Совет — Кытай чиген сакларга куштылар. Полкның өч батальоны мең ярым километр озынлыктагы чик буена сибелде.

Полк кызылармеецлары заставаларга урнашкач, күп тә үтмәде, партия сафларын беренче чистарту эшләре башланып китте. Мин, хезмәт вазифам буенча, бу чараны үткәрүдә турыдан-туры катнашырга тиеш идем.

1921 ел. Көзге кичләрнең берсе. Без Гавриловка авылында (хәзер Талды Курган шәһәре) чиркәү бинасына җыелдык. Чиркәүнең кыңгыравы күптән алынган, шуның белән аның ходайга мөнәсәбәте дә беткән иде.

Җыелышка катнашучылар тантаналы тынлыкка чумган. Һәркемнең йөзендә дулкынлануы сизелеп тора. Бу аңлашыла да. Чөнки партия сафларын чистарту беренче мәртәбә үткәрелә әле. Заманы — кырыс һәм таләпчән.

Тикшерү алфабит тәртибендә алып барыла.

Сәетгәрәй Гайфетдинов беренчеләрдән булып комиссия каршына чакырылды.

— 1900 елда Казан губернасы, Чистай өязенең Такталы авылында ярлы семьяда туганмын, — дип сөйләп китте ул. — Унике яшемдә ике еллык батрак стажым бар иде инде. Садыйк кулак бер генә минутка да тик торырга ирек бирми иде, бик авыр куллы кеше иде. Мин, ул намаз укыган вакытларны туры китереп, азрак тын алырга тырыша идем. Ләкин бай, рәкагатен бозып булса да, мине тик тотмас өчен эш куша иде. Анда җәфа чигә-чигә тәмам эштән чыктым. 1912 елны эш эзләп читкә — Оренбург ягына киттем. Покровка авылында тегермәнчегә кара эшче булып ялландым, соңрак кирпеч заводында эшләдем. Өч елдан туган авылыма кайттым. Ләкин анда да миңа кулакка ялчы булудан башка эш юк иде. Тиздән тагын Покровкага китеп бардым...

Гадәттә мәзәкчән һәм шук сүзле Сәетгәрәй бу моментта бик җитди иде. Күзләрендә кыюлык бөркелеп тора, йөзендә каушауның эзе дә күренми — чөнки партия алдында намусы саф иде аның.

— Революцияне Оренбургта каршы алдым, — дип дәвам итте ул. — Питерда беренче Совет хөкүмәте оешканнан соң, Оренбург Советы да властьны үз кулына алырга карар кылды. Ләкин анда Совет власте озак яши алмады — Совет членнары кулга алынды һәм Оренбургта ак казаклар атаманы Дутов диктатурасы урнашты. Менә шул көннәрдә, 1917 елның 19 ноябрендә, мин партиягә кердем һәм матросларның күчмә отрядына кызылармеец булып язылдым. Бу вакытта отряд Платовка авылында тора иде. Мин шунда ук Оренбургка һөҗүм итүче кызыллар сафында беренче сугышчан чыныгу алдым. 1918 елның январь ахырында Оренбургны азат иттек һәм, ниһаять, анда да Совет власте урнашты. Әмма ул куркыныч астында иде, ак казаклар зур көчләр белән еш кына һөҗүм итеп тордылар. 4 апрельгә каршы төндә ак казаклар, шәһәргә кинәттән һөҗүм итеп, 129 кешене суйдылар. Алар арасында балалар һәм хатын-кызлар да күп иде. Бу юлы без акларны шәһәрдән куып чыгардык. Ләкин 1918 елның июлендә Оренбургны тагын калдырырга туры килде. Мин көнчыгышка — Актүбәгә чигенүчеләр арасында идем һәм III интернационал исемендәге легион составында сугыштым. 1919 елның гыйнварында, Каратугай, Мартук, Яйсан, Сагарчин, Иләк һәм башка сугышларны үтеп, Оренбургка кайттым. Шул ук елның язында Колчакка каршы сугышка киттем. Аны Себергә кудык. Генерал Беловның Көньяк армиясен Беренче революцион армия тар-мар иткәннән соң, Совет Урта Азиясен әйләндереп алган боҗра өзелде. Оренбург тирәсендәге сугышлар җиңү белән тәмам булды. Мин Казанга укырга киттем. Татарстан республикасының Запас Армиясе каршындагы «Югары хәрби мәктәп»не тәмамладым. Беркадәр запас полкта эшләдем һәм Беренче татар полкына җибәрелгән өстәмә көчләр составында монда килдем. Калганын үзегез беләсез...

Әйе, Сәетгәрәйнең тормыш юлы безнең күз алдында ачык иде. Шуңа күрәдер, аңа сорауларны да аз бирделәр.

— Партиянең соңгы съезды карарларын таныйсызмы? — дип сорады комиссия председателе.

Бу сорау юкка гына бирелмәде — полкта, съездның бу карарлары белән килешмәгәнлектән, партиядән чыгучылар да бар иде.

— Яңа экономик политикага күчүне вакытлы һәм дөрес дип саныйм, — диде Гайфетдинов, уйлап та тормыйча. — Партиянең бердәмлеге турындагы карарларын таныйм.

— Профсоюз дискуссиясендә кайсы платформада тордың?

— Ленин платформасында.

— Безгә, Төркстан коммунистларына, карата Ленин күрсәтмәләрен ничек үтисең?

Комиссия председателе В. И. Ленинның 1919 елның ноябрендә язган «Төркстан коммунистларына» хатын күз алдында тота иде. Ә бу хатта: «Төркстан халыкларына карата дөрес мөнәсәбәт хәзер Россия

Федератив Совет Социалистик Республикасы өчен, арттырмыйча әйтергә була, гигант, бөтендөнья тарихи әһәмияткә ия».— диелгән иде.

Полкта партия мобилизациясе буенча алынган берничә казакъ коммунистлары бар иде. Аларның берсе — элек өяз комитетының агитация-пропаганда бүлеге мөдире булып эшләгәне — Гайфетдиновка карата болай диде:

— 1916 елда кыргыз-казакъ восстаниесе вакытында качканнар туган илләренә кайткач, аларга кулаклар үзләштергән җирләрне кире кайтаруда полкның коммунистлары зур ярдәм күрсәтте. Бу эштә бигрәк тә Гайфетдинов иптәш зур активлык күрсәтте. Халык аңа зур рәхмәт әйтте.

Әлеге сораугa моннан да яхшырак җавапның булуы мөмкин түгел иде.

Председатель Гайфетдиновка залдан чыгарга кушты. Бу шулай тиеш иде.

— Үзе югында нәрсә әйтә аласыз?

— Идейный иптәш.

— Партиядә калдырырга!

Гайфетдиновны залга чакырдылар. Председательнең:

«Комиссия сине тикшерелгән дип саный», — дип белдерүен зал алкышлар белән каршылады.

1922 елның көзендә, Кызыл Армияне сан ягыннан кыскарту башлангач, безнең полкны тараттылар. Командирларның теләгәненә запаска китәргә, теләмәгәненә кадровый хәрби кеше булып калырга мөмкин иде. Мин бер кечне командирларның шундый сөйләшүләрен ишеттем:

— Милициягә китәм, — диде Җамал Усманов, — эчке дошманнарга каршы көрәшергә дә кирәк бит.

— Ә минем тыныч вакытта хәрби хезмәткә күңел ятмый, — дип дәвам итте Гыйззәт Камалетдинов. — Җирне сагындым. Безнең якта — Казан артында җир өшәнгән. Ә монда, Җиде Суда, менә дигән, тартә утыртсаң арба үсәрлек. Хатынны бирегә алдырам да иген игәм... Ә син, Наполеон, ни эшләргә уйлыйсың?

— Балык сусыз, Наполеон армиядән башка яши алмый, — дип җавап кайтарды Сәетгәрәй. — Тәндә җан бар чагында мин армиядән китмим.

Шулай итеп, 1922—23 ел кышында безнең дус, бердәм коллектив таралды һәм шуннан соң минем Гайфетдиновны очратканым булмады...

## 3. Еллар үткәч

Еллар бер-бер артлы үтә торды. Сугышчан дуслар-полкташлар белән юк-юкта очрашкалаган вакытларда бер-беребез турында сорашкалыйбыз. Наполеонны да еш кына искә төшерә идек. Ләкин мин аның язмышы турында озак вакытлар берни дә белә алмадым. Аерылды да суга чумган кебек юкка чыкты. Хәер, бу бик табигый да: беребез бер якка китте, икенчебез — икенче якка. Бөек Ватан сугышы ахырында гына, 1945 елны, Верховный Башкомандующий приказларында Гайфетдинов фамилиясе берничә тапкыр очраштыргалады. Ләкин аның Наполеон булуы-булмавын тикшерергә вакыт юк, үзем дә фронтта идем. Запаска чыккач кына мин аның язмышы белән чын-чынлап кызыксынырга вакыт таба алдым. Полкташларымның берсе — Шәриф Хафизов — Гайфинең Мәскәүдә яшәгәнлеген әйтте. Беренче мөмкинлек булу белән мин башкалага киттем һәм Садово-Спасский урамындагы 1/2 номерлы йорттагы квартираларның берсенең ишеген шакыдым. Ишекне урта яшьләрдәге, шактый калын гәүдәле бер ханым ачты. Кем икәнлегемне әйттем дә Гайфетдиновны сорадым.

— Гафу итегез, сез Сәетнең кеме буласыз? — дип сорады ул, мине бүлмәгә уздырып.

— Полкташы.

— Мин — Елена Ильинична, Гайфетдиновның хатыны. Ә бу, — һәм ул каршы чыккан офицер егеткә күрсәтте. Егет нәрсәсе беләндер Сәетгәрәйне хәтерләтә иде,— улыбыз була инде. Исеме Олег. Утырыгыз!..

Диванга урын тәкъдим итеп, Елена Ильинична тиз-тиз аш-су әзерләргә кереште.

— Сәет юк инде, — диде ул, кайгылы тавыш белән. — 1953 елның февралендә вафат булды...

Бу хәбәр миңа башыма күсәк белән суккандай тәэсир итте. Хәтта кайгыларын уртаклашырга да онyттым. Беравык дәшми торгач, Гайфетдиновның соңгы еллардагы тормышы турында сорашырга керештем.

— Без Оренбург ягында таныштык,— дип сөйләп китте Елена Ильинична. — Мин Мәләвез авылында укыта идем. Ә ул допризывникларны өйрәтергә килде. Аннары өйләнештек. Ул бик еш белем җитмәүдән зарлана иде. Ниһаять, 1929 елны хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек чыкты, «Выстрел» курсларына укырга җибәрелде.

— Пулеметны ташладымыни?

— Бик кыенлык белән генә. «Выстрел»да да пулемет бүлегендә укырга теләде, — диде ул, елмаеп. Һәм икенче бүлмәгә чыгып, 1919 елда партиянең Бозаулык комитеты тарафыннан Гайфетдинов исеменә бирелгән таныклык алып керде. Анда Гайфетдиновның Актүбә фронтында катнашуы, пулемет взводы командиры булуы турында әйтелгән иде.

— Ләкин «Выстрел»да ул пулемет бүлегенә эләгә алмады. Шулай да тырышып укыды. Бу курсларда алган белем генә аны канәгатьләндермәде, академиягә әзерләнергә кереште. Үзегез беләсез: ул хәтта урта мәктәп тә тәмамламаган иде. Шуңа карамастан, 1932 елда, конкурс экзаменнарын уңышлы биреп, Фрунзе исемендәге Академиягә керә алды. Академияне отлично билгеләренә генә бетерде. Аннары полк командиры булды. Тиздән аны күтәрделәр, ныгытылган район комендантлы итеп куйдылар. Соңрак моторлаштырылган дивизиянең штаб начальнигы итеп билгеләделәр. Ул төннәр буе белемен арттыру өстендә эшләде, ару-талуны белмәде. Тора-бара педагогик сәләте барлыгы ачылды. Аны В. И. Ленин исемендәге хәрби-политик Академиянең өлкән укытучысы итеп куйдылар...

Элекке батрак малай — Академиянең өлкән укытучысы... Утлар-сулар кичеп, бик кыенлык белән яулап алынган язмыш бу! Әйе, шул ук вакытта бик күпләр өчен уртак та ул...

1941 ел...

Сугыш башлангач ук, Гайфетдиновны Баш команда идарәсенә чакырып алалар һәм анда аны шул вакытта оеша торган дивизиянең штаб начальнигы итеп билгелиләр...

Сәетгәрәй Гайфетдиновның сугыш елларындагы эше белән мин аның көрәштәшләре белән сөйләшеп, Оборона министрлыгы архивы, сугыш елларындагы газеталар аша таныштым.

Аның бу еллардагы тормышын күбрәк белгән саен, минем күз алдымда бөтен гомерен халык, партия эшенә багышлаган офицер-большевик образы тулырак, яктырак булып гәүдәләнә барды.

Андагы дивизия планда күрсәтелгән срокта оешып җитә. Ул вакытта инде фронт та Вышний Волочекка килеп җитә яза. Дивизияне сугыш эшенә өйрәтүгә вакыт бөтенләй калмый. Шуңа күрә Гайфетдинов поход вакытында Академиядә алган белемен командирлар белән уртаклашу өчен һәр минутны файдалана.

«Немецлар, кинәт һөҗүм итеп, вакытлыча стратегик инициативаны

яулап алуга ирештеләр, — дип фикер йөртә ул. — Без әлегә фронт артында. Ләкин гитлерчылар еш кына безнең позицияләрнең аерым урыннарына көчле удар ясап, оператив тылга тирән үтеп керүләре мөмкин. Шуңа күрә, позициягә чыкканчы ук, дивизиянең дошман белән очрашуын көтәргә була. Сугышта кем сак, кем шартларны яхшы белә һәм, шул шартларга карап, маневрны тиешенчә оештыра ала — җиңү шуның ягында». Һәм ул дивизиядәге көчләрне һәрвакыт сугышка әзерлек хәлендә тотуга зур әһәмият бирә.

Чыннан да, Валдай районында позициягә чыкканчы ук, дивизия берничә тапкыр дошман белән очраша. Бу очрашуларда дивизия сугышчылары зур батырлык күрсәтәләр, дошман отрядларын тар-мар итәләр.

Дивизия фронтка сугышчан әзерлек хәлендә килеп җитә. Фронт штабында дивизия командирын һәм штаб начальнигын шартлар белән таныштыралар.

— Гитлерчылар безнең Төньяк-Көнбатыш фронтны өзеп, Мәскәү — Ленинград юлын кулга төшерергә тырышалар, — ди фронт штабы вәкиле.—Ә бу башкала өчен дә, Ленин шәһәре өчен дә куркыныч тудыра...

Дивизиягә Валдай сазлыкларына ныгып урнашырга һәм Мәскәү белән Ленинград обороналары флангысында немецларны тоткарларга приказ бирелә. Яшь, әле чыныкмаган дивизия үзенең сугышчан сәләтен тиз күрсәтә: дошман, үз планын тормышка ашырырга теләп, күп тапкырлар һөҗүмгә күтәрелсә дә, бу участокта безнең фронтны өзә алмый.

1941 елның декабренда Сәетгәрәй Гайфетдиновка полковник званиесе бирелә һәм ул яңа оеша торган укчы дивизия командиры итеп билгеләнә. Гайфетдинов дивизиясенә бу юлы оборона түгел, һөҗүмгә күчү бурычы куела. Әлбәттә, полковник беренче һөҗүмгә күчү приказын үтәргә зур күтәренкелек белән керешә. Аның дивизиясе немец-фашист гаскәрләренең Демьянск группировкасын камап алу сугышларында катнаша. Бу сугышларда дошманның өч дивизиясе юк ителә.

* * *

Гайфетдиновлар квартирасына соңгы баруымда Елена Ильинична өйдә юк иде. Мине уллары Олег каршы алды. Мин әтисе турында белгәннәремне, үзем элек белгәннәремне генә түгел, архивлардан, газеталардан алган мәгълүматларны, көрәштәшләреннән ишеткәннәремне аның белән уртаклаштым. Без озак кына сөйләшеп утырдык. Олег Гайфетдинов та миңа әтисе турында шактый нәрсәләр сөйләде, миңа таныш булмаган күп кенә документлар күрсәтте.

Сугыштан соң Сәетгәрәй Гайфетдиновка генерал-майор исеме бирү турындагы аттестациягә маршал К. К. Рокоссовский кул куя һәм СССР Верховный Советы Президиумы 1945 елның 11 июнендә бу турыда указ чыгара.

Гайфетдинов сугыштан соң яңадан укыту эшенә кайта. Башта өлкән укытучы, соңрак Ленин һәм Суворов орденлы Кызыл Байраклы М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби Академиядә хәрби-тарих факультетының курс начальнигы булып эшли, бик күп җәмәгать эшләре алып бара.

— Әтием бик гади, тыйнак кеше иде, — ди Олег. — Мин аны гадәттән тыш батырлык үрнәге күрсәткән кеше итеп күз алдыма китерә алмыйм.

— Юк, алай түгел, — дидем мин аңа. — Сәетгәрәй үзенең тормышын партия, халык эшенә багышлады. Аның гомер юлы шул эш өчен, киләчәк өчен көрәш белән тулы. Ә бу, минемчә, кайсыдыр бер моментта гадәттән тыш батырлык үрнәге күрсәтүдән артыграк...

Әйе, ул Ватан алдында, күп санлы иптәшләре алдында бурычлы булып калмады...

*Шакир Абилов*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА НӘВАИ

*(Нәваиның тууына 525 ел тулу уңае белән)*

Дөньяда бер генә культура һәм әдәбият та башка кардәш һәм күрше халыкларның культурасы, әдәбияты белән бәйләнмәгән хәлдә үсмәгән, үрләргә менмәгән. Культура һәм әдәби бәйләнешләр, алардан килә торган йогынты заманына карап төрлечә булган. Әмма бернәрсә бәхәссез: төрле-төрле урыннарда яшәгән халыкларның алдынгы карашлары, якты уйлары һәм ышанычлы өметләре, эксплуататор җәмгыятьләрнең киртәләре, дини тыюларның җәтмәләре аша үтеп, бер-берсенә юл тапкан, хезмәт кешеләре арасындагы татулык, туганлык хисләрен үстерергә ярдәм иткән. Аерым халыклар әдәбиятларындагы күренекле вәкилләрнең рольләре бу процесста тагын да зур булган. Рус поэзиясе күршы А. С. Пушкин татар әдәбияты өчен нинди якты илһам чишмәсе булып торса, урта гасыр татар әдәбияты өчен үзбәк шагыйре Галишер Нәваиның роле шундый ук. Алдынгы идеалларны чагылдырган, килер буыннарга үрнәк булырлык гаҗәеп матур образлар тудырган Нәваи гөлләренең хуш исләрен озын тарихлы татар поэзиясе бакчасында да яхшы сизәсең.

Татар культурасының һәм әдәбиятының күренекле вәкилләре Нәваины һәрвакыт таныдылар, аның осталыгы алдында баш иделәр һәм, зур ихтирам итеп, аңа югары бәя бирделәр. Нәваиның күп язучылар өчен үрнәк булганлыгын күз алда тотып, Шиһап Мәрҗани «Вәфиятел-Әсляф вә тәхиятел-Әхляф» дигән әсәрендә болай дип язды: «Галишер Нәваи — Хорасан илендәге галимнәрнең иң мәшһүрләреннән, үз заманындагы әдипләрнең югары идеалы, мохтаҗларга булышучы, олы галимнәрнең таянычы, атаклы әдипләрнең ярдәмчесе иде!»[1]

Каюм Насыйри мәгърифәтчелек идеяләрен таратуда Нәваи иҗатындагы алдынгы карашлардан файдаланды һәм аның әсәрләреннән алынган өзекләрне үзенең «Фәвакиһел-җөләса фил әдәбият» («Әдәбият турындагы аңгәмәләрнең җимешләре», 1880) һәм «Кавагыйде китабәт» («Язу кагыйдәләре», 1892) дигән китапларында бастырды. Нечкә сүз остасы, ярсу йөрәкле Дәрдмәнд Нәваи поэзиясенең сихри моңнарына сокланып мөрәҗәгать итте һәм аерым парчаларын аның әсәрләре үрнәгендә язды (мәсәлән, «Рәсем» шигыре). 1909 елда «Шура» журналында бастырган мәкаләләрендә Нәваины ул «төрки халыкларның әдәбиятын нигезләүче, аның остазы» дип атады. Бу әйтелгәннәр Нәваиның татар әдәбияты тарихында билгеле урын алып торганлыгын күрсәтәләр. Әлбәттә, Нәваи иҗат иткән заманнан безне биш йөз елдан артык вакыт аера. Шундый зур чорда татар әдәбияты, бигрәк тә поэзиясе, үсешендә булган Нәваи әсәрләренең уңай тәэсирен эзлекле рәвештә һәм бөтен тулылыгы белән күрсәтү бер мәкаләдә мөмкин түгел. Биредә үзбәк һәм татар әдәби мөнәсәбәтләрен, бу бәйләнештә Нәваиның ролен киң күләмдә алмыйча, XVI йөз әдәбияты гына күз алда тотыла. Шул чор татар поэзиясенең зур вәкиле булган шагыйрь Мөхәммәдъяр иҗатын караганда да Нәваи йогынтысының ни дәрәҗәдә булганлыгы турында фикер йөртергә мөмкин.

Галишер Нәваи XV йөздә, Урта Азиядә феодаль тәртипләр хакимлек иткән заманда, кеше исеменә дан җырлады, аның акыл көченә ышаныч һәм өмет тудырды, халык күргән авырлыкны һәм газапны башыннан кичерде. Ул «Мәхбүбел-Колуб» әсәрендә:

> Бәси эссыг, сывуг күрдем заманда,
> Бәси эччыг, чөчек таттым җиһанда[2], —

дисә, Мөхәммәдъяр «Төхфәи Мәрдан» поэмасында:

> Мән бикин[3] эш адәмигә төшмәгәй,
> Мән тиккән утка кеше пешмәгәй, —

дип язды.

Нәваи киң катлау хезмәт ияләренең кайгысын якын күрде һәм зарын уртаклашырга теләде. Аның «әгәр син кеше икәнсең, халык кайгысын кайгыртмаучыны кеше санама» диюенә Мөхәммәдъяр:

> Нәфегъ тикер адәмигә сән бу көн,
> Гакыйль ир, ил күңлегә салма түнкел, —

дип җавап бирә һәм кешегә файда (нәфегъ) күрсәтергә, халык күңеленә төшенкелек (түнкелмәк), кайгы салмаска чакыра.

Нәваи халыкка игелеклелек күрсәтү юлында «күктән башыңа таш яуса да, чын егетлек хезмәтеннән баш тартма»:

> — Ирәнләр хезмәтедин чикмәгел баш,
> Әгәр башыңга гәрдундин ягар таш, —

ди.

Мөхәммәдъяр исә:

> Мән тәкыи фәрман биләдер һәр эшем,
> Куймагам ил күңле өчен гәрдешем, —

дип, халык өчен үзенең эшчәнлеген (гәрдешен) туктатмаячагын сөйли. Нәваиның киң катлау массага карата кешелекле бу-

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1964 ел, 4 сан.

[2] Заманның күп эссесен, суыгын күрдем,
Дөньяның күп ачысын-төчесен татыдым.

[3] Бикин — кебек.

лу турындагы якты өметләре Мөхәммәдъярның ярлы-юксылларга игелекле, ярдәмчел булырга өндәгән авазы белән уртак тел таба.

Үз иҗат диңгезенең тирәнлеге һәм киңлеге белән Урта Азия халыклары әдәбиятында тарихи бер чор барлыкка китергән Нәваи урта гасыр татар әдәбиятына үзенең якты рухы белән килеп керде. Аның кешегә ихтирам, гадел җәмгыять турындагы хыяллары, мәхәббәткә турылыклы геройлары шул заман татар әдәбияты өчен үрнәк булдылар. Нәваиның алдынгы карашларын без Мөхәммәдъяр иҗатында ачык күрәбез. Бу ике зур шагыйрьне заман сорауларына айнык караулары, золымга корылган җәмгыятьне савыктырырга омтылулары, халыкның авыр хәлен җиңеләйтергә тырышкан изге теләкләре, авыр язмышларының берсе икенчесенә охшаш булулары якынайта. Нәваи, түбән катлауларны яклап, аларга теләктәшлек күрсәткәне өчен, бер урыннан икенчесенә сөрелгән булса, Мөхәммәдъяр хан-феодалларның җәберләүләре, эзәрлекләүләре аркасында кабер сакчысы хәлендә — мөҗәвирлыкта яшәргә дучар ителә. Ләкин алар халыкка хезмәт итү уеннан читләшмәделәр. Нәваи «ярлыны да һәм хуҗаны да туйдыручы — деһкан» (крестьян), «дөньяның төзеклеге һәм сөенече дә — аңардан» дисә, Мөхәммәдъяр да илнең иминлеген, аның муллыгын кеше көчендә, аның хезмәтеннән килә дип саный һәм гади хезмәт кешеләрендә — һөнәрчеләрдә, хәммалларда (йөк ташучылар) иң кешелекле сыйфатларны күрә, аларга мәдхия җырлый.

Җирдә күп нәрсәдән мәхрүм ителгән киң катлау халык, феодаль тәртипләргә вакыты белән стихияле рәвештә, вакыты белән революцион протест белдереп, кем икәнлеген сиздереп торды һәм үзенең акыл көче белән рәхәт дөнья турында тылсымлы әкиятләр уйлап чыгарды, бәхет өчен көрәшүче хыялый образлар иҗат итте. Бу исә киләчәк бәхеткә өмет баглау иде. Халыкның мондый хыяллары фольклор аша язма әдәбиятка үтеп керде. Рәхәт, мул, тигез тормыш турындагы хыялый картиналар Низаминың «Икбаль-намә», «Искәндәр-намә», «Җиде гүзәл», «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхзанел-әсрар» әсәрләрендә урын алса, шул ук мәсьәләләр икенче бер җирлектә Нәваи һәм Мөхәммәдъяр кебек шагыйрьләрнең иҗатларында да чагылды. Шагыйрь, үзе килешә алмаган җәмгыять тәртипләренә каршы буларак, күптән булып үткән вакыйгаларны һәм аерым хөкемдарларны, шәхесләрне идеаллаштыру юлына баса.

Нәваиның «Сәдди Искәндәр» дастанында Искәндәр һәм Мөхәммәдъярның «Төхфаи Мәрдан»ында шул ук Искәндәр (Александр Македонский), Наушированның «Нуры содур»ында һарун әл-Рәшид образлары илгә — төзеклек, җиргә — матурлык, халыкка — рәхәт җәмгыять тәртипләре урнаштыручы итеп сурәтләнәләр. Чынында, ул хәлләрнең берсе дә булмаган. Үткән заманны бизәп күрсәтү, әкияттәге кебек гадел фантастик образлар белән язучы үз чорында булган золымны, тигезсезлекне бетерергә, җәмгыятьне гаделлек нигезендә төзәтергә тырышкан. Автор өчен бу бер әдәби алым да булган.

Гарәп, фарсы әдәбиятларындагы мондый идеаллаштырылган, гадел образлар борынгы татар әдәбиятына турыдан-туры язма әсәрләр, риваятьләр, сәяхәт итүче сюжетлар аша юл алды. Бу процесста үзбәк әдәбиятының да роле зур булды.

Нәваидан бер гасыр диярлек элек иҗат иткән Лотфи да «Гөл вә Науруз» дастанында гаделлекне кешелек җәмгыятенең иң кирәк сыйфатларыннан саный һәм аның «төзек булыр гадел илә һәркайда вилаять» дигән теләкләре Мөхәммәдъяр иҗатындагы төп омтылышлар белән берләшә. Шул заман татар әдәбиятына үзбәк әдәбиятының тәэсире Нәваи каләме аша тагын да ачыграк күренде.

Нәваи да, Мөхәммәдъяр да илдәге авыр тормышның, бөлгенлекнең сәбәбен ачарга телиләр һәм аны золымда дип беләләр. Алар җәмгыятьтәге тигезсезлек һәм золым дәүләт башында торучы ханнардан, патшалардан гына килә дип уйлыйлар. Нәваи «Хәйрәтел-әбрар»да шаһ гадел эш йөртә икән, ил барлык бәлаләрдән котыла ала дип хыяллана.

Шушы ук фикерләрне, хәтта сүзләрдәге якынлыгы белән, без Мөхәммәдъярда да очратабыз:

Көфер берлә мәмләкәт булмас харап,
Золым берлә йыкылар улус[1] йәдәп.
Көфер вә кяфир нәфсенә кылыр зыян,
Золым берлә булыр ил хале яман.

Нәваи һәм Мөхәммәдъяр өчен эш ил башында торган кешенең нинди диндә булу-булмавында түгел, ә аның гаделлегендә. Аларча, хөкемдар гадел эш йөртә икән, үзе кяфир булса да, илен чәчәк аттыра; залим, мөселман булса да, илне җимерә, халкын бөлгенлеккә төшерә.

Гадел хөкем йөртү нигезендә җәмгыятьне савыктырырга тырышуның бердән-бер юлы итеп үгет-нәсихәт алынды. Дидактик әсәр булу ягыннан Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасы аеруча характерлы. Ул, бер яктан, Сәгъдинең «Бостан»ы белән Юсуф Хас-Хаҗибның «Кутадгу билиг»ен хәтерләтсә, икенче яктан, Нәваиның «Мәхбүбел-Колуб»ын искә төшерә. «Нуры содур»да, «Бостан»дагы һәм «Мәхбүбел-Колуб»тагы кебек, гадел булмаган җәмгыять тәртипләре гаепләнә һәм гадел хөкемдарда булырга тиешле мораль таләпләр сурәтләнә. Нәваича һәм Мөхәммәдъярча, ил башлыгы гадел булу белән бергә, сәхавәт (юмартлык), рәхим-шәфкать, киң күңеллелек, вафа (сүздә тору), гафу итүчәнлек, дөрес сөйләү кебек сыйфатларга ия булырга тиеш.

Шик юк ки, Мөхәммәдъяр үзеннән алда иҗат иткән күп язучыларның әсәрләре белән таныш булган; гарәп, фарсы, Урта Азия классик әдәбиятының зур осталарына мөрәҗәгать иткән, аларның әсәрләреннән иҗади файдаланган. Урта гасыр әдәби методы буенча бу — язучының зур та-

[1] Улус — дәүләт, ил, халык.

лант нясе инанлеген курсәтүче фактор булып саналган.

Гарәп һәм фарсы телләрендәге әсәрләр урта гасыр татар әдәбиятында аерым катламны тәшкил итте, һәм алар халыкка, үз вәкилләренең иҗат җимешләре кебек үк, якын булдылар. Урта Азия халыклары (үзбәк) әдәбиятына килгәндә, эш тагын да җайлырак иде. Бу ике халыкның тарихи язмышларының, социаль тормыш шартларының охшашлыклары, гадәт һәм телләрнең якынлыклары культура һәм әдәбият өлкәсендәге бәйләнешләрне көчәйтте, үзара туганлык җепләрен гасырлардан гасырларга ныгыта килде. Татар укучысы Нәваины үз язучысы рәтендә күрде. Нәваи татар әдәбиятына үзенең иҗатындагы гуманистик идеяләренең тирәнлеге, изелгәннәргә игелекле карашлары, әсәрләрендәге дөньявилык мотивларының тирәнлеге, реалистик тенденцияләренең көче, образларның җанлылыгы белән якын иде. Нәваи дөньяны суфиларча бәяләүдән ерак торды, җир тормышының матурлыгын күрә алды һәм аның җимешләреннән ләззәтләнергә теләде:

Заһид[1], сәңгә хур вә мәнгә җананә[2]
кәрәк.
Җәннәт сәңгә булсын, мәнгә мәйханә
кәрәк, —

ди ул робагыйларының берсендә.

Мөхәммәдъяр да тормышны кешенең рәхәтлек, муллык урыны итеп карый һәм андагы кешеләрнең игелекле, ярдәмчел булуларын күрәсе килә:

Ингам[3] вә ихсан[4] йиредер бу җиһан,
Хәер вә ихсан булгусыдыр куәт җан.

Шулай итеп, заман сораулары буенча, Мөхәммәдъярдагы омтылышлар Нәваидагы теләкләр белән яраша һәм аваздаш булып яңгырый. Ләкин әдәби тәэсир катлаулы күренеш; ул текстларның охшаш килүләрендә генә түгел, бәлки, тормыш күренешләрен типиклаштыру чараларында, уңай яисә тискәре геройларны биргәндәге үзара йогынты итүләрдә. Әлбәттә, үзара әдәби бәйләнешләрне, берсе икенчесенә булган әдәби тәэсирне аерым охшашлык, параллельләр белән генә чикләп булмый, андый күренешләр очраклы да булуы мөмкин. Әдәби элементләр һәм үзара әдәби тәэсир итешүләр халыклар һәм дәүләтләр арасындагы бәйләнешләрнең закончалыклы тәрәккый итүе белән бергә бара. Төрле әдәбиятларның үзара бәйләнешләре күп яклы, һәм аның тамырларының тирәнгә киткән җепләре бар. Кайвакытларда алар күренерлек кенә түгел, хәтта тиз генә сизелерлек тә булмаска мөмкин. Ләкин Урта Азия халыклары әдәбиятының, Нәваи иҗатының татар әдәбияты белән бәйләнешен һәрвакытта сизәргә мөмкин иде: татар халкының укымышлы кешеләре элек-электән Нәваи әсәрләре белән таныш булдылар, ул әсәрләрне оригиналында укый алдылар. Аның күп шигырьләре борынгы татар шагыйрьләренең әсәрләре белән бергәттән язылып, кулдан-кулга күчеп укыла килделәр. Хәзерге көндә дә Казанда Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәдә Нәваи «Хәмсә»сенең (биш поэма җыентыгының) һәм зур күләмле шигырьләр диванының XVI йөзләргә караган кульязмалары саклана. Кайбер очракларда аның аерым моңнары Тукай кебек талантларның сазына да килеп тоташа. Тукайда:

Очты дөнья читлегеннән
Тарсынып күңлем кошы, —

дигән юллар бар.

Шундый ук юлларны, хәтта бөтен төсмерләре белән, башлап без Нәваида очратабыз:

Иа, җан кошы очты җисми хасдин,
Газме ватан әйләде кафәсдин [5].

Тукайның халыкка тирән мәхәббәт белән сугарылган «һич кайгысыз кеше булса, адәм түгел»[6] дигән сүзләре Нәваи иҗатындагы югарыда телгә алынган «Халык кайгысын кайгыртмаучыны кешегә санама» дигән бөек гуманистик тезиска барып бәйләнә.

Бу китерелгәннәр Нәваи мирасының татар әдәбияты үсеше белән тыгыз бәйләнгән булуын раслыйлар. Гарәб Көнчыгышы, Иран, Урта Азия әдәбиятларындагы бөек сүз осталарының иҗатлары белән татар язучылары илһамлана килделәр. Ярсу йөрәкле, уйлары бөркет канатлы каһарман шагыйрь Муса Җәлил автобиографик язмаларында үзенең иҗатына Хәйям, Сәгъди, Хафиз һәм Нәваи кебек зур художникларның тәэсир иткәнлекләрен сөйли. Әйе, Нәваи шигърияте диңгезенең шавы татар әдәбиятында еракларга китеп яңгырый.

Совет илләрында Нәваи иҗатын төрки халыклар арасында пропагандалауда профессор Г. Сәгъди хезмәтләренең дә роле зур булды. Танылган татар совет шагыйре Әхмәт Исхак тарафыннан гаять оста тәрҗемә ителгән «Фәрһад һәм Ширин» дастанының нәшер ителүе Нәваины татар укучысына тагын да якынайтты. Казан шәһәре урамнарыннан берсенең Нәваи исеме белән аталып йөртелүе дә халыкның бу бөек шагыйрьгә булган зур ихтирамының билгесе.

Татар поэзиясе үсешендә Нәваиның оныталмаслык якты эзләре бар. «Бу әдәбият, — дип язды Г. Ибраһимов борынгы үзбәк әдәбияты турында, — Урта Азиядәге бер мәдәниятнең җимеше булып, безгә дә, госманлыларга да, әзәрбәйҗан әдәбиятына да зур тәэсир ясады. Моның алтын дәверендә җитешкән шагыйрьләреннән Нәваи кебекләре Төркестанда ничаклы кадерле булса, Анатолиядә дә шул кадәр мәшһүр иде» [7]. һәм Идел буенда да ул шулай!

[1] Заһид — тәкъва, үзен суфиларча тотучы.
[2] Җананә — сөйгән яр.
[3] Ингам — бүләк.
[4] Ихсан — игелек.

[5] Нәваи. Ләйлә вә Мәҗнүн. Үзбәк шигърияте антологиясе, II том, 336 бит.
[6] Г. Тукай. Сәрләүхәсез. Шигырь. Әсәрләр, II том, 38 бит.
[7] Г. Ибраһимов. Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы. «Безнең юл» журналы, 1922 ел, 2 сан, 43 бит.

*Фатих Урманчеев*

# СОВЕТ ЧОРЫ БӘЕТЛӘРЕ

Безнең көннәрдә халык авыз иҗаты нинди үзгәрешләр кичерә, ул үсәме, әллә акрынлап югаламы? Үссә, аның үсеше нинди юллар белән бара, югалса, аны нәрсә алыштыра? Соңгы елларда фольклорчылар арасында менә бу мәсьәләләр буенча кайнар һәм кискен бәхәсләр бара. Халык иҗатын өйрәнүче галимнәрнең кайберләре фольклор безнең көннәрдә акрынлап юкка чыга дигән караштa торалар. Икенче төркем галимнәр фольклорның бертуктаусыз алга баруы, үсүе, чәчәк атуы турында язалар [1]. Халык иҗатының бүгенге торышы, киләчәктәге язмышы турындагы бу бәхәсләр хәзер инде гомуми рәвештә генә сөйләшү рамкаларыннан читкә чыкты. Бәхәс тагын да тирәнәйде, кискенләште, бәхәс халык авыз иҗатындагы аерым төрләрнең һәм жанрларның язмышын ачыклауга да күчте. Шул исәптән, безнең фольклорда зур урын тоткан бик үзенчәлекле жанр — бәетләр турында да бүген кызу бәхәс бара, капма-каршы фикерләр әйтелә. Кайбер галимнәр бәетләрнең әле дә иҗат ителеп, халык тормышының төрле якларын чагылдырып килүе турында язалар [2]. Икенчеләре исә аларны бетүгә йөз тоткан жанр дип исәплиләр [3]. Менә бу катлаулы мәсьәләне беркадәр ачыклар өчен, татар халык иҗатында бәет жанрының үсү, үзгәрү тарихына киңрәк тукталып үтик.

Бәетләр берничә йөз ел буена халыкның кайгы-хәсрәтен, авыр тормыш шартларына нәфрәтен һәм киләчәккә булган якты теләкләрен чагылдырып килделәр. XIX йөздә алар бай поэтик тәҗрибә туплаган, зур традицияле жанр булып әверелделәр. 1910 елда Г. Тукай бәетләр һәм җырлар турында: «Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык. Чү, аз гына бернәрсә «шылт!» иттеме, инде аның тугрысында иртәгә урамга бәет чыга» [4], — дип язды.

Бәетләр — татар халык иҗатына гына хас милли жанр. Борынгы төрки халыклар иҗатында да, башка халыкларда да бәетләр белән рәттән куярдай, аларга билгеле күләмдә тәңгәл килердәй жанр юк. Һәм аларны төрле халыкларның тарихи әсәрләреннән: рус, башкорт һәм башкаларның тарихи җырларыннан, украин думаларыннан аерып торган үзенчәлекләрнең берсе — бәетләрнең элек-электән язма поэзиягә якын торуында. Билгеле булганча, бәетләрнең бер өлеше, әдәбият әсәре кебек үк, халык арасына кулъязма китаплар, истәлек дәфтәрләре аркылы да таралалар. Ләкин бәетләр белән язма әдәбият арасындагы якынлык моның белән генә чикләнми. Күп кенә бәетләр үзләренең иҗади принциплары, шигъри чаралары белән дә язма поэзия әсәрләрен хәтер-

---

[1] Карагыз: В. Е. Гусев. Две дискуссии. «Русская литература» журналы, 1962 ел, 4 сан. Проблемы современного народного творчества. Русский фольклор. Т. IX. М.—Л. Рус телендә, 1964 ел.

[2] Бәетләр. Текстларны әзерләүче, җыентыкны һәм аңлатмаларны төзүче Х. Ярми. Казан, 1960, 22 бит.

[3] Шунда ук, 22 бит.

[4] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. 2 том. Казан, 1955 ел, 263 бит.

ләтәләр. Бу — аларның тел-стиль үзенчәлекләрендә аеруча ачык күренә. Халык иҗаты әсәрләренең башка төрләрендә борынгы әдәби тел өчен характерлы архаик элементлар сирәк очрыйлар (мәсәлән, борынгы җырларда, әкиятләрдә, хәтта йола фольклорында да). Ә инде «Лашманчы зары», «Кади бәете», «Урта Тигәнәле» кебек элекке бәетләрнең стиле XVIII—XIX гасырдагы китап теленә шактый якын тора:

— Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең тешең энҗе диләр, бән күрәем.
— Бәнем тешем энҗесенә сән ни дирсең,
Асламчыда асыл энҗе күрмәймесең?

*(«Хан кызы»)*

Бәет стиленең «борынгы» үзенчәлекләре язма чыганакларда яхшырак саклана лар, әлбәттә. Татарстан Үзәк музееның иске язмалары арасыннан табылган «Мүкән кантон», Г. Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» (Казан, 1909) исемле китабында басылып чыккан «Чәй бәете» кебек әсәрләрнең телендә еш кына очрый торган архаик элементларны китап, язма поэзия йогынтысы белән генә аңлатырга мөмкин:

Самовардыр дәхи матлуп [1], калепләрдә
булып мәхбүб [2],
Самовар белән чәй эчсәләр, эчкәннәргә
булыр мәргуп [3] һ. б.

Профессор Х. Госман бәетләрне «татар халкының ярым телдән, ярым язмача алып барган шигъри иҗаты» дип атый һәм «укымышлылар иҗаты белән халык иҗаты шушы ноктада билгеле дәрәҗәдә уртак багланышка» керүе турында яза [4]. Һәм бу багланыш торган саен тирәнәя һәм киңәя бара, дип әйтергә мөмкин. Чөнки язма поэзиядә булган әһәмиятле үзгәрешләр, гадәттә, көзгедәге кебек, бәетләрдә дә чагылып баралар. Әйтелгәнчә, XVI—XIX йөз бәетләрендә шул чор әдәбиятының һәм әдәби теленең йогынтысын төсмерләп була. Ә инде XX йөз бәетләре татар совет поэзиясе белән тыгыз бәйләнештә үсәләр. Шигъри интонацияләре, эмоциональ яңгырашлары һәм тел-стиль үзенчәлекләре белән гражданнар сугышы бәетләре, мәсәлән, шул чорда аеруча алга киткән публицистик-агитацион поэзиягә якын торалар. М. Гафури, Г. Камал, Ф. Бурнаш һ. б. шагыйрьләрнең бер төркем әсәрләрен «Кызыл көрәшчеләр», «Җаек суын кичкәндә» кебек бәетләр белән чагыштырып караганда, алар арасындагы фикер бердәмлеген, шигъри чаралар уртаклыгын күреп булыр иде. Без тик бер мисал белән чикләник. «Гражданнар сугышы» бәете белән М. Гафуриның «Кызыл байрак» шигыре арасындагы идея һәм эмоциональ яңгыраш, хәтта ритмика һәм рифма якынлыгы күзгә бәрелеп тора:

| **М. Гафури шигыре** | **Бәет** |
|---|---|
| Кузгал, эшчеләр!<br>Дошман җиңелсен,<br>Көч кемдәлеген<br>Бар дөнья белсен.<br>. . . . . . . . . . . | Күңел ашкына<br>Барып житәргә,<br>Ак солдатларны<br>Тар-мар итәргә.<br>. . . . . . . . . . . |
| Әй, Кызыл байрак,<br>Нур бир җиһанга!..<br>Әйдә, эшчеләр,<br>Алга вә алга! | Атка атланып<br>Киттек без алга,<br>Кылычлар айкап<br>Ташландык яуга! |

[1] Матлуп — кирәкле.
[2] Калепләрдә булып мәхбүб — күңелләр хуш булыр.
[3] Мәргуп — канәгатьлек.
[4] Х. Госман. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан университеты нәшрияты. 1960, 5—6 битләр.

Совет чоры фольклорының беренче үрнәкләре — «Җаек суын кичкәндә», «Гражданнар сугышы», «Кызыл көрәшчеләр» кебек бәетләр — илне тетрәткән көчле көрәш, иске лек белән яңалык арасындагы кискен бәрелешләр дәвамында тудылар. Күләм ягыннан зур булмасалар да, алар әле генә яңа тормышка аяк баскан совет халкының эчке һәм тышкы дошманнарга каршы көрәшен һәм сугыш кырларында күрсәткән батырлыгын эпик киңлек белән сурәтлиләр. Бу бәетләрнең вакыйга мәйданы гаять киң. Алар Татарстан кырларында, Астрахань далаларында, Урал таулары һәм Җаек буйларында барган каты сугышларны, бәрелешләрне гәүдәләндерәләр һәм гадәттә күп кенә эпизодлардан торалар. «Гражданнар сугышы бәете»ндә, мәсәлән, авыл егетләренең, туганнары белән саубуллашып, илдән чыгып китүләре турында сөйләнә. Әсәр салмак кына тасвирлау-хикәяләү белән башланып китә:

Мин язам, дуслар,
Баштан үткәнне,
Туган илемнән
Чыгып киткәнне.

Әмма, акрынлап, хикәяләү темпы һәм бәетнең шигъри интонациясе үзгәрә. Вакыйга мәйданы киңәйгән саен, конфликт та кискенләшә. Бәеттә сурәтләнгән күренешләр бер-берсен яшен тизлеге белән алмаштыралар. Әсәрнең стилендә дә күтәренке рух өстенлек ала. Геройларның аклар белән бәрелешләрен, азатлык һәм җир, туган илнең якты киләчәге өчен көрәшен сурәтләгән күренешләр публицистик пафос белән яңгырыйлар:

Акларны җиңеп —
Коллык богавын,
Сибереп түктек без
Байларның барын.

Байрак күтәреп
Кайттык Казанга;
Безнең җиңүдән
Шауланы кала.

Гражданнар сугышы бәетләренең геройлары да аерым шәхесләрдән түгел, ә бәлки тулы бер коллективтан тора. Әле генә телгә алынган бәеттә «алты иптәш» турында сөйләнә. Ә инде «Кызыл көрәшчеләр»дә сүз партизан отрядына язылган 4—5 кеше исеменнән алып барыла. Әсәрнең беренче өлешендә, борынгы бәетләрдәге кебек, фаҗигале вакыйгалар сурәтләнә. Аклар белән бәрелешләр вакытында партизан отряды зур югалтуларга очрый һәм пленга эләгә:

Иң азакта без камалдык,
«Стоп!» диеп кычкырдылар.
Кайсын атып, кайсын кадап,
Шунда күп кеше кырдылар.

XVI—XIX йөзләрдә туган күпчелек бәетләрдә геройның үлүе яисә башка берәр фаҗигасе, гадәттә, әсәрнең соңгы эпизоды һәм конфликтның трагик чишелеше булып килә. Шуңа күрә бәетнең эмоциональ яңгырашы да кайгы-хәсрәт, авыр хисләр белән сугарылган була. «Кызыл көрәшчеләр» исә халык вәкилләренең тантаналы җиңүен сурәтләү белән тәмамлана:

Буржуйларны кудык та без,
Под Байкалда булдык та без,
Үзләренең каны белән
Борыннарын юдык та без.

Димәк, бәеттә халыкның җиңелмәс көч булу идеясе алга сөрелә. «Җаек суын кичкәндә», «Гражданнар сугышы» һ. б. бәетләр дә шул ук идея белән сугарылганнар.

Бәетләрне татар халык иҗатының трагик жанры дип әйтергә мөмкин. Алар, Г. Ибраһимов язуынча, «сугыш, солдатлык, суга бату вә башкача бер адәмнең бер хәсрәте хакында яки берәүгә һөҗү (көлү) өчен чыгарылган булалар»[1]. Трагик эчтәлек — бәетләрнең иң зур күпчелегенә, шул исәптән, совет чоры бәетләренә дә хас. Әмма революциядән соң туган бәетләр моның белән генә чикләнмиләр. Аларда жанрга хас трагизм, моң-хәсрәт революция уяткан яңа фикерләр, яңа хисләр белән үрелеп килә. Совет чоры бәетләрен шартлы рәвештә «оптимистик трагедияләр» дип атарга мөмкин. Чөнки революция бәетләрнең моңсу пәрдәсен ертып ташлады, аларның трагик эчтәлегенә яңа төс бирде, эмоциональ яңгырашын үзгәртте. Һәм бу гражданнар сугышы бәетләрендә үк бик ачык күренә.

Бәет герое — халык вәкиле булганга күрә, хезмәт халкы аның фаҗигасенә битараф булып калмый, әлбәттә. Революциягә кадәр иҗат ителгән бәетләрдә, гадәттә, халыкның изүче сыйныфларга, төрле фаҗигаләр тудырган тормыш шартларына ачы нәфрәте чагыла. Совет чоры бәетләрендә исә халык үзенең дошманнарына нинди мөнәсәбәттә торуын белдереп кенә калмый, ул аларга каршы актив көрәш алып бара һәм, кагыйдә буларак, җиңеп чыга. Хезмәт халкы гражданнар сугышы, гомумән, совет чоры бәетләренең актив герое булып әверелә, һәм бу факт еш кына әсәрнең идея эчтәлеген билгеләүдә хәлиткеч роль уйный. Герой язмышы халык язмышы белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Нәкъ менә шуңа күрә сугышчан оптимизм, күтәренке рух белән сугарылган бу бәетләрдә халык бәхете өчен көрәш пафосы, заманның кискен һәм төгәл ритмы, чор өчен характерлы лозунглар, чакырулар үтә көчле яңгырыйлар:

Иптәшләр, без Кызыл гаскәр,
Барыйк бергә тезелеп;
Алга, алга, алга иптәшләр,
Бетсен дошман изелеп.

*(«Җаек суын кичкәндә»)*

Гражданнар сугышы бәетләренә хас драматик киеренкелек, публицистик пафос ул елларның кискен каршылыкларын, заманның дәһшәтле сулышын гәүдәләндерәләр. Азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән халыкның искиткеч батырлыкларын сурәтләгән бу бәетләр халык иҗатында революцион чор рухының шактый уңышлы чагылуы турында сөйлиләр.

Гражданнар сугышы бәетләреннән үзгә буларак, 20—30 еллар бәетләрендә төп урынны бөтен бер коллектив образы түгел, ә аерым герой, аерым шәхес образы алып тора. Бәетләрнең вакыйга мәйданы да тарая. Идел буйларыннан Себер урманнарына кадәр сузылган сугыш кырлары урынын аерым авыллар һәм колхозлар ала. Бу чор бәетләрендә совет кешесенең образы тулырак булып күз алдына баса. Бу яктан караганда, 20—30 елларда иҗат ителгән бәетләр элеккеге, традицион бәетләргә якын кебек. Әмма алар арасында зур аерма бар. Конкрет вакыйгаларга нигезләнгән традицион бәетләрнең эчтәлеге күп очракларда шул вакыйгаларны, фаҗигаләрне тасвирлау белән чикләнә. Герой образы исә икенче, арткы планга күчә. Мәсәлән, «Суга баткан ялчылар» бәетенең төп герое — Галиәкбәр. Ләкин әсәрдә ул күп телгә алынса да, аны, кеше буларак, күз алдына китерү шактый читен. Ул — көрәшче дә, сугышчы да түгел, үзе кебек меңләгән ялчылардан берничек тә аерыл-

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960, 40 бит.

мый торган, «язмыш буенча» яшәгән бер кеше. Әгәр ул бәхетсезлеккә очрамаса, аның турында бәет тә тумаган булыр иде. Икенче бер мисал итеп «Җиде кеше бәетен» алырга мөмкин. Бу бәеттә дә конкрет образ юк, аның төп өлеше шахтерларның авыр тормышын, аларның фаҗигасен сурәтләүдән тора. Гомумән, традицион бәетләрнең күбесендә геройның фаҗигасе белән аның образы арасында тыгыз логик бәйләнеш юк. Фаҗига герой язмышының логик нәтиҗәсе буларак ачылмый. Бу кешеләрнең шәхес буларак та, бәет герое буларак та, күзгә күренерлек үзенчәлекләре юк. Алар — шул чордагы коточкыч тормыш шартларының гаепсез корбаннары. Төрле фаҗигаләрне тасвирлауга нигезләнгән мондый бәетләрнең тарихи һәм эстетик әһәмияте дә билгеле бер образ тудыруда түгел, ә бәлки күп бәхетсезлекләр тудырган тормыш шартларына нәфрәт уятуда. Шуңа күрә дә, күрсәтелгән бәетләрнең төп фикере, идеясе гадәттә ачык булса да, аларның образлары тулаем ачылып бетми, ә кайвакыт бөтенләй диярлек ачылмый кала. Нәтиҗәдә, кайбер бәетләрдә фаҗигане бөтен нечкәлекләре белән тәфсилләп сурәтләү, натурализм өстенлек ала. Бу үзенчәлекләр традицион бәетләрнең һәммәсе өчен дә хас түгел, әлбәттә. Жанрның поэтик эшләнеш дәрәҗәсе камилләшкән саен тарихи актив герой беренче планга күчә бара. XVIII йөздә Пугачев һәм Салават Юлай, XIX йөздә солдатлар, җир һәм азатлык өчен көрәштә катнашкан халык вәкилләре бәетләрдә актив герой образлары булып гәүдәләнәләр. Совет чорында исә, бигрәк тә 20—30 елларда иҗат ителгән бәетләрдә, иҗтимагый көрәштә актив катнашучы геройлар: коммунистлар, комсомоллар, активистлар төп урынны алалар һәм аларның образлары да тулырак һәм җанлырак булып күз алдына басалар. Совет чоры бәетләрендә дә Габделнур, Мирсәет, Рәхи кебек билгеле дәрәҗәдә трагик образлар сурәтләнә һәм бу яктан алар традицион бәетләргә шактый якын торалар. Әмма совет чоры бәетләренең үзәгендә геройның фаҗигасе түгел, аның якты идеаллар өчен көрәше, иҗтимагый эшчәнлеге тора. Мәсәлән, «Егерменче ел башында» бәетендә сүз халык вәкиле коммунист Хәсәннең сәнәкчеләр белән бәрелеше турында бара. Бәеттән аңлашылуынча, бандалар авылга бәреп керәләр һәм авыл халкын кырырга, юк итәргә тотыналар. Коммунист Хәсән, аларга каршы чыгып, геройларча сугыша:

Мылтыгыннан бишне атты
Вәхши сәнәкчеләргә;
Куркак дошманнар сирпелде,
Кая якын килергә.

Патроны беткәч, кыныннан
Тартып алды кылычын;
Батыр коммунист бер үзе
Көрәшә — көчле лачын.

Дошман көченең күп мәртәбә артык булуы аркасында, Хәсән һәлак була. Ләкин бәетнең үзәгендә аның фаҗигасе түгел, ә батырлыгы, дошманнар белән лачын кебек көрәшүе тора. Бәетнең идеясе дә геройның **актив көрәштә, халык азатлыгы өчен сугышта** үлүен күрсәтүгә юнәлтелгән. Хәсән, Мирсәет, Рәхи образларын традицион бәетләрдәге Сәмигулла яисә Галиәкбәр белән бер рәткә куеп булмый. Совет чоры бәетләрендә гәүдәләнгән геройның характеры, аның тормышы, көрәше һәм фаҗигасе арасында тыгыз бәйләнеш бар. Бәетнең төп өлеше геройның эшләрен, көрәшен сурәтләүгә багышлана. Аның һәлак булуы якты тормыш, халык бәхете өчен көрәшнең логик дәвамы, нәтиҗәсе рәвешендә килә. Традицион бәетләрнең азагында, гадәттә, геройның туганнары белән саубуллашуы, вакытсыз үлем килүенә үкенеч белдерүе кебек күңелсез хәлләр турында әйтелә:

Газиз улмыш күршеләрем, бәндин бәхил булыңыз,
Исләрегезгә төшереп, хәер-дога кыйлыңыз.

*(«Лашманчы зары»)*

Үтте шулай көннәр, айлар, еллар,
Чахуткадан кибеп беттем мин;
Яшь кипмәде минем күзләремдә,
Егълый-егълый үлеп киттем мин...

*(«Бәхетсез килен»)*

Совет чоры бәетләренең йомгак өлеше исә бөтенләй башкача яңгырый:

Сыйнфый дошманнарга каршы үткен булсын уегыз,
Көрәш сафларыннан китәм, хуш, исән-сау булыгыз.

*(«Габделнур бәете»)*

Гомерен халык бәхете өчен корбан итүнең мәгънәсен тирәнтен аңлау — геройның уңай сыйфатларыннан берсе. Һәм бу, гадәттә, бәетнең соңгы строфасында ачыклана:

Миннән калган киемнәрне
Иптәшләрем кисеннәр;
Совет власте өчен
Корбан булды дисеннәр.

*(«Мирсәет бәете»)*

20—30 еллардагы бәетләрнең тагы бер үзенчәлеге — аларда хатын-кыз образының яңача ачылуы. Суга баткан Гайшә, атасы тарафыннан картада оттырылган Зөлхәбирә, сөйгәненнән аерылган Фәйрүзә кебек образлар революциягә кадәр хатын-кызлар тормышының чиктән тыш авыр һәм коточкыч ямьсез булуы турында сөйлиләр. Совет чоры бәетләрендә инде революция нәтиҗәсендә гражданлык хокукы яулап алган һәм иҗтимагый тормышта, көрәштә актив катнашу дәрәҗәсенә күтәрелгән хатын-кыз образы гәүдәләнә. Моның мисалы рәвешендә сыйнфый бәрелешләрдә актив катнашып, мулла һәм кулакларга каршы чыккан һәм яшь гомерен корбан иткән Гаптиеваны күрсәтергә мөмкин:

Дөбъяз юлларына чыккач,
Гаптиева каберлеге
Күренеп тора;
Өстендә кызыл әләме,
Кулакларга җәза сорап,
Җилфердәп тора.

«Тәзкия матур» бәетендәге укытучы кыз образы да жанрга хас эстетик принципларның беркадәр үзгәрүе турында сөйли. Тәзкия — традицион бәетләрдә гәүдәләнгән хокуксыз, авыр изелүдән котылу юлларын эзләп тә таба алмаган бәхетсез кыз түгел. Бәеттән күренүенчә, ул — зифа буйлы, кыйгач кашлы матур кыз. Тормышта нинди юлдан һәм ничек барырга кирәклеген Тәзкия яхшы аңлый: ул үзенең туган халкына хезмәт итә.

Авыл халкы карап кала
Мәктәплэрдән кайтканда.

Реакцион гореф-гадәтләргә, шәригать кануннарына каршы көрәштә Тәзкия зур активлык күрсәтә. Авыл кулаклары һәм муллалар аңа теш кайрыйлар. Әмма Тәзкия куркып калмый, ул совет яшьләренең иң алдынгы сафында булу турында хыяллана:

Тәзкия матур үсеп җитте,
Зифа иде буйлары;
Комсомолга керергә
Иде аның уйлары.

Көрәш юлында Тәзкия һәлак була, ләкин аның батырлыгын, якты истәлеген халык күңелендә саклый.

Димәк, 20—30 елларда туган бәетләрдә жанрга хас иҗади принципларның, поэтик чараларның беркадәр үзгәрүе, камилләшүе сизелә. Ләкин аларның тематик эчтәлеге авыл җирлегендә барган сыйнфый көрәшне чагылдыру белән чикләнгән. Гражданнар сугышы бәетләре өчен зур тарихи вакыйгаларны эпик планда сурәтләү характерлы булып, 20—30 елларда аерым геройлар образын чагылдыру беренче планда торса, Бөек Ватан сугышы чорында туган бәетләрдә бу иҗади принципларның икесе дә дәвам итә. Эчтәлек һәм шигъри үзенчәлекләреннән чыгып бу чор бәетләрен ике төркемгә бүләргә мөмкин: «Кызыл сугышчы», «Мәскәүне саклау» кебек лиро-эпик бәетләр һәм «Кайгылы хатын», «Ана бәете», «Салих улым» шикелле лирик бәетләр. Бөек Ватан сугышына кадәр иҗат ителгән бәетләр арасында саф лирик әсәрләрне табуы читен. Ватан сугышы чоры жанрның яңа баскычка күтәрелүе — лирик бәетләрнең барлыкка килүе белән характерлы. Дөрес, лиризм бәетләр өчен элек тә ят нәрсә түгел иде. Хатын-кызлар, рекрутлар, солдатлар турындагы борынгы бәетләрдә дә, 20—30 елларда туган кайбер бәетләрдә дә лиризм шактый көчле. Әмма Бөек Ватан сугышына кадәр барлыкка килгән бәетләрнең лиризмы геройның фаҗигасен тәфсилләп сурәтләүгә нигезләнгән. Ә сугыш чорында туган лирик бәетләрнең төп үзенчәлеге — геройның кичерешләрен, кайгысын яисә шатлыгын, уйфикерләре үзгәрүен, гомумән, каршылыклы хисләр алмашынуын гәүдәләндерүдән гыйбарәт. Мәсәлән, «Кайгылы хатын» бәете сугыш чоры өчен характерлы булган һәм язма поэзиядә дә зур урын алган озату мотивы белән башлана. Иренең Сталинград янында үлүе турында хәбәр килсә дә, хатын аны көтә, көрешү турында хыяллана. Әмма сугыш беткәч, аның өмете өзелә. Сугыш кырында вафат булган иренә тирән ихтирам, аның истәлегенә турылыклы булу — геройның бердәнбер юанычы булып кала. Бәетнең төп фикере кызыл йолдыз образы аркылы ачыклана:

Кабер өстендә тактага
Исемең язылгандыр;
Ядкарь булып исемеңә
Бер йолдыз кабынгандыр.

Бөек Ватан сугышы чорында туган лирик бәетләр геройның катлаулы кичерешләрен, чын йөрәктән чыккан кайнар хисләрен искиткеч тыйнаклык, гадилек белән ачып бирәләр. Гасырлар дәвамында шигъри тәҗрибә туплап килгән халык кешенең йөрәк ярасына каты кагылырга ярамаганлыгын бик яхшы аңлый. Шуңа күрә ул сугыш корбаннарына үзенең мөнәсәбәтен белдерү өчен бик уңышлы шигъри чараларның берсен сайлый: «Ана бәете», «Мин этине онытмыйм», «Ил батырлары» кебек бәетләрдә кешелеклелек, җылы хисләр белән сугарылган лирик монолог гаять зур роль уйный. Моның ачык мисалы итеп «Батыр егет» бәетен алырга мөмкин. Каты яраланган герой сугыш кырында ялгыз кала. Бу авыр минутта аның йөрәген тетрәткән беренче уй — әнисе турында. Еракта әнисенә ул гаять җылы, ягымлы сүзләр белән эндәшә (әнием, бәгырем), аны юатырга, хәсрәтен уртаклашырга тырыша:

Беләм, әнкәй, авыр сиңа,
Көрешүләр өмет иткәнсең;
Минем хәлләремне белер өчен,
Хатларымны өзелеп көткәнсең.

Герой туган иле, туган халкы өчен үләсен яхшы аңлый, ләкин аның яшисе килә, һәм бу изге теләк үтә гади сүзләр белән әйтелә: «Өйдә чакта гармонымны туйганчы уйнамадым...» Тирән хәсрәт, чиксез кайгы

геройның йөрәген әрнетә. Әмма соңгы минутта авыр хисләр, кичерешләр — якты тормыш, ил азатлыгы өчен үлүнең бөек мәгънәсен ачык аңлау белән алмашына:

Чәчәк гомерем өзелде,
Фашист җитте башыма;
«Хак эш өчен үлде» диеп
Язылгыз кабер ташыма.

Монда лиро-эпик бәетләрдәге кебек зур вакыйгалар юк, геройның тормышыннан тик бер генә эпизод — яшәү белән үлем арасындагы трагик момент алынган һәм шул нигездә кешенең кичерешләре бөтен тирәнлеге һәм катлаулылыгы белән ачылган. Бәет җылы лиризм белән сугарылган, аның эмоциональ яңгырашы гаять көчле. Бөек Ватан сугышы чорында ил батырларының гүзәл сыйфатларын, мораль сафлыгын, эчкерсезлеген сәнгатьчә гәүдәләндерү өчен бәетләрнең лиро-эпик характердагы тасвирлау ысулы тулысынча җавап бирә алмаган булыр иде. Заман героеның катлаулы психологиясен, тирән кичерешләрен сурәтләү өчен лирик планда иҗат ителгән әсәрләр кирәк иде. Шуңа күрә, чор таләпләренә җавап буларак, бәетләрнең яңа төркеме — лирик бәетләр барлыкка килүе табигый бер күренеш дип исәпләнергә тиеш.

Эпик һәм лиро-эпик бәетләрдә кешенең эчке дөньясын, аның психологиясен тирәнтен һәм бөтен тулылыгы белән чагылдыру тәҗрибәсе әллә ни зур түгел иде. Жанрның традицион рамкаларында калып, аның төп үзенчәлекләрен саклаган очракта, бәетләр геройның эчке дөньясын «Батыр егет» яисә «Ана бәете»ндәге кебек тирәнлек белән ача алмаган булырлар иде. Димәк, жанрның эстетик рамкаларын киңәйтергә, аның традицион спецификасын беркадәр җимерергә кирәк иде. Һәм бу шулай булды да. Бөек Ватан сугышы чорында бәетләр шул елларның лирик җырлары һәм язма поэзиясе тәҗрибәсеннән, иҗади принципларыннан шактый киң файдаландылар [1]. «Ана бәете», «Читкә озатылган кыз» кебек лирик бәетләрнең стиле, шигъри үзенчәлекләре халык җырларына бик якын тора:

Дон буйлары алмагач,
Сайрый сары сандугач.
Фашист кисеп утка якты
Алмалары калмагач.

Дон буйлары чиядер,
Пешсә җиргә тиядер,
Фашист аяк баскан җирдә
Үлән, яфрак көядер.

«Тыңлагыз, дусларым, мин җырлыйм» бәете исә лирик шигырьдән берничек тә аерылмый дип әйтергә мөмкин:

Тыңлагыз, дусларым, мин җырлыйм
Берничә сүз сугыш ягыннан;
Бигрәк авыр икән сугыш хәле,
Эчкә хәсрәт уты кабынган...

Җир селкетеп төшкән снарядлар
Куркә очра адәм баласын,
Көчле кызыл гаскәр каршы тора,
— Бирмибез! — дип Ленин каласын.

Яисә «Салих улым» бәетен һәм М. Җәлилнең «Ана бәйрәме» балладасын чагыштырып карарга мөмкин. Иң элек бу ике әсәрнең сюжет-

[1] Карагыз: И. Надиров. Халык һәм җыр. Казан, 1961, 91—95 битләр.

ларында билгеле уртаклык барлыгын әйтеп китәргә кирәк. Шулай ук аларның образларында да шактый якынлык сизелә: бәетнең дә, балладаның да үзәгендә ана образы тора. Һәр ике әсәрдә дә сүз ана исеменнән алып барыла. Бу — аларның эмоциональ яңгырашын көчәйтә, образларга аеруча ягымлылык, җылылык бирә. Ананың кичерешләре, кайгы-хәсрәте риторик сораулар ярдәмендә ачыклана:

**М. Җәлил балладасы**

Кайда йөри минем улларым,
Ана күңеле тели белергә;
Кая илтә язмыш юлларың,
Җиңүтәме, әллә үлемгә?

**Бәет**

Әллә дошман җирләрендә
Тоткын булып ятамсың,
Әллә яуны тар-мар кыйлгач,
Илебезгә кайтамсың?

Улының (бәеттә) яисә улларының (балладада) язмышы турында ана җилләрдән, кошлардан сорый.

**Баллада**

— Әйтегезче, җилкәй, йөргән җиреңдә
Күрмәдеңме минем улымны?

**Бәет**

Хәлләреңне сорыйм һаман
Саба җилдән, кошлардан.

Эчтәлеге, композициясе һәм образлар төзелеше белән баллада бәеттән катлаулырак. Шулай да, бу ике әсәрнең сюжетында, шигъри чараларында һәм эмоциональ яңгырашларында күп уртаклык бар. Әлбәттә, М. Җәлил балладасы «Салих улым» бәете нигезендә яисә, киресенчә, бәет баллада йогынтысы нәтиҗәсендә туган дип әйтү һич тә дөрес булмас иде. Сүз жанрлар арасындагы охшашлыклар, бу чорда бәетләрнең язма поэзиягә тагын да якыная төшүе турында бара.

Сугыш чорында туган лирик бәетләр жанрның традицион үзенчәлекләреннән беркадәр читтә торалар. Бу әсәрләр халык иҗаты белән язма поэзиянең очрашкан ноктасында барлыкка килгәннәр. Хәтта алар бәетләрнең жанр үзенчәлекләренең үсүе турында түгел, бәлки аларның эстетик асылының беркадәр югалуы, җимерелүе турында сөйлиләр, дип әйтергә мөмкин. Бу аңлашыла да: совет чорында бәетләр үтә каршылыклы юл уздылар һәм моның нәтиҗәсе соңгы 20 ел эчендә тагын да ачыклана төште.

Жанр составында яңа әсәрләр барлыкка килүгә таянып кына жанрның чәчәк атуы турында сөйләү дөрес булмас иде. Идея эчтәлегенең, образлар тудыру принципларының беркадәр камилләшүе белән бергә, XX йөздә бәетләр шактый зур эстетик югалтулар да кичерделәр. Монда иң беренче чиратта жанрның тематикасы тараюын әйтеп үтәргә кирәк. Чыннан да, традицион бәетләрнең тематикасы гаять киң һәм катлаулы: туган илне саклау, крестьян хәрәкәтләре, рекрутлар һәм солдатлар язмышы, шахтерлар, эшчеләр тормышы, хатын-кызлар язмышы, бәхетсез мәхәббәт һ. б. һ. б. Традицион бәетләрдә гаять күп тарихи вакыйгалар һәм халык тормышының төрле яклары гәүдәләнә. Совет чоры бәетләренең тематик эчтәлеге исә туган илне эчке һәм тышкы дошманнардан саклау, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү кебек тарихи вакыйгалар тәшкил итә. Тормыш-көнкүреш бәетләренең дә чын сәнгатьчә эшләнгән-

нәре совет чорында бик сирәк очрыйлар. Жанрның тематикасы нигездә тарихи вакыйгалар белән чикләнгәнлектән, аның образлар системасы да, билгеле, тарая. Элекке бәетләр арасында юмористик характердагы әсәрләр дә бар («Уңмаган килен», «Сеңел белән түтәй», «Кашык бәете»). Революциядән соңгы чорда исә андый бәетләрне очратып булмый. Традицион бәетләр белән совет чоры бәетләренең шигъри үзенчәлекләре арасында да сизелерлек аермалар барлыгын әйтергә кирәк. Бер генә мисал алыйк. Элекке бәетләрдә еш очрый торган һәм шактый камилләшкән алымнарның берсе — рефрен. Мәсәлән, «Солдат бәете»ндә рефрен әсәрнең төп фикерен ачыклау өчен кулланыла:

И әнкәем, елан керде лә куйныма...
И әнкәем, некрот йөкләнде муйныма.

Рефрен, гадәттә, эмоциональ яңгырашның иң югары ноктасы булып, шигъри кульминация ролен үти:

Нигә тудым дөньяга кыз булып?
Нигә акмадым дәрьяга боз булып?

*(«Фәрузә кыз»)*

Билгеле булганча, рефрен әсәрнең эчтәлеген тулырак, образларын җанлырак итеп сурәтли торган уңышлы поэтик чараларның берсе. Ләкин традицион бәетләрдә еш кулланылган бу алым XIX йөз азагында жанрга хас шигъри чаралар составыннан төшеп кала, XX йөз бәетләрендә рефрен гомумән очрамый. Диалог, параллелизмнар, чагыштыру, эпитет кебек поэтик чаралар да совет чоры бәетләрендә сирәк күренә.

Бәетләрнең бүгенге язмышы турында сөйләгәндә, арифметиканы да истән чыгармаска кирәк. 1960 елда басылып чыккан «Бәетләр» җыентыгына, мәсәлән, XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөз башында иҗат ителгән бәетләрдән җитмештән артык, совет чорыннан исә нибары утыз бер бәет кергән. Бөек Ватан сугышыннан соңгы 20 елда бүгенге көн тормышын чагылдырган югары художестволы бәетләрнең бер генә үрнәге дә язылып алынмавын да күрсәтеп үтәргә кирәк. Дөрес, яшен сугып, суга батып, поезд, машина астында калып үлү кебек бәхетсезлекләр турында бүген дә бәетләр иҗат ителә. Күләм ягыннан алар, гадәттә, шактый зур булалар һәм 50—60 куплеттан торалар. Ләкин мондый бәетләрнең эчтәлеге, эмоциональ яңгырашы гомумхалык настроениесен, заман рухын чагылдырмый. Шуңа күрә алар халык арасына таралмыйлар, ягъни коллектив иҗат җимеше (фольклор) булып әверелмиләр. Үзешчән авторлар тарафыннан иҗат ителгән һәм теге яки бу фаҗигане тәфсилләп сурәтләүгә нигезләнгән мондый бәетләрнең эстетик сыйфатлары да түбән. Алар, гадәттә, төрле натуралистик эпизодлардан торалар һәм жанрның үсүе турында түгел, ә бәлки аның акрынлап сүрелүе турында сөйлиләр.

Димәк, совет чорында бәетләр катлаулы һәм гаять каршылыклы юл үттеләр. Аларның киләчәк язмышын өзеп әйтүе читен. Шулай да мәсьәләнең бер ягы һичшиксез ачык: бәетләрнең чәчәк ату чоры XX йөздә түгел, бәлки XVIII—XIX йөзләргә кайтып кала.

Бер жанр тарихын өйрәнү нәтиҗәсендә ачыкланган фикерләрне бөтен фольклорга, яисә аның башка аерым жанрларына күчерү дөрес булмас иде. Халык иҗатының әкият, мәкаль-әйтем, җыр һ. б. жанрларының бүгенге торышын ачыклау өчен махсус тикшеренүләр таләп ителә.

———●———

*Бу истәлек Туймазы шәһәрендә яшәүче пенсионер Гали Хөсәен улы Хикмәтуллин иптәштән язылып алынды.*

*Гали ага Уральск шәһәрендә 1900—1903 елларда Габдулла Тукай белән бер мәдрәсәдә укыган. Аның белән еш очрашкан, күп сөйләшкән. Шуңа Тукай образы аның хәтерендә нык сакланган. «Социализм, демократия дигән төшенчәләрне мин башлап Габдулладан алдым», ди ул.*

*Хикмәтуллин иптәш Кызыл Армиядән кайткач, әүвәл Сорочинскида авыл Советында, аннан Колчакка каршы сугышкан 1 нче Армиянең политбүлегендә эшли. Колчак куылгач, Туксуран волостенда Давыт Юлтый һ. б. белән бергә совет органнарын яңадан оештыруда катнаша.*

*Аннан, Гали ага, Д. Юлтый тәкъдиме белән, Бәләбәйгә татар-башкорт частьларына агитатор булып китә. Бәләбәйдән Чокадытамак волостена укытучы булып бара. Анда иң башлап волость партия ячейкасын төзи. Аның секретаре булып эшли.*

*Аннан соң төрле җирдә совет сәүдә оешмаларында эш алып бара.*

*Персональ пенсионер Гали аганы Тукай юбилейларында мәктәпләр, клублар даими очрашуга чакырып торалар. Ул Тукай хакында исендә калганнарын сөйли, Тукайның яраткан көйләрен балаларга, яшьләргә җырлап күрсәтә.*

*Гали ага 1939 елда «Знак почета» ордены, 1957 елда Башкортстан Верховный Советының «Мактау грамотасы» белән бүләкләнгән. 1949 елдан бирле пенсиядә. Әмма әле дә җәмәгать эшләренә бик актив катнаша.*

*Г. Хикмәтуллин*

# Тукай турында исемдә калганнар

**Мин Габдулла Тукай белән Җаек-Уральск мәдрәсәсендә булган вакытларымны, аның иптәшләрчә биргән акыллы киңәшләрен гомерем буе онытмадым. Шул киңәшләр аркасында минем күзләрем ачылды, дөньяга карашым оешты. Байларның, руханиларның мәкерле йөзләрен һәм дөньяның башка серләрен безгә, надан шәкертләргә, Тукай төшендерде.**

**Мин үзем, бик яшьли ятим калганлыктан, ата-ана тәрбиясе күреп үсмәдем. Шуна күрә Тукайның сүзләре, атам-анам васыяте кебек, кадерле булды.**

**Мин 1887 елны Туймазы районындагы Тукай авылында туганмын. Мин нәни чакта, әти, семьясын алып, Уральск ягына «бәхет эзләп» чыгып киткән. Әмма 1891 елгы ачлыкта әти дә, әни дә үлгәннәр. Мине Хәтирә апам үз карамагына алган. Апа укый-яза белә, искечә китаплар укый иде. Ул мине дә бик яшьли укырга өйрәтте.**

**1900 елда Хәтирә апа мине, Уральскига алып барып, Мотыйгулла Төхфәтуллин мәдрәсәсенә укырга бирде. Әле дә исемдә — безне мәдрәсәдә Салих казый каршы алды. «Ничек укытырга телисез? Кадимчәме? Җәдитчәме?» — дип сорады. «Җәдитчә укытырбыз дип уйлаган идек»,— диде апа. Салих казый шуннан: «Әнә тегендә барыгыз, алай булгач!» — дип, ачуланып кычкырды. Апа мине икенче бинага алып китте.**

**Шулай итеп мин Нурый хәлфәдән укый башладым. Габдулла Тукай югары сыйныфта, Мотыйгулла хәзрәттән укый иде. Бер гомуми торакта булмасак та, мин бик тиз Г. Тукай белән танышып киттем. Ул, үзе дә ятимлекнең, ярлылыкның газапларын татып үскәнгәдер, миңа аеруча илтифат итә иде. Бу вакытта Тукайга 14 яшь. Шулай да**

ул шактый укыган, шул мәдрәсә янында татарлар өчен ачылган рус мәктәбен [1] тәмамлаган мәгълүматлы шәкерт иде. Мин үзем дә, яңа гына мәдрәсәгә килгән булсам да, апам ярдәмендә «Таһир-Зөһрә», «Йосыф китабы», «Буз егет», «Бакырган» китапларын укыган идем.

Ятим бала моңлы була бит. Мин яшьтән үк җырга һәвәс идем. Тукай белән танышуның башы да җырдан булды. Ул минем җырлавымны ошата, үзе дә җырны бик ярата иде. Аннары аның белән бергәләп тә җырлый башладык. Безне җыр якынайтты һәм дуслаштырды. Габдулла бик матур җырлар уйлап чыгара, аларны без нинди дә булса бер көйгә салып җырлый торган идек. Менә аның кызлар турындагы җырлары:

«Укыгыз, кызлар, укыгыз, күп фәннәрне белегез!
Остабикәләрне ташлап, мәктәпләргә керегез!

— Укытам, — дип остабикә сездән бала карата,
Идәннәрне дә юыгыз, сезне бигрәк ярата.

Сезгә кирәк гыйлем эстәп, игътикатне [2] тазартмак,
Нигә кирәк остабикә самоварын агартмак?

Безгә мәктәп юк дисәгез, үзегез салдырыгыз,
Казаннан мөгаллимәләр чакыртып алдырыгыз!

. . . . . . . . . . . . . . .

Шулай ваклап җыйсагыз да, бер кисмәк алтын була,
Тамчы-тамчы тамган судан тирән диңгезләр тула».

**(Соңгы строфага чаклы янә бер-ике строфа бар иде. Алары истән чыккан.)**
**Муллалар турындагы җыры да истә:**

«Дөньяны болгар [3] болгар, монкариз булды [4] болгар...
Муллалары — бүрәнә, мөәзиннәр — утыннар.

...Мулла максатка җитсен, мөәзин йөз түбән китсен:
Мөәзингә ашарга юк, мулла шәраплап типсен.

...Бер бай кешегә очраса, мулла тезе калтырый,
Тычкан күргән песи кебек, күзе уттай ялтырый.

Ник аның күзе янмасын, разыйкы [5] һәм рыйзкы шул:
Бай аркасын кашыса да, мулла тизрәк суза кул.

Бай янында әйләнәдер утырып, торып, чүгәләп,
Ничек әйләнә кич белән ут янында күбәләк».

**(Монда да кайбер юлларын онытканмын.)**
**Нурый хәлфә турында Тукай менә шушы җырны чыгарган иде:**

Ачык та тишек тәрәзә, ишек,
Хәлфәсе кыйшык авыз, дусларым [6].
Хәлфәсе надан, укымый калган,
Укыта ялган, аңла, дусларым.

**Тукай руханиларны бер дә яратмады. Аның аларга карата язган җырының азагы хәтердә әле. Ул шушылай бетә иде:**

Ахирәт, ахирәт дигәннәр — ахирәткә китәләр,
Анда да дөньядагыдай гел йоклап көн итәләр.

**«Мулла-мунтагай ата-анамны корбан итмәде, бәлки милләтне харап итте. Милләткә хезмәт итмәде...» — дигән сүзләре дә һич онытылмый.**

---

[1] Ул мәктәпнең вывескасында: «Русская школа при татарском медресе» дип язылган иде. Уку срогы 3 ел. Әхмәтша исемле учитель укыта иде.
[2] дөньяга караш.
[3] болгатыр мәгънәсендә.
[4] юкка чыкты.
[5] туйдыручысы.
[6] Нурый хәлфәнең авызы аз гына кыек иде.

Ул вакытларда байлар гаиләсеннән берәр кеше вафат булса, җиназага барып, азмы-күпме хәер-садака алуны шәкертләр ганимәт[1] дип беләләр иде. Ә Тукай моны һич тә яратмады, «үләксә козгыннары» дип, алардан нәфрәт белән көлә, алар турында сатирик җырлар, шигырьләр яза иде.

Онытып торам, Тукайның яшел күн читек, яшел башмак кигән бер шәкерттән көлеп чыгарган җырын да җырлый идек. Менә ул:

«Яшел башмаклар киминчә[2],
Юк сираттан ашмаклар.
Сираттан кичәргә кирәк
Яшел читек-башмаклар.

Мондый башмаклар киминчә,
Сираттан кичү кая!
Итек кисәң, шуа, имеш,
Шиблитле кеше тая».

(Башка строфалары онытылган.)

Бер кызыклы эпизод сөйлим әле. Тукайның муллалар турында чыгарган җырларын мәдрәсәдә еш җырлый идек, дип әйттем инде. Моны бер шәкерт Мотыйгулла хәзрәткә җиткергән. Хәзрәт бер кич Тукай белән икебезне үз өенә чакыртты. Салкын гына каршы алды. Утырышкач: «Хуш, пишкадәмнәр[3]. Безләр, голамәләр, хаккында кандай мөнәҗәтләр әйтәсез, шуларны әйтеп күрсәтсәгез иди», — диде. Без бер-беребезгә караштык. «Рөхсәт булса, җырлап бирәбез», — диде Апуш. «Рөхсәт!» Шуннан Апуш башлады, мин кушылдым. Хәзрәт, чыраен сытып, тыңлап утырды да соңыннан бик нык тиргәде. Бигрәк тә мине. «Укуыңны белмисең, голамәләрне[4] хәкарәт[5] итеп, мыскыллап җырлап йөргән буласың, хәшәб»[6], — дип әйтте миңа.

Яшермим, мин бик курыктым, ә Габдуллада куркуның әсәре дә булмады. Шунда хәзрәтнең үзенә ул бик тапкыр сүз әйтте: «Минемчә, хакыйкатән әйтү хәкари булмый ул, хәзрәт. Безнең халыкның бик акыллы мәкале бар: «Авызың кыеш булса, көзгегә үпкәләмә», диләр. «Фигылең чалыш булса, кешегә үпкәләмә», дип өстәп әйтергә дә була бит», — диде Тукай.

Габдулла бу сүзләрне әйткәндә, минем тез буыннарым калтырады. Инде хәзрәт кызып китәр дә җәзалар дип уйладым. Ләкин хәзрәт кызып китмәде, башын түбән иебрәк: «Габдулла әфәнде, сезгә могътәбәрле[7] кешеләрне тәнкыйть итүдән башка маугуз да күп бит. Сез моны киләчәктә исегездә тотарсыз дип ышанам. Ә син, Гали, ятим бәрәч кебек, теләсә кемгә ияреп йөрмә!» — дип әйтте дә бүлмәдән чыгып китте.

Тукай иплән кенә: «Улым, синә әйтәм, киленем, син тыңла», дигән сымаграк булды бит әле. Сине тиргәп миңа тәрттерә бу», — диде. Аннан абыстай кереп, безне үгетләде-үгетләде дә: «Сез икегез дә ятим, мин сезне кызганам, балалар», — дип, чәй әчереп чыгарды.

Зур фаҗига белән бетәр инде бу дип торганда, эшнең шулай хәл ителүенә мин һич тә төшенә алмадым. Фәкать соңыннан гына белдем: ул вакытта ук Тукайның авторитеты зур булган икән. Бу эш 1902 елда булды, ахры.

Чыннан да Тукай бик авторитетлы иде. Без урамда хәзрәт, хәлфәләрне очратсак, кулларыбызны күкрәккә куеп, сәлам биреп үтәбез, ә алар Тукайның үзенә «Габдулла әфәндегә сәлам!» дип исәнләшеп китәләр. Тукайның шундый дәрәҗәле булуына без, шәкертләр, бик соклана идек.

Һәр шәкерт аңа якын булырга тырыша, аңа сырыша иде. Шәкертләр аннан белмәгән дәресне һәм төрле киңәшләр сорый. Кайберәүләр Тукай шикелле шигырь, җырлар язалар. Ярулла Моратов, Йосыф һәм башкалар язганнарын Тукайга укыйлар, Тукай аларга ярдәм итә иде.

Тукай бер төрек шәкерте Габделвәли белән бик дус булды. Төннәр буе бер бүлмәдә сөйләшәләр, бәхәсләшәләр иде. Тукай аннан күп мәгълүмат алды булса кирәк. Габдулланың дусы Хәкимҗан Йосыпов соңрак миңа Габделвәлинең шагыйрь булуын, Габдулланың аннан төрек телен өйрәнүен сөйләде. Бу инде Габделвәли киткәч булды.

Габделвәли белән Тукай төннәр буе кайдадыр йөреп тә кайталар иде. Хәзер Тукайның Уральскидагы революционерлар белән элемтәдә булуын ишетәм. Бәлки, алар шул изге юлда йөргәннәрдер, һич тә әйтә алмыйм. Мәгәр төннәрдә самовар куеп аларны чәй әчерүем, самовар артыннан гына күзәтеп утыруларым исемдә.

Г. Тукай яшьтән үк үзенең халык җырларын яратуы турында сөйли иде: «Кече яшьтән үк күңелемә урнашкан җырларны сөйгәнлегемнән миндә туган телебезне сөю хисе туды...», дип горурлана иде ул.

[1] табыш.
[2] кимиенчә, кимичә.
[3] алдынгылар, ягъни: отличниклар.
[4] муллалар.
[5] мыскыл.
[6] олтаны агач, юкәдән үргән «галош».
[7] хөрмәтле, дәрәҗәле.

Яз көне, карлар эри башлагач та, шәкертләрнең күбесе авылларга эшкә китә. Тукай шәкертләргә халык иҗатын өйрәнергә, җырлар, бәетләр, әкиятләр җыеп алып кайтырга кушып җибәрә иде. Мин «Суга баткан Гайшә» бәетен һәм күп кенә җырлар җыеп алып кайтып, Тукайны шатландырганым хәтеремдә. Башка шәкертләр дә җыр, мәкаль һ. б. җыеп кайталар иде.

Габдулла дус бик туры сүзле булды. Икейөзлеләнү, корыга мактану, ялганлауны белмәде. Мондый эшләрне тәмам күрә алмый иде. Сүзгә бик бай, бик мәгънәле итеп сөйләүчән булды. Сүзе һәм үзе бик сабыр. Кеше алдында үзен бик оста тота. Шуңа күрә ул безнең барыбызга да бик матур, сөйкемле күренә иде. Барыбыз да аны Апуш, Апуш әфәнде дип йөри идек, якын күреп.

Кигән киеме шул шәкерт киеме: җилән, бишмәт, камзул. Башта — кара кәләпүш, «мескен» бүрек, кайсы чакта камалы бүрек. Мәгәр чәчен җиткереп, тарап йөри торган иде.

Шадрасы бик аз, матурлык биреп кенә тора. Бер күзе никтер кысыграк. Хәтерен калдырсалар, тиз генә онытмый иде. Кайберәүләр, зәгыйфь күзенә ишарә ясап, шаярып: «тавык» дип әйтәләр иде. «Тавык» дип әйтсәләр, җәһәт: «Иот... кабып!» — дип җавап бирә иде. Мондый хәл бик сирәк, баштарак кына булгалады. Ә соңрак алай әйтү бетте: бөтенесе дә аны бик ихтирам итә башладылар.

Тагын шуны әйтә алам, Габдулла сүзгә бик тапкыр булды. Ни әйтсәләр дә, бик тиз, оста җавап таба иде.

Тукай белән гәрчә һәрвакыт бергә булырга туры килмәсә дә, миңа аның холкы, фигыле бик зур тәэсир итте. Ул кешегә ягымлы, бик илтифатлы булды. Үз тирәсендәге яшьләрне һәрвакыт укырга кызыктыра, бигрәк тә рус теле, әдәбияты белән танышуны алга куя иде. Шәкертләрне русча укырга даими димләп торды.

Апушның яттан русча шигырьләр әйтеп йөрүе дә истә. Мин аннан «Пахнет сеном над лугами» дигән шигырьне өйрәндем.

Тагын бер факт: Апуш папирос тарта иде. Мине записка белән рус сатучысына папирос алырга җибәргән чаклары булды. Записканы русча яза: «Дайте ему на 5 коп «Трубача».

Тукайдан башка тәмәке тарткан шәкертне мин бер дә белмим. Әллә яшереп тартканнар? Ә Тукай ачыктан-ачык тартты. Бер вакыт шулай уразада безнең җәдит корпусының аскы катында, ашханәдә, кичкә таба аш пешерәбез. Тукай авызына папирос капкан, шырпы тоткан килеш утыра. Үзе сорый: «Шәкертләр, азан әйттеләрме әле?» Азан әйткән булса, папиросны кабызып җибәрмәкче. Белеп торам, үзе ураза түгел. Юри шаяра.

Гомумән, мин аның ураза тотканын күрмәдем. Үзем дә тотмадым. Намазга да җинел карый иде ул. Бер көнне шулай иртән миңа болай ди: «Казый бәйләнмәсен. Әйдә, Гали, иртәнге намазның фарызын укып ташлыйк. Сөннәте чурт с ним».

Мәдрәсәдә «мендәр сугышлары» күп булгалады. Исемдә: бер-ике рәт бу сугышларны Камил (хәзрәтнең Мисырда укып кайткан улы) башлап җибәрде. Бу уеннарга Апуш бер дә катнашмады. Мәчет юлында кичен безнең мәдрәсә «Мотыйгыя» һәм икенче бик кадим мәдрәсә «Рәкыйбия» шәкертләре арасында урам сугышлары да булгалады. Хәтта шәһәрдә татарлар белән руслар арасында йодрык сугышлары да була иде. Тукай боларның берсенә дә катнашмады. Әмма «чәй мәҗлесләрендә» бик актив булды. Аны эчә дип тә сөйләделәр. Ләкин мин моны һич күрмәдем дә, сизмәдем дә.

Габдулла гарәп, фарсы һәм төрек телләрен бик яхшы белә иде. Хәтта дәрестә хәлфәләрнең, хәзрәтнең дә хаталарын төзәтеп утыруларын хәтерлим әле мин.

Кайчак шәкертләр, сүз көрәштереп җиңелгәч, аннан гарәп, фарсы телләрен яхшы белүенең серен сорыйлар иде. Ул: «Сарыф, нәхүне[1] яхшы үзләштерегез. Шунда телне яхшы белеп була», дия иде. «Мин, — дип әйтә иде Габдулла, — сарыф, нәхүдә чуртан шикелле йөзәм». Шаһит була алам, бу сүз дөрес!

Тукай, минем тормышымның авырлыгын күреп, мине кызгана иде. «Безнең Гали кышны мәдрәсәдә җырлап үткәрә дә, яз белән, мәдрәсәне ташлап, эшкә чыгып китә», дип көлдерә иде. Ә миңа шунсыз яшәү мөмкин булмады. 1903 елда мәдрәсәне бөтенләй ташларга мәҗбүр булдым.

Габдулла минем китәчәгемне белгәч, болай диде:

— Гали, син китап укырга бик яратасың. Ә китап алырга акчаң булмас. Шулай булгач, сиңа китап сатучы булудан да файдалы эш юк. Син ничек булса да китап сату урынына керергә тырыш.

Мин аның киңәше белән Уральск сәүдәгәре Латыйп хаҗиның Бүрле авылындагы кибетенә китап сату хезмәтенә ялланып киттем. Укуны дәвам итә алмадым. Шулай да Уральскига килгән вакытларымда Тукай белән очраша һәм бергәләп кайгыларны уртаклаша идек. Әмма ара ерак, мин бик сирәк килә идем шул.

Мин Уральскига бер килүемдә Г. Тукайны урамда очраттым. Икебез дә бик куандык. Апуш миннән бик җентекләп хәл сорашты. Өс-башымны карап чыкты. Мин аннан бер шәкертнең адресын сорадым. «Ул бездә наборщик булып эшли. Әйдә киттек. Мәтбагане дә күрерсең».

[1] морфология, синтаксисны.

Барып керү белән, миңа кирәк кеше күренде. Ул минем белән күреште дә Тукайга мөрәҗәгать итте: «Габдулла әфәнде, «Әлгасрел җәдит»нең бер битенә шигырь юк». «Ә, алаймы? — диде Тукай. — Хәзер. Син, Гали, бер 15—20 минут көт». Шулай дип ул үз бүлмәсенә кереп китте. 20 минут чамасы үткәч, чыгып, өстәлгә бер бит кәгазь куйды. Мин башын укып алдым: «Хур кызына». Тукай мине кечкә үз номерына (мосафирханәгә) чакырды. Мин чыгып киттем. Шул шигырь буенча күренә: бу очрашу 1906 елда булган икән.

Кичен эзләп барып керсәм, аның янында бер кеше утыра иде. Тукай тагын мине ачык йөз белән каршы алды, теге кеше белән таныштырды.

Ул Габдулла Кариев булып чыкты. Тукай мине аңа: «Бу — минем Гали дус. Ул бик матур җырлый», — дип мактап та җибәрде. Аннан миңа: «Әйдә әле, Гали, «Мал кайда»ны җырлыйк», — диде. Мин тәкәллефләнеп[1] тормадым:

— Ай дуслар, мал кайда? — дип җырлап җибәрдем. Габдулла да кушылды. Без элек тә бу җырны бергәләп җырлый идек. Тукай аны бик ярата иде. Ләкин мин хәзер ул җырның көен ишеткәнем юк. Көен Хөсәен Әхтәмовка Йоматау санаториясендә ял иткәндә 1964 елның февралендә җырлаган идем. Ул аны «Совет Башкортстаны» газетасында бастырган бугай.

Без менә ничек җырладык:

Ай дуслар, мал кайда?
Баш сау булса, шул файда!..

Сикерә дә генә, сикерә, юллар кичә
Куян гына дигән ак нәрсә.

Ай дуслар, мал кайда?
Баш сау булса, шул файда!..

Хатлар гына язып, халь белдерсәм,
Аңлар гына микән яшь нәрсә?

Ай дуслар, мал кайда?
Баш сау булса, шул файда!..

(Бу көйне мин извозчик жизнидән отып алган идем. Баштарак «Язу язып, халь белдерсәм», дип җырлый идек. Соңрак Тукай: «Хатлар язып...» — дип төзәтте.)

Мин Тукай янына барганны сөйли идем бит әле... Бераз утыргач, Габдулла Кариев:

— Әйдә, Гали әфәнде, безнең оешмага кер, җырларсың, уйнарсың, киләчәктә артист булып чыгарсың, — дип тәкъдим ясады.

— Мин артист була алмам,— дип ризалык бирмәдем. Хәзер, аның тәкъдимен нигә тыңламадым икән дип, үкенеп тә куям.

1908 елда янә бер рәт Уральскига бардым. Тукайның аннан киткәнен белгәч, миңа бик күңелсез булды. Аның дусы, хәзер инде кайнагам булган Хәкимҗан белән Тукай хакында озак сөйләшеп утырдык. Шулай итеп, соңгы күрешү 1906 елда булды.

Аннан соң Тукай белән очраша алмадым. Хәтта ул вафат булгач, аны җирләргә дә бара алмадым.

— Сәүдә калдырып йөрмә! — диде миңа Кәримовларның Оренбург вәкиле, Тукай авырганда аның янына Казанга барырга рөхсәт сорагач. Бу минем күңелемдә гомерлек төен булып калды.

Тукайның мин әле сөйләп биргән җыр-шигырьләрен бер җыентыгында да күргәнем юк. Нигә ул алай икән? Бәлки, шагыйрь аларны шигърият ягыннан түбән дип санагандыр. Бәлки, язмагач, оныткандыр. Әмма мин аларны шул заманнан бирле хәтердә сакладым. Аларның һәрберсе йөз җырланган бит!

Иң ахырдан шул: ник Тукайның кайбер шигырьләрен «төзәтеп» бастыралар икән? Мәсәлән, «Шагыйрьгә» шигыре «Әлгасрел җәдит»тә:

«Бу сүзләрне язып «Әлгасрел җәдит»кә,
Итәм тәкъдим Нәҗип белән Мәҗиткә», —

дигән юллар белән бетә иде. Бу строфаны төшергәннәр. «Өзелгән өмид» шигырендә дә ике юл югалган. Алай итмәскә иде!

*Язып алучылар:*
*ЮСЫФ ГӘРӘЙ,*
*ИМАМ СӘМИГУЛЛИН.*

---

[1] карышып тормадым мәгънәсендә.

Локман Аитов

# АРТИСТНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ



*Локман Аитов — татар театры үсешенә шактый өлеш кертқән сәхнә ветераны. Шушы елның апрелендә аңа 75 яшь тулды.*

*Аның ярты гасырдан артык гомере театр белән бәйле. Татар театры һәм культурасы вәкилләре: С. Волжская, Г. Кариев, Ш. Камал, М. Гафури, М. Фәйзи, Г. Камал, М. Мутин, Н. Чикин, Ш. Шамилский, З. Богданова, Ф. Латыйпов, Ф. Туишев һ. б. лар белән озак еллар буена ул бергә эшли. Аның җитәкчелегендәге труппа гражданнар сугышы чорында Азин дивизиясе кызылармеецларына культура хезмәте күрсәтә.*

*Революциядән соңгы тормышын да тулысы белән театрга багышлый. Озак еллар дәвамында ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли.*

*Хәзер Л. Аитов пенсиядә. Ләкин ул һаман да тынгысыз: бик еш пионерлар арасында була, җәмәгать эшләре алып бара, татар театры һәм культурасы тарихына карата истәлекләр, мәкаләләр яза.*

*Без укучыларга Л. Аитовның революциягә кадәр һәм гражданнар сугышы чорында татар артистларының эшчәнлегә турындагы китабыннан кайбер өзекләр тәкъдим итәбез.*

## Мин туган шәһәр

**Б**езнең шәһәр Кама елгасы буена сузылган Урал тавы башында утыра. Аның вокзалы да бар, шуннан Уралга, Себергә тимер юл башланып китә. Җәй көннәрендә Камада пароходлар йөри. Без пристаньга төшәргә яратабыз. Бертуган Каменскийларның, Любимов һәм Кашиннарның пароходлары бик зур, ваграк хуҗаларның — Курбатов, Истомин кебекләрнең пароходлары кечкенәләр.

Пермьнан ерак түгел Усолье дигән җирдә тоз чыга, аны пристаньнарга якын булган яр буйларына ташыйлар. Әллә кайларга сузылып киткән тоз тауларын күреп: «Бу кадәрле тозны ничек ашап бетермәк кирәк?» дип гаҗәпләнә идем. Читтән килгән кешеләр безнең шәһәр халкыннан: «Пермяки — соленые уши!» дип көләләр. Янәсе, без колактан тозга баткан!

Тоз чыннан да бездә күп иде, әмма без Кама елгасы буенда утырсак та, суга кытлык күреп яшәдек. Тау башында водокачка утыра. Суны шуның белән өскә кү-

тәртәләр. Водокачка шактый еракта булганлыктан, анда һәркем бара алмый. Җитмәсә, анда һәркайчан чират — атлы кешеләр суның мичкәсен биш тиенгә сатып алалар. Әмма урам буенча су сатып йөрүчеләр чиләген бер тиенгә саталар. Бу — ярлылар өчен бик кыенга килә иде. Шәһәрдә коелар булса да, эчәр өчен тәмсезләр иде.

Шәһәрдә рус байлары күп булган шикелле, галантерияче борадәран Агафуровлар, манфактурачы Тимкиннар һәм Гәрәй хаҗи Насыйров кебек татар байлары да җитәрлек иде. Ниһаять, 1907 елда бер таш мәчет салдыруга ирештеләр. Аңарчы алар Ибәтуллин Җиһанша дигән бер байның өендә генә намаз укыйлар иде.

Шәһәрдә таш пулатлар да күп түгел. Булганнары да Сибирская, Торговая һәм Красноуфимская дигән үзәк урамнарда гына. Аларда зур базар, толчок һәм кибетләрнең дә күбесе урнашканлыктан, юлларга таш җәелгән, кичләрендә, керосин лампалы гына булса да, фонарьлар да очрый. Башка урамнарда яз-көз көннәрендә тездән пычрак, кичләрендә күзгә төртсәң күренмәслек караңгы...

1905 елларда булырга кирәк, электр утлары да күренгәли башлады. Бераздан «Кинемотограф» ачылды. Монысы без малай-шалайларга бик ошады. «Томанный картина» карарга йөри башладык. Глупышкин, Макс Линдр дигән шамакайларның кыланышларын күреп, эчләребез катканчы көләбез, үзебез дә шулар шикелле маймыллanырга тырышабыз. Хикмәт, нигә шулай булгандыр, минем үземнең дә шулай кеше көлдерәсем килә башлады. Өйдә кеше булмаган чакларда, көзге алдында чырайларымны бозып, төрле кыяфәтләргә кереп кыланудан һич кенә дә туймый идем. Бервакытны утынлыкта балаган ачтым. Анда төрле даганнар асып, акробатларча уйнамакчы булдым. Күрше-тирә малайлары-кызлары белән утын амбары шыгрым тулды. Ләкин даганда озак уйнарга туры килмәде, егылып төшеп башымны тиштем.

Ләкин моңа карап миндә кәмит уеннарына да, «томанный»га да мәхәббәт сүрелмәде. Киресенчә, мин аны тагын да яхшырак аңлар өчен русча укырга өйрәнә башладым. Хәрефләрне вывескалар укып йөреп өйрәнә идем. Таныш рус малайлары да миңа бу юлда бик күп ярдәмнәрен күрсәттеләр. Күп тә үтмәде, мин инде басма хәрефләрне оештырып укый белә башладым.

## Казак камчысы

Шулай итеп, айлар-еллар уза торды. Абыйга сызылып мыек чыкты. Ул инде баштанаяк приказчикларча киенә — аягында ялт иткән кара ботинкалар, башында кырын салган каракүл бүрек. Мин дә кулымнан килгәнчә аннан калышмаска тырышам. Чәчне дә ике атна саен кырдырасы килми. Үстереп, ике якка тарап, әтигә күрсәтмәс өчен кәләпүш янсә бүрекне батырыбрак киеп йөрергә яратам.

Бу елларда приказчиклар байларына бик буйсынмый башладылар. Рус приказчиклары якшәмбе көннәрендә ял итүне, кибеттә сигез-тугыз сәгать кенә сату итүне таләп итәләр. Кыскасы, эшчеләрдән үрнәк алып, приказчиклар да үз хокукларын даулый башладылар — приказчиклар җәмгыяте оештырдылар. Анда хезмәт хакын арттыруны таләп итеп җыелышлар уздырыла. Әлбәттә, мондый урыннарда булу минем ише яшүсмергә дәрт бирә, ниндидер мин аңлап җиткермәгән батырлыкларга рухландыра иде.

Пермьнан дүрт-биш чакрым җирдә генә Мотовелиха дигән пушкалар ясый торган казна заводы бар. Шундагы эшчеләр баш күтәргәннәр — забастовка ясаганнар. Мондый эш ташлаулар башка шәһәрләрдә дә башланган икән. Кыскасы, зур чуалышлар китте. Мәйданнарда халык кайный. Атлы казаклар, полицейскийлар да өерләре белән тыз-быз йөриләр. Кемнәрнедер кулга алалар — төрмәгә ябалар. Забастовщиклар, краснофлажниклар, революция, хөррият кебек моңарчы без ишетмәгән яңа сүзләр ишетелә тора — алар үзләренең яңалыклары, көчле булулары белән безнең яшь күңелләребезне рухландыра, аңнарыбызны киңәйтә...

Беркөнне без — мин, күрше малае Фатих һәм башка бик күп рус малайлары — ат чабышларын карарга дип, ипподромга киттек. Билет алырга акчабыз булмаганга, шундагы койма кырыендагы зур имәннең ботакларына менеп кунакладык. Мәйдан эчендә халык шыгрым. Шулай ук койманың бу ягында да аз түгел. Җитмәсә тагы, алар артканнан-арта бара. Мин аптырый калдым. Нишләп алар чабышны карарга

кермиләр икән? Боларның күбесе эшчеләр, безнең шикелле малай-шалайлар түгел!

Менә берзаман эчтә ат чабышлары башланды. Ләкин бу яктагы кешеләрнең берсе дә тамаша белән кызыксынмады, акрынлап шундагы куаклыклар арасындагы аланлыкка җыелды. Һәм шунысы гаҗәп: алар чабыш карарга килгән тамашачылардан да артып киттеләр.

Калкулыкка урта яшьләрдәге бер рус эшчесе менеп басты да кызып-кызып сөйләргә кереште. Шулай итеп, күз белән чабышны күзәтәм, колак белән эшчеләрнең сөйләгәннәрен тыңлыйм. Минем кебек яшүсмер егеткә тегесе дә кызык, монысы да күңелле!

Менә мәйданда чабышның иң кызган чагы! Бу яктагы сөйләүләр дә чамадан тыш ялкынланып китте.

Чү!.. Көтмәгәндә әллә ни булды. Каядыр куаклар артында свисток кычкыртты-лар. Аланлыктагы эшчеләр беравык тынып калды, ләкин сөйләүләр дәвам итте. «Яшәсен, ура!» тавышлары яңадан яңгырады. Берзаманны ни күрим: шәһәр ягыннан атларын җан-фәрман чаптырып, бирегә таба атлы казаклар килә! Мин агачтан чак төшеп өлгердем, алар килеп тә җитте. Килүләре белән эшчеләр өстенә ябырылдылар да кулларындагы камчылары белән халыкны пран-заран китерергә, каезларга тотындылар. Мин дә абына-сөртенә каядыр качып бара идем, янымнан гына ажгырып торган атка атланган бер казак узып китте. Камчы белән сыртыма шундый итеп чажлатты... Күземнән утлар күренде!.. Мин мәтәлә-мәтәлә юлдан бер кырыйга тайпылдым да, ниндидер баганага бәрелеп, борынымны канаттым. Өйгә кайтып кергәндә, минем борын яулыгым кып-кызыл иде.

Шулай итеп мин дә беренче рус революциясенең беренче көннәрендә аркамда казак камчысының тәмен татыдым, борыннан гына булса да кан койдым.

## Сәхнәгә беренче адым

Пермьда приказчиклар җәмгыяте оешты. Приказчиклар, үз хокукларын яклап, белемнәрен күтәрүгә дә омтылдылар. Рус мәктәбендә зурлар өчен кичке курслар ачтылар. Бу курсларга татар яшьләреннән дә унлап егет эләкте. Болар арасында абый белән мин дә бар идем.

Мин инде русча яхшы ук сөйләшә, русча хикәяләрне укырга ярата башлаган идем.

Салих абый исә мандолинаны ярыйсы гына чиртергә өйрәнеп җитте. Беркөнне, рождество бәйрәменә әзерлек уңае белән, учительләр әдәби-музыкаль кичә уздырырга булдылар. Кыллы оркестр оештырылды. Абый шул оркестрга, мин декламация сөйләүчеләр рәтенә эләктем.

Көтелгән бәйрәм тиз килеп җитте. Кичәгә укучыларның ата-аналары, шәһәр җәмәгатьчелеге һәм башкалар җыелды. Бу кичәгә алтмыш яшькә җиткән әтине алып бардык. Программаны башлап җибәрделәр. Минем күзгә ак-кара күренми. Матур җырлар да, оркестрның дәртле көйләре дә колакка керми. Минем күңелемдә Крыловның «Аккош, Чуртан һәм Кысла» дигән мәсәле генә. Әгәр анысы яхшы чыкса, запаста «Үгез мөгезендә чебен» дигәне дә бар. Шуларны эчемнән генә кат-кат кабатлыйм. Ялгышмаячагымны яхшы белсәм дә, килешле итеп сөйләп чыга алуыма бераз ышанып җитә алмыйм. Залда шулкадәр халык! Кайбер җырчыларны, биючеләрне кат-кат сәхнәгә чыгаралар. Беренче тапкыр халык алдына чыгудан да дулкынландыргыч хәл юк икән! Каушап кына калмасам ярар иде...

Менә минем чират җитте. Мәсәлне салмак кына сөйләп бирдем. Залда бер дә харап... кул чабу башланды. Бу хәл мине гадәттән тыш рухландырды. Кая ул баш иеп кереп китү, икенче шигыремне сөйләргә күңел кыткылдап кына тора. Үзем белмим, монысын тагын да яхшырак сөйләгәнмен. Укытучыларым да, иптәшләрем дә, хәтта әти дә: «Кара, юньсез, син урысчаны һәйбәт кенә сукалыйсың икән!» дип мактады.

Мине сәхнәгә әтәргән бу көнне мин гомеремдә дә оныта алачак түгел. Бу кичә 1905 ел 25 декабрьда (искечә) узды.

# Куанычлы хәбәрләр

1905—1907 еллар вакыйгалары эшче һәм хезмәт ияләренең күзләрен ачты, яшьләрнең күңелләрен җилкендерде. Без канатланып киттек. Барысын да күрергә, белергә ашкындык.

Матбугат мәйданы да иркенәеп китте. «Таң йолдызы», «Азат» һәм «Азат халык» исемендә татарча газеталар күренә башлады. «Ялт-йолт», «Чүкеч» кебек көлке журналлар туды. Оренбургтан «Урал» һәм «Вакыт» газеталары килде. Болар безгә тансык, без аларны йотлыга-йотлыга укый идек. Алар, кулдан-кулга йөртелә-йөртелә, теткәләнеп бетә иде. Болар арасында хуҗалар тарафыннан яздырыла торган «Тәрҗеман» исемле бер газета да бар иде. Ләкин без аның телен аңламый идек, аңлаган хәлдә дә, ул безнең иркенлеккә омтылган җаннарыбызга азык бирми иде.

Тора-бара әдәби әсәрләр — хикәяләр, шигырьләр дә күренә башлады. Габдулла Тукай шигырьләрен күңелдән ятлап, көйгә салып, җырлап йөри идек. Без яшьләрнең ин яратып укыган газеталары «Урал» һәм «Азат халык» булды. Мин дә, бу гүзәл күтәрелештән калышмыйча, «Урал» газетасын берьюлы алты айга яздырган идем. Ләкин бу газетаны берничә ай чыгу белән туктаттылар. Патша реакциясенең ул газетаны ни өчен яптыруын мин соңыннан, үсә төшкәч кенә аңладым.

Безнең Пермь театры бинасында эшләп килгән рус труппасы бар иде, аннары ара-тирә һәвәскәрләр дә спектакльләр куйгалыйлар иде. Без, татар яшьләре, бу спектакльләргә, әти-әниләребездән яшеренеп (анда да кайберләребез генә) йөри идек. Мин үзем бигрәк тә чит шәһәрләрдән килгән артистларның уеннарын калдырмаска тырыша идем. Әле яшь вакытымда ук миңа Островский, Гоголь, Мольер әсәрләрен күрергә туры килде.

Озак та үтмәде, газеталарда шундый бер хәбәр күренде: Оренбург шәһәрендә Ильяс Кудашев-Ашказарский дигән кеше Островскийның «В чужом пиру похмелье» дигән әсәрен татарчалаштырып, «Галимнәр һәм наданнар» исемендә сәхнәгә куяр өчен яшьләрне оештырган. Хәтта афишалар да тараткан. Ләкин бу уен, муллаларның, байларның каршылыгы, губернаторның рөхсәт бирмәве сәбәпле, уйналмыйча калган. (Бу хәбәр «Вакыт» газетасының 1906 ел, 20 нче санында басылды.)

Күп тә үтмәде, 1906 елның 21 апрелендә, Уфада, приказчиклар клубында, яшьләр тарафыннан театр куелуы турында хәбәр килде. Ләкин болар әле һәвәскәрләр уены гына иде, аларны, әлбәттә, нинди дә булса бер профессиональ театр дияргә мөмкин түгел иде. Шул елны 5 майда Казанда, приказчиклар клубы сәхнәсендә, Гафур Колахметов, Галиәсгар Камалларның катнашы белән, «Гыйшык бәласе» һәм «Кызганыч бала» исемле әсәрләр куела. Үзәк шәһәрләрдән читтә яшәүче без, һәвәскәрләр, татар театрының тууын ишеткәч, куанып кына калмыйча, үзебез дә шундый гүзәл эшләрне оештыруга керештек.

Без уйнаган уеннар баштарак һич тә театр уенына охшамый иде. Моның күбесе каз өмәләренә җыелган кызлар янында яки аулак өйләрдә гармон, скрипка, мандолина уйнап, җырлап-биеп утырудан гыйбарәт иде. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк: бу утырулар искечә аулак өйләрдән бик нык аерыла иде, без бирелә шигырьләр сөйлибез, театр китапларын укыйбыз. Чигү чигеп яки башка кул эшләре эшләп утырган хатын-кызлар да безне яратып тыңлыйлар. Кайбер вакытларда бу кичәләргә, бу утыруларга ирле-хатынлы өлкән яшьтәгеләр дә җыелалар. Хатын-кызларның күбесе, күршe бүлмәләргә урнашып, безне ишек артыннан гына күзәтәләр.

Озак та үтми, без «Сәйяр» исемендәге шәһәрдән шәһәргә күчеп йөри торган артистлар труппасы оештырылуын ишеттек. Труппа Оренбургта «Галимнәр һәм наданнар» исемле пьесаны сәхнәгә куйган. Оренбургтан Бозаулыкка, аннан Самарага, Сембергә, Сембердән Казанга килеп «Аркадия» бакчасында берничә спектакль куячак икән. Казаннан Чистайга, аннан пароходка утырып Мәкәрҗә ярминкәсенә, Мәкәрҗәдән Мәскәүгә китәчәкләр икән... Хәерле юл!..

Бер көнне кулыбызга бер театр китабы килеп төште. Исеме «Казанга сәяхәт» — һәркемне җилкендерерлек исем. Казанга кемнең генә барасы килми икән! Китапны укып чыктык. Әсәрнең баш герое Гата байның Казанда күргән мажаралары безгә бик ошады. Мондый томана, кара байлар безнең Пермьда да җитәрлек. Сәхнәгә чыгып

шуларны хур итсәң, ничек яхшы буласы. Халыкның күзен ачуда да кечкенә генә булса да бер хезмәтебез булыр иде. Пьесаның безгә кулай икенче ягы да бар иде: нибары ике хатын-кыз катнаша: берсе яучы карчык, икенчесе аш пешерүче хатын, сүзләре дә күп түгел. Безнең Әхәт Вәлиев дигән егетебез гел карчыклар булып кыланырга ярата иде. Карчык белән аш пешерүче хатын сәхнәгә берьюлы кермәгәнлектән, ул аларның икесен дә бер үзе башкарып чыга алачак. Аннары әсәрдә, гомумән, бер кешегә икешәр роль уйнап чыгу мөмкинлеге бар. Чөнки алар сәхнәгә берәм-берәм кереп чыгучылар. Шуннан соң без рольләрне бүлештек. Миңа Хәйрүч белән Мәҗит хәлфә роле булды. Болар өстенә, тагын мин кичәне оештыру, ягъни администраторлык ягын да үз өстемә алдым. Ачык әйтергә кирәк, бу эшне үз өстемә йөкләп, башыма бәла генә алган икәнмен. Театр кую уен эш түгел икән! Аны кую өчен бина табу артыннан йөреп карасагыз иде сез!

Йөри торгач, Городской театр бинасында көндез уйнарга рөхсәт иттеләр. Ләкин полицеймейстердан аерым рөхсәт китерүне шарт итеп куйдылар. Без: «Вакыты җиткәч, анысын да алырбыз әле!» дип, җиң сызганып әзерләнергә тотындык. Җыела торгач, ун кешегә җиттек. Минем туган Салих абый режиссер сыман кеше булып алды. Агалы-энеле Хәйретдин белән Нуретдин Хәнҗаровлар: беренчесе маклер Сафаны, икенчесе хезмәтче Габдрахман белән Бәһман рольләрен башкарачаклар. Пьесадагы иң зур рольне — Гата байны — Шиһап Бәһаветдинов уйный; чөнки ул болай да коеп куйган бай! Насыйбулла Чикинга, гәүдәсе озын булганга, Һинди белән Вәлине уйнарга куштык. Безнеңчә, бу кешеләр, нәкъ менә шулай, озын булырга тиешләр иде. Фатих Юсупов суфлер булды.

Хәзер инде киемнәр юнәштерергә, афишалар чыгарырга кирәк иде... Ләкин көтелмәгән бәла аяк астыннан килеп чыкты. Полицеймейстерга рөхсәт сорап барган идек, ул: «Китабыгызның өстендә Петербург цензурасының печате сугылмаган булса, сәхнәдә уйнарга рөхсәт итә алмыйм»,— дип, кырт кисте.

Кая инде ул безгә Петербургтан рөхсәт алу! Бик күп талкынулардан соң, Казанга хатлар язып, афишалар соратып, шунын өстенә тагы, Казан полицеймейстерыннан пьесаның Казанда куелганлыгын раслаган телеграмма да алуга ирешкәннән соң гына, Пермь начальствосы бер мәртәбә уйнарга рөхсәт бирде. Бу рөхсәт алуның мәшәкатьләре Казанга сәяхәт кылып кайтудан да озакка сузылды — без инде бөтенләй өметебезне өзгән идек.

Ничек булса булды, башыбызга төшкән мең төрле бәлаләрне ерып чыктык. Пермьда шәһәр театры сәхнәсендә беренче мәртәбә татарча спектакль куюга ирештек. Бу хәл 1908—09 елның кыш урталарында иде.

Тамашачылар артык күп түгел иде. Акчага билет алып керүче алтмыш-җитмеш кешегә тагы уйнаучыларның егермеләп белеш-танышларын кушсаң — барлыгы 80—90 кеше булды. Уйнаучылар арасында бер генә хатын-кыз да булмаган кебек, караучылар арасында да дүрт-биш кенә хатын-кыз утырды. Аларның да икесе минем кыз кардәшләрем иде. Һәм аларны, ирләрдән яшереп, ложаның чаршауларын төшереп, аерым утыртырга туры килде. Шунысы бик аяныч: җыелган акча расходларны да капларга җитмәде.

Спектакль бик тыныч һәм шома үтсә дә, җиле-бураны соңыннан купты.

Шәһәрнең ахун хәзрәте Нурулла Хәйрелзаманов, мәчеттә вәгазь сөйләгәндә, безнең тетмәбезне теткән:

— ...Әлгаязе биллаһи, кыямәт шушы инде ул, җәмәгать! Олуг могътәбәр кешеләребезне мәсхәрә кылалар. Шайтани уеннар корып, динемезне рисвай итәләр! Бу — падишаһ әгъзам хәзрәтләренә, хуҗаларыбызга буйсынмау!..

Үз кул астындагы хезмәтчеләрнең, приказчикларның буйсынмый башлавыннан иза чиккән байлар, ахун хәзрәтнең бу вәгазеннән соң, кабарынып киттеләр, театр уенында катнашканнарны эштән куарга тотындылар.

Әле дә ярый, без афишаларда уенга катнашучыларның чын исем фамилияләрен язмаган идек. Бары тик, җитәкчеләр буларак, абыйны Ханов, мине Аитов дип язып чыгардык. Сакал-мыек ябыштырып, кулдан килгәнчә грим ясап кыяфәтләрен үзгәртеп сәхнәгә чыккан артистларны гомерендә беренче тапкыр театр күргән тамашачылар, әлбәттә, таный алмаганнар. Танылсак та — абый белән мин генә танылганмындыр.



Л. Аитов Хәйруч ролендә.

Чөнки безнең рольләр дә шундый иде, киемнәрне дә, кәяфәтләрне дә үзгәртергә туры килмәде.

Уртача буйлы, кап-кара кәҗә сакаллы, тап-такыр башлы, болай да акаеп торган күзләренә һәркайчан хаҗ сөрмәсе тартып йөри торган Нурулла ахун, вәгазь сөйләү белән генә канәгатьләнеп калмыйча, Пермьның иң зур бае Ибраһим хаҗи Тимкиннарга барып чыга. Ул театрны без оештырганны кемнәндер белеп алган була. Әгәр теләсә, ул этинең үзен чакыртып та алган булыр иде, юк, ул алай эшләми, ул безгә каршы бөтен шәһәр байларын күтәрергә тели.

Нурулла ахун озаклап дога кылганнан соң, байның хәл-әхвәлен сораша, шуннан шәһәрдәге соңгы вакыйгаларга күчә:

— ...Теге Мөхәммәтханны әйтәм әле, балаларына рәтле тәрбия бирә алмаган икән. Итсә юньле сәүдә итә белмәде... Инде менә, алла рәхмәтендә кылсын, хатыны да үлеп китте, мондый азгын малайлары белән нишләр икән инде ул? — дип ярсый.

Мәчеткә дә ат җиктереп бара торган бу кыска аяклы, алап корсаклы, намазны җыелмалы тәбәнәк урындыкка утырып укучы карсак Ибраһим хаҗи, өеннән күп чыгып йөрмәсә дә, безнең эшләр турында шактый хәбәр ишеткән була.

— Ишеттем, ишеттем, хәзрәт,— ди хаҗи,— ул каферләр безнең хезмәтчеләрне генә аздырып калмаганнар, динне хурлап, без тәһарәт ала торган ләгән-комганнарны дисеңме... алай гынамы, үз аталары Мөхәммәтханның мәсехле читек-кәвешләрен, кәләпүш-бүрекләрен, казакиларын киеп чыгып кәмит күрсәткәннәр.

Әйе, болар бар да нәкъ Ибраһим хаҗи сөйләгәнчә булган иде: этинең намазга гына кия торган киемнәрен, ләгән-комганнарны, хәтта самоварны да өйдән без яшереп ташыган идек. Өстәвенә, Гата бай ролендә уйнаучы болай да буй-сыны белән этигә охшашлы Шиһап Баһаветдинов, эти киемнәрен киенеп алгач, анык шикелле ак көрәк сакал да ябыштыргач, коеп куйган этигә әйләнгән иде. Моның шулай булып чыкканын күргәч, абый белән икәүләшеп әчебез катканчы көлгән дә идек. Ләкин, көлке көлә килер дигәндәй, безнең өчен бу куанычларның ахыры бик көенечле булды...

Нурулла ахун коткысыннан ачуы чыккан Тимкин бай шул көнне үк этине үз янына чакырта да эттән алып, эткә салып сүгә:

— Синең каһәр төшкән малайларың аркасында улларым, приказчикларым юлдан язды. Нинди инсафлы Касыймым белән Хафизым синең шайтаннарыңның котырыгы белән гөнаһ ясаганнар, кәмит карап йөргәннәр... Алла сакласын, ахун хәзрәтнең бәддогасына юлыгырбыз. Тый малайларыңны! — ди.

Бу вакытларда этинең сәүдә эшләре чыгырыннан чыгып, муеннан бурычка да баткан көннәре иде. Ахун хәзрәтнең дә, Ибраһим хаҗиның да безнең аркада янаулары эти өчен чүп өстенә чүмәлә булды. Безне тотып тиргәү, ара-тирә кабыргаларыбызны санау белән генә эш чыкмасын белгән эти, ахыр чиктә, безне өйдән куып чыгарырга мәҗбүр булды: «Барыгыз, гомерегез кәмитче булып үтсен!» диде ул безгә.

*(Дәвамы бар.)*

## СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Һәрбер эше аның бер вакыйга,
Исем китә минем Вакыйга.

С. ХӘКИМ.

# ГАҖӘП ҺӘЙКӘЛ САЛА

Чәчәкләр! Нур өстенә нур өстәүче, шыксыз бүлмәгә дә җан кертүче чәчәкләргә без тумыштан гашыйк. Әгәр дә өстәл күрке гәлсәр вазага утыргач терелә белгән ул чәчәкләр телгә дә килсәләр, шулай диярләр иде:

— И хөрмәтле Кеше! Миңа булган мәхәббәтеңне иябез бакчачы белән дә бүлеш син. Безне назлап үстерүче һәм бөтен нәфислегебезне саклап синең кулыңа тапшыручы шул бит...

Кайгырганда юандыра, сөенгәндә куандыра торган таныш симфония... Кеше телендә сөйли белсәләр, алар композиторның без ишетә алмаган күңел серләрен дә ачар иделәр.

Ә ташлар... һәйкәлләр...

Муса Җәлил исемен йөрткән опера һәм балет театрына килүчеләр дәһшәтле җыры белән фашист төрмәләрен дер селкеткән шагыйрьнең мәрмәр бюсте каршында тәэсирләнеп торалар.

— Исәнме, Җәлил!

— Хәтерлим бит мин сине, Муса дус. Син бу! Синең тормышың, үлемсез җырларың, якты истәлегең бу!

— Муса Җәлил абый, син ич бу. «Туган тел» китабымдагы рәсемеңә ошатып таныдым.

Әгәр дә бюст шунда телгә килсә:

— Мин башта таш идем. Скульптор мастерскоенда бюстка әйлән-



Скульптор Муса бюстын ясаганда.

дем. Аның тылсымлы кулы миңа әлеге кыяфәтемне бирде, үзенең шигъри җанын өстәде. Менә хәзер күрәсез, таныйсыз — мин мәрмәр генә түгелмен, мин хәзер Җәлил һәм Бакый,— дияр иде.

Әйе, ташлар да сөйли беләләр. Сөйләү генә түгел, дәшәләр, җырлыйлар алар. Аларда — скульптор белән һәйкәл иясе тапкан уртак тел, теләсә кайсы заманда теләсә кайсы милләткә аңлаешлы Кеше теле — сәнгать теле.

Әнә алар үлми торган чын кешеләр. Аларны китаплар терелтә, истәлекләр яшәртә, һәйкәлләр яшәтә. Меңнәргә кардәш, меңнәргә сердәш мәрмәр Тукай. Могҗизалар корифее, легендар галим Әбугалисина. Тугандаш әдипләр остазы Абай... һәм тагын таштан коелган, күңелдә уелган бик күп исемнәр — сәхнә йолдызлары, заман маяклары, каләм мастерлары.



Г. Тукай (мәрмәр).

Сәнгать остасы Бакый Урманчы аларның һәрберсен үзенең җаны белән сугарган, күңел яктысын төшергән. Ә без, еш кына, шул истәлекләргә баш игәндә, аларның ташлыгын онытkан кебек, әнә шул остаsucc да искәрмибез.

Әйдәгез, ул койган бюстлар, ул ясаган рәсемнәр, ул иҗат иткән паннолар эзеннән, аның үз сукмагына төшик, бу юлы иҗат галлереясына түгел, авторның шигъри күңеленә сәяхәт ясыйк.

Кешеләр никадәр тирәнрәк булсалар, шулкадәр гадиерәк тә булалар икән. Гади кешенең эчке балкышы бар. Андыйларны ерактан күрәләр, әллә кайдан таныйлар. Бакый Урманчы әнә шул кешеләр төреннән. Күп йөргән, күпне күргән, күп эшләгән кеше ул. Ул үткән маршрутны километрлап түгел, меридианнар, параллельләр белән үлчәрлек. Татарстанның читән капкалы караңгы бер авылыннан чыккан сукмак бөтен Россияне иңләгән, Европаны буйлаган, Азияне ураган.



Ш. Бабич (гипс).

Яшьли нужа күргән кешеләрнең тормышта үз учаклары, үз сукмаклары була. Бакый ага учакның сүрелмәсен яккан, сукмакның өзелмәсен тапкан. Аның җылысы ул тәрбияләгән сәнгать сөючеләр күңелендә, аның эзләре ул яшәгән шәһәрләр музеенда. Мәскәү, Алма-Ата, Казан, Ташкент, Сәмарканд, Балхаш, Байконур — Урманчыны үз иткән, Урманчыны художник иткән тугандаш калалар. Художник өчен күпне күрү генә җитми, күпне белергә дә кирәк.

«Художник — һәм тарихчы, һәм шагыйрь, һәм философ, һәм күзәтче... һәм ул шулай да. Бөек художниклар барысы да галим булганнар»,— ди И. А. Бестужев.

Сәнгать әһелләренә әйтелгән бу

юлларны укыгач, уйга каласың. Кем белә, мәдрәсә һәфтияген кимергән, соңыннан «мәшһүр» Мөхәммәдиягә үрелгән фәсле шәкертне юлга, бәлки, шул фикерләр әйдәгәндер.

Миллионнар бәхетеннән канатланыр чакта купкан Октябрь дулкыны Бакыйлар карабын иркен океанга алып чыга, кулларына компас бирә, хөрлек җиле яшьләрне гел алга, гел яктыга өнди, хыялларына канат бирә.

Башта Казан художество училищесы, аннан Мәскәү. Югары дәүләт мастерское, Көнчыгыш телләр институты. Заманның атаклы художникларыннан алган сабаклар һәм әчесен-төчесен таныткан, яшәргә, көрәшергә өйрәткән тормыш мәктәбе — тормыш академиясе... Әнә шул күк күкрәүле, яшен яшьнәүле тормыш сукмагыннан янәшә атлаучы, уйларын аңлаучы, шатлыгын уртаклашучы, кайгысын кичерешүче акыллы, сабыр Сарасы...



Г. Ибраһимов (агач).

Бай, Бакый Урманчы бик бай. Тумыштангы бер өлеш сәләткә өстәлгән мең өлеш хезмәт аны шулай баеткандыр. Кешенең гыйлем көзгесе — акыллы фикере, уе, эрудициясе, ә аларның шәүләсе — укып белгәне, китапханәсе. Фатирның ярым стенасы сүзлек китаплардан түшәлгән. Ә калганнары — Тукай, Шолом, Гейнс, Айни, Байрон, Есенин һәм йөзләрнең томнары.

Язу өстәлендә «Дейли уоркер», «Юманите», «Социалистик Татарстан». Урманчыга тылмач кирәкми. Назимны төрекчә, Шекспирны инглизчә, Анатольне французча укый ул. Дәлилләрең күп булса да, чамалап бәхәсләш аның белән, җиңелүең ихтимал. Сөйләшкәндә уйлап сөйләш, җөмләң дерес, сүзең үткен булсын. Телне бик ярата Бакый ага.

Тарихи үткәннәр, чамасыз озын сукмаклар, актарган томнар, шуның өстенә күпме онытылмас истәлекләр. Я, хәзерге художниклар арасыннан Тукайны күреп белгән кем бар дисең? Бакый бар. Фатих Әмирханны кем хәтерли? Бакый Урманчы яхшы хәтерли. Кайчандыр Мәскәүдә татарча чыккан «Комсомол» газетасының әдәби хезмәткәрләре кемнәрдер дисең? Бакый белән Муса. Шагыйрь белән художник уртак сүз тапмаганнардыр дисезмени? Габдулла Кариев, Галиәсгар Камал, Шәриф Камалны бүгенгедәй күз алдында тота ул. Атаклы казакъ язучысы академик Мохтар Ауэзовның дуслары күп булгандыр, шуларның берсе Бакый Урманчы. Орденлы Җамбулны каршына утыртып портретын да ясаган ул. Кәрим Тинчурин белән якын бәйләнештә яшәгән художник.

— Дәрдмәнднең карашы моңлы иде. Рәсемен ясаганда гел шул күз алдымда торды, — ди Бакый ага.

...Эх, шул һадиның тәэсирләнеп шигырь укулары... Минем аны шундый итеп ясыйсым килә ки, шагыйрьнең мөлаем ак йөзе, шигъри зур күзләре, акыллы карашы, бөтен кыяфәте безгә, космос чоры вәкилләренә, ялкынланып «Киләчәккә хатлар»ын укып торсын иде...

— Бик җитди иде Галимҗан ага, — дип дәвам итә Б. Урманчы. — Бу яшьрәк, шүрләмәсен, бу картрак, хәтере калыр диючеләрдән түгел иде ул. Яшеңә, белемеңә, һөнәреңә, дәрәҗәңә карамас, күзеңә карап туры әйтер иде. Галим иде, сәнгатьне ярата, бәяли белә иде. Бер чакны шулай артык таләпчәнлеге белән үпкәләткәне дә бар үземне. Шулай кирәк булган. Таләпнең гаделлегенә еллар үткәч төшендем... Бик акыллы сабак биргән ул. Мин Галимҗан Ибраһимовны иҗат иткәндә, аның әнә шул тирәнлеген, кыюлыгын, тугрылыгын бирәсем килде.

Мираска бөтен тормышын, мәхәббәтен калдырган, ә сурәтен калдырмаган тарихи шәхесләрне күпме «терелтергә» туры килгән аңа. Телсез ак ташка, җансыз соры кин-

дергә «бу — көнчыгышның бөек галиме Олугбәк», «бу — дастанлы Колгали», «бу — мәгърифәтче Насыйри», «бу — Салават» дип әйттерү өчен күпме тир түгелгәндер.

— Иң җаваплысы, иң катлаулысы Ленин образын тудыру булды, — ди скульптор, үзара сөйләшкәндә.— Ул бит миллионнар күңеленә сеңгән образ. Ул бит замандашларыныкы гына түгел, туган һәм туачак һәр сабыйның таный башлаячак беренче сурәте.

Без сөекле юлбашчының мәрмәр бюсте янында.

— Сөекле юлбашчы!

Аңа шулай дәшерләр, шулай дәшәләр. Бюстка багышланган беренче рецензияләр. Аларны Ленинны күреп белгән замандашлары язган:

«Хөрмәтле художник! Мин бүген сезнең зур хезмәтегез — бөек Ленин бюсте белән таныштым.

Тәэсирем бик шәп!

Мин Владимир Ильич белән очрашкан һәм берничә мәртәбә очрашкан кеше: киңәшмәләрдә, митингларда, съездларда һәм эш вакытында... Әйтергә кирәк, художник буларак, юлбашчының иң характерлы сызыкларын — акыл куәтен, үз эшенә тирән ышанганлыгын, тыйнаклыгын һәм шул ук вакытта гадәти булмаган сөйкемлелеген зур осталык белән чагылдыра алгансыз.

Микъдәт Брундуков. 1964 ел. 20 август».

«...Мин бүген синдә Ленин белән очраштым. Әйе, бу чын Ленин, бу — бөек юлбашчы. Мин аны күп мәртәбәләр якыннан күрү бәхетенә ирешкән кеше. 1919 ел. VI Бөтенроссия Советлары съезды бара иде. Съездның башыннан ахырына кадәр Ильичның бөтен хәрәкәтен җентекләп карап тордым. Бу бер. Шул ук елны Бөтен шәрык Коммунистларының II съездында тагын күрдем. Бу ике. Аннан соң ВЦИКның Кызыл шәрык агитпоездын Төркстанга озатканда, поездның комиссары Г. И. Сафаров белән иптәш Ленинның үз янына кереп инструкция алдык. Бу өч. Сез ясаган бюст минем әнә шул өч мәртәбә якыннан һәм мең мәртәбә рәсемнәрдә, киноларда күргән В. И. Ленинның нәкъ үзе.

М. Бәдәйли».

Бакый агадан еш кына «сез кем соң?» дип сорыйлар.

— Скульптор булам, — ди ул.

— Ә иҗатыгызның яртысын тәшкил иткән рәсем сәнгатен, каләмегез туктаусыз уйнаган графика, декоратив һәм декорацион театраль әсәрләрегезне кая куясыз?

— Бер генә тармактан үрмәләү, бер генә юл тоту, әлбәттә, ераккарак алып китә, теләгән максатыңа иртәрәк ирешәсең, ә менә шул алган юлыңа сукмаклар да кушсаң, акрынрак атласаң да, юлың киңрәк була, эзең тирәнрәк кала.

Әнә шундый сукмакларга бай, диңгезләр кичешле, күперләр атлашлы олы юлдан бара Бакый Урманчы.

— Мин юллар яратам, — ди ул үзе дә, — никадәр атласам да армыйм. Миңа диңгез шавы ишетелеп торсын, шуны никадәр тыңласам да туймыйм. Мин чәчәкләр яратам, әгәр ике гомерем булса, шуның яртысын чәчәкләр ясап үткәрер идем.

Чү! Художникның кичжеле татар сөлгеләре эленгән, «агач җен-парилар» иялэшкән, үз сүзләре белән әйткәндә «остахана»гә охшаш фатирында мин могҗиза күрдем. Нагышлы ашъяулык япкан тәбәнәк түрек өстәлендә Себер умырзаясы — богуля! Ул — чәчәктә. Тышта чатнама салкын, ә бүлмәдә яз, кырыс Себер язы! Ун мең чакрымнан корымый кайткан эрсез ботаклар, Идел суын авыз иткәч, яңадан яңарганнар — башта чеметем-чеметем алсу чәчәкка төренгәннәр, аннан ямь-яшел вак-вак яфрак ярганнар. Мин шул чакта Байкал күзендә тамыр җәя, Татарстан кышында чәчәк ата алган, үзе талымсыз, үзе нәфис, үзе гомерле шушы агачны художникның тынгысыз тормышына ошаттым. Унҗиденче күздә шытып чыккан Октябрь умырзаясы алтмыш алтынчы язны да чәчәктә каршылый. Тәгаллисе эшләре, башланган гына эшләре, башлаячак эшләре бик күп, бик күп әле Бакый аганың. Аның иҗаты һаман чәчәктә.

*Диләрә ЗӨБӘЕРОВА.*

# БОРЫНГЫ ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫ ӨЙРӘНҮНЕҢ ӨЛГЕРГӘН ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Татар әдәбиятының үткәндәге тарихына бәйләнешле күп яклары инде ачыклана бара. Бигрәк тә XIX йөзнең башларыннан алып, безнең көннәргә кадәр булган ара шактый өйрәнелгән. Егерменче елларда борынгы әдәбиятыбызны фәнни тикшерү, өйрәнү эшенә Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Газиз һәм Г. Рәхим кебек әдәбият белгечләре күп көч куйдылар. М. Гайнуллинның XIX һәм XX йөз башы әдәбияты буенча дәреслекләре, Г. Халит, Х. Хисмәтуллин һәм Б. Гыйззәтләр тарафыннан язылган «XX йөз башындагы татар әдәбияты», И. Нуруллинның шул чор әдәбияты буенча тикшеренүләре әһәмиятле хезмәтләрдән санала. Ул хезмәтләргә шул дәвернең күп язучылары кертелгән, иҗатларына төрле яклап анализ ясалган һәм әдәбиятыбызның үсү юлында урыны билгеләнгән.

XIX йөз башларына кадәр яшәгән аерым язучыларның әсәрләре дә билгеле бер күләмдә өйрәнелгән инде. Бу өлкәдә Б. Яфаровның «X—XIV йөзләрдә Кама-Волга болгарлары әдәбияты һәм «Нәһҗел-фәрадис» (1950 ел), Ү. Беляеваның «Габдерахим Утыз Имәни иҗаты» (1953 ел) дигән фәнни хезмәтләре мәгълүм. СССР Фәннәр академиясенең Азия халыклары институты сотруднигы, танылган тюрколог Ә. Нәҗип татар әдәбиятының XIV йөзләргә караган аерым язма истәлекләре турындагы эзләнүләрен бастырды. Соңгы вакытларда ул Сәйф Сараиның «Гөлстан»ы турында зур хезмәт язып бетерде. Шул ук әсәр өстендә филология фәннәре докторы, профессор Х. Госман да эзләнүләр алып бара һәм аны бастырып чыгару чараларын күрә. Җ. Алмазов XIV йөз кыпчак-татар шагыйре Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан» дастанын әзерләп, матбугатка тапшырды һәм әдәбиятыбызның иң борынгы истәлеге — Галинең «Кыйссаи Юсеф» («Йосыф вә Зөләйха») поэмасы турындагы зур хезмәтен төгәлләп килә. Ниһаять, 1964 елда Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы сотрудниклары тарафыннан язылган «Борынгы татар әдәбияты» дөньяга чыкты.

Күрәсез, әдәби мирасыбызны барлау, өйрәнү юлында шактый эш башкарылган. Шулай да безгә тынычланырга, борынгы әдәбиятыбызны өйрәнүне игътибар үзәгеннән төшерергә бик иртә әле. Беренчедән, әдәби мирасыбызны бик нык тулыландырасы бар, икенчедән, борынгы әдәбият турында моңарчы язылган, әйтелгән күп фикерләрне яңадан карап, дөресләп чыгарга кирәк. Татар халкының культурасы һәм әдәбияты үзенең үсешендә катлаулы юл үткән. Ханнар, патшалар, руханилар, байлар кысуы астында хезмәт кешесе ирек, бәхет турында хыялланган, изүчеләргә нәфрәт тойгылары белдергән. Шул изге омтылышларын ул фольклорда, язма әсәрләрдә чагылдырган. Хаким сыйныфларның кешене кимсетә торган эгоистлык әхлак таләпләренә ул хезмәт кешесен зурлый торган мораль принципларын каршы куйган. Болар барысы да ул заман язучыларының иҗатында теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш тапкан. Әлбәттә, урта гасырлар әдәбияты, андагы язучыларның иҗатлары гаять катлаулы һәм каршылыклы. Без, әдәбиятчылар, аның катлаулылыгын, каршылыклы булуын һәрвакытта да искә алып җиткермәдек.

Борынгы әдәбиятны тикшерүдә шактый киң таралган берьяклы, ялгыш карашларның берсе шуннан гыйбарәт: күп кенә хезмәтләрдә үткән мирас бербөтен итеп каралды, аерым әсәрләр һәм аерым язучылар иҗаты арасындагы сыйнфый аерымлыклар күрсәтелмәде. Шунлыктан Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Утыз Имәни кебек шагыйрьләрнең иҗатлары берьяклы бәяләнде. Аерым әдәби истәлекләрдәге халыкчанлык тенденцияләре инкарь ителде, яисә куперетелеп күрсәтелде. Партия Үзәк Комитетының 1944 ел 9 август карары татар халкы тарихын өйрәнүдәге андый ялгышларны вакытында төзәтергә ярдәм итте.

Борынгы татар әдәбиятын өйрәнгәндә, аны халыкның билгеле бер тарихи чорлардагы социаль җирлегеннән аеру, татар әдәбиятын гомуми төрки яисә госманлы, чыгтай әдәбияты төшенчәсе астында йөртү кебек ялгыш карашларның да зыяны шактый күп булды. Мондый карашның нәтиҗәсе буларак, халыкның үз арасыннан чыккан язучыларының оригиналь иҗаты танылмады, булган әдәби истәлекләр читтән кергән һәм күчермә (тәрҗемә) әсәрләр хисабына кайтарып калдырылды.

Борынгы гарәп, фарсы-таҗик һәм Урта

Азия халыклары әдәбиятында бары ислам идеологиясен генә күрү ул дәвер татар әдәбияты да дини-мистик идеяләр белән генә сугарылган диган ялгыш, фәнни булмаган карашка китерде.

Шуңа күрә дә, татар әдәбиятының элеккеге күп кенә яклары бөтенләй өйрәнелмәде һәм әдәбиятны борынгы заманнардан башлап чорларга бүлүдә дә төрле карашлар яшәп килде. Г. Ибраһимов һәм Г. Сәгъди кебек зур галимнәр дә татар әдәбиятының башлангычы итеп XVI йөзне күрсәттеләр. Аңа кадәр булган болгар-кыпчак дәверен инкарь итмәсәләр дә, ул вакытларда алар кулында шул әдәбиятныкы диган язма истәлекләр әле табылмаган яисә бик аз иделәр. Тик 40 нчы еллардан башлап, әдәбиятны чорларга бүлү мәсьәләсенә җитди караш күренә, әдәбиятыбызның тарихын чорларга бүлгәндә нигез итеп экономик формацияләр алына башлый. Формацияләр исә үз нәүбәтендә тагын да төрле дәверләргә бүленәләр. Чөнки җәмгыятьтәге иҗтимагый-әдәби процесслар һәм аларның үзенчәлекле үсү закончалыклары иҗтимагый формацияләрнең кысалары белән генә чикләнмәскә дә мөмкин. Димәк, әдәбиятны чорларга бүлгәндә аны тудыручы халыкның язмышы, әдәбиятның үзенчәлеге, җәмгыятьтәге үсү этаплары белән дә хисаплашырга туры килә.

Әдәбият тарихын дәверләргә бүлгәндә аның аерым этапларында барлыкка килгән язма истәлекләре турында да сөйләргә кирәк. Мәсәлән, болгар-кыпчак (татар) әдәбиятының XIII—XIV йөзләр дәверендә «Мәхәббәт-намә» «Җөмҗөмә солтан», «Дастаны Бабахан», «Нәһҗел-фәрадис» кебек зур күләмле әсәрләр язылган. Низаминың «Хөсрәү вә Ширин»ы, Сәгъдинең «Гөлстан»ы Котыб һәм Сәйф Сараи кебек шагыйрьләр тарафыннан Идел буе төрки әдәби телгә — иске татар әдәби теленә тәрҗемә ителгәннәр. «Нәһҗел-фәрадис» әсәренең авторы үзенең исеменә «Болгари» диган әдәби кушамат—тәхәллусны өсти. Хисам Кятип һәм Бәркә Фәкыйһ үзләрен турыдан-туры кыпчаклардан саныйлар һәм әсәрләренең кыпчак телендә язылуын әйтәләр. «Казан татар әдәби теле, Казан татар сөйләм диалекты белән берлектә, XI—XIV йөзләрдәге кыпчак теле белән дәвам иттерелә килгән үзенең бәйләнешен хәзергә кадәр тулы килеш ачык саклый»[1], дип язды А. Самойлович. Хәзерге күренекле тюркологлардан А. Боровков, Н. Баскаков, Ә. Нәҗип кебек галимнәр дә татар теленең кыпчакча тел икәнлеген күрсәтәләр. Соңга таба да, XV—XVI йөзләрдә, без шул ук әдәбиятның һәм телнең яңа шартларда үзенчәлекле дәвам иткәнен күрәбез. Мәсәлән, шагыйрь Мөхәммәдъяр әсәрләре һәм аның теле—бөтен грамматик, морфологик, стиль үзенчәлекләре белән болгар-кыпчак теле.

Димәк, XIII—XIV йөзләрдә Идел буенда кыпчак теле нигезендә формалашкан әдәби тел татарның «иске әдәби теле» булып тора. Шул телдә иҗат ителгән язма истәлекләр татар әдәбиятының аерым дәверен тәшкил итәләр.

Борынгы дәвер татар әдәбияты ядкярлары һәм аның хәл ителмәгән яклары турында сөйләгәндә «төрки тел» мәсьәләсе хакында да әйтми булмый. Гадәттә, «төрки тел» — күп төрле халыкларның билгеле бер дәверләге уртак әдәби телләре диелә. Чөнки ул, нигездә, татарына, төркмән һәм үзбәгенә дә, кыргыз-казагына, әзербайҗан һәм башкортына да аңлашылган. Әмма бу — мәсьәләнең бер генә ягы. Аның икенче ягы — билгеле өлкәләрдә яшәгән җирле төрки халыкларның шул төрки телне үзләренең конкрет сүзлек материаллары нигезендә баетулары һәм үстерүләре. Монысы инде төп һәм хәлиткеч фактор. Шуңа күрә дә, безнеңчә, Урта Азия төрки (чыгтай) теле белән шул вакыттагы Идел буе төркисен (болгар-кыпчак телен) бер үк нәрсә иттереп карап булмый. Нәваи язган төрки (чыгтай) телен үзбәкләр «иске үзбәк әдәби (китап) теле» итеп карыйлар икән, бу дөрес. Шул заманның Казан шагыйре Мөхәммәдъяр үз әсәрләрен төрки (нигездә болгар-кыпчак) телендә язам ди икән, ул да татарның шул чордагы иске әдәби (китап) теле булып тора, монда да каршылык юк. Әмма соңгы вакытлардагы татар телен үткәндәге «төрки» исеме белән йөртелгән шул үк халыкның уртак әдәби (дөресрәге китап) теленә каршы куюю очраклары күренә.

Р. Бикмөхәммәтовның «Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре» диган әсәрендә: «Татар әдәби теле XIX гасырга кадәр төрки элементлары белән чуарланган иде» диелә (53 бит). Татар теле үзе төрки телләрнең берсе һәм иң алга киткәннәреннән. Аның «төрки элементлар» белән чуарланган булуы нидән гыйбарәт? Татар теленә алар каршы нәрсәме — болар бирледә ачыкланмый кала.

Әхнәф Харисов 1964—1965 елларда «Агыйдел» һәм «Шәрык йолдызы» журналларында «Үткәннәргә сәяхәтләр» диган мәкаләләр бастырды. Анда татарның әдәби истәлекләре, әдәби теле, төрки тел мәсьәләләре турында да сүз бара. Ул XX йөз башына кадәр татар халкының үзе аңлаша алырлык әдәби теле булмаган, тик төрки тел генә булган һәм «без татар телендә басылган китапларны да белмибез» дип яза («Агыйдел, 1964, № 8, 83 бит). Ә. Харисов Дәрдмәнднең «Яңгыр» шигыреннән:

Көн кызды, кызды һава монарланып,
Сагымлап кыр белән дала чобарланып.
Һава тымык—шылт итми!.. Кысылды тын:
Яңгыр көтә җирнең йөзе комарланып...
Күренде күк йөзендә кара болыт,
Болганып гайрәт белән ужарланып,—

диган юлларны китерә дә: «Шигырь татарча язылган, әмма ул татар укучысына өлешчә, ә башкорт укучысына тулысынча аңлашыла» — дип тә җибәрә хәтта («Агыйдел», 1964, № 3, 87 бит).

Дәрдмәнд бу шигырендә Оренбург, Урал татарлары телендәге урынчалыклардан файдаланып, табигать күренешләрен сокландыргыч осталык белән бирә. «Монарланып», «комарланып» кебек сүзләр, билгеле. башкорт сөйләмендә дә булырга мөмкин. Ләкин

[1] А. Самойлович. К истории крымско-татарского языка. ВНОТ. Рус телендә. 1927 ел, 7 сан, 27 бит.

моның белән шигырь татар телендә язылмаган исә «татар телендә язылса да, ул башка телдәге кешегә күбрәк аңлашыла» дияргә урын юк. Г. Тукайның «Китмибез!» шигырендә:

Ап-ачык бу бер җавaптыр, сүздә түгел, басмада:
Если лучше вам,
Туда сами пожальте, господа! —

дигән юлларда рус сүзләре бар икән, моңа карап кына шигырь татарча язылмаган яисә ул татар укучысына караганда рус укучысына яхшырак аңлашыла дип әйтү урынсыз булыр иде.

Һәрбер чорның үзенең әдәби (китап) теле була. Хаким сыйныфлар, руханилар китап телен гади халык теленнән ераклаштырырга, читләштерергә күпме генә тырышмасыннар, аның нигезен һәрвакыт халыкның җанлы сөйләм теле тәшкил иткән. Ул әдәби китап теленең вакыты белән һәм язучысына карап, гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланганлыгы да бәхәссез. Ләкин озын тарихлы һәм бай әдәби тәҗрибәләре белән яшәгән халыкның үткәндә «төрки» исеме белән йөртелгән әдәби, китап телен ниндидер бер катып калган һәм халыкка аңлашылмый торган «ясалма» тел итеп кенә карау дөрес булмас иде. Төрки халыкларның телләрендә уртаклыклар күп. Ләкин бу шул халыкларның барысы өчен дә ачыктан-ачык аңлашылган, абсолют саналган уртак булган тел дигән сүз түгел бит әле. Үткәндә язучының «төрки» телдә язам диюендә шул вакытта яшәгән теге яисә бу төрки халыкның (үзбәк, татар, әзербайҗан, төркмән, казакъ һ. б.) конкрет телен аңларга кирәктер. Күптән түгел доцент В. Хаковның «Татар әдәби теле буенча очерклар» дигән китабы басылып чыкты. Автор анда, элеккеге язма әдәби истәлекләргә таянып, кызыклы күзәтүләр ясый, татар әдәби теленең X—XIV йөзләрдә үк формалашуын күрсәтә һәм «борын-борыннан халык(ның) сөйләм телен чагылдырган, әдәби телнең сөйләм формасына якын торган — халык стилендә язылган әсәрләрнең дә зур урын тотканлыгы» хакында сөйли. Иске татар теле белән хәзерге әдәби тел арасында аерма зур, әлбәттә. Бу закончалыклы күренеш, чөнки һәрбер яңа чор җәмгыяте халык теленә, аның әдәби (китап) теленә зур үзгәрешләр алып килә.

Гомум «төрки тел», «төрки әдәбият» дигән сүзләр белән конкрет төрки халыкларының үткәндәге телен, әдәбиятын һәм рухи культура казанышларын күрмәскә тырышу — яңа караш түгел. Буржуаз милләтчеләр, пантюркистлар Октябрьга кадәр һәм аннан соң да «гомум төркилек» лозунгысын сөйрәп йөрделәр. «Гомум төркилек» идеясе үткән культураны бәяләүдә һәм аның үсеш юлларын билгеләүдә зур зыян китерде. Татар язучыларының әсәрләре «төрки тел», «гомум төрки әдәбият» төшенчәләре белән күмелә килде; барысы да конкрет җирлегеннән аерылган, ватаны, барлыкка китерүчесе билгеле булмаган ниндидер «гомум төрки» әдәбияты итеп каралды. Мондый карашларны пантюркистлар үзләренең явыз ниятләре өчен файдаландылар. Алар «гомум төркилектә» госманлы төрекләрен күз алда тоттылар һәм башка төрки халыкларны шул госманлы төрекләре кул астына каратып яшәтергә ниятләнделәр. Күренә ки, төрле фикерләр тудырган, хәтта ялгыш карашларга илткән гомум «төрки тел» дигән мәсьәлә «иске татар теленә» һәм аның үткәндәге әдәбиятына мөнәсәбәттә конкрет материаллар нигезендә фәнни хәл итүне сорый. Тел галимнәре, белгечләр бу хакта үзләренең фикерләрен әйтерләр.

Татар әдәбияты тарихын фәнни өйрәнү мөһим һәм җитди мәсьәләләрдән. Чөнки бу бөтен җәмгыять катнашында мең еллар буена тудырыла килгән әдәби иҗат процессын өйрәнү дигән сүз. Татар халкының үткәндәге материаль һәм рухи культура байлыкларының үсү юлын өйрәнүдә Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында тарих, этнография, археология, тел һәм фольклор фәннәре буенча шактый эшләр алып барыла. Болгар-татар кабер таш язулары да фәнни эшкәртелеп дөньяга чыкты. Татар халкының килеп чыгышына карата яңача яктыртулар алып килгән «Идел буендагы болгарларның борынгылары» дигән китап та укучылар хөкеменә тапшырылды. Аерым гыйльми хезмәткәрләр халкыбызның музыка, архитектура, орнамент (бизәк, рәсем) тарихын да өйрәнәләр. Әмма әдәбиятыбызның борынгы заманнардан алып XIX йөзгә кадәр булган тарихы тиешле дәрәҗәдә фәнни нигездә ныклап эшләнмәгән; аның хәл ителмәгән яклары күп, шул чорлардагы әдәби истәлекләрне тел ягыннан да өйрәнү таләп ителә.

Фәннәр академиясе Советлар Союзы халыкларының борынгы чордан алып Октябрьга чаклы әдәбиятларының күп томлы тарихларын чыгаруны кирәк дип таба. Анда безнең әдәбиятыбызның тарихына да урын биреләчәк. Шуның белән бергә, алда татар әдәбиятының фәнни тарихын төзү бурычы куела. Бу зур мәсьәләгә керешкәнче әле төрле юнәлештә кичектергесез үтәлергә тиешле эшләр бар. Беренчедән, татар әдәбиятының булган язма истәлекләрен барларга, аларның кыскача эчтәлекләрен аңлаткан (аннотацияле) каталогларын булдырырга кирәк. Бу да СССР Фәннәр академиясе тарафыннан куелган һәм барлык СССР халыкларының әдәбиятына кагылган гомуми бурыч. Борынгы татар әдәбияты ядкярлары, кулъязмалар хәлендә, Казанда гына түгел, Мәскәү, Ленинград, Киев, Ереван, Баку, Ташкент кебек шәһәрләрдә, хәтта чит илдә — Истамбул, Каһирә, Париж, Лондон, Берлин, Лейден, Краков кебек шәһәрләрнең китепханәләрендә сакланалар. Аерым кешеләрнең киштәләрендә дә ул кулъязмалар бар. Татарстанның үзендә булган кулъязмалар, сирәк очрый торган басма әсәрләр, нинди телдә булуларына карамастан, Казанда бер урында тупланырга тиешләр. Татар әдәбиятының иске язма истәлекләрен барлау эшен алып барганда, аның моңа кадәр исемнәре генә телгә алынып йөргән, әсәрләре хакында хәбәрләребез булмаган, хәтта исемнәре билгесез калган язучыларны да ачыкларга мөмкин булыр иде. Мәсәлән, XV—XVI йөзләр әдәбияты Мөхәммәдъяр белән генә чикләнмәгән бит. Ул чорда Колшә-

риф, Кол Габиди, Гарифбәк, Шәмсе Гасый, Шәмсетдин Гарип, Касыйм әл-Казани кебек язучылар һәм галимнәр яшәгән. Мөхәммәдъярның шул вакыттагы Казан турында:

Бер гаҗип бу кем шәһәр эче тулуг:
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг. —

дип язуының нигезе булырга тиеш, әлбәттә.

XVIII йөз әдәбияты да шагыйрь Утыз Имәни исеменнән генә гыйбарәт түгел, әлбәттә. Гарәп-фарсы телләре укытучысы, борынгы татар әдәбияты белгече Зәйнәп ханым Максудова XVIII йөздә яшәгән унлап шагыйрьнең исемнәрен һәм кайберләренең әсәрләрен барлаган. Алар арасында Бәшир бине Габдулла, Габделҗәббар Тайсугани, Габдулла бине Габдулла, Хәлиулла кебек шагыйрьләр бар. XIX йөздә дә Габделҗәббар Кандалыйдан тыш Габдрафик Габделгаффар, Шәмсетдин бине Ярәхмәт, Габдулла углы Мөхәммәт-Садыйк кебек шагыйрьләр иҗат иткәннәр. Мәгълүм булганча, исемнәре телгә алынган бу шагыйрьләрнең кайбер әсәрләре Москва, Ленинград, Казан китапханәләрендә һәм аерым кулларда саклана-лар. Ул язучыларның иҗатларын өйрәнү үткәндәге әдәбиятыбызны тагын да баетыр, поэзиябез тасмасына тезелә барган шигъри энҗеләрне тагын да арттырыр иде.

Борынгы татар әдәбиятында художество алымнары, әдәби жанрлар, язма әдәбиятның фольклор белән бәйләнеше, гуманизм һәм гаделлек идеяләренең чагылышы, шушы яктан алганда урта гасыр татар әдәбиятының гарәп Көнчыгышы, Урта Азия, рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятлары белән, ягъни дөньякүләм әдәбият белән бәйләнеш проблемалары әле бөтенләй өйрәнелмәгән хәлдә. Котыб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр кебек шагыйрьләр прогрессив кешелек алдында торган зур мәсьәләләр турында борчылганнар, җәмгыятьтә гаделлек, тигезлек күрергә теләгәннәр һәм әдәбиятта гадел, игелекле хөкемдарларның образларын иҗат иткәннәр. Шулай итеп, урта гасыр әдәби истәлекләрдә без татар халкының социаль-философик фикерләвенең башлангычын да күрә алабыз. Шушы яктан караганда, кайбер әдәби истәлекләрне тарихчылар һәм философлар белән дә бергәләп өйрәнгәндә эш тагын да нәтиҗәлерәк булыр иде.

Татар культурасы һәм әдәбиятының башка халыклар культурасы һәм әдәбиятлары белән бәйләнеше киң булган. Бу өлкәдә эзләнүләр алып барсак, ул бәйләнешләрнең дуслык һәм туганлык җепләренең бик ерак заманнарда ук барлыкка килеп, гасырлар буена киңәя һәм ныгый барганлыгын күрә алабыз. Бездә, урта гасырларның башлангыч дәверләреннән алып, татар әдәбиятының рус әдәбияты һәм культурасы белән бәйләнешен күрсәтү өчен дә материаллар бар. Рус әдәбиятының борынгы гүзәл истәлекләреннән берсе булган «Слово о полку Игореве»да, элек-электән килгән елъязмалар (летописьлар) да болгар-кыпчак (татар) сүзләре билгеле урын ала. XV йөзләрдә үк төзелгән русча-татарча, татарча-русча сүзлекләрнең үрнәкләрен дә очратып була. Ә XII йөз әрмән философы Мхитар Гошның «Әрмән судебнигы» исемле трактаты 1570 нче елларда кыпчак (татар) теленә тәрҗемә ителә, хәтта Евангелие әрмән хәрефләре белән татарчага күчерелә, мөнаҗәтләр, шигырьләр языла. Болар әдәби бәйләнешләрне өйрәнгәндә игътибарга алынырга лаеклы фактлар.

Урта гасыр татар әдәбиятында язучының эш методы, аның чынбарлыкка мөнәсәбәте, дөньяны танып-белүе, аны чагылдыру үзенчәлекләре, шуның белән бәйләп ул әсәрләрдәге дөньяви мотивларның көче, реалистик тенденцияләр, реалистик метод яралгылары кебек мөһим мәсьәләләр турында сүз йөртергә бик вакыт. Болар татар әдәбиятының үсү юлында реализмга һәм иң алдынгы метод социалистик реализмга китергән әдәби процессны күзәтү һәм аңлау өчен дә әһәмиятле.

Татар әдәбиятының борынгы ядкярларын өйрәнү бүген канәгатьләнерлек булмаса, аларны бастырып чыгару тагын да начаррак хәлдә. Мөхәммәдъяр һәм Утыз Имәни кебек шагыйрьләрнең кечкенә күләмдә булса да сайланма әсәрләрен бастырып чыгару кирәктер. Ә фән дөньясы өчен аерым памятникларны үз язуларында яисә транскрипция, транслитерацияләрдә русча тәрҗемәләре белән дә чыгаруның зур әһәмияте бар. Таҗик, әзербайҗан һәм үзбәк иптәшләр бу өлкәдә зур эшләр башкаралар. Аларда барлык мөһим әдәби истәлекләр фәнни эшкәртелеп, нәшер ителгән диярлек. Бездә нибары Мөхәммәдъярның поэмалары һәм Сайядиның «Бабахан дастаны» кебек әсәрләр генә матбугатка өзерләнә. Эшне җиңеләйтү һәм тизләтү өчен, аерым язма ядкярларны университет, педагогия институтының гыйльми көчләре белән бергәләп эшләү, координация булдыру күптән көн тәртибенә куелган нәрсә. Безгә татар поэзиясенең иң яхшы үрнәкләрен эченә алган, аерым чорларга караган антологияләрен чыгару да кирәк нәрсә.

Борынгы дәвер татар әдәбиятының көн тәртибенә куелган шушы якларын хәл иткәндә, булган памятникларны барлап фәнни эшкәртеп, алар белән укучыларны таныштырганның соңында, теоретик планда һәм фәнни нигездә аның тарихын төзергә керешү өчен дә мөмкинлекләр туачак.

А. ШАКИР.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

# ҮТКӘННӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Исмәгыйл ага Рәмиев хакында сүз чыкканда, аны якыннанрак белгән кешеләр «аяклы энциклопедия ул», диләр. Ярым житди, ярым шаяру рәвешендәрәк әйтелгән әлеге сүзләрдә бу тынгысыз картка карата олы ихтирам тойгысы да, рәхмәтле күңел җылысы да бөркелеп тора. Шулай булуы табигый да. Татар журналистикасы, әдәбият тарихы, театр сәнгате өлкәсендә эшләүчеләрдән, бигрәк тә яшьләрдән, кемнәр генә, теге яки бу мәсьәләне ачыкларга теләп, Исмәгыйл ага Рәмиевкә мөрәҗәгать итми икән? Инде күптән пенсиядә булуына карамастан, аны хәзер дә фәнни китапханәләрнең уку залларында, китап палатасында, архивларда очратасың. Ул, студентлар һәм аспирантлар белән янәшә утырып, я революциягә кадәрге татар газеталарында басылган әдәби әсәрләр, тәнкыйть мәкаләләренең библиографиясен җыя, каталоглар төзи, я студентлар белән очрашу кичәләренә килеп, аларга беренче татар укымышлылары, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Г. Кариевлар турында мавыктыргыч истәлекләр сөйли...

И. Рәмиевнең вакытлы татар матбугаты турында 1926 елда ук чыккан альбомы татар филологиясе һәм журналистикасы тарихын өйрәнүче белгечләр һәм студентлар өчен бүгенге көнгә кадәр бердәнбер кулланма булып килә. Соңгы елларда өлкән журналист-язучы үзенең әдәби-фәнни хезмәтен тагын да активлаштыра төште. Бер «Совет әдәбияты» журналында гына да аның «Чәнечкеле еллар үтә килгәндә» дигән истәлекләре, С. Рәмиев шигырьләрен басудагы төгәлсезлекләр, Г. Кариев, Ф. Сәйфи-Казанлы турындагы мәкаләләре, «Татарча басма сүз» дигән хезмәтләре басылды.

Узган ел Татарстан китап нәшрияты И. Рәмиевнең истәлекләрен, татар матбугаты турындагы хезмәтен аерым китап итеп чыгарды[1]. Бу — күптән көтелгән китап иде. Бездә соңгы елларда мемуар әдәбияты гомумән активлашып бара һәм укучы тарафыннан яратып кабул ителә. Күренекле әдипләребез тарафыннан язылган истәлек китапларын укыганда, анда сурәтләнгән вакыйгаларда син үзең катнашкан, халкыбызның тарихи эшлеклеләре белән үзең сөйләшкән кебек буласың. Шуңа күрә дә мондый китаплар укучының йөрәгенә үтәләр, күңелләрдә җуелмас тирән эз калдыралар.

Беренче буржуаз-демократик революциянең татар халкын да уятуы, әдәбиятын, культурасын аңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә кайнатып, үстереп җибәрүе турында безнең матбугатта күп язылган һәм хәзер дә язылып тора. Шуңа да, И. Рәмиевнең әлеге кечкенә генә китабын кулга алганда, берәр яңалык булырмы дип, шикләнеп тә куясың. Әмма шикләнү юкка чыга. Автор «шәкерт кайнаган» елларның җанлы күренешләрен кабатланмас конкрет детальләрдә күз алдына китереп бастыра, «халыкка хезмәткә» дип омтылган татар яшьләренең рус культурасына таянып үсүләрен, уку һәм көнкүрештәге үтә дә кыен шартларын, образлы тел белән, рәсемләп бирә.

«Шагыйрьнең «апартаменты» дип исемләнгән бер бүлек сөекле шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган. «Тарихи шәхесләр, бөек кешеләр турында сөйләгәндә, уең төзек, сүзең үлчәүле булганы яхшы», — ди автор һәм үзе дә шушы бик

---

[1] И. Рәмиев. Истәлекләр. Татарча басма сүз. Татарстан китап нәшрияты, 1965 ел.

дөрес принциптан тайпылмаска тырыша. Кечкенә генә деталь дә, сизелер-сизелмәс сызылган штрих та сине ышандыра, халык шагыйренең таныш һәм кадерле образын әле бер яктан, әле икенче яктан яктыртып-яктыртып җибәрә. «Умырзая чәчкәсе төсле кыска гына гомерендә...» дип башлый автор бер җөмләсен. Һәр чагыштыру аксый, ди немец мәкале. Шулай да, әлеге тиңләштерү бик уңышлы. Тукай иҗаты иҗтимагый хәрәкәт ташкыннарында сугарылып, халык көрәшендә туып килгән хөррият кояшының беренче җылы нурларында чәчәк атты, ул яз киләчәген, «хөр мәмләкәт, хөр Русия» туачагын ялкынланып җырлады. Ләкин шагыйрь үзе бу яз тантанасын күрә алмады. Беренче җылытудан соң ук башланган җан өшеткеч салкын көннәр, «уты сүнгән җәһәннәм» кебек кара төннәр, карлы бураннар аның гомерен иртә өзделәр. Исмәгыйль ага, оста экскурсовод кебек, Тукайның «Амур» мосафирханәсендәге яшәү шартлары турында бәйнә-бәйнә сөйләп, күрсәтеп йөри. Тире-яры, йон-ябага, нафталин исеннән гүя үзеңнең дә тының кысыла, җилекләргә үтәр салкыннан гүя үзең дә калтырый-дерелди башлыйсың. Шагыйрьнең өзгәләнеп язган юллары ирексездән күңелдә кабат яңара:

**Номер салкын, якмыйлар бит, арка туңа,**
**Иртә берлән, киям дисәң, яка туңа...**

Автор, шагыйрьнең кием-салымы турында сөйләгәндә: «Столыпин реакциясе чорында студент фуражкасы, Горький эшләпәсе, озын чәч, кызыл күлмәк полициянең нервысына тия торган атрибутлар иде»,— ди. Полициянең нервысына тию белән бергә, мондый өс-баш, мондый кыяфәт татар милләтчеләренең, «Печән базары» әһелләренең, «дин вә мәгыйшәт айгырлары»ның канына да тоз сала. Алар «бу динсез, кызыл авыз, тар балак, кяферләргә» бүрегә караган кебек карыйлар. Шуңа күрә, Тукайның ни өчен чәч җиткереп, зәңгәр кырпулы студент фуражкасыннан, Г. Ибраһимовның, С. Рәмиевнең, шулай ук, озын чәч үстереп, «Горький эшләпәсе» киеп, кызыл күлмәк өстеннән озын чуклы ишелгән билбау бәйләп йөрүләре тагын да аңлашыла төшә.

Китапның «Студентлар көне» һәм «Шәрык клубында» дигән бүлекләре дә кызыклы яңа фактларга бай. Хикәяләүгә җылы агым булып лирик чигенешләр кушылып китә. Автор культура учакларының беренче карлыгачы турында тирәнтен дулкынланып яза. Шәрык клубы... Беренче татар театр труппасы «Сәйяр»ның иҗат студиясе шунда оеша. Г. Тукайның «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», — дигән сүзләре тәүге тапкыр шушы клуб трибунасыннан яңгырый. Реакцион кара көчләр чолганышында, Шәрык клубы сәхнәсеннән, яшәү һәм көрәш авазы булып, халык моңы агылды. Бу исә татар профессиональ музыкасын тудыру зарурияте хакында матбугатта киң сөйләшү башлануга этәргеч булды. Рус профессорлары ярдәмендә, халык көйләрен нотага салдырган С. Рәмиев [1], 1909—1910 елларда гына да, профессиональ музыка сәнгатен яклап, дистәгә якын мәкалә белән чыкты. «Истәлекләр»дә телгә алынган Казан музыка мәктәбе укытучысы И. А. Козлов, татар профессиональ музыкасының тәүге адымнарыннан башлап 20 елларга кадәр, халык көйләрен җыю, өйрәнү һәм башкаруда күп хезмәт күрсәткән, фәнни докладлар ясаган, мәкаләләр белән чыккан кеше. Беренче татар музыкантларын зур хөрмәт белән искә алып, күренекле композитор С. Габәши болай дип язган иде: «Татар булмаса да, татар музыкасы бабында зур роль уйнаган сукыр скрипкачы Козлов та боларның (татар музыкантларының — Ш. С.) иң атаклыларыннан саналырга тиеш» [2].

«Татар сәхнәсе йолдызы» исемле бүлекчә белән танышкач, күз алдына халкыбызның галантлы һәм турылыклы тагын бер улы килеп баса. «Габдулла Кариев — үзенең гомерен татар театрына багышлаучыларның берсе. Татар сәхнәсенә «вакытлыча тамак туйдыра торган кәсеп» итеп түгел, бәлки, «изге трибуна» дип карады ул. Театр аның өчен яшәми, ул театр өчен яшәде. Шуңа күрә театрны үзенең шәхси мәнфәгатьләреннән өстен куйды», — дип яза автор һәм моның хакыйкатьтә шулай икәнлеген конкрет детальләрдә, күренеш-

[1] «Ашказар», «Тәфтиләү» кебек борынгы көйләрне беренче булып нотага С. Рәмиев яздыра. Г. Тукай бик яратып җырлаган бу көйләрнең ноталары аның «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» пьесасына кушымта итеп бирелә. Ләкин пьесаның наширлары — Хәсәниләр, динчеләрнең көчле басымы астында, китапны кибетләрдән бик тиз җыеп алып, утта яндыралар. Әмма ноталарын, әрәм булмасын дип, И. Богдановның «Помада мәсьәләсенә» кушымта итеп чыгаралар (1908 ел).

[2] С. Габәши. Татар сәхнәсендә музыка. («Татар театры» исемле җыентыкта. Казан, 1926 ел.)

ләрдә ачып сала, Кариевка Тукай кебек әдипләрнең, Ямашев кебек революционерларның уңай йогынтысын күрсәтә. Реалист актерның иҗат лабораториясенә керү, режиссерлык алымнары, сәхнә культурасы белән танышу — хәзерге профессиональ артистларыбыз, театр белгечләребез өчен дә файдалы.

Сәгыйть Рәмиев турындагы истәлекләрен автор «Сәйяр»ның 1913 елның җәендә Әстерханга килеп төшү күренешләре белән башлап китә. Театр труппасының төрле шәһәрләрдә гастрольдә йөрүе, артистларның куптәнге якын дуслары һәм фикердәшләре белән кочаклашып күрешүе табигый бер хәл. Ләкин әлеге вакыйга бөтенләй башка шартларда үткән, аңа заманында бөтенләй башка мәгънә бирелгән. Бу турыда С. Рәмиев тә, Г. Кариев та, Исмәгыйл ага Рәмиев тә белмәгәннәрдер: аларны дистәләрчә яшерен агентлар күзәткән. Шуңа күрә автор сурәтләгән бу күренеш бөтенләй башка яктылыкта ялтырап китә...

Җәен без, Г. Тукай, С. Рәмиев һәм Н. Нариманов эзләреннән, Әстерханга барып чыктык. Әстерхан дәүләт өлкә архивында, «Идел» газетасы, Н. Нариманов, С. Рәмиев турында губернатор канцеляриясе, жандарм идарәсе һ. б. органнардагы документлар белән беррәттән, «Сәйяр» труппасы хакында җыелган мәгълүматлар да табылды. Әстерхан губерна жандарм идарәсе һәм шәһәр полиция идарәсе бирегә сөргенгә җибәрелгән революционер доктор Н. Нариманов өстеннән — ачык, С. Рәмиев артыннан яшерен күзәтү алып барганнар. 1913 елның маенда Казаннан «үтә яшерен» дигән билгеләмәле кәгазь алына. Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы үзенең бу кәгазендә Г. Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасы артистларының гастрольгә чыгып китүе, Самара, Саратов, Әстерхан һәм башка шәһәрләрдә булачагы турында хәбәр итә һәм алар өстеннән һәркайда яшерен күзәтү оештырып, мәгълүматларны үзенә җибәреп торуны сорый [1]. Әстерхан канцелярияләрендә ашыгыч эш башлана. «Сәйяр» әле Самара, Саратов шәһәрләрендә торган чакта ук, аны «каршыларга» яшерен агентлар чыгып китә. Алардан телеграммалар килә башлый. Телеграммалар, әлбәттә, шифрланган. Төрле саннардан гына торган текстны канцеляриядә махсус кеше укый һәм, эчтәлеге язылган кәгазьне телеграмма астына ябыштырып, начальникка кертә. Алар артистларның, бигрәк тә «Центральный»ның (Г. Кариевка жандармерия таккан шартлы, яшерен исем) кемнәр белән бәйләнешкә керүен, кайда урнашуларын, кыскасы, һәр адымын энәсеннән җебенә тикле язып (извозчикка үзләренең ничә тиен түләгәнлекләрен дә теркәп) хәбәр итеп торалар. Исмәгыйл ага Рәмиев, суфлер булып, театрда тыйнак вазифа гына үтәсә дә, «Дело»га аның турындагы мәгълүматлар да җентекләп теркәлә.

Истәлекләрдә С. Рәмиевнең киң җәмәгать эшчәнлеге, «Әстерхан халкы арасында театрга мәхәббәт тойгысын шактый югары күтәргән»леге ассызыклап күрсәтелә. «Башка шәһәрләрдә бер спектакль куеп китәргә мәҗбүр булсак, Әстерхан тамашачысы ике-өч спектакльне күтәреп килде»,— дип яза автор. Ул шулай ук шагыйрь С. Рәмиевнең киң белемле, үтә нечкә табигатьле, югары культуралы, Г. Тукай язганча, «һәр тугрыда садәдел кеше» булганлыгын, аралашучан һәм кешелекле сыйфатларын яңа детальләр белән тагын да бер тапкыр раслый. С. Рәмиевнең көчле оратор, нәфис сүз остасы булуы да күпләргә билгеле. Автор шагыйрьнең бу үзенчәлегенә дә киң туктала һәм Һ. Такташ белән чагыштыра. Такташ С. Рәмиевне күреп белгәнме — әлегә мәгълүм түгел, ләкин, шагыйрь буларак, аңа таянып үсүе билгеле. Г. Ибраһимов, 1924 елда ук, «Сәгыйть Рәмиев белән Һади Такташ арасында шигъри куәт ягыннан байтак охшашлык бар»лыгын күрсәткән иде [2]. Һәм бу мәсьәлә фән тарафыннан исбат ителә килә. Такташ иҗатының беренче чор әсәрләрендәге төп мотивларның С. Рәмиевкә тартымлыгы, формада аваздашлык, рухи тәңгәллек, күрәсең, хәтта сөйләм техникасында да охшашлыкка китергәндер.

Автор караңгы чорда тормышның төбеннән күтәрелгән халык талантлары турында да кызыклы мәгълүматлар бирә («Оста куллар»). Алар заманының шактый танылган кешеләре булганнар. Мәсәлән, халык көйләрен саклау һәм популярлашты-

[1] Әстерхан дәүләт өлкә архивы, 290 ф. 1 оп., 4875 эш, 30 бит. Бу документның бер нөсхәсен һәм Саратовтан алынган җавапны Р. Нәфыйгов ТАССР Үзәк дәүләт архивыннан (2 ф, 3612 эш) тапкан һәм шул турыда «Совет әдәбияты» журналында (1960 ел, 4 сан) язып чыккан иде.

[2] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1924 ел, 10 январь.

руда зур хезмәт күрсәткән Г. Минкин һәм аның шәкерте Г. Сәйфуллинны С. Габәши дә «Татар сәхнәсендә музыка» дигән хезмәтендә ихтирам белән искә ала, һәм «Без белә башлаган заманда кайсы гына шәһәргә барсаң да, татарлар арасында музыка ящигы белән өстенә «Мастер Гыйләҗетдин Сәйфуллин» дип язылган тәлинкәләрне очратырга була иде», — дип өсти.

Китап ике мөстәкыйль өлешкә аерылган кебек күренсә дә, композицион бөтенлеккә зыян килмәгән, аларның икесе дә асылда бер теманы — татар культурасы тарихын яктырта. «Татарча басма сүз» өлешендә китап басу тарихы, нәшриятлар эше турында күптөрле мәгълүматлар тупланган. Автор борынгы заманнарда таралган татарча кулъязма әсәрләр, китап күчерүчеләр белән таныштыра, китап басу эшенең башланып, үсеп китүенә алдынгы рус культурасының бәрәкәтле йогынтысын ассызыклап күрсәтә. Автор җыйган мәгълүматлардан күренгәнчә, татарда китап басу эше XIX гасырда ук инде шактый зур адым ясый, Казанда басылган китаплар Россиянең күп өлкәләрендә, Урта Азия һәм Кавказда гына таралып калмый, Һиндстан һәм Африка илләренә дә барып җитә. XX йөз башында исә татар нәшриятлары һәр җәһәттән — һәм сан ягыннан, һәм географик яктан — үсәләр, киңәяләр. Беренче рус революциясе чорында Казанның үзендә күп кенә яңа нәшриятлар ачылу өстенә, татарча китап басу Петербург, Мәскәү, Оренбург, Уральск, Әстерхан, Уфа, Орск, Троицк шәһәрләрендә киң җәелә. Сан ягыннан күп булган бу нәшриятлар һәм басмаханәләр татар әдәбияты һәм культурасы үсешенә киң мөмкинлекләр тудыралар, әлбәттә. Ләкин халыкның аңын агулаган дини китаплар, «әдәби» чүп-чар да чамасыз дәрәҗәдә басыла, һәм чын каләм осталары — демократик язучылар моңа каршы кискен көрәш ачалар. Автор моны дөрес күрсәтә, Г. Ибраһимов һәм Г. Тукайның ачы тәнкыйть сүзләрен бик хаклы һәм урынлы китерә.

Китапта эреле-ваклы бу нәшриятларның кайчан оешуы, кемнәр кулында, кайсы юнәлештә булганлыгы, нинди рәк китаплар һәм журналлар чыгарганлыгы турында мәгълүматлар бирелә. Теге яки бу язучыларның берәр әсәрен укыганда, аны чыгарган нәшрият белән дә кызыксынасын икән — рәхим ит.

Әсәрнең теленә килсәк, ул гаҗәп матур тәэсир калдыра. Җанлы тасвирлар арасында нечкә юмор балкып, сирпелеп-сирпелеп китә. Китапны урыны-урыны белән зур оста каләменнән чыккан тарихи повесть кебек, йотылып, онытылып укыйсың. Шуңа күрә ул безнең белемебезне, мәгълүматыбызны арттырып кына калмый, бәлки, чын сәнгать әсәре кебек үк, эстетик ләззәт тә бирә.

Китапның бернинди кимчелеге дә юкмы? Бар. Аларның кайберләре принципиаль характерда түгел, ә кайберләре хакында автор белән бәхәскә дә керәсе килә. Иң элек шушы соңгылары, аерым тукталып, ачыклауны сорый. Мәсәлән, С. Рәмиевнең революциядән соңгы эшчәнлеге турында язганда, автор урыны-урыны белән, «күңел дәфтәрендә ачык, әйе, ачык калган чаклысы белән» генә чикләнмичә, үзе күреп белгән вакыйгалардан читкә чыгып, юраугa, фараз итүгә бирелә. Нәтиҗәдә, кайбер бик үк дөрес булмаган фикерләр дә әйтеп ташлый. «Тау ягыннан кайткан чагында шагыйрь үзе дә, калыбы да бик өшәнгән иде», (47 бит) — ди И. Рәмиев. Әйе, өшәнгән була. Ләкин моның төп сәбәбе — шагыйрьнең бугазыннан алган көчле үпкә авыруы. С. Рәмиев белән якын аралашкан Г. Касыймов, Д. Юлтый мәкаләләреннән, С. Кудаш, Р. Алуши, К. Гыйрфановларның истәлекләреннән дә бу ачык күренә. Ләкин автор, алардан бөтенләй аермалы буларак, мондый юраугa бирелә: «Гомере буена аралашып килгән әдәби чолганыштан читтә, ялгызлык һәм гаҗизлектә калгач, үзенең иҗат эшен чорының бөек идеяләре югарылыгына күтәрергә көче җитмәгәч (?), рухи төшенкелеккә бирелеп (?!), аны җиңәрлек көч таба алмавы гаҗәп түгел» (47—48 битләр). Әдипнең Октябрь революциясеннән соң биш елны эченә алган зур бер чоры турында, юраугa корып, мондый үтә сәер нәтиҗәне ясау үзе гаҗәп! Авторның С. Рәмиевкә булган олы ихтирамына һәм мәхәббәтенә һич тә икеләнмибез, ләкин бу очракта шагыйрь эшчәнлегенә карата элекке елларда урнашып калган ялгыш карашларның инерциясе тәэсир итмәдеме икән?.. Әдәби чолганыштан читтә дә булсын, ди. Ләкин моңа карап кына, ул ялгызлыкта һәм гаҗизлектә рухи төшенкелеккә бирелеп утырган дип уйларга нигез юк бит әле. Киресенчә, Бөек Октябрь революциясеннән соң С. Рәмиев, зур дәрт белән ялкынланып, яңа тормыш төзү эшенә керешә. Гражданнар сугышының иң кызган чорында ул большевиклар партиясе сафына керә. 1919 елда

ул — Урал өязе, Ваһапов авылында ревком председателе, хәзерге Магнитогорск урынында булган Магнитка станицасында коммуна оештыра, ак банда калдыкларына каршы кулына корал алып көрәшә. 1920 елны Верхний Урал шәһәрендә үткәрелгән съездга сайланып, анда Коммунистлар партиясенең шәһәр комитетында бүлек мөдире итеп калдырыла. Аннан соң Чиләбедә үткәрелгән съездга сайланып, милләтләр эше буенча губерна бүлеге мөдире булып эшли, «Кызыл Урал» газетасында языша, педтехникумда укыта.

Соңыннан моны автор үзе дә икърар итә. «Дөрес, илебездә гражданнар сугышы барган елларда шагыйрь совет платформасында торды, Совет оешмаларында җаваплы эшләрдә булды, Совет җәмәгатьчелеге сафында торып эшләде. Ләкин авыруы көннән-көн көчәйде»,— дип яза. Аннан соң, нәкъ менә шушы чорда С. Рәмиев югары идеяле, зур күләмле әсәрләргә мөрәҗәгать итә. Азатлык турында «Мәсихы хөррият» («Азатлык Христосы» дигән сүз — Ш. С.) исемле поэмасын яза, контрреволюцион буржуазия агентларын, милләтчеләрне, динчеләрне фаш иткән «Саботаж» хикәясен, «Иблис тә дердерәде» дигән философик-атеистик әсәрен, «Коммунист» псевдонимы белән күп санлы мәкаләләрен бастыра. Шулар өстенә «Спартак» романын, романдагы «Азатлык, әй мөкатдәс гам азатлык!» дип башланган җырларны, борынгы Рим шагыйре һәм философы Лукрецийның дөнья төзелеше турында материалистик карашларны бәян иткән шигырьләрен, ниһаять, Коммунистлар партиясе һәм халыкара эшчеләр хәрәкәте гимны — «Интернационал»ны тәрҗемә итүе әдипнең бу чорда нинди идеяләр белән ялкынланганлыгын ачык сөйлиләр. С. Рәмиевнең башкарган эшләренә илебез, халкыбыз ул чагында ук бәя бирде. Соңыннан аның үлеме турында «Правда», «Известия» (1926 ел, 21 март саннары), РКП(б) Үзәк Комитеты янындагы «Эшче» газеталары язып чыктылар. Төрле телләрдәге матбугат битләрендә басылган күп санлы мәкаләләрдә С. Рәмиев үлеме татар әдәбиятында зур тарихи югалту, мәңге онытылмас классик шагыйрьне югалту итеп карала. Кызганычка каршы, С. Рәмиев эшчәнлегенең ифрат кызыклы һәм бай эчтәлекле бу дәвере әле җентекләп өйрәнелмәгән генә...

Авторның: «Спартак» романын татарчага күчерсә дә, дөньяга чыгара алмады»,— дигән фикере дә өлешчә генә дөрес. С. Рәмиев тәрҗемәсендә бу революцион роман 1923 елда «Яңа юл» журналында (1—6 саннарда) басыла башлый, тик журналның тукталуы сәбәпле бүленеп кала.

Истәлекләрнең «Совет әдәбияты» журналында басылган вариантларында «Редакцияләрдә», «Әдәби салон», «Болгар»да», «Трамовой» һәм ломовойлар», «Көфер почмагы», почмагында Җантимер» дигән бүлекләр дә бар иде. Ләкин шул чор күренешләрен тулырак күзалларга ярдәм итә торган бу бүлекләр, ни өчендер, китапка бөтенләй кертелмәгән. Әлеге дә баягы, редактор кайчысыдыр, бәлки...

Әгәр китап әдәбият һәм культура эшлеклеләренең фотолары, элекке Казан күренешләре, аерым китапларның тышлык рәсемнәре белән бизәлгән булса, тагын да отышлырак, нур өстенә нур булыр иде.

Гомумән, Исмәгыйл ага Рәмиев зур һәм кирәкле эш башкарган. Бу очерклар аша үткәннәр белән очрашу — барыбыз өчен дә файдалы һәм гыйбрәтле.

*Ш. САДРЕТДИНОВ.*

# ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК КАРАШЛАРНЫҢ ҮСЕШЕ БУЕНЧА ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Тарих фәннәре докторы Р. Нәфиговның 1964 елда басылып чыккан «Алдынгы татар иҗтимагый-политик карашларының формалашуы һәм үсеше» [1] дигән хезмәте Татарстанда гына түгел, бөтенсоюз җәмәгатьчелегенең дә игътибарын казанып өлгерде. Бу очраклы хәл түгел. Автор анда XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башындагы (Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр) Россиядә революцион-демократик, эшчеләр һәм милли азатлык хәрәкәтләре тарихындагы иң актуаль, иң әһәмиятле проблемаларны яктырта.

[1] Р. И. Нәфигов. Алдынгы татар иҗтимагый-политик карашларының формалашуы һәм үсеше (1895—1917 еллар тарихы очерклы). Рус телендә 1964. 445 бит. Казан университеты нәшрияты.

Татарлар арасында алдынгы иҗтимагый карашларның формалашуы һәм үсеше моңа кадәр тирәнтен, һәрьяклап өйрәнелмәгән. Татарстан тарихы буенча чыккан әдәбиятта бу проблеманың тик кайбер мәсьәләләре генә әзме-күпме күләмдә яктыртылган иде. Андыйлар арасында «Россиянең милли районнарында 1905—1907 еллар революциясе» исемле мәкаләләр җыентыгын күрсәтергә була. Р. Рәимовның бу җыентыкта басылып чыккан мәкаләсендә алдынгы иҗтимагый карашлар үсешенә караган шактый бай фактик материал китерелә. Татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимовның 1925, 1926 елларда татар һәм рус телләрендә басылып чыккан «1905 ел революциясендә татарлар» исемле китабы да игътибарга лаек. Соңгы елларда тарихчылар республикабыз тарихы буенча 30 дан артык кандидатлык диссертацияләре якладылар, шактый гына документаль җыентыклар, монографияләр басылып чыкты. Аларның да кайберләрендә Р. Нәфигов хезмәтендә тикшерелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар юк түгел. К. Фасеевның 1955 елда басылып чыккан «Татарларда алдынгы иҗтимагый карашлар тарихыннан» дигән хезмәте, С. Батыевның «СССР тарихы» (4 сан, 1964 ел) журналында басылып чыккан «Татар җәдитчелеге һәм аның эволюциясе» исемле мәкаләсе дә Р. Нәфигов хезмәтендә күтәрелгән проблеманың кайбер якларын яктырта.

Шулай булуга карамастан, татарлар арасында алдынгы иҗтимагый карашларның формалашуы һәм үсеше соңгы вакытларга кадәр тиешенчә тикшерелмәде. Моңача чыккан хезмәтләрдә бу проблемага караган аерым мәсьәләләр буенча җитди ялгышлар яшәп килә. Аларның күбесенә тематик һәм хронологик чикләнгәнлек хас; тикшеренүләр аерым кешеләргә яки кыска тарихи чорга бәйле рәвештә генә алып барылды.

Мондый хезмәтләрдән аермалы буларак, Р. Нәфигов монографиясенең өстенлеге шунда: анда татарлар арасындагы алдынгы иҗтимагый карашларның формалашуы һәм үсеш мәсьәләләре гомуми фонда, киң планда, Россиядәге революцион хәрәкәтнең барлык мәсьәләләре белән бәйләнештә, гомуми положениеләрне, социаль-экономик шартларны, сыйныфларның һәм политик партияләрнең карашларын, алдынгы рус иҗтимагый карашларының үсешен, аның татарларга йогынтысын анализлау нигезендә яктыртыла. Р. Нәфигов монографиясе — зур һәм катлаулы проблема буенча беренче зур һәм җитди тикшеренү.

Куелган проблеманы тикшерүдәге кыенлык һәм катлаулылык тагын шунда: автордан бик күп мәсьәләләрне яңабаштан карап чыгу, эшкәртү таләп ителгән. Татарлар арасындагы социаль һәм милли хәрәкәт, эшче-крестьян һәм алдынгы татар интеллигенциясе арасында марксистик-ленинчыл идеяләрнең үтеп керүе һәм үсүе, татар халкы арасында демократик идеологиянең барлыкка килүе, үсеше һәм башка мәсьәләләр В. И. Ленинның, большевиклар партиясенең, аның урындагы оешмаларының эшчеләр һәм крестьяннарның сыйныфый көрәше, милли-азатлык хәрәкәте белән җитәкчелек итүдәге эшчәнлеге яктылыгында тикшерелә. Шул ук вакытта буржуаз милләтчелек белән көрәштә татар демократик әдәбиятының, матбугатының, сәнгатенең үсешен һ. б. моңа кадәр өйрәнелмәгән нәрсәләрне автор тирәнтен, шактый тулы күрсәтә.

Эшчеләр сыйныфының барлыкка килүе һәм шул нигездә Россиядә марксистик партияләрнең оешуы белән бергә эшче-крестьяннарның социаль һәм милли изүгә каршы көрәше өчен тиешле шартларның да тууына автор зур игътибар юнәлтә.

Татарлар арасындагы милли хәрәкәттә барлык сыйныфлар һәм катламнар: эшче һәм крестьяннар, татар буржуазиясе, буржуаз һәм вак буржуаз интеллигенция дә катнаша, һәм һәр сыйныф, һәр катлам бу хәрәкәтне, үз интереслары өчен файдаланырга, аңа үз эчтәлеген салырга тырыша.

Татар буржуазиясенең, әлбәттә, омтылышы бердәм булмый: аның бер өлеше бөтенроссия капитализмы белән бәйле булса, икенче өлеше үзенең пантюркистик максатларын тормышка ашыру өчен чит илләргә, башлыча Төркиягә, күз тота. Ләкин бу төркемнең һәрберсе, үзләренең тар һәм эчкерле максатларын тормышка ашыру өчен, халык массаларын милләтчелек флагы астына тупларга теләләр.

Кадимчеләр агымы татар феодаллары, мөселман руханилары — барлык реакцион, консерватив көчләрнең интересларын чагылдырса, 1905—1907 елларда «Мөселман иттифакы» исеме астында оешкан җәдитчелек агымы промышленность-сәүдә буржуазиясенең һәм аның белән бәйле буржуаз интеллигенциянең интересларын чагылдыра. «Мөселман иттифакы»ның программасы кадетлар программасыннан күп аерылмый, асылда ул кадетизмның нәкъ үзе. Шуны да әйтергә кирәк: Р. Рәимовның «Урта Иделдә һәм Урал ягында 1905—1907 еллар революциясе» дигән мәкаләсендә җәдитчелеккә ялгыш бәя бирелә. «Башында Каюм Насыйри торган татар интеллигенциясе, — дип яза ул үзенең мәкаләсендә, — татарлар арасында тарихта җәдитчелек дип аталган (җәдит — яңа дигән сүз) яңа иҗтимагый агымны башлап җибәрде. Бу агым алдынгы рус культурасы, мәктәп һәм мәдрәсәләргә реформа үткәрү, укытуның яңа методларын кертүне, политик азатлыкны һ. б. ларны тормышка ашыру өчен тырышты» [1].

Каюм Насыйри һәм башка мәгърифәтчеләрнең демократик эшчәнлекләрен җәдитчелек белән тиңләү, безнең карашыбызча, дөрес түгел. 1905—1907 еллардагы җәдитчелек инде татар буржуаз милләтчеләре кулындагы агулы корал иде. Р. Нәфиговның җәдитчелеккә карата позициясе дөрес һәм ул тарихи чынбарлыкка да туры килә.

Китапта марксистик-ленинчыл идеяләрне таратуда татар демократик матбугаты-

[1] Россиянең милли районнарында 1905—1907 еллар революциясе. Госполитиздат, 1949 ел, 670 бит.

ның роленә дә зур урын бирелә. Әйтергә кирәк, бу — монографиядә тирәнтен һәм һәрьяклап тикшерелгән иң әһәмиятле һәм катлаулы мәсьәләләрнең берсе. Автор татар демократик матбугатының шушы көнгә кадәр бөтенләй дип әйтерлек тикшерелмәгән катламнарын ача. Р. Нәфигов хезмәтендә татар демократик матбугатының Бөек Октябрь революциясенә кадәр үткән авыр һәм катлаулы юлы, аның буржуаз милләтчелеккә каршы көрәше, татар эшчеләре, хезмәт ияләре арасында гына түгел, Россиянең Көнчыгышындагы барлык халыклар арасында да марксистик-ленинчыл идеяләрне таратуда һәм популярлаштырудагы әһәмиятле роле тулы сурәтләнә. Монографиядә «Азат», «Азат халык», «Әлислах», «Яңа тормыш», «Әлгасрел-җәдит», «Карчыга», «Туп» кебек газета-журналларның, «Мәгариф» китап нәшриятының эчтәлеге һәм юнәлеше, Гафур Коләхметовның, халык шагыйре Г. Тукайның иҗаты тирән анализлана. Татар демократик матбугатында В. И. Ленинның нинди әсәрләре, социал-демократик характердагы нинди мәкаләләр һәм листовкалар басылуы беренче булып өйрәнелә. Мәсәлән, ул «Азат» газетасында басылып чыккан «Социал-демократик партиянең максатлары» исемле мәкаләнең большевиклар партиясе программасының татар те.енә тәрҗемәсе икәнен күрсәтә.

1905—07 еллардагы демократик матбугат битләрендә большевикларның ни дәрәҗәдә катнашуын ачыграк күзаллау өчен, «Азат» газетасында басылган «Сословие, класс, партия», «Азат халык» газетасындагы «Социал-демократлар нәрсәгә өйрәтә?» исемле мәкаләләрне күрсәтергә мөмкин. «Азат» газетасында чыккан мәкаләдә **сословие, класс, партия** кебек тарихи категорияләргә марксистик аңлатма бирелә. «Азат халык» газетасында 1906 елның июль-август айларында басылган (9—13 саннар) «Социал-демократлар нәрсәгә өйрәтә?» дигән мәкаләләрдә фәнни социализм нигезләре турында сөйләнә. «Социаль революция котылгысыз һәм аның котылгысыз булуын беркем дә туктата алмаячак, рус хөкүмәтенең бернинди законнары да эшчеләр хәрәкәтен туктата алмады һәм алмаячак», — диелә ул мәкаләләрнең берсендә. Революцион эчтәлекле материаллар ул елларда «Уклар», «Фикер», «Карчыга», «Әлислах», «Туп», «Яшен», «Ялт-йолт» кебек газета-журналларда да аз басылмаган.

Р. Нәфигов 1905—1907 еллар революциясе, В. И. Ленин, урындагы социал-демократик оешмалар йогынтысы астында, татар революцион-демократик интеллигенциясенең марксистик-ленинчыл идеологиягә якынаюын ышандырырлык фактлар һәм документлар нигезендә күрсәтә. Китапта Г. Сәйфетдинов, З. Садиков, В. Хөснетдинов-Усманов, М. Вахитов, С. Исхаков, Садыйк һәм Зариф Сәгъдиевлар составындагы татар социал-демократик группаның күпкырлы эшчәнлеге киң яктыртыла. Бу группаның җитәкчесе атаклы татар революционеры большевик Х. Ямашев була.

Автор, татар революцион демократиясе вәкилләренең (Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал һ. б.) реакция шартларында катлаулы һәм каршылыклы юллар, төрле икеләнүләр аша хәлиткеч көрәш сафына басуларын күрсәтеп, аларның царизм политикасын, буржуаз милләтчелекне һәм аның панисламизм, пантюркизм кебек төрләрен фаш итүләрен алгы планга куя.

Җирле партия оешмаларының тарихын өйрәнү, аларның реакция һәм яңа революцион күтәрелеш елларындагы эшчәнлекләрен ачыклау буенча да Р. Нәфигов зур эш башкарган. Казан большевикларының бу еллардагы эшчәнлеге моңа кадәр бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек иде. Тагын шунысы да бар: «Беренче революция елларындагы Казан» дигән хезмәтнең авторы С. Лифшиц моңа кадәр, 1908 елның ахырында Казан комитеты членнарын кулга алудан соң, Казанда революцион эш бөтенләй туктала, большевикларның берничә мәртәбә оешманы яңадан торгызу буенча тырышлыклары уңышсызлыкка очрый, дип исәпли иде. Бу ялгыш фикер бүтән тарихчыларның да хезмәтләрендә берничә тапкыр кабатланды. Р. Нәфигов бу ялгыш фикерне юкка чыгара торган күп кенә кызыклы документлар, зур фактик материал тапкан. Һәр кулга алудан соң, Казан большевиклары үз сафларын тулыландырганнар, эшчеләр белән бәйләнешкә кергәннәр, крестьяннар һәм студентлар арасында актив эш алып барганнар, кыскасы, Ленин күрсәтмәләре буенча эшнең яңа формалары һәм алымнарын кулланып, көрәшне дәвам иттергәннәр.

Автор Казан большевикларының партия Үзәге белән, большевиклар матбугатының үзәк органнары белән даими бәйләнеше турында кызыклы документлар китерә.

Китапта Казан партия оешмасының ленинчыл пролетар интернационализм политикасын тормышка ашыру буенча көрәшенә зур урын бирелә. Бу мәсьәләгә махсус багышланган бүлектә РСДРПның Казан оешмасының рус, татар һәм башка милләт хезмәт ияләрен интернациональ рухта тәрбияләү, аларны патша самодержавиесенә, алпавытларга, рус һәм татар буржуазиясенә каршы көрәшкә туплау буенча зур эш башкаруы гәүдәләнә. Монографиядә Уфа, Чиләбе, Пермь, Уральск, Троицк, Түбән Тагил һ. б. шәһәрләрдәге социал-демократик оешмалардагы татарлардан торган группаларның зур революцион эш алып барулары да киң яктыртыла.

Хезмәттә тикшерелгән проблемаларның катлаулылыгы, күпьяклылыгы автордан, тарих буенча махсус әдәбият өйрәнү белән бергә, философия, экономика, татар әдәбияты, матбугаты, театр тарихы һ. б. мәсьәләләр өстендә дә җентекләп тикшеренүне таләп иткән. Р. Нәфигов, Татарстан, Мәскәү, Ленинград, Оренбург, Уральск һәм башка шәһәрләрнең архивларын актарып, күп кенә кыйммәтле документлар тапкан, эшкәрткән. Архив документларының күп өлешен автор әле беренче тапкыр

дөньяга чыгара. Китапта бик күп вакытлы матбугат материаллары (СССР халыкларыннан 7 телдә, биш чит ил телендә, 100 дән артык исемдәге газета һәм журнал) һәм шулай ук революция ветераннары, милли азатлык хәрәкәтенә катнашучылар белән шәхси әңгәмәләр, мемуар әдәбият файдаланылган.

Р. Нәфигов монографиясе, әйтеп үткәнебезчә, бик күп мәсьәләләрне үз эченә ала. Шуңа күрә, бик табигый, бәхәсле, чишелеп бетмәгән һәм моны чишү аерым бер авторга гына мөмкин булмаган, ләкин көн тәртибенә куелган мәсьәләләр дә бар анда. Шундыйлардан, мәсәлән, татар журналистикасы, гомумән матбугаты тарихын махсус эшкәртү мәсьәләсен алырга була. Шулай ук, безнең уебызча, Идел буендагы төрле милләтләрдә эшчеләр сыйныфының барлыкка килүе, аның формалашуының үзенчәлекләре мәсьәләсе буенча тарихчылар, философлар һәм экономистлар арасында фикер алышу уздырырга кирәк. Шулай ук «История СССР» журналында күтәрелгән һәм бу монографиядә шактый гына сүз алып барылган җәдитчелек мәсьәләсе буенча да фикер алышу таләп ителә.

Монографиядә кайбер кимчелекләр дә юк түгел. Р. Нәфигов хезмәтендә татар промышленность буржуазиясенең барлыкка килүе һәм үсеше процессы, Казан губернасыннан читтә эре татар сәүдәгәрләренең промышленность өлкәләренә әверелүе процессы ачык күрсәтелгән. Ләкин автор Казан губернасының үзендә милли промышленность буржуазиясенең үсеш процессына анализ ясамаган.

Историографик кереш сүзнең юклыгы, шулай ук әдәбият һәм чыганакларның библиографиясен күрсәтмәү дә шундый зур монографик тикшеренү өчен бик үк табигый түгел. Китапның ахырында әдәбият, вакытлы матбугат, архив документлары һәм башка чыганакларның исемлеге бирелсә, китаптан файдаланучылар өчен эш җиңеләер иде.

Ү. БИЛАЛОВ,
А. ТАРАСОВ,
тарих фәннәре кандидатлары.

# ҖЫР БЕЛӘН ОЧРАШУ ӨЧЕН

Ватан сугышы ветераны Госман бабай, әкият сөйләсәң әкияттән, чынын сөйләсәң чынныннан туймас малай-салайны үз тирәсенә җыеп утырткан да, төрле мәзәкләр кыстыргалап, солдат башыннан үткән хәлләрне сөйли. Ул хәлләрнең исә, тыңлап баксаң, шактый гына гыйбрәтлеләре дә бар икән. Әйтик, Россия солдатлары илебезгә бәреп кергән дошманны тиресе туналып чыгарлык итеп пешекли белгәнме, белгән. Ватанныбызның азатлыгын яклап Париж белән Берлин калаларына хәтле барып җиткәнме, җиткән. Һәм бер генә түгел, безнең солдатлар әллә ничә мәртәбәләр ул калаларның түбәсенә җиңү байрагын кадап кайтканнар. Ләкин дөньяның кай читендә генә булмасыннар, туган илнең изге туфрагын, яз айларында ап-ак шомырт чәчәгенә күмелеп утырган хәтфә тугайларын, җиңелчә томан белән өртелгән айлы төннәрен бер генә мизгелгә дә исләреннән чыгармаганнар алар. Солдат өчен туган илнең чут-чут итеп сайраучы яки гөрләүче кошчыгына хәтле кадерле икән. Зиннәт Вәлинең Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Җирдәге йолдызлар» исемле җыентыгына кергән «Күгәрчен» хикәясендә шул турыда сөйләнелә.

Яшь укучыларыбызда Ватанга, аның батыр йөрәкле халкына, туган якларыбызның табигатенә мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә ике-өч битле генә бу кечкенә хикәя зур әһәмияткә ия.

Немец илбасарларын тар-мар итүдә совет хатын-кызларының өлеше кечкенә булмады. Ләкин сугыш — аларны кайгы-хәсрәткә күмгән, чәчәк кебек гомерләрен вакытсыз сулыктырган фаҗига да иде. Зиннәт Вәлинең «Солдат-ана» исемле хикәясен укып, без бу фикернең дөреслегенә тагын бер кат инана алабыз. Дөрес, хикәядә ирләренең үле хәбәрләре килгәч, басу буенча, шашар дәрәҗәгә җитеп, йөгереп йөргән хатыннар белән дә, яки йөрәк ярырлык бүтән нәрсәләр белән дә очрашмыйбыз. Бары тик авторның сугыш хәлләрен булганынча сабыр гына сөйләп чыгуын ишетеп торабыз һәм инде ул хикәясен тәмамлагач, ничектер, моңаеп калган кебек булабыз. Ни өченме? Өстенә шинель киеп сугышка киткән Идел кызы Газизәнең яшьли үк тормышны көйсезрәк башлап җибәрүе, яшьли үк бәхет дигән нәрсәдән мәхрүм калуы өчен. Ләкин уфтанырга ашыкмыйк, чөнки Газизә авырлыклар алдында сыгылып төшүче йомшак буынлы кызлардан түгел. Югыйсә ул, кулына корал тотып, дошман явына каршы китмәгән һәм, ир-ләр белән беррәттән, сугыш кырларында батырларча көрәшмәгән булыр иде. Аннары аның да бит, бик озакка сузылмаса да, мәхәббәт дигән ширбәтне татып, шатлык кичергән көннәре булган: башта яшертен генә, аннан инде чәчләреннән иркәләп, ачыктан-ачык Хафиз исемле лейтенантны сөйгән. Ләкин сугыш дигәннәре шул хәтле шәфкатьсез икән — бу ике гашыйкның мәхәббәтен көйдереп кенә калмый, аларны як-якка кагып, аерып ук җибәрә. Үпкәсе дошман уклары белән телгәләнгән Хафиз, госпитальдән госпитальгә йөри торгач, үзенең Донбассына, Газизә исә, сугыш беткәндә, туган-үскән авылы Чыршылыга кайтып төшә. Ләкин берүзе генә кайтмый, авыр солдат котомкасы белән бергә ул үзенең йөрәк парәсе — сабый баласын да күтәреп кайта.

Туп шартлаулары һәм пуля чыелдаула-

ры тынуга, менә шушы сагынып көтелгән иминлеккә сөенәсе генә иде дә бит, әмма героиняbызның хәленә керик, аны якынынрак аңларга тырышыйк без. Әйтик, күкрәкләре медальләр белән тулы фронтовикларны музыка һәм тантана белән каршы алганда, Газизәнең күкрәгенә баласын кысып, тын гына кайтып керүе, өстәвенә кайбер авылдашларының чәнечкеле карашына очравы аның өчен гарьлек түгелмени? Бигрәк шунысы бәгырен өзә аның: әгәр әнисе, туган әнисе дә шикле сорауны бирә калса, ни дип җавап бирер ул? Ятим бала түгел, тиздән аның атасы кайтыр, диярме?

Әйе, укучының да яшь ана хәлен җиңеләйтәсе, Газизәне тизрәк Хафизы белән кавыштырасы килә. Хикәядә бу теләккә бернинди дә киртә юк кебек, Газизәнең өмете менә-менә чынга ашар кебек. Ләкин нәкъ шул көннәрдә кинәт бер хәбәр ишетелә: Хафизның инде күптән һәлак булды дип йөргән тормыш иптәше Нураниясе исән икән бит. Һәм хәзер инде Хафиз да, Нурания дә, бер-берсен табышып, Донбасста матур гына тормыш корып яталар икән.

Укучы Газизәнең күңел ярасын газаплы сугыш еллары китергән кайгыларның берсе итеп кабул итә. Әмма Газизә хикәянең буеннан буена үз биеклегендә кала килә, йөрәгендәге давылны солдат түземлеге белән сабыр кичерә. Сугыш аны нинди генә хәсрәтләр белән күмеп ташламасын, сөйгәне турында ул матур итеп уйлый белә, мәхәббәте, Хафизы хакына хәтта иң кадерле нәрсәсе — үз бәхетен корбан итә. Моңарчы чыккан китапларында карчык-корчыклар, базымсыз яки бик хәтәр кыю егетләр тирәсендә кайнашкан Зиннәт Вәлине олы җанлы гади татар кызы Газизә образын тудыра алуы белән котлыйсы һәм шул ук вакытта героинясын артык мәшәкатьләр белән борчыганы өчен шелтәлисе дә килә. Авторга Газизә биографиясенең икенче өлешен ачып җибәрү, ягъни аны икенче берәү белән башлы-күзле итәргә тырышулар ни өчен кирәк булды икән? Газизәнең хәлен җиңеләйтү, укучылы исә тынычландыра төшү өченме? Ләкин, безнең уебызча, юкка гына бу күңел юатулар. Әгәр автор Газизәне үзенең Хафизына ахырына хәтле турылыклы итеп калдырган булса, һәм аның мәхәббәтен эчке кичерешләре белән тагын да тулыландыра төшсә, хикәянең драматик көче арта гына төшкән булыр иде.

Җыентыкка авторның беренче зур күләмле әсәре — «Җыр белән очрашу» исемле повесте да кергән.

Бөек Ватан сугышының иң тәүге һәм иң авыр көннәре. Дулап килгән фашист илбасарларын күкрәкләре белән каршы алган совет солдатлары һәм шулар арасында татар егете Тәүфыйк Шәрипов. Туп гөрселдәүләреннән тетрәп торган туган ил җирләре, дәһшәт һәм ут эчендә калган качаклар. Повестьны укыганда әнә шундый картиналар бер-бер артлы күз алдыннан үтәләр.

Сугыш бөткәннән соң да инде әллә никхәтле сулар агып, әллә нихәтле гомерләр узган. Сугышта үлем белән күзгә-күз очрашып та исән калган Тәүфыйкның сугыштан соңгы тормышы ничегрәк оешып киткән, тыныч шартларда ул үзен чын мәгънәсендә солдат итеп, хезмәт фронтының солдаты итеп күрсәтә алганмы?

Иң әлек шуны әйтик: автор бирешендә Тәүфыйк коеп куйган тәти герой түгел. Сугыш аның характерына тирән эзен салган, нервларын шактый какшаткан. Туганнары юк, сугыштагы дуслары туган җирләренә таралышып, алардан да аерылган, җитмәсә Казанда эшкә урнашкач коллективка иялэшә алмыйча эленке-салынкы йөрүләр һәм, ниһаять, колхозга кайтып җиң сызганып эшли башлагач та әле, тирә-яктагы кайнап торган тормышка борынны җыерыбрак караулар, гаилә кору бәхетенә ирешә алмау сәбәпле, күңел төшенкелегенә бирелүләр...

Авторның үз героеның, балтасы суга төшкән кешедәй, мескенәеп йөрүенә эче поша: ничек инде электә батыр йөрәкле солдат булган кеше тыныч тормыш шартларында үз урынын таба, үз бәхетен кора алмасын икән?

Әлбәттә, тормыш катлаулы нәрсә ул. Олы җанлы, көчле рухлы кешеләрне дә, барыр юлларына киртәләр куеп, мескен итеп калдырган чаклары була аның. Монда инде түземлек кирәк тә, үз язмышыңны тезгенли, аңа хуҗа була белергә кирәк — авырлыклар бары шул чакта гына җиңелә.

Повесть, үткәндәге авыр көннәребезне бик үк онытып бетермичә, тормышыбызның кадерен белеп, ямен табып яшәргә чакыра, тынычлыкка, иминлеккә һәм кешелекнең киләчәге — сабый балаларга гимн җырлау белән тәмамлана. Гимн җырлау диюебез пафос өчен генә түгел. Әгәр героебызга мең михнәте артыннан бер рәхәт тә килә икән, ягъни аның кыен тормышы хәтта җыр җырларлык бәйрәм, тантана сымаграк нәрсә белән төгәлләнә икән, монда бернинди дә төчелекнең булуы мөмкин түгел. Хикмәт җырны куллана белүдә.

Автор җырны әсәр азагында бирү белән генә чикләнеп калмый, аны геройларның биографияләре белән бәйли, гомумән, җыр ярдәмендә әсәргә үзенә бертөрле рух кертергә тырыша.

Зиннәт Вәли повестендагы җырда иртәнге саф нурга төренгән туган ил, урман буйлары белән басу юллары, йокысыннан уянган сабыйның иртәнге кояш нурына елмаеп каравы турында җырлана. Кабатланганрак булса да, идеясе дә әйбәт: туган илнең тыныч күгендә һәрвакыт тургай сайрасын.

Әйе, әсәрнең герое өчен бу җыр (финалда!) юш килерлек: тузанлы һәм әче төтенле сугыш юлларын узган Тәүфыйкның күзләре туган ил табигатенең ямен күреп сөенсен, ялгыз каз кебек каңгырап йөргән егет гаилә кору һәм кочагындагы сабый кызчыгының атасы булу шатлыгын да кичерсен, тиешенчә тантана итсен — без моңа бик риза! Ләкин әсәрнең керешенә чигеник һәм авторның исенә төшерик. Анда Тәүфыйкларның бу җырны малайлыктан аерылып бетмәгән чакта ук чыгарулары

һәм жырлап йөрүләре турында әйтелә. Тиле һәм гамьсез яшьлектә шундый үтә акыллы жыр уйлап чыгаруларына, житмәсә ул юеш борыннарның, тумас борын, бала жанлы аталар күк, семья шатлыгын кичерүләренә кем ышансын икән? Бу табигыйлектән ерак тора һәм укучыда хаклы рәвештә шик тудыра.

Жыр күтәренке рухлы. Андый жырны фажигагә тарган минутларда жырларга ярамаганлыгы көн кебек ачык. Ләкин повестьта без моның капма-каршысын күрәбез. «Сугыш, сугыш! Күпме михнәт китердең син халыкка, күпме хәсрәт алып киллең... Шау Днестр буенда, сугышның рәхимсез тырнаклары жәрәхәтләп бетергән көньяк жирендә, якын-тирәдә туктаусыз гөрселдәп торган туп тавышларын, пулеметлар тыкылдавын басып, ерак Идел буйларыннан килгән горур жыр яңгырады.

**Иртәнге нурлар,**
**Иң якты юллар**
**Кая барсам минем күңелдә...**
**Һәрвакыт шулай**
**Сайрасын тургай**
**Туган илнең тыныч күгендә!»** (37—39 битләр.)

Әйе, жыр белән, — аны кадерсезләп, — теләсә ничек эш итәргә ярамый икән, ул әсәрнең эченә кергән һәм геройның кичерешләре белән нык бәйләнгән булырга тиеш. Шул чакта гына укучы чын мәгънәсендә жыр белән очраша алачак.

«Жирдәге йолдызлар» — Зиннәт Вәлинең дүртенче китабы, ул аның әдәби осталыкка якынаеп килүен күрсәтә. Шулай да әле без аның бу жыентыгындагы әсәрләрен укыганда сөртенгәләп куйгалыйбыз яки, автор ни әйтергә теләде икән монда дип, бөтенләй туктап калабыз. Сәбәп — авторның теле әле дә булса шомарып житә алмавында, яисә оригинальлек артыннан куып, каш ясыйм дип күз чыгаруда. «Идел өсте тып-тын. Моторлы көймәләр, баржалар юк, теплоходлар узмый. Әйтерсең, алар барган жирдән туктап калганнар...» (6 бит.) Булмаган, күренмәгән нәрсәнең туктап калуы мөмкинме? «Снаряд актарып ташлаган кара чокырдай булып, ян-якка ишелеп төшкән идән асты урыны чекерәйгән» (16 бит). Күп сүзле бу жөмләне берничек тә аңлап булмый. Кайчак сүзгә, бигрәк фразеологик әйтелмәләргә «экономия» ясауның да зыяны тиюе мөмкин: «Ул кыз турында... инәсеннән жебенә сорашырга теләде» (18 бит).

Осталык һәр яктан камиллекне сорый. Зиннәт Вәлинең мавыгып укырлык әсәрләрендә дә әнә шул камиллекнең житеп бетмәве сизелә. Автор үзенең укучылар каршындагы жаваплылыгын исеннән чыгармасын, киләчәктә аларны сәнгатьчә эшләнеп житкән әсәрләре белән очраштырсын иде.

**Т. НУРМӨХӘММӘТОВ.**

# ГАДИ КЕШЕНЕ ОЛЫ ИТЕП

Ниһаять, Чыңгыз Айтматовның әсәрләре, бер китапка тупланып, татар телендә басылып чыкты. Бу безнең барыбыз өчен дә шатлыклы һәм әһәмиятле күренеш. Хәзер без язучының үзе, аның ижаты турында укучы белән иркенләп сөйләшә алабыз.

Бүгенге көндә «Правда» газетасының үз корреспонденты булып эшләүче Чыңгыз Айтматовның тормышы һәм әдәбиятка килү юлы укучыларга аз мәгълүм. Сугыш чорында авыл Советы секретаре, налог агенты, ә аннан соң, техникумны һәм институтны тәмамлап, зоотехник булып эшләгән Чыңгыз 1952 елда, 24 яшьтә чагында, үзенең беренче хикәясе «Дзюдо»ны «Кыргызстан» альманахында бастырып чыгара. Шул вакыттан соң аның әсәрләре укучыларга еш күренә башлый.

1958 елда авторның «Жәмилә» повесте үзәк матбугатта басылып чыга. Тиздән бу әсәр, илебез эчләрендә генә калмыйча, чит илләргә дә тарала. Китапны француз теленә тәрҗемә итүче күренекле әдип Луи Арагон 1959 елда «Француз язмалары» исемле мәкаләсендә «Жәмилә» повесте турында болай яза: «Мәхәббәт турында «Жәмилә» повестендагыдай тирән һәм матур итеп моңа тикле берәү дә әйтмәгәндер».

50 еллар азагында һәм 60 еллар башында Чыңгыз Айтматовның «Кызыл яулыклы гүзәлкәй генәм», «Дөя күзе», «Беренче мөгаллим», «Анам кыры» һәм башка әсәрләре басылып чыкты.

1963 елда Чыңгыз Айтматовка Ленин премиясе лауреаты дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Чыңгыз Айтматов әсәрләрен укыгач, син, андагы гадилекне күреп, ирексездән кулыңа каләм алып, әсәр ижат итәргә тотынып халәткә киләсең: әдәби әсәр язу бик ансат, бик гади нәрсә кебек күренә башлый. Һәм шул вакытта, син бу әсәрләрдәге гадилекнең примитив гадилек түгел, ә «Капитан кызы», «Безнең заман герое» китапларындагы кебек, сәнгать осталыгының югары баскычындагы гадилек икәненә ирексездән төшенә башлыйсың.

Чыңгыз Айтматов үзенең ижади карашын гадәти тормышка, таныш тарихка, гап-гади кешеләргә юнәлтә, файдалы казылмалар чыгаруның иске чыганакларыннан яңа метод белән файдаланган кебек, таныш нәрсәләрнең таныш түгел якларын эзли, үзенең карашы аркылы шул предметлар, вакыйгалар турында яңа эмоциональ фикер тудыра. Мисалга «Беренче мөгаллим» әсәреннән Ленинга багышланган күренешләрне генә алыйк. Автор Ильич турында берничә сүз генә әйтә. Ләкин меңәрләгән әсәрләр аркылы безгә таныш булган Ленин Айтма-

тов повестенда башка яктан ачыла. Караңгы кыргыз авылындагы идәненә салам түшәлгән иске бер ат сараенда укучы балаларның һәм аларда белемгә, яктылыкка омтылыш тәрбияләүче Дүшәннең бөек юлбашчы турындагы уйлары һәм аңа мөнәсәбәтләре гаять самими яңгырый. Бу юлларны укыганнан соң, олы җанлы остазыбызның башка милләт халыклары өчен дә элек-электән үк ничек якын һәм үз булуын тагын бер мәртәбә күрәсең.

Чыңгыз Айтматов әсәрләрендә кеше күңеленә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәткә игътибар искиткеч дәрәҗәдә көчле. Менә аның «Анам кыры» повесте. Бу әсәр новаторларча эзләнүнең уңышлы нәтиҗәсе булып тора. Чыңгыз Айтматов иҗаты өчен хас булган реализм белән романтизмның, проза белән лириканың органик рәвештә кушылып баруы бу әсәрдә тагын да ачыграк күренә. Төрле лирик чигенешләр, риторик сораулар, поэтик чагыштырулар, стиль үзгәрешләре аша язучы әсәр эчтәлегенең рухын көчәйтеп бирә ала торган музыкаль яңгыраш табуга ирешкән. Табигатькә, тормышка бөтен йөрәге, бөтен барлыгы белән гашыйк булган Толганай Ватан азатлыгы өчен барган сугышта үзенең сөйгән ирен, күз карасыдай өч улын югалта. Ләкин ул бирешми: чал башын югары тотып, тормыш арбасын тартуын дәвам итә. Дөньяга килү белән әнисен югалткан оныгы Бикбулатны тәрбияләүдә Толганай үзе өчен ләззәт таба. Аның оныгы үсә, Толганай буыны яши, дәвам итә. Авыр минутларда ул Җир-ана белән киңәшә, аңа үзенең күңел моңнарын, йөрәк хисләрен сөйли. Туган халкының, туган иленең, кыюкасы, тормышның символы булган Җир-ана Толганайны юата, аңа егылырга ирек бирми.

Ил анасы да, Җир-ана да — иҗатчылар. Алар һәрвакыт яшәү яклы, алар өчен җимерү — җинаять. Аналар һәрвакыт яшәүгә сусый; алар үз балаларының бәхетле гомер кичерүләрен һәм тормыш бакчасына алдагы буыннар өчен матур гөлләрне тагын да күбрәк утыртып калдыруларын телиләр. Әсәрнең һәр юлы снарядларны шартлатмас, балаларны атасыз, аналарны баласыз калдырмас өчен көрәшергә кирәклек турында набат булып яңгырый.

Матбугатта басылып чыгу белән укучыларның күңелен җәлеп иткән «Беренче мөгаллим» повестенда автор бик актуаль мәсьәлә күтәргән. Ул һәрбер гади кешене олы, бөек итеп күрергә тели, әгәр дә безнең гади кешебез төрле сәбәпләр аркасында күздән югалып калган икән, аны эзләп табарга, аның олылыгын булдыру өчен көрәшергә кирәк, ди. Язучы кешене дәрәҗәсенә, биләгән постына карап түгел, кешелеклелек сыйфатларына, кылган эшләренең башкаларга ни дәрәҗәдә файда китерүенә карап хөрмәт итәргә чакыра.

Әсәр герое Дүшәннең мәктәп оештыру, балалар укыту тарихы — шул елларда бөтен илдә барган иҗтимагый процессның конкрет бер чагылышы ул.

Язучының бу әсәре укучыны тирә-ягына кат-кат карарга, үткән юлын, белгән кешеләрен кабат күздән кичерергә, белмәгәннәре белән ныклап кызыксынырга мәҗбүр итә, **юлдан читтә калып, сукмагын үлән каплаган, ләкин суы саф, тәмгә көч кертерлек чишмәләр барлыгын** истән чыгармаска куша.

Айтматовның барлык әсәрләрендә мәхәббәт олы һәм изге бер хис буларак сурәтләнә. Олы мәхәббәткә ия булган кеше олы нәфрәткә дә ия. Шуның белән бергә, андый кеше теләсә нинди авырлыкны да җиңәргә сәләтле. Мәхәббәт җырчысы дип аталырга лаек булган Айтматов бөтен дөньяда элек-электән үк үзенең мәхәббәт поэзиясе белән дан алган көнчыгыш әдәбиятының һәм фольклорының гүзәл традицияләрен өйрәнеп һәм аларны иҗади рәвештә бүгенге көн дәрәҗәсенә үстереп, Фәрхад һәм Ширин, Ләйлә һәм Мәҗнүн, Шәхсәнәм һәм Гариб, Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтләре белән тиң куелырлык Җәмилә һәм Данияр, Ильяс һәм Асыл мәхәббәтләрен тудырган.

Язучының сөю хисләрен бөек һәм калку итеп сурәтләргә тырышуының сәбәбе дә бар. Башка төрки хатын-кызлары кебек, кыргыз хатын-кызлары да хокуксыз, мәхәббәткә бары тик хыялда гына ия иделәр. Күп хатынлылык, көчләп кияүгә бирү кебек кыргый гадәтләр аларны бәхетсез итте, аларның кешелек дәрәҗәсен аяк астына салып таптады. Совет власте аларга җаны теләгәнне сөяргә хокук бирде. Кыргый гадәтләр алар өчен җимерелә барды. Алтынай — ул гадәтләрнең соңгы корбаны. Ләкин ул да, бу тозактан чыгып, яңа тормыш төзү юлына, яңача яшәү баскычына аяк баса. Нәкъ менә шушыларны исәпкә алып, язучы ирекле җәмгыятьтә хатын-кызның ни дәрәҗәдә олы мәхәббәткә ия булуын калку рәвештә тасвирлый.

Чыңгыз Айтматов хәзер дә, бик интенсив рәвештә, яңа әсәрләр иҗат итүен дәвам итә. Ул әле яңа гына шәхес культы чорында нахак бәла аркасында гаепләнгән гади коммунистның кичерешләрен тасвирлаган повестен тәгәлләде. («Хуш, Гөлсары».) Материалына бәйле рәвештә бу әсәрдә язучының эпиклык интонациясе көчәюе күзгә ташлана. Җыеп әйткәндә, Чыңгыз Айтматов әсәрләрен укучыларның киң катлавына җиткерү һәм популярлаштыру массаны югары мораль сыйфатлар һәм коммунистик эстетика принциплары рухында тәрбияләүгә нык ярдәм итә.

Бу язучы хәзер татар укучысының да дустына әйләнде, чөнки ул бу әдипнең әсәрләре аркылы дөньяны ныграк аңларга, гади кешеләргә игътибарлы булырга, тормыштагы гүзәллекне күрә белергә өйрәнә; аларны укып рухи яктан байый, тулылана һәм соң чиктә, шәхес буларак, үзе дә олылана төшә.

**Х. МИННЕГУЛОВ.**

# КӨН ИСЕМНӘРЕ

*Мәгълүм булганча, хәзерге вакытта кулланылышта йөргән рәсми көн исемнәре безгә Көнчыгыштан кергән. Татарлардагы һәм Урта Азия халыкларындагы көн исемнәренең килеп чыгышлары хакында А. Самойлович болай яза: «Ислам дине туу белән бәйле рәвештә, Урта Азия һәм башка төрки халыкларына гомуммөселманча көн исемнәре фарсылар аша керә: атна (җомга), шимбә, якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе. Шул ук система, бөтенләй үзгәрмәгән хәлдә, борынгы болгар истәлекләрендә дә очрый».*

*Урта Азия халыклары арасында ислам дине исә XII—XIII йөзләрдә тарала. Ел вакытларын ай календаре белән исәпләүгә күчү дә шул чорларга туры килә. Димәк, фарсыча көн атамалары куллану моннан күп гасырлар элек кергән икән.*

*Атнаның бишенче көне фарсыча «җомга» (сирәк кенә «атна» сүзе дә очрый), алтынчы көне — «шимбә» дип аталган. Калган көн исемнәре* «шимбә»*не санап чыгу, аңа бер-бер артлы тәртип саннары өстәп-кушып бару юлы белән (беренче шимбә, икенче шимбә һ. б.) ясалган (як+шәмбе, дү+шәмбе, си+шәмбе, чәр+шәмбе, пәнҗе+шәмбе). Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, атнадагы көннәр саны җиде булып, атна җомгадан җомгага кадәр сузылган, соңгы — җиденче көн ял көне исәпләнгән.*

*Төрле календарьларда, эш кәгазьләрендә кулланылган фарсыча көн атамалары белән берраттән, борын-борыннан көн исемнәренең халыкча вариантлары да гамәлдә йөргән. XVIII йөз сәяхәтчесе Г. Миллер атнаның ике көне, кабул ителгән фарсы атамалары урынына, халыкча исемнәре белән (чәршәмбе — кече атна; җомга — олы атна) йөртелүен әйтә (Г. Ф. Миллер. Описание живущих в Казанской губернии языческих народов. Рус телендә. 1791 ел, 82 бит). Көн атамаларының халыкча вариантлары Г. Миллер күрсәткән ике исем белән генә чикләнми, билгеле.*

*Казан татарларында, мишәрләрдә һәм керәшеннәрдә нинди атамалар кулланылуын түбәндәге таблицадан күрергә мөмкин:*

| Фарсыча көн исемнәре | Казан татарларында | Мишәрләрдә | Керәшеннәрдә |
|---|---|---|---|
| Дүшәмбе | Дүшәмбе | Баш көн | Баш көн |
| Сишәмбе | Сишәмбе | Буш көн | Буш көн (Атлаган көн) |
| Чәршәмбе | Чәршәмбе | Чәршәмбе | Кан көн |
| Пәнҗешәмбе | Кече атна (Атна кич) | Кече атна | Атна кич |
| Җомга | Олы атна (Олы җомга) | Атна көн (Атна) | Атна көн |
| Шимбә | Атна арты | Атна арасы | Атна арасы (Атна арты) |
| Якшәмбе | Базар көн | Базар көн (Урыс атнасы) | Базар көн |

*Халыкча көн исемнәренең этимологияләрен, ничек барлыкка килүләрен игътибар беләнрәк өйрәнә башласаң, борынгы татарларның көнкүрешенә, гореф гадәтләренә һәм йолаларына бәйлә нешле кызыклы гына әйберләр ачыла.*

*Көн исемнәренең этимологиясен ачыклап, Ш. Х.*

*Гали борынгы татарлар атнаның бер көнен башка күеп, беренче итеп санаганнар һәм аны* баш көн *дип атаганнар, ди. А. Самойлович фикеренчә, бу атама мишәрләрдә дә шул ук мәгънәне белдерә. Тау ягы керәшеннәрендә* дүшәмбенең *тагын да борынгырак атамасы сакланган. Алар атнаның беренче көнен* туды көн *дип атап йөртәләр. Бу, күрәсең, туу сүзе белән бәйләнгән булса кирәк.*

*Шул ук Тау ягы керәшеннәрендә сишәмбенең* «атлаган көн» *дигән варианты да бар икән. Монысы, бәлки, ат ярышлары уздырыла торган бер бәйрәм, йола белән бәйләнгәндер?.. Башка урыннарда атнаның икенче көне* буш көн *дип йөртелә. Ш. Х. Гали фикеренчә (Ш. Х. Гали. Еллар, айлар вә көннәр. «Шура» журналы, 1912 ел, 13 сан.), элекке кешеләр атнаның бер көнен яман көн дип исәпләгәннәр һәм ул көнне зур, җитди эшләрне башларга ярамый дип уйлаганнар. Олы яшьтәге кайбер кешеләр әле бүген дә сишәмбедә ерак сәфәргә чыгу, язгы чәчү, уракка төшү кебек аеруча җаваплы, җитди эшләргә тотынмаска тырышалар.*

*Диалектологик сүзлектә чәршәмбенең халыкча варианты* кан көн *дип бирелгән. Ихтимал, бу атаманың этимологиясе халыкның борынгы гореф-гадәтләренә ишарәлидер. Корбан чалу кебек дини йолалар шул көнне башкарыла торган булгандыр. Халыкта чәршәмбенең* калым көне *дигән варианты да очрый. Картлар кыз өчен калым, гадәт буенча, атнаның өченче көнендә түләнә торган иде, диләр.*

Пәнҗешәмбенең кече атна, бәләкәй атна, атна алды, атна кич *кебек вариантлары бар. Гадәттә, бу көннең икенче яртысында эштән туктап, икенче көн булачак* олы атнага *әзерләнә башлаганнар.*

Атна көн *ял исәпләнгән. Шулай ук бер җомгадан икенче җомгага кадәрге вакыт аралыгын да* атна *дип йөрткәннәр.*

Шимбәнең *бер җирдә* атна арты, *икенче урыннарда* атна арасы *дигән вариантлары бар.*

Якшәмбенең *исә* базар көн, урыс атнасы көне *кебек формалары аеруча киң таралган. Ул көнне сату-алу эшләре башкарылган, һәм бу традиция безнең көннәргә кадәр дәвам итеп килә.*

*Этимологик күзәтүләргә йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: элек татарларда, атна бер җомгадан икенче җомгага кадәр булып, атнадагы көннәр саны хәзерге кебек җиде түгел, ә биш кенә булган. Галимнәр шимбә һәм якшәмбе көннәре ахырдан гына өстәлгән булырга тиеш дип уйлыйлар. Чөнки ай-кояш календаре буенча да атна озынлыгы башта биш кенә көннән торган.*

*В. БЕРКУТОВ,*
педагогия фәннәре
кандидаты.

# «ТҮП» ЖУРНАЛЫ

*1907 елда социал-демократларның Астрахань комитеты каршындагы татар группасы «Түп» исемле сәяси, әдәби, экономик, рәсемле кеолке журнал чыгара башлый. Ләкин вакытлы матбугатыбыз тарихында уңай бәя алырлык бу әһәмиятле журналның гомере бик кыска була. Аның беренче санына ук, Столыпин «галиҗәнапләреннән» көлеп язган мәкалә урнаштырган һәм җирле Ахун Салиховны фаш иткән өчен, Астрахань вице-губернаторы тарафыннан арест салына. Астрахань округы суды журналның редакторы Хәбибулла Гомәревкә каршы эш кузгата*[1]*. Округ суды губернаторга язган эш кәгазендә Хәбибулла Гомәревнең ике айга төрмәгә ябылуга хөкем ителгәнлеген һәм «Түп»ны бөтенләйгә туктатырга карар чыгарылганлыгын хәбәр итә*[2]*.*

*Бу карар көченә кергәнче, журналның тагын ике саны чыгып өлгерә. 3 нче санга тагын арест салына һәм «Түп» бөтенләйгә ябыла. Өлкән советник губернаторга җибәргән донесениесендә бу турыда түбәндәгечә яза: «Хөкүмәт, халык белән идарә итүне кулдан ычкындырмаска тырышып, өченче ел инде халык канын түгә, бөтен халыкны бөлгенлеккә төшерә. Помещикларга сатылган идарә башлыклары, билгеле, алар өчен тырышалар, ә крестьяннар чебен урынына ачтан кырылалар, үзләренең газиз балаларын сатарга мәҗбүрләр. Ләкин хөкүмәтнең монда эше юк, аңа акча гына кирәк. Эше көчең юк икән, газиз улыңны солдатка бир.*

[1] Астрахань дәүләт архивы, 286 фонд, 2 оп., саклану берәмлеге 297, 33 бит.
[2] Шунда ук, 34 бит.

синең тәнеңә сөлек булып ябышкан помещикка хезмәт ит...» дип башланган һәм хөкүмәт хезмәтендә торучыларга каршы язылган башка мәкаләләре өчен «Туп» журналының өченче санына минем тарафтан арест салынды»[1].

Царизмның сатлык ялчылары ни өчен «Туп» журналыннан шулкадәр курыкканнар һәм аны ябу өчен ашыгыч чаралар күргәннәр соң? Журналда басылган материаллар белән танышкач, моның сәбәпләре тагын да ачыклана төшә.

Беренче санда басылган баш мәкаләгә мөрәҗәгать итик. «Туп нәрсәләргә атачак?» дип исемләнгән ул мәкаләдә журналның мәсләге, тоткан юлы ачык аңлатылган: «Туп» иң әүвәл: хөкүмәтнең егылырга торган иске крепостена, бөтен кызганыч халыкны аяк аска салып изүче истибдад[2] үгезенә, иске тормыш бүркенә атылачак. Аннан соң бөтен тугрылыкка каршы төшүче төрки вә мәгариф дошманнары — хәзрәтләргә; хезмәтнән качып, үзен суфи күрсәтеп, мәдрәсәдә ятучы надан карт хәлфәләргә; үзләре үнсигез сәгать йоклап, фәкыйрь эшче-крестьянның үнсигез сәгать эшләгән көчләре белән җилкә калынайтучы 16 потлы байларга, 17 потлы помещикларга; бөтен семьясы ачлыктан кырылмакта булган фәкыйрь халыкны Габдулла Кулиамга иганә итәргә тәкълиф[3] итеп тә, халык өчен файдалы нәрсәләрне язарга өркүче татар мөхәррирләренә; бөтен халыкны агызына каратып, череп-сасып беткән нәрсәләр белән халыкның башын авырттыручы җәмгыять рәисләренә... атылачактыр».

Күрәсез, журнал социаль һәм милли изүгә, наданлык һәм артталыкка каршы рәхимсез сугыш ача.

Журнал «Телеграф хәбәрләре», «Төрле хәбәрләр», «Авыл хәбәрләре» исеме белән чыккан материалларында тормышта булган вакыйгаларга, төрле кешеләргә үзенең бәясен биреп бара. «Туп»ның ядрәләре Казанның печән базарында яшь кызларны «аулап» утыручы читек-кәвешчеләрне дә; музыка коралларын ватып, савап җыйган «гайрәтле» Орск байларын да; «берсе русча, икенчесе закон белмәгән» дума членнарын да көйдерә.

Дини фанатизм белән көрәшү, мулла-ишаннарның чын йөзләрен фаш итү — журнал алдында торган төп максатларның берсе була. Халат киеп, башын бөгеп, сәмән җыеп, мин татар түгел, мөселман дип йөргән ишан, ахуннар, халык ачлыктан кырылганда, мунчага пәрдәсез кергән кешенең шәһадәте дөресме-түгелме дигән мәсьәлә белән баш ваталар, ди «Туп», фанатик дин әһелләреннән көлеп.

«Милләт турында кайгырабыз» дип төкерек чәчеп тә, чынлыкта үз корсакларын гына кайгырткан байларга «Безнең төрки» шигыре багышлана:

Безнең төрки кардәшләре
бик шәп бара,
Ышанмасаң, аршин ал да,
үлчәп кара.

Мөкатдәс һәм тәбәрәкләр
корсагына
Табак пылау, алты четверть
кымыз бара.

Мең елдан да артык безләр
һаман татар,
Мәгариф һич кирәкми дип
таштай катар.
Татар түгел, мин мөселман
диеп йөреп,
Өскә чыккандай эшләр дә
аска батар.

«Туп»та урнаштырылган материаллар актуальлекләре, җитди тонда язылган булулары белән аерылып торалар. Һәр санның баш мәкаләсе реаль тормыштагы берәр зур мәсьәләгә багышлана. Беренче сандагы баш мәкалә журналның тоткан юлын аңлатты, дидек. Икенче санда исә дәүләт Думасындагы мөселман фракциясе, аның булдыксызлыгы турында сүз бара. Мәкаләдә шундый юллар бар:

«Чөнки эшче белән бай, игенче белән алпавыт һичбер вакытта бер табактан аш ашый алмыйдыр. Мәсәлән, Зиналов Тагиевка «сигез сәгать» ди башласа, Тагиевның, сүзенең ахырын тәмам итмәенчә, кул селти башлавы билгеле булган кебек, Атласов та «җир» дип авыз ачса, Сыртлановның[1] (гәрчә үзе крестьяннар депутаты булса да) колагына чүбек тыгачагы шөбһәсездер. Бу вәкилләр ифтисадый, ягъни экономический мәсьәләләрдә бер-береннән аерылдыкларыннан дини вә милли мәсьәләләрдә дә һичбер файда чыгара алмаслар».

Ахырдан: «...Шулай итеп, мөселман фракциясе коры җиргә су тегермәне корырга куелган бер эш булып каладыр. Бу исемнән ни милләткә вә халкымызның күпчелек өлешен тәшкил иткән игенчеләргә, ни җанлы машина шикелле көне-төне хезмәт иткән эшчеләргә һичбер файда килмидер», дип нәтиҗә ясала.

---

[1] Шунда ук, 35 бит.
[2] Деспотизм.
[3] Өндәп, өйрәтеп.

[1] Зиналов, Тагиев, Атласов, Сыртланов — Дума депутатлары.

*«Туп»та Габдрахман Галиев, Габделгани Ниязи, Габдрәхим Сәмәки, Шәһит Гайфи, Әүбәкер Мәзинилләр кебек алдынгы карашлы кешеләр эшли. Араларында иң белемлесе һәм каләме дә шактый шомарып килгәне Мәхмүт Галәү (Мәрҗәни) була. Ул заманда типографиядә наборщик булып эшләгән һәм «Туп»ны чыгаруда турыдан-туры катнашкан кешеләрдән Вәлит ага Алеев: «Мәхмүт Галәү журналның иң актив сотрудникгы, аның фактик редакторы иде. РСДРПның Астрахань комитетында актив эшләде. Революцион эчтәлекле листовкалар, прокламацияләрнең дә күбесен ул язды. Телгә бик оста, менә дигән юморист иде, «Туп»ны көлмичә укый алмый идек», — дип сөйли.*

*1930 елда язган автобиографиясендә Мәхмүт Галәү үзе дә: «Туп» журналының фактик редакторы идем...», ди.*

*РСДРПның Астрахань комитеты җитәкчеләреннән Ибраһим Моратовның да «Туп»ны чыгарышуда ярдәме зур була. Моратов өстеннән даими күзәтү алып барган полицеймейстер аның «Туп» идарәсендә еш булуын хәбәр итә*[1]*. Мәхмүт Галәүнең журналда һәм яшерен оешмада Моратов белән бергә эшләүләре турында профессор Бороздин мәкаләсендә дә әйтелә*[2]*.*

*Журналны популярлаштыруда, аны халыкка якынайтуда карикатураларның да әһәмияте зур. Аларны Шаһит Бәйди дигән кеше ясый (псевдонимы — Ш. Гуни). Карикатуралар газеттә журналда яктыртылган берәр мәсьәләгә яки вакыйгага багышлап эшләнгәннәр.*

*Журналдагы мәкаләләрнең кайсы кем тарафыннан язылганлыгын ачыклау бик кыен эш. Кагыйдә буларак, алар имзасыз басылганнар. Бары берничә мәкалә ахырында гына псевдонимнар куелган.*

*«Туп» беренче адымнарыннан ук цензура әзәрлекләвенә очрый һәм аның һәр саны бер-бер артлы конфисковать ителә. Ләкин шул кыска гына гомерендә дә бу журнал демократик вакытлы матбугат алып барган зур көрәшкә үзеннән лаеклы өлеш кертеп калдыра. «Туп» — патша хөкүмәтенең нигезен җимерү өчен барган көрәшнең бер солдаты, аның ядрәләре шул көрәштә корал булдылар.*

*Ф. ГЫЙЛЬМАНОВА.*

[1] Астрахань дәүләт архивы, 286 фонд, 1 оп., саклану берәмлеге 471, 59 бит.

[2] М. Галяу. Муть. Мәскәү, 1931 ел (Бороздин тарафыннан язылган кереш сүзне карагыз).

# ТУЗГА ЯЗМАГАН СПОРТЧЫЛАР

*Кеше акылы уйлап тапкан һәм кеше тәненең матурлыгын, аның зур техник сәләткә ия булуын күрсәтә торган рекордлар бар. Һәм берниндн әһәмияткә ия булмаган рекордлар да бар. Андый рекордларны я майларына чыдый алмаучы байлар, яисә ничек итеп булса тамак туйдырырлык акча табарга теләүчеләр куя. Коточкыч буржуаз дөнья рекордлары алар. Менә шул рекордларның берничәсе.*

*1959 елны Индианополис шәһәрендә яшәүче Мэри Роз исемле унҗиде яшьлек американка 12 метр биеклегендәге колга башына беркетелгән мәйданчыкта 211 тәүлек буена утыра. Әйтүенә караганда, бу колгага ул үзен яше җитмәгән хокук бозучы дип атаганга протест йөзеннән менеп утырган. Кайбер «спортсменнар» колга башына беркетелгән мичкәләр эчендә утыруны яраталар. Бу төр буенча рекордны, ихтимал, англичан Виктор Ривс куйган булса кирәк: 12 метр биеклектәге колга башына беркетелгән диаметры 70 сантиметрлы мичкәдә 31 тәүлек тә җиде сәгать утырган ул.*

*50 нче еллар башында американлыларда таган атынуның озаклыгы буенча рекорд кую чире бик нык көчәеп китә. Бер Америка университетының ике студенты, бертуктаусыз 52 сәгать буена атынып торып, бу өлкәдә беренче рекордны куйганнан соң, таганга игътибар тагын да көчәеп китә. Теге ике студентның рекорды күптән артта калган инде. Хәзерге чемпионнар— Джим Лейк һәм Джон Уэйвер. Алар өзлексез рәвештә 100 сәгать буе атынганнар. Таган тактасы башларына йоклау капчыклары җайлаганнар да, чиратлашып йоклый-йоклый атынганнар ул чемпионнар. Кресло-таганнар да читтә калмаган. Анда атыну буенча рекорд хәзергә тикле илле яшьлек Уир исемле Канада карчыгы кулында иде: үз таганында дүрт тәүлеккә якын (93 сәгать) туктаусыз атынган кеше ул.*

*Бер туктаусыз озак йөрү буенча рекорд кую белән хәзер беркемне дә шаккатыра алмыйлар инде. Ә менә Масей дигән бер кеше 1951 елда дүрт сәгать эчендә 25 километр җир үтеп, рекорд куйган. Нәрсәсе искитәрлек соң моның? диярсез инде сез. Әйе, шаккатмалы түгел, әмма шунысын истән чыгармагыз: бу араны ул арты белән барып үткән.*

*Йокламыйча күпме түзәргә мөмкин? Менә шушы мәсьәлә буенча Сан-Антонио шәһәрендә (АКШ) үткәрелгән чемпионатта җиңеп чыккан кеше — 150 сәгать буена йокламаган. Шулай озак йокламыйча түзү өчен, ул 40 кап сигарет тарткан һәм 287 чәшкә кофе эчкән. Ләкин беренчелекне озак тота алмаган. Американың Джексонвиля шәһәрендә яшәүче Дэвид Хант 225 сәгать, ягъни 9 тәүлектән артыграк, йокламаган һәм яңа рекорд куйган.*

*Бер утыруда бер баш суганны кем тизрәк ашый ала? дигән сорау да ярыш чыганагы булырга мөмкин икән лабаса. Шундый ярышларның берсе Англиянең Тайне буендагы Ньюкасл шәһәрендә үткәрелгән. Һәркайсы зур-зур берәр баш суган тоткан биш кеше, ярыш башлануын белдереп гонг яңгырауга, ач бүредәй ыргылып, кулларындагы суганны ашарга керешәләр. Ярыш башлануга 2 минутта 15 секунд тулганда Уолтер Пинчен дигән шофер суганын ашап та бетерә һәм чемпион исемен ала. Ә калганнары исә яшьләрен бушка коеп кына калалар.*

*Кем, армыйча, барысыннан да озак ләчтит сата ала? Бу өлкәдә рекорд, ихтимал, Ирландиядә туган Шихин кулындадыр. 1955 елда Англия шәһәре Дартфордта уздырылган такылдыклар ярышында ул 133 сәгать буена авызын япмаган! Ә Төньяк Каролина штатында (АКШ) яшәүче Олтон Клэпп дигән хатын туктаусыз рәвештә 96 сәгать 54 минут һәм 11 секунд сөйләп торган. Бу уңайдан Жерар О Доннелны искә алып китмичә ярамый. Иң озын политик речь — 29 сәгать буена! — сөйләгән диләр аны.*

*Дөньяда иң озын хат язган кеше дә билгеле. Соңгы официаль белдерүләргә караганда, Америка армиясе солдаты Джордэк Кэннигхем 18 көн эчендә хатынына язган хатларның озынлыгы 26 метрдан артыграк булган.*

*Көнбатыш илләрендә бер трубканы кем озаграк тарта алу буенча да әледән әле тәмәкечеләр чемпионатлары булып тора. Әлегә кадәр дөнья рекордын голландияле Каганаару тотып килгән. Трубканы тартучыларның халыкара ярышында 3,3 грамм тәмәке тутырылган (ярыш шарты шундый була) бер трубканы туктаусыз рәвештә 2 сәгать 4 минут һәм 47 секунд буена тартып торып беренчелекне яулап алган ул. Ә икенче урында американы Лодербек. Ул бер трубканы сүндермичә 1 сәгать 55 минут кына тарта алган.*

*Биш кешедән торган семьяның табак-савытларын тиз юу буенча чемпион исемен алу өчен шактый күп күнегүләр ясарга кирәк булгандыр, ихтимал. Бу эшне нибары 2 минут эчендә башкарып була икән бит! Ә сакал-мыек кыру рекордсмены нибары 15 секунд эчендә ялт иттереп кырынып ташлый ала.*

*Бельгиянең Нивель шәһәрендә елның елында торт ашауга ярыш уздырылып килә. Соңгы ярышта, 72 минут эчендә биш торт ашап, Жан Фульти җиңеп чыккан. Шулай итеп, моннан җиде ел элек дүрт ярым торт ашаган Андре Жийеның рекордын узып киткән. Әмма 1920 елда 168 минут эчендә 168 банан ашаган Флорида кешесе Сэм Хартның рекордын узучы кеше юк әле. Шунысын да искәртеп үтик: мондый төр ярышларда катнашучылар, еш кына авыр хәлдә калып, турыдан-туры больницага эләгәләр.*

*Дюссельдорфта (ФРГ) яшәүче алтмыш алты яшьлек Хайнц Арнц рояльдә озак уйнау буенча үзе куйган рекордны (850 сәгать) узып китәргә ниятләп йөри. Ул моңа 44 көн буена тәүлегенә 22 шәр сәгать туктаусыз уйнау юлы белән ирешмәкче.*

*Күптән түгел генә Франциядә яңа «дөнья рекорды» куелды. Аркан өстендә биюче Эмиль Рохатен һәм аның хатыны унбиш метр биеклектәге тарттырып куйган арканда 174 сәгать 15 минут буена биегәннәр. Алар хәтта арканда йоклаганнар да. Берсе йоклаган вакытта икенчесе аның тигезлеген саклау турында кайгыртып торган. Бу рекорд реклама өчен куелган. Марафон бию Рохатенның хатыны аңын югалтканнан соң гына тукталган.*

# Укучылар сүзе

## ГАҖӘЕП ХИСЛӘР УЯТА

**Моннан ун еллар элек мин хат ташучы булып эшләдем һәм шул чакта «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналына язылдым. Журналның беренче саннарын алу белән, ул кулдан-кулга, укучыдан-укучыга күчә башлады. Бу журналны алдыручы башка кеше юк иде бугай. Без яшәгән Карл Маркс исемендәге колхозның яртысы руслар булуын искә алганда, бүгенге көндә 77 данә «Казан утлары» журналын алу канәгатьләнерлек кебек. Ләкин эш аның санындамыни! Минем төп әйтергә теләгәнем журнал битләрендә басылган әсәрләр турында. Укытучы буларак, журналның һәр битен мин игътибар белән укыйм, андагы мәкаләләрне дәрестә файдаланам. Укучыларга аерым әсәрләрне укырга кушып, соңыннан әсәр турында үз фикерләрен әйтә белүләрен таләп итәм.**

**Мин журналны соңгы битләреннән укый башлыйм. Бу, күрәсең, татар әдәбиятындагы яңалыкларны, журнал укучы бүтән иптәшләрнең нәрсә язуларын тизрәк беләсе килүдәндер. Шулай журналларның берсендә журнал укучы Ф. Заһитов (Воткинскгэсстрой механизаторы) хатына тап булдым. Ул болай яза: «...Минем аеруча яраткан язучым бар. Ул — Әмирхан Еники. Аның әсәрләре мине бик дулкынландыра...» Ә миндә икенчерәк фикер бар иде. «Саз чәчәге», «Рәшә», «Рәхмәт, иптәшләр!» әсәрләрен укып чыккан идем. Искитәрлек берни дә юк кебек иде. Менә журнал битләрен актара торгач «Әйтелмәгән васыять» хикәясен очраттым. Хикәяне бер тында укып бетердем. Хикәядә сөйләнгән вакыйга миңа да таныш кебек тоелды. Кайдадыр ишеткән идемме, әллә берәрсе сөйләгән идеме! Юк икән. Халкыбыз, көндәлек тормышыбыз турында, кешеләргә, бигрәк тә аналарга, аз игътибарлы яки бөтенләй игътибарсыз булуыбыз турында сөйләнә бит хикәядә. Шулай булгач, ничек таныш булмасын соң бу әсәр!**

**Тау юлыннан кулына чемодан тотып һәр төшеп килүчене, кулын каш өстенә куеп, «минем балам түгелме бу» дип, өзелеп көтеп торучы әниләр азмыни әле бездә. «Мама, привет» дип, узышлый гына туган өенә кереп китүчеләр юкмыни! Хикәя нәкъ бүгенге көн тормышыннан алып язылган, шуңа һәркемне үзенә тарта да ул.**

**Мин Заһитов иптәш фикеренә хәзер тулысы белән кушылам һәм өлкән сүз остасы язучы Әмирхан Еники абыйның, моңарчы әсәрләрен тиешенчә игътибар белән укымаганым өчен, мине гафу итүен үтенәм.**

**Фәрвәз СӘЛИХОВ,**<br>
Башкортстан АССР, Федоровка районы,<br>
Әтәч сигезьеллык мәктәбе укытучысы.

**Мин Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ен бик ошаттым. Кыска гына бу хикәя күңелдә гаҗәеп хисләр уята, дулкынландыра. Ул һәркем өчен бик гыйбрәтле әсәр. Язучы бик дөрес яза: Гөлбикәләр, Суфьяннар бар шул әле.**

**Үзләре авылда туып-үсеп, шул авыл мәктәбендә белем алып, шул дәрәҗәгә күтәрелгәч туган якларын, телләрен оныткан кешеләргә укытыр идем мин аны, һай укытыр идем... Күрсеннәр иде Акъәби кебек яхшы кешеләрне!**

**ГОМӘРОВА Тәзкирә,**<br>
Балтач районы,<br>
Түбән Кенә авылы.

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары



*Лениниана концертыннан. Артистлар П. Серебряков (сулда) һәм С. Дудкин.*

## МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

Бөтен совет халкы белән берлектә республикабыз хезмәт ияләре дә кешелек дөньясының бөек юлбашчысы В. И. Ленинның тууына 96 ел тулу көнен зур итеп билгеләп үттеләр. Предприятиеләрдә, төзелешләрдә, колхозларда һәм совхозларда В. И. Ленинга багышланган җыелышлар, әңгәмәләр уздырылды. Казанда **14 апрельдән 24 енә кадәр** В. И. Ленинның тууына 96 ел тулуга багышланган дүртенче традицион музыкаль фестиваль булып үтте. Бу фестивальдә Мәскәүдән, Ленинградтан һәм Советлар Союзының башка шәһәрләреннән килгән күренекле артистлар катнашты.

Фестиваль Куйбышев филармониясенең симфоник оркестры концерты белән ачылды. Казан тамашачылары оркестр башкаруында Чайковский, Бетховен, Шостакович һәм башка композиторларның әсәрләрен яратып тыңладылар. Бородин исемендәге квартетның Гайдн, Шостакович, Хиндемит, Стравинский әсәрләрен башкаруы да җылы тәэсир калдырды.

**18 апрельдә** музыка бәйрәмен Совет Армиясенең А. В. Александров исемендәге Кызыл Байраклы җыр һәм бию ансамбле дәвам итте. Бөтен дөньяга атаклы бу ансамбльнең В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры һәм М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры биналарында булып үткән концертларын шәһәребезнең меңнәрчә тамашачылары карады. СССР Зур театрының скрипкачылары ансамбле концерты, РСФСРның атказанган артисты, Бөтенсоюз конкурсы лауреаты Виктор Бединның эстрада концерты, Мәскәү артистлары башкаруындагы Зур эстрада концерты, РСФСРның атказанган артисткасы Людмила Зыкина башкаруындагы җырлар, шулай ук күренекле сәхнә мастерларының башка чыгышлары Казан тамашачыларына зур рухи азык бирде.

Бу концертларда В. И. Ленинга, Бөек Октябрь революциясенә, партиягә багышланган әсәрләр, Владимир Ильич яратып тыңлаган җырлар, музыкаль әсәрләр башкарылды.

Юлбашчыбыз истәлегенә багышланган бу музыка бәйрәменә РСФСРның халык артисты, Ленин премиясе лауреаты, күренекле совет композиторы В. П. Соловьев-Седой да килгән иде. В. П. Соловьев-Седой һәм Ленинград шәһәренең эстрада мастерлары катнашында концертлар Менжинский исе-



*РСФСРның атказанган артисткасы Л. Зыкина җырлый.*



*В. И. Ленин ролендә артист П. Морозов.*

мендәге клубта, Урицкий исемендәге Культура сараенда һәм Офицерлар йортында булып үтте.

В. И. Ленинның туу көненә багышланган дүртенче музыкаль фестиваль республикабызның культура тарихына әһәмиятле бер вакыйга булып кереп калды.

## XXIII СЪЕЗД ЙОМГАКЛАРЫ һӘМ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

**27 апрельдә** Г. Тукай исемендәге клубта Татарстан язучылары союзы каршындагы партия оешмасының ачык җыелышы булды. Җыелышта КПССның XXIII съезды делегаты, Татарстан язучылары союзы председателе **Мирсәй Әмир** съездда туган тәэсирләре белән уртаклашты һәм язучылар, гомумән, әдәбият алдында торган зур, җитди бурычларга тукталды.

Татарстан китап нәшриятының баш редакторы урынбасары **К. Фәсәхов** үзенең чыгышын әдәби әсәрләрнең тематикасы мәсьәләсенә багышлады.

— Нәшриятта басылып чыгачак әсәрләр тематик планга бары тик кулъязма кергәч кенә теркәлә,— диде ул.— Бу нәрсә нәшриятта чыга торган китапларның сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә. Нәшриятта ел саен күп кенә зур күләмле әсәрләр чыгып тора. Ләкин бүгенге көн геройларын сурәтләгән актуаль проза әсәрләре бик аз. Эшчеләр сыйныфы турында, нефтьчеләр, химиклар тормышын сурәтләгән әсәрләргә дә безнең әдәбият мохтаҗ.

Шагыйрь **С. Хәким** бүгенге тормышның алгы сызыгында коммунизм төзү өчен көрәшүче укучыларның әдәбиятка, язучыларга булган югары таләбе турында сөйләде. Әсәр үзенә үзе юл ярырга, укучыларның дикъкатен һәм мәхәббәтен казанырга тиеш, диде ул. Ә моның өчен язучының да үз иҗатына гаять таләпчән булуы кирәк. Әдәбият укучы таләбеннән түбән булмасын!

Ләкин соңгы елларда язылган проза әсәрләре (ә проза әдәбиятны әйдәп баручы жанр) әле тиешле югарылыкка ирешмәгәннәр. Алар бөтен совет әдәбиятына, дөнья әдәбиятына үзләренә үзләре юл яра алмыйлар әле. Ә безнең язучыларның моңа ирешү мөмкинлекләре бар.

**Н. Дәүли** кешеләр арасындагы матур мөнәсәбәтләрне яклап чыгыш ясады һәм әдәбиятта Ватан образын тиешле киңлектә сурәтләү буенча язучыларыбызның житәрлек эшләмәүләрен тәнкыйтьләде.

«Азат хатын» журналы редакторы **А. Хәсәнова да** әдәби әсәрләрнең сыйфатын яхшырту, аларга карата редакторларның таләпчән булуы кирәклеге турындагы башка ораторларның фикерен куәтләде, кайбер язучыларның үз иҗатларына таләпчән карамауларын әйтте. **Ә. М. Рафиков** әдәбият әсәрләре аша яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләренә тукталды.

**И. Гази** уңай геройның ышандыргыч сыйфатларга, нык характерга ия булырга тиешлеген күз алдында тотып язарга чакырды, һәм яшь язучыларны тормыш тәҗрибәсе тупларга тырышмауда гаепләде.

Соңыннан съезд йомгаклары турында КПСС өлкә комитеты секретаре **М. Вәлиев** чыгыш ясады.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Украина совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе П. Г. Тычина болай дигән иде:

«Күп милләтле поэзиябез күгендә украина шагыйрәсе Л. Украинка, белорус шагыйре Я. Купала, әрмән шагыйре А. Акопян, татар шагыйре Г. Тукай исемнәре һәрвакыт балкып торыр».

Әйе, бу исемнәр еллар үткән саен яктырак балкый. Бу исемнәрне Советлар Союзындагы барлык милләт халыклары да олылыйлар. Барлык халыклар өчен уртак исемнәр алар. Шуңа күрә дә татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның тууына 80 ел тулу көне бер Татарстанда гына түгел, бөтен Советлар Союзы күләмендә билгеләп үтелде.

Татарстанның башкаласы Казанда да, республикабызның шәһәр һәм авылларында да, мәктәпләрдә, клубларда, культура сарайларында, китапханәләрдә, югары уку йортларында бу дата уңае белән әдәби кичәләр булып үтте, күргәзмәләр оештырылды.

**8 апрельдә** Татарстан язучылары союзы идарәсендә һәм **15 апрельдә** Г. Тукай исемендәге клубта язучылар, журналистлар шагыйрьне якыннан күреп белгән кешеләр белән очраштылар. Очрашуда Г. Тукай замандашлары: Шиһап Әхмеров, Заһид Нуркин, Гөлсем Болгарская, Зәйнәп Хәсәни, Касыйм Шамил, Исмәгыйл Рәми, Каюм Мостакаев, Галим Әмирханов, Бакый Урманчы, Рабига Мөхәмматҗанова, Касыйм Субаев, Сәгыйт Исәнбаев шагыйрь турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар.

**25 һәм 26 апрельдә** СССР Фәннәр Академиясенең Казан институтлары конференцзалында Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган фәнни сессиясе булып үтте. Сессияне кереш сүз белән институт директоры М. Мөхәррәмов ачты. Анда «XX йөз башы татар әдәбиятында герой проблемасы» (Г. Халит), «Татар поэ-

зиясенең тарихи үсешендә Г. Тукайның урыны» (Х. Госман), «Ә. Фәйзинең «Тукай» романында Г. Тукай образы» (Х. Хәйри), «Г. Тукай сатирасында тел һәм стиль чаралары» (В. Хаков), «Кисекбашның әдәби версияләре һәм Г. Тукайның «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш» поэмасы» (Ш. Абилов), «Г. Тукай, Сабир һәм К. Иванов реализмының үзенчәлекләре проблемасына карата» (Р. Ганиева), «Г. Тукай теләндә каламбур һәм сүз уйнату» (И. Абдуллин), «Г. Тукай һәм XX йөз башында татар фольклористикасы» (Ф. Урманчеев), «Г. Тукай һәм патша цензурасы» (Х. Хәсәнов) һәм башка темаларга докладлар укылды, бу докладлар буенча фикер алышынды.

**26 апрельдә** Куйбышев мәйданындагы Г. Тукай һәйкәле янында Г. Тукай көненә багышланган традицион шигырь бәйрәме үткәрелде. Г. Тукай һәйкәле куелган бакчага йөзләрчә әдәбият сөючеләр җыелды. Казан шәһәре җәмәгатьчелеге һәйкәл янына чәчәк бәйләмнәре куйды.

Митингны Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким ачты. Ул Г. Тукай иҗатының татар әдәбияты үсешендәге әһәмияте, аның интернациональ рухы турында сөйләде. Аннары Н. Арсланов, И. Юзиев, Н. Дәүли, З. Нури, М. Садри, Г. Латыйп, М. Фәйзуллина, С. Шакир, Р. Гатауллин, М. Хөсәен, Ә. Юныс, М. Ногман, шигырь бәйрәменә кунакка килгән рус шагыйрьләреннән М. Львов (Мәскәү), В. Бакалдин (Краснодар), О. Фокина (Вологда) үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар. Казан шәһәренең 80, 40, 35, 6, 75 мәктәп укучылары һәм педагогия институты студентлары Тукай шигырьләрен сөйләделәр.

Шигырь бәйрәме кичен Казан педагогия институтының Актлар залында, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында, Ленин районының Төзүчеләр клубында дәвам итте. Бу кичәләрдә барлык татар шагыйрьләре һәм кунаклар катнашты.

Лениногорск шәһәренең М. И. Калинин исемендәге Культура сараенда Г. Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби кичәдә шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында КПССның Лениногорск шәһәр комитеты инструкторы Р. Зарипова доклад ясады. Соңыннан Казаннан шагыйрь Ә. Баянов, әлмәтле Ә. Маликов һәм «Ильич васыятьләре» газетасы каршындагы әдәбият түгәрәге членнары үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Г. Тукайның 80 ел тулу көне Урта Азия республикаларында, Башкортстанда, Чиләбе, Оренбург өлкәләрендә дә зур итеп билгеләп үтелде.

Уфада Башкорт дәүләт университетында үткәрелгән әдәби кичәдә университет доценты Ә. Нигъмәтуллин шагыйрьнең иҗаты турында доклад сөйләде. Тукай белән күп тапкырлар очрашкан пенсионер К. Фәхретдинов үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Шагыйрь С. Агиш Г. Тукайның «Пар ат» шигырен яттан укыды. Г. Әмири, К. Даян тамашачыларны бөек шагыйрьгә багышлап язган әсәрләре белән таныштырдылар.

Соңыннан сәнгать мастерлары һәм үзешчән коллективлар көче белән Г. Тукайга багышлап зур концерт бирелде.

Оренбургта Х. Ямашев исемендәге китапханә һәм Чкалов исемендәге клубның үзешчән түгәрәге коллективы Дзержинский исемендәге клубта Г. Тукайның тууына 80 ел тулу уңае белән зур әдәби кичә үткәрде. Шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында укытучы Г. Хәсәнова доклад сөйләде.

Г. Тукай замандашы, өч сугыш ветераны Ф. Солтанов, Т. Сабиров, Оренбург филармониясе каршындагы татар драма театры режиссеры В. Фатихов Г. Тукайның тормышына һәм иҗатына бәйләнешле төрле моментлар турында чыгыш ясадылар.

Клуб фойесына Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты турында зур фото-стенд куелды, китап күргәзмәсе оештырылды. Алар янында китапханә эшчеләре кичәгә килгән әдәбият сөючеләр белән Тукай әсәрләренә карата әңгәмәләр үткәрделәр.

Соңыннан үзешчән түгәрәк коллективының концерты булды.

Чиләбе шәһәрендә дә һәм шулай ук өлкәнең районнарында Тукай көннәре уңае белән күп кенә әдәби кичәләр булып үтте. Чиләбе трактор заводы театрында, Металлургия заводы Культура сараенда, татар-башкорт китапханәсендә һәм Троицк шәһәрендә Татарстаннан килгән тәнкыйтьче һәм прозаик И. Нуруллин белән шагыйрь Ш. Галиев Г. Тукайның иҗаты һәм бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар.

Бөек татар шагыйре Г. Тукай юбилеен билгеләп үтү май, июнь айларында да дәвам итте. Бу уңай белән Мәскәүдә Дөнья әдәбияты институты белән СССР Фәннәр Академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйльми Советларының Г. Тукай иҗатына багышланган утырышы булды. Язучыларның Үзәк йортында Тукайны искә алуга багышланган зур әдәби кичә үткәрелде.

## ТАТАР СӘНГАТЕ МАСТЕРЛАРЫ МӘСКӘҮДӘ

Апрель аенда Татарстанның халык артисткасы Рәисә Билалова, Татарстанның атказанган артистлары Зифа Басыйрова, Илһам Шакиров, баянчы Рифгать Гумеров һәм яшь шагыйрә Г. Зәйнашева, Мәскәүгә барып, андагы хезмәт ияләрен татар сәнгате белән таныштырдылар. Концертлар бик җанлы үтте, заллар тамашачылар белән шыгрым тулы иде.

## «МУСА ҖӘЛИЛ» ТЕПЛОХОДЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ РЕЙСЫ

Советлар Союзы заказы буенча Югославиядә ясалган «Муса Җәлил» теплоходы апрель аенда, Канада һәм Куба өчен йөк төяп, Одесса портыннан беренче рейска чыгып китте. Теплоходны рейска озатырга КПССның Казан шәһәр комитетыннан Ә. Миндубаев һәм язучы, шагыйрьнең дусты Гази Кашшаф барды.

Теплоход капитаны Роман Александрович Довгаль Казан кунакларына корабль биографиясе турында түбәндәгеләрне сөйләде:

— «Муса Җәлил»не Пула шәһәренең «Ульяник» верфендә ясадылар. Бу шәһәр Әндәр диңгез буенда. Анда Советлар Союзы өчен шушындый ук 12 мең тонна йөк сыйдырышлы 30 корабль ясаячаклар. Беренче корабльгә верфь урнашкан шәһәр исеме — «Пула» кушылды. Аннан инде «Язучылар сериясе» китте. «Назыйм Хикмәт», «Дмитрий Гулиа», «Аркадий Гайдар» инде океаннарны гизәләр. Дүртенче «язучы»быз — «Муса Җәлил». Корабль Муса Җәлил туган көнгә суга төшерелде.

Корабль бик яхшы эшләнгән. Биеклеге 9 катлы йорт кадәр, буе 160 метрлы бу гигантны бер ел эчендә эшләп бетерделәр.

Җәлил турында Югославиядә яхшы беләләр. Үзләре фашист табаны астында җәфа чиккәнгә һәм хәзерге эшчеләрнең күбесе ул елларда партизаннар отрядында илбасарларга каршы көрәшкәнгә, герой шагыйрьнең исеме алар өчен бик якын.

Корабль өстеннән Югославия флагын төшереп, Советлар Союзы флагын күтәргәч, «Ульяник» фирмасының генераль директоры иптәш Фоскио речь белән чыкты. Аның реченең шактый өлеше Муса Җәлилгә багышланган иде.

Хәзер менә «Муса Җәлил»дә өч айдан артык илебез ярларыннан еракта океан киңлекләрен гизәчәкбез.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНДА

Татарстан язучылары союзы идарәсенең **18 апрельдә** үткәрелгән чираттагы утырышында «Казан утлары» журналының соңгы саннарында басылган әсәрләр турында фикер алышынды. Журналның эше, планнары турында җаваплы редактор **Р. Мостафинның** кереш сүзеннән соң, сүз **Г. Минскийга** бирелде. Ул «Онытылмас еллар» повестеның дәвамы булган «Канатланыр чак» әсәренең художество сыйфатлары турында сөйләде, аның революцион һәм тарихи чынбарлыкны дөрес сурәтләвен билгеләп үтте. Профессор, тәнкыйтьче Х. Госман М. Шәйминең «Безнең шәһәр утлары» әсәренә карата журналда басылган А. Яхин рецензиясен, кайбер дорфа урыннары булуга карамастан, дөрес, объектив язылган, дип бәяләде. Шулай ук ул И. Рәминең журналда басылган «Мәдрәсәдән университетка» мәкаләсенә дә зур бәя бирде.

Тәнкыйтьче **И. Нуруллин** үзенең чыгышын театр сәнгатенә карата басылган мәкаләләрне анализлауга багышлады. «Гадәттә, театрлар,— диде ул,— театр сәнгатендәге торгынлыкны драматургиягә кайтарып калдыралар. Ләкин эш драматургиядә генә түгел. Театрларның эшчәнлегендә эзләнү юк, алар хәзерге заманның киң колачлы проблемаларын тамашачыга җиткерү ысулларын җитәрлек өйрәнмиләр. Шулай ук тәнкыйтьчеләр дә театрларның иҗат йөзен билгеләү буенча тиешенчә эшләмиләр.

**Шәйхи Маннур** үзенең чыгышында С. Батталның «Чирмешән ярларында» шигъри романына һәм Ш. Галиевнең «Сөзгәк үгез маҗаралары» поэмасына тукталды, аларның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтте.

Шулай ук **Ф. Хәсни, М. Әмир, З. Нури, Г. Гобәй** һ. б. лар да журналда басылган әсәрләргә һәм редакциянең эшчәнлегенә карата фикерләрен әйтеп чыгыш ясадылар.

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘДӘ

СССР Язучылары союзының Чиләбе бүлеге каршында күптәннән бирле инде татар-башкорт әдәби берләшмәсе эшләп килә. Чиләбе һәм өлкәнең башка шәһәрләрендәге предприятиеләрдә эшләүче башлап язучылар, күп санлы әдәбият сөючеләр берләшмәнең эшенә актив катнашалар.

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән бу берләшмәгә Муса Җәлил исеме бирелде.

Соңгы вакытларда берләшмәнең эше тагы да җанлана төште. Апрель аенда, мәсәлән, инженер-металлург Булат Баттал белән китапханә работнигы Салисә Гәрәева шигырьләре укып тикшерелде. Фикер алышуда Ф. Сырлыбаев, К. Низаметдинов, З. Зарипов һ. б. лар катнашты.

Берләшмәнең шул ук айда үткәрелгән икенче бер утырышында Чиләбе политехника институты студенткасы Фирдәвес Галиева һәм Рамазан Шаһгалиев әсәрләре буенча фикер алышу үткәрелде.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Апрель аенда Ленин орденлы Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем әсәл» (татарчага Ә. Еники тәрҗемәсе) исемле әсәре күрсәтелде. Әсәрне сәхнәгә Үзбәкстан ССРның халык артисты Т. Хоҗаев куйды, декорацияләр — ТАССРның халык художнигы Э. Гельмс эше.

Татарстанның халык артисткасы Г. Ибраһимова, ТАССРның атказанган артистлары Г. Надрюков, Ш. Биктимеров, Ш. Әсфәндиярова, Г. Фәтхуллин, Р. Хәйретдинова, Тукай премиясе лауреаты Р. Бикчәнтәев, артистлардан Н. Гәрәева, Р. Таҗетдинов, Р. Әхмерова һ. б. ларның уенын тамашачылар яратып карадылар.

Казанның В. И. Ленин исемендәге Культура сарае каршындагы татар халык театры Г. Минскийның «Иртәгә соң булыр» исемле пьесасы буенча эшләнгән спектакль күрсәтте. Әсәрне сәхнәгә Тукай премиясе лауреаты Р. Бикчәнтәев куйган.

## ЯЗУЧЫ — ФӘННӘР КАНДИДАТЫ

28 апрельдә Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Гыйльми Советы утырышында «Кояш көн дә чыга» повесте, «Гомер ике килми» романы һәм күп кенә хикәяләр авторы, язучы Э. Касыймов «Татар халык әкиятләрендә юмор һәм сатира» дигән темага диссертация яклады. Гыйльми Совет бертавыштан Э. Касыймовның фәнни хезмәтен филология фәннәре кандидаты исеменә лаек дип тапты.

## ЯЗУЧЫ ДЕПУТАТЛАР

Халкыбызның СССР Верховный Советына депутат итеп сайланган иң яхшы уллары һәм кызлары арасында язучылар да күп кенә.

12 июньдә илебез хезмәт ияләре күренекле совет язучысы, Ленин премиясе лауреаты Михаил Александрович Шолоховны, күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклеләре Константин Александрович Фединны, Николай Семенович Тихоновны, Якутиянең халык язучысы Николай Егорович Мординовны, күренекле украин язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Александр Евдокимович Корнейчукны, Украина язучылары союзы идарәсе председателе Александр Терентьевич Гончарны, Ленин премиясе лауреаты Михаил Афанасьевич Стельмахны, Дәүләт премиясе лауреаты Степан Иванович Олейникны, Грузия язучылары союзы идарәсенең беренче секретаре Ираклий Виссарионович Абашидзены, Дагстан халык шагыйре, Ленин премиясе лауреаты Рәсүл Гамзатовны, Таҗикстан язучылары союзы идарәсе председателе, Ленин премиясе лауреаты Мирза Турсун-Задәне һ. б. ларны дәүләт властеның иң югары органына сайладылар.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/IV-1966 ел. Басарга кул куелды 2/VI-1966 ел. ПФ 15008. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 36900 экз. Заказ Н-586. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

**ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ**